# казан утлары

2
ФЕВРАЛЬ-1977

Редакция журнала "Казан утлары"
("Огни Казани")

УКАЗ ПРЕЗИДІЇ ВЕРХОВНОЇ РАДИ СРСР
УКАЗ ПРЭЗІДЫУМА ВЯРХОЎНАГА САВЕТА СССР
СССР ОЛИЙ СОВЕТИ ПРЕЗИДИУМИНИНГ ФАРМОНИ
СССР ЖОҒАРҒЫ СОВЕТІ ПРЕЗИДИУМЫНЫҢ УКАЗЫ
[illegible]
ССРИ АЛИ СОВЕТИ РӘЈАСӘТ ҺЕЈ'ӘТИНИН ФӘРМАНЫ
TSRS AUKŠČIAUSIOSIOS TARYBOS PREZIDIUMO ĮSAKAS

УКАЗУЛ ПРЕЗИДИУМУЛУЙ СОВЕТУЛУЙ СУПРЕМ АЛ УНИУНИЙ РСС
PSRS AUGSTĀKĀS PADOMES PREZIDIJA DEKRĒTS
СССР ЖОГОРКУ СОВЕТИНИН ПРЕЗИДИУМУНУН УКАЗЫ
УКАЗИ ПРЕЗИДИУМИ СОВЕТИ ОЛИИ СССР
[illegible]
СССР ЁКАРЫ СОВЕТИНИҢ ПРЕЗИДИУМЫНЫҢ УКАЗЫ
NSV LIIDU ÜLEMNÕUKOGU PRESIIDIUMI SEADLUS

# УКАЗ
## ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР

О награждении журнала "Казан утлары"
("Огни Казани") орденом "Знак Почета"

За заслуги в области советской литературы и активное участие в коммунистическом воспитании трудящихся наградить ЖУРНАЛ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРСКОЙ АССР "КАЗАН УТЛАРЫ" ("ОГНИ КАЗАНИ") орденом "ЗНАК ПОЧЕТА".

Председатель Президиума
Верховного Совета СССР Н.ПОДГОРНЫЙ.

Секретарь Президиума
Верховного Совета СССР М.ГЕОРГАДЗЕ.

Москва, Кремль.
17 января 1977 г.
№ 5091-IX.

# СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
# УКАЗЫ

**«Казан утлары» журналын «Почет билгесе» ордены белән бүләкләү турында**

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре һәм хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдә актив катнашуы өчен **Татарстан АССР Язучылар союзының «Казан утлары» журналын «Почет билгесе» ордены** белән бүләкләргә.

**СССР Верховный Советы Президиумы Председателе**
**Н. ПОДГОРНЫЙ.**

**СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре**
**М. ГЕОРГАДЗЕ.**

Мәскәү, Кремль.
1977 ел, 17 январь.

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

2

ФЕВРАЛЬ
1977

## БУ САНДА

**Б. КАМАЛОВ.** Канатлы кырмыска. Повесть . . . 3
**Г. АФЗАЛ.** Чияле тау итәгендә. Шигырьләр . . 51
**Г. АХУНОВ.** Идел кызы. Роман . . . . . . . 57
**ЗӨЛФӘТ.** Яңа шигырьләр . . . . . . . . . 102
**Д. ЗӨБӘЕРОВА.** Сызган балдак. Хикәя . . . . 111

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . 117
**К. ТИМБИКОВА.** Кара юрга . . . . . . . . . 119
**З. ӘХМӘТҖАНОВ.** Еллар үткәч . . . . . . . 131

ГЕРОЙ-ШАГЫЙРЬ ИСТӘЛЕГЕНӘ

**Л. НЕБЕНЦАЛЬ.** Җәлил рухы . . . . . . . . 136
**Р. МОСТАФИН.** Соры плитәләрдә ал кан таплары. 138
**А. КЛАБУКОВ.** Онытылмас кешем . . . . . . 139

И. ГАЗИНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

**Ә. МАЛИКОВ.** Әдәбият һәм хезмәт . . . . . 141
**И. ГАЗИ.** Чирәм ерту — һәр язучы бурычы. Мәкалә. Хатлар . . . . . . . . . . . . . 143

Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ 90 ЕЛЛЫГЫНА

**Ш. ТУРДЫЕВ.** Ул безгә дә кадерле . . . . . . 149

СӘНГАТЬ

**Ш. МОНАСЫЙПОВ.** Сызылып кына моң чыккан-да . . . . . . . . . . . . . . . . 152

Б. УРМАНЧЕГА 80 ЯШЬ

**А. НОВИЦКИЙ.** Зирәклек һәм камиллек гадилеге . . . . . . . . . . . . . . . 161

ТӨРЛЕСЕННӘН

**В. СЕМЕНОВА.** Алексей Толстой Казанда . . . 170
**И. СИБГАТУЛЛИН.** Капитанның төньяк одиссеясе . 175

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ж. МИНДУБАЕВ.** Гимназист Ульянов турында яңа китап . . . . . . . . . . . . . . . 177
**Ш. БИККОЛОВ.** Витаминлы шигырьләр өчен . . 179

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Ш. ГАЛИЕВ.** Яз чиге шушы икән. Шигырьләр . . 181

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**КИЗӘНОВ.** Чәнечкеле монологлар . . . . . . 184
**С. КАЛЬМЕТОВ.** Үз-үзеңне дәвалау. Юмореска . 185
Каратау мәзәкләре . . . . . . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 3/XI-1976 ел. Басарга кул куелды 11/I-1977 ел. ПФ 13001. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83844 экз. Заказ К-380. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1977 ел.

Барлас Камалов

# КАНАТЛЫ КЫРМЫСКА

ПОВЕСТЬ

1



Быелгы язда, мөгаен, беренче шундый иртәдер бу. Вак, бик вак тамчылы яңгыр төшеп тора. Күк гөмбәзенә сыек кына болыт чыбылдыгы корылган.

Сәрбиҗиһан түтинең күңелендә күптән үткән хатирәләр яңаруга да шушы пыскак яңгыр сәбәп булды шикелле. Тәрәзә буенда утырган килеш, ул күзен урамнан алмады. Уйлары, елларны кире чигереп, узган көннәргә тоташкан иде.

Әүвәл елларда, сугыштан соң, әле ире Низам да исән чакта, авылда яшәгәндә, шулай була торган иде. Чәчүләр беткәч, ике-өч көн шундый яңгыр явар иде. Алны-ялны белми өшәнгән авыл халкы йокы туйдырыр, мунчасын ягар, акланыр-пакьланыр, җегәр җыяр...

Кичә күк күкрәүле, яшенле яңгыр Казан тирәләрендә гөлдерәп әйләнгән итте. Бәлки кайдадыр ярыйсы ук төшкәндер, Сәрбиҗиһан түтәйләрнең Савиново поселогында тузан куырып кына узды.

Ничә ел инде рәтле-юньле явым-төшем булганы юк. Быелгы яз, мең тугыз йөз җитмеш бишенченең язы, бигрәк тә аяусыз килде. Май аеның соңгы көннәре, ә җирнең беренче тамчы дым күрүе — кичәле-бүгенле.

Галәмәт корылык кешеләр җанына шом, шик, сагаю сала. Үз гомерләрендә күпне күргән өлкән һәм урта буын кешеләр кытлык кыйнамагае дип имәнә, чиратлар газабын күз алдына китереп хафалана. Яшьрәкләр башына андый уйлар төшми бугай — тормыш авырлыгын татыганнары юк.

Корылык — илгә-көнгә уртак килгән каза. Дәүләтебезнең халыкны ач-ялангач итмәсен Сәрбиҗиһан түтәй белә, җитмеш ел гомеренең илле сигезен Совет шартларында яшәгән кеше. Аның илдән-көннән аерым борчуы бар, шуңардан гаҗиз ул. Бу борчуның сәбәбе — кече улы Саматның пырдымсызлыгы, үҗәтлеге, кешечә көн итә белмәве.

Булдыксыз бер адәм имгәге булса икән, аттан ала да туа, кола да дип, язмышыңа рәнҗер идең. Җитмеш һөнәр иясе бит. Ташчы, балта остасы, столяр, калайчы, кирәк икән, мич тә чыгара. Рәсемне тел шарт-

латырлык итеп ясый, кулында гармун сайрата. Ат урынына эшли, хезмәтнең ниндиеннән дә тайчанмый. Эштән тәм таба. Әмма ләкин үзсүзле инде, баш бирмәс. Акчаны чамасыз ярата. Кесәсендә акча күп чакта баш югары, кешеләр белән исәпләшеп тормый.

Өйләнде. Башлы-күзле булганына өч ел. Әлегә (кайчанга тикле? Утызны тутыра лабаса!) бала-чаганы кирәксенми. Югыйсә, хатыны Зәмирә багалмадай балалар үстерер иде. Уңган, булган. Чибәр, акыллы.

Төп йорт белән янәшәдә генә менә дигән өй өлгерттеләр. Буралык наратны үзе моннан биш ел элек мари урманында эшләп алган иде. Өйне алты почмаклы итеп, урамга буй белән салдылар. Калай белән яптылар. Идәннәр буяулы. Верандасы киң, якты. Рәхәтләнеп яшәргә генә дә соң, юк кына! Шабашка тартыла Самат. Өч җәй йөрде, сүз әйтмәделәр: өй житкерү, аңа җиһаз булдыру ансат кына барып чыкмый. Инде килеп, быел да шул эшкә китүенә хатыны да, абыйсы Морат та риза түгел. Сәрбиҗиһан түти, кулыннан килә торган булса, улын һич кенә дә җибәрмәс иде. Ләкин тегесе киңәшкә колак сала торган түгел шул.

Абыйсы белән бер бригадада эшлиләр иде. Күршедә генә, кул сузымында, утыз җиденче кварталда, тугыз катлы йорт салалар иде. Тагын эшеннән расчет алган.

Үткән елларда читкә бергә чыккан белеше бар. Егор атлы. Шуның белән китмәкчеләр. Кул алмашка күрше малаен, Ильясны ияртәселәр. Тегесе быел тугызынчыны гына бетерсә дә, бәдәнле-буйлы, өздереп эшли торган егет. Күп балалы семьяда үскән, эшләп ашарга өйрәнгән. Мотоцикл кирәксенә, йөртергә право алган, шуңа акча юнәтмәкче. Ике-өч көн укуы кала икән дә, ташлап китәргә ризалашкан.

Табылмаган мал тау чаклы инде ул. Нәфсесенә булышмасын иде дә соң Самат... Әйтеп сүзеңә колак салса икән...

Тәрәзә пыяласын вак-вак шадрага күмгән бөрчек-бөрчек тамчылар, тора-бара зураеп-авыраеп, бер-берсенә кушылдылар да эз калдырып аска сузылдылар. Сәрбиҗиһан түтәй уйларыннан аерылып урыныннан торды. Аягы ойый башлаган иде, балтыр буйларын сыйпаштыргалап алды. Гәүдәсен турайтыйм дигәндә, биле чатнап киткәндәй булды. «Сөбханалла!» дип куйды ул. Аннары, күзге янында үтешли ак яулыгы астыннан чыгып торган чал чәчләрен яшерде, бармак битләре белән күз төпләренә кагылып алды. Күзгедән аңа кайчандыр бик матур коңгырт булган, инде төсләре уңып, нуры кимеп барган күзләр текәлде. «Яшьлек дәвер язга охшар, картлык дәвер кышка охшар. Үтте гомерләр!»

Гәүдә сылулыгын сагынып сөйләргә генә инде. Аркага бөкре кунмаган кунуын, мәгәр калак сөякләре иркен күлмәк аша да төртеп тора. Картлыкның иң рәхимсез шаһитлары — җыерчыклар. Маңгайга да тирән сызылганнар, борын төбеннән ирен читләренә таба да аяусыз уелганнар. Бит уң ягындагы бәләкәй миң, ерымга төшкән таш сыман, җыерчык эчендә югалып калган.

Ике өй арасындагы кәлиткә ачылып ябылды. Күзге каршында тукталуын кемдер күреп, гаепләр төсле тоелгач, Сәрбиҗиһан түти күзге яныннан читкә тайпылды. Аннары ишегалды тәрәзәсенә күз салды. Җил-җил атлап Самат кайтып килә иде. Җилкәләрен сикертә-сикертә атлавыннан ук күренеп тора — тузынган, ярсынган, нинди чебен тешләгәндер?.. Мондый чакта килен генә кыйшык сүз ычкындырмасын берүк...

Әнә Зәмирә, Саматын каршыларга дип, болдырга чыкты. Иренең йөзе чытыклыгын абайлау белән:

— Бик кәефсез кайтып киләсең, юлың уңмадымы әллә? — дип сорады.

Самат ачыргаланып кул селтәде.

— Уңганын-туңганын кем белсен! Сафдил абыйның артына кыл сыймый. Ике авыз сүз сөйләшергә вакыт таба алмады. Ни булса булды, гаризам биргән. Мине көчләп тота алмыйлар. Өйгә килеп чыгалмассынмы дидем, килерме, юкмы?

— Соң шуннан?

— Шуннан шул: табын көйлә. Мәеңне чыгар. — Саматның тузган куе кашлары озын кара тап булып бергә кушылды. Шомырттай күзләрендә ачулы очкын кабынып сүнде. Ул, нервланып, учлары белән башта сул кулының, аннары уң кулының бармак төпләренә басты. Бармак төпләре шырт-шырт килде. — Алып куйганың бардыр бит?

— Юк иде шул.

— Син дә кибетче булып йөрисең, әйтмәсәм дә әйтим. — Йорт башы плащын, кепкасын салып, чөйгә элде, туфлиләрен бер читкә тибәрде дә өйгә узды. Зәмирә дә аңа иярде.

— Кибетче дип... — Аның чәчәк таҗыдай матур иреннәре үпкәләүдән турсаеп куйды, зәңгәр күзләренә рәнҗү бәреп чыкты. — Бу атнада ял итәм ич. Сишәмбедә генә эшкә...

Самат керпеләнеп торган каты кара чәчен зур учы белән сыйпыйсыйпый әйтеп салды:

— Галимҗан Ибраһимов проспектына ике атлап, бер сикерәсе. — Аның тавышында каршы сөйләүне өнәмәү ярылып ята иде. — Ике ел гастрономда эшлисең, сине дә сәгать унбер тулганны көттермәсләр, шәт! Озаклама!

Зәмирә өстенә болоньи плащын киде, башына плащның кыекча яулыгын япты. Гадәткә бирелеп, плащ кесәсеннән кечкенә көзге алган иде, бик тиз кире тыкты. Чәч төзәтеп, күз-каш буяп көзге тирәсендә тулганганын иренең пәрие сөйми.

Болдырда кайнанасы туры килде.

— Кая киттең болай бик ашыгып? — диде ул кече килененең кәефе кырылганын чамалап. — Бер-бер хәерсез хәл бармы әллә?

— Юк, әнкәй, юк. Кер, әйдә, — дип елмаерга тырышты Зәмирә. — Мин үзебезнең гастрономга гына барып киләм...

— Алай гына булса ярый, килен.

Сәрбиҗиһан түтәй өйгә кергәндә, улы, газета алып, түр өстәл янына утырган иде.

— Нишләргә булып беттең инде, улым.— Карчык тыныч кына шулай сорады.— Китәмсез?

— Китүен китәргә инде. — Самат урыныннан күтәрелде. — Уз, әнкәй. Утыр.— Ул әнисенә урындык бирде.— Кая булса да китәргә. Эштән шул исәп белән китүне беләсең. Менә Фариз абыйны көтәм әле. Ул бер колхоз председателе белән сөйләшеп кайткан булырга тиеш иде...

Анасы урындыкка барып утырды да тирән сулап куйды. Тамырлары бүртеп торган кул аркаларын ышкыштыргалап, Саматка карады һәм:

— Быел чыгып йөрмәсәң дә ярар иде дә бит инде, улым, — диде.

Самат ялт итеп башын күтәрде, әнисенә чекерәеп бакты. «Ни сөйлисең» янәсе.

Саматның карашы ананы сискәндермәде.

— Чыны шулай, улым. Чыны шулай. Килен дә дүртенче җәен ялгыз калырга тиеш була. Яшьлектә гөрләшеп яшисе чакта... Эшләп тора торган җирең дә яхшы иде, акчаны әйбәт төшереп килдең. Абыең гел шунда төпләнгән килеш бит, бер дә зарланмый.

— Абыйның дөньясы түгәрәк лә аның!

— Сөбханалла! Синең тормышның кай чите китек? Йорт-җирең менә дигән. Кием-салымыгыз да җитәрлек. Инде дә килеп, ызбаң эче әйләнеп чыкмаслык. Шөкер итә белергә дә кирәк.

— Юк әле, әнкәй, шөкер итмим әле. Беләгемдә көч барында, башым эшләп торганда, шөкер итмим. Тагын да тырышып карыйм әле.

— Ул тикле дә...

Самат әнисенә фикерен очлаганны да көтмәстән сөйләп китте. Сөйлисе килә иде аның, күңелендәгесен әйтәсе килә иде. Тормышта нәрсәгә һәм ник омтылганын әнисенә генә булса да аңлатып бирү кытыгы биләп алган иде аны.

— Менә син шөкер ит, әнкәй. Безне үстереп җиткердең, аякка бастырдың. — Болар Саматның рәхмәтен аңлатырга тиеш сүзләр иде. Ул төчеләнә белми, эчендәгесен гап-гади генә әйтеп салды. — Туган энеңә, мәрхүм Салихҗан абыйга рәхмәт диген. Колхозда ул заманда рәт югын аңлаган. Илленче елны безне монда төяп алып килгән. Мунча хәтле генә булса да, өй әмәлләшкән. Әткәй үлгәч, нужаңны уртаклаша белгән. Хәзер инде, әнкәй, ике ягында ике гүрнәчә...

— Шуңа шөкерана итик дим бит. Мал корчаңгысы, улым, дәвалап булмас бозык ул.

— Юк, әнкәй, мин ныгырга да ныгырга тиеш әле. — Самат, өстәлгә кадак сугып керткәндәй, учы белән шап итеп сукты. Рухлану галәмәте аның йөзен ачып җибәрде. Иреннәренә елмаю чыкты, карашы балкып китте. Төз борынының яфраклары дерелдәшкәләп алды. — Теплицаны киңәйтәсем бар, машина аласым... Боларга акча кирәкме? Күп кирәк. Лотерейга откканны көтеп ята алмыйм, аның буласы юк... Машинаның консерва банкасы кебек ни җиттесен түгел, «Волга» алачакмын...

— Бәхет анда гына булса икән, улым...

— Бәхет турында күп ишеттем мин, әнкәй. Гапытуыда да аңлаттылар, армиядә дә политзанятие булмый тормады. Аннан соң, беләсең, кичке мәктәп бетердем. Аттестат кулда... Ну мин үземчәрәк уйлыйм. Бәхет, әнкәй, менә монда, алдан йөрүчедә...— Самат, уң кулын алга сузып, имән бармак бите белән баш бармак очын ышкып күрсәтте.

Сәрбиҗиһан түтәй кәефсезләнеп башын бер читкә борды һәм, тирән көрсенеп:

— Әй, бала, бала... — диде. — Кемгә генә охшап мондый булдың икән? Әткәң бу сүзләреңә ни әйтер иде дип уйлыйсың?

Улының моңа да җавабы әзер иде.

— Әткәй ошатмас иде. Ул гомере буе артык туры, артык беркатлы булган. Шуңа күрә сиңа да, безгә дә җиргә сеңгән иске ызба белән мүкләк кәҗәдән башка берни дә калдыра алмаган.

Сәрбиҗиһан түти утырган җиреннән капылт калкынып куйды. Эчке ярсыну аның күңелендәге ниндидер пружинаны ычкындырып җибәрде төсле.

— Әткәң турында яман сүз әйтәсе булма! Гүргә кергәндә дә бәхилләмәм. Еллары нинди иде! Низам Билалов кем булганын авылдашлардан сорашып кара, Кушкаенныкылардан...

Әнисе күз яшен тыя алмагач, Саматка читен булып китте, тавышын йомшатты, сүзләрен сайлабрак сөйләргә тырышты. Әмма барыбер уендагысы теленә килеп кенә торды.

— Ярый, бетте, әнкәй, бетте, — дип юатмак булды ул. — Гафу ит... Ну мин, әйтмәсәм дә әйтим, әле яңа гына буй турайтып киләм. Дөньяның җаен белеп яшәгән кешеләрнең балалары, минем яшьтәшләр, тормыштан бушлай, бер тиенсез алганны мин ни бәягә алдым, беләсеңме? Кабан күле хәтле тир агызып... Егермегә җиткәнче димәсәң, кеше күзенә карап яшәдем. Инде менә уйлап кара, шул мескенлекне үземнән тамчылап чыгарып бетерер өчен, мин нишләргә тиеш идем?

— Кемгә охшап болай каты бәгырьле булдың син, улым?

Ана моны шул тикле ихлас итеп сорады, Самат бермәл җавапсыз торды, аннары әнисенә якынрак килеп әйтте:

— Юк, каты бәгырьле түгел, уяулык, сизгерлек бу, әни, Авыз ачып көн итеп булмый бит.
— Абыең болай түгел ләбаса!..
— Ул дөньяда күбрәк яшәгән, йомшарга өлгергәндер. Ападан биш яшькә өлкән, миннән унбергә.... Аның яшенә җиткәндә, кем белсен, мин дә бүтәнчәрәк булырмын. Һәркемнең үз аршыны барын да онытма, әнкәй!
Сүз шунда өзелде. Сумка кабартып Зәмирә кайтып керде. Бүгенгәчә гаиләдә аңардан бернинди дә сер булмаса да, кайнана авызын чамалабрак ачкан яхшы дип исәпләде. Киленнең кемлеге оныкк тумый беленмәс, диганнәр.
— Тагын явып китә алмады, җилли, аяза...
Киленнең һава хәле турында әйткәненә кайнана ялгап китте.
— Ахыры гына хәерле булсын инде. Шәһәр җирендә әле бер хәл. Чәчәкне су сибеп тә үстереп була. Авыл халкын кайгыга урый инде бу явымсызлык...
Шунда, авыл халкы дип авыз ачуга, Сәрбиҗиһан түтәй баядан бирле онытып торган хәбәрен кинәт исенә төшерде.
— Һә-әй, бу хәтернең кимеп-саегып калулары! — диде өтәләнеп. — Ни гомер онытып торам ич. Керүем дә шуның өчен иде. Авылдан хат бар. Парторг Кыям язган булса кирәк. Менә...
Карчык хатны Зәмирәгә сузды, килене Самат кулына бирде.
Самат, хәтта язылганнарны үтәли күрергә теләгән шикелле, конвертны тәрәзә яктысына куеп карады, аннары аның бер читен чеметеп ертты. Хатны алып, ак кәгазьгә тезгән юлларны беравык эченнән генә укып барды. Шуннан соң башын күтәрде.
— Барыбызга да сәлам язганнар...
— Рәхмәт яусын, сәламәт булсыннар. Авылда ниләр бар дигәннәр? — Сәрбиҗиһан түтәй, күп хәбәр ишетергә ниятләп, колагын торгызды.
— Алай бик җәелеп китмәгәннәр, — диде Самат колхоз партком секретаре язганнарга бик илтифат итмәгән сыман. — Үзләренә кирәкне кайгыртканнар.
— Нәрсә ул?
— Менә болай язган Кыям абый. Тыңла. «...Һәммәгезгә мәгълүм, хөрмәтле авылдашлар. Сиксәненче елда безнең «Яшәр» колхозы оешуга илле ел тула. Авылның гына түгел, тирә-юньнең мөхтәрәм кешесе Низам абзый Билалов, белгәнегезчә, колхозны төзешкән һәм аның беренче председателе булган кеше. Шушы постта ул Бөек Ватан сугышына үзе теләп киткән көненә кадәр эшләгән. Авыр яраланып кайткач та, Низамов ага байтак истәлекләр язган дип сөйлиләр. Авылның өлкән яшьтәге кешеләре әйтүенчә, кумәк хуҗалыкның уңъеллыгына багышлап үткәрелгән тантанада, кырыгынчы елның язында, ул бик гыйбрәтле доклад сөйләгән. Чыгышының тексты кызыл коленкор тышлы калын дәфтәрдә иде, диләр. Ул язмаларның саклан булуына шикләнмибез һәм аларны колхозның үзәк утарында — Кушкаенда ачылачак Дан музеена бирерсез дип ышанабыз, үтенеп калабыз...»
Самат укып барганда, Сәрбиҗиһан түти хыялында тагын яшьлегенә кайтты. Аның күз алдына табигатьнең ямьле бер почмагындагы туган авылы Кушкаен килде.
...Зөя суын җил-давыллардан ышыкларга теләгәндәй, елгадан читтәрәк сузылган таулар куенына сыенып утырган авыл якында гына. Җиләкле печәнгә бай урман аланнары... Авыл уртасында мәһабәт ике күл... Тау итәгеннән агып чыккан чәлтер чишмәләр... «Тимерче кизләве», «Йолдызлы чишмә», «Кыштуңмас»... Авыл буенда гына да унлап алар. Шуңадыр, тау асты урамын «Чишмәле урам» дип тә йөртәләр. Һәр чишмәнең үз җыры, үз көе, үз сере бар сыман. Суларының тәме —

теленне йотарлык, салкыны — теш камаштыра торган. Гасырлар күкрәген тишеп, җир астыннан ташлар ярып, ургып чыкканга шулайдыр. Шул чишмәләрдән су эчсәң, ару-талуларың юкка чыга, дөнья ямьләнә төшә. Яшәү көче биреп ага ул чишмәләр. Аккан юллары — гомер юлы...

Ә шул чишмәләрнең берсен инде кырык елдан артык авыл халкы «Низам чишмәсе» дип йөртә. Утыз беренче елның җәеннән бирле.

Ул елны тирә-юнь авылларда, иген өлгереп килгәндә, колхоз басуларына ут салу хәлләре булгалады. «Яшәр» колхозын оештыручы ирегетләр, коммунистлар, комсомоллар да һәр төнне кыр сагына чыгалар иде. Көннәрнең берендә, караңгы июль төнендә, дозорга чыкканда, тау астына җиткәч, яшь председатель Низамны ат өстеннән атып ектылар. Ул, уң иңбашы җәрәхәтләнеп, чишмәгә йөзе белән капланып төште. Кайнар каны чишмә суына кушылып акты.

Мылтык тавышыннан өркеп, аты читкә ташлангач, председатель әле һаман ат өстендә дип белеп булса кирәк, кабат аттылар. Низамның колхозга әтисе йортыннан алып килгән малкае төн суыгы төшкән җиргә гөрселдәп ауды һәм, үлем ачысы белән тартыша торгач, катып калды.

Чишмә суының салкыны хәл өстәде кебек Низамга. Һәрхәлдә, һушыннан язарга ирек бирмәде. Төнге тынлыкны тыңлап ятып, үзенә һөҗүм итүчеләрнең китеп баруына ышангач, ярасын сул кулы белән басып (бәйләр әмәле юк иде), көч-хәл белән авылның иң кырый йортына менде. Җил капканы ачып керде. Ишек шакырга көче җитмәде, болдырда егылды. Ике-өч минут үттеме икән, тыны кабып, йорт хуҗасы — авылның ярлы-ябагаеннан берсе — Чишмәбаш Сәлим кайтып керде. Болдырга аркылы яткан кешене күреп, коты очты.

— К-к-кем бу? Ниш-нишләп ятасың? — диде ул тотлыгып.

— Мин әле бу, Сәлим абый. Низам... — Яралының тавышы зәгыйфь чыкты. — Аттылар... Иңбашым яралы... Бәйләргә иде, бу килеш кайтып җитә алмам...

— Ә-ә... ни... хәзер...

Сәлим каядыр китте. Тавыш ишетеп, хатыны торып чыкты. Йокысыннан айнып җитәр-җитмәс.

— Сиңа әйтәм, нәрсә бар, ходаем? — дип куркынды.

Болдыр буена әйләнеп килгән Сәлим:

— Чишмә буенда мылтык шартлагач чыккан идем... Председатель Низамга атканнар икән... Ул менәтерә безгә кайтып егылган. Лампаны алып чыгар идең...

Аннары икәүләшеп Низамны өйгә алып керделәр.

Самат хатны ашыкмый гына укый бирде:

«Колхозыбыз тарихын язарга керештек. Аны авылдаш журналистыбыз Әдһәм Сәлими язачак. Партком өч кешедән редкомиссия төзеп раслады. Низам абый Билалов хатирәләре бу эштә зур терәк, тарихи документ булачак. Беренче председателебезнең истәлекләрен безгә ирештерүегезне сорап, колхоз идарәсе һәм парткомы исеменнән: «Кыям Хайсаров».

Сәрбиҗиһан түтәй, яулык очын күзләренә тидерә-тидерә, тыңлап утырган җиреннән кинәт сикереп торды. Зәмирә олы кешенең болай өермәләнеп китүенә сәерсенеп тә калды. Ул әле иренә, әле кайнанасына карады.

— Шулай булмыйни! — Ананың тавышы гыжлап-ысылдап чыкты. Сәлим Әдһәме тарих язсын да, мин аңа иремнең истәлек язмаларын үз кулым белән тоттырыйм ди. Һе! Тапканнар Тархан тилесен. Шуның атасы бит чишмә буенда эткәгезнең гомерен өзәргә теләүче, канын коючы... Кая, бир әле! — Сәрбиҗиһан түтәй хатны Саматтан алды. — Эткәгезне атканның иртәгесен тикшерүче килгәч, иң беренче Сәлимне кысып алдылар. Ялгышмадылар бит! Утырып кайтты ләгънәт орган җан. Хәерче булганга, аңсыз эшләгән дип, мәрхәмәтлерәк тордылар бугай

инде. Кулак Баһау-карун яллаган булган. Карунның эзе шуннан бөтенләй суынды...

— Сөйләгәнең бар, энкәй, беләбез... — Самат әнисенең язмаларны ят кулга бирүгә аяк терәп карышасын белеп торды. Шунлыктан, үзенчә бик тиз исәп йөртеп алгач, ананың нечкә кылларын чиртергә булды. — Бирмәсәң, бик дөрес эшләгән буласың, энкәй. Әткәйнең төсе итәрлек бердәнбер хатирә. Ну алдан ук шунысын әйтим, синнән ул дәфтәрләрне абый кулы белән алачаклар. Алар абыйны күндерәчәк, абый сине риза-бәхил итәчәк.

— Морат ник чәчелеп төшсен?

— Үзең әйтә торасың бит, йомшак күңелле. Намуслы. Сөттән ак, судан пакь. Син — коммунист кеше, диячәк аңа Кыям абый, шундый эшнең тәрбияви ягын чамалыйсыңмыни, диячәк. Коммунистик хезмәт ударнигы булган совет кешесенә мондый тар карашлы булырга ярамый, дип җибәрәчәк.

— Дәфтәрләр минем кулда. Мин исән чакта бирәү дә үрелә алмас. Хаклары юк!

— Талап алмаслар, анысы... Олы улың үгетеннән балавыздай эриячәксең дип әйтеп торам бит, энкәй! Син үзең дә намуслы, саф күңелле, гадел...

— Ярар, ярар, тел шомартма. Каты әйтмәгән саен да. Гадел булмыйм дип нишлим? — Карчык хәзер үк әйле-шәйле килә башлады. Мораты әйтсә (ә ул ышандыра белә, яхшы укытучы шикелле), йомшарачак та төшәчәк. — Нишлим?

Самат нәкъ менә шушы сорауга нәкъ менә шушы секундта җавап бирү кирәген сизеп торды. Карчыкның шик-шөбһәсен өреп очырырлык җавап кирәклеге аңа бик ачык иде.

— Нишлим дип баш чатнатып торасы түгел, энкәй: әткәйнең бөтен дәфтәрләрен керт тә куй безнең сандыкка. Шуның белән шул, нокта! Абый таптыра башласа, кая куйганымны онытканмын диген. Хәер, кирәкмәс, алдашып гөнаһлы булма. Саматларда диген. Укырга алды дип әйт. Минем йодрыкны абыйдан тегеләйрәкләр дә тиз генә ача алмаслар...

— Хәзер үк кертеп куйыйм булмаса.

— Керт шул, энкәй. Калган эшкә кар явуы бар.

Зәмирә иренә сораулы караш ташлады, ләкин сүз әйтмәде. Самат исә күз кыскандай итте һәм канәгать елмайды.

2

Прораб Сафдил абыйсы килмәде. Җәй үзәгендә, төзелештә кылны кырыкка ярырдай булып йөргәндә, бригаданы ташлап китәргә вөҗданы җиткән кеше белән уртагым юк, дигәндер.

— Хәерле булсын! — Самат, һәммә нәрсәгә битараф кеше сыман, кул селкеде.— Мин үзем генә дә утыра беләм өстәл артында, әйтмәсәм дә әйтим...

Бригададан тәмсезләнеп китүенә Самат, чыннан да, нык борчыла, кире кайтырын уйлый, бездә эшсезлек юк, муенның булса — камыты табыла дип үз-үзен юатырга тырышса да, күңеле тынгысызлана иде.

Берне күтәреп куйгач ук, галстугын бушатты, изүенең өске төймәсен чишеп җибәрде, кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып, битен сөртте.

Бер уйлаганда нәрсә, азимуты билгеле аның. Колхоз белән сүз башы сөйләшенгән. Барасы, договор төзисе, дөбердәтеп эшкә башлыйсы. Дөрес, бер нәмәрсәкәй кире килебрәк тора: медпунктның яңасын да шул урында ук төзергә булганнар. Авыл уртасы бит. Иске бинаны сүтү дә алар җилкәсенә төшәсе. Ну... сүтү — төзү түгел. Шуның өстенә мо-

ның өчен тияре аерым булырга тиеш... Председательләре — ут кеше инде, каһәр! Акча санарга бик оста. Эшче куллар житмәгәннән генә гажиз. Хак килешеп, договор язганда, аяк терәп торырга туры киләчәк... Калганы — үзләреннән тора. Батырып эшләргә дигәндә — буыны нык әле. Шабашка сыек буынлылар йөрми дә. Акчага йөрүчеләр бригада подряды ысулын зрә дә шәп отып алган кешеләр алар. Үзләренә күрә Злобиннар, Мәүликовлар. Аерма шунда: шабашниклар сәгатьләрен санап эшләми. Аларның эш көне — бер таңнан икенче таңга! Жекләре суырыла. Ну сәмәне — во!

Самат бераз черем итеп алмакчы иде, барып чыкмады: шактый изрәгән булса да, күзен йокы алмады. Сикереп торды да юл хәстәренә кереште. Кашык-савыт, алмашка эчке кием, кырынырга пәке, көзге, ислемай, кулъяулыклар — һәммәсе кирәк. Энә-җеп, хәтта чалбар ямаулыкларын да онытмаска дип күңеленә киртләгән иде ул. Зәмирә барысын әзерләп куйган. Кайда соң әле үзе? Ә, әнә, ишегалдында Язгөл белән сөйләшеп тора икән. Ярар, серләшсеннәр!..

Самат бөтен кирәк-ярагын рәте-чираты белән, иплэп-таслап дигәндәй, биштәренә тутырды. Күңеле белән Балыклыда иде инде ул. Колхоз председателе каршында, өстәлгә терсәкләрен җәеп утырган килеш, кирпечтән медпункт, аңа ялгап медперсонал өчен торак һәм аптека салуның хакын сатулаша...

Куллары биштәрендә, авыз эченнән генә җыр көйли.

Иртә торып суга барам,
Суның салкынын алам...
Суым салкын, эчем ялкын,
Синең утыңда янам...

Ул һаман шулай: теленә килеп юлыккан җыр сүзләрен ун да кабатлый, йөз дә... Көен дә. Иртән үзенә ияргән көйдән кичкә кадәр арына алмый. Нидер эшли бирә, көйли бирә, видеомагнитофон тасмасын кирегә әйләндергән кебек, үткәннәрне берәм-берәм хәтерендә яңарта, гүя гомер йомгагын сүтеп карый.

...Суым салкын, эчем ялкын...

Өйгә кемдер кереп килә. Абыйсы икән, Морат. Эштән кайтып, өсбаш алыштырган да сугылып чыгасы иткән, күрәсең.

— Сәлам күчмә кабилә кешеләренә! — табигате белән юаш, үтә тыйнак кеше булса да, Мораtның кайчак шулай төрткеле сөйләшә торган гадәте бар.

— Сәлам утракларга! — Самат борылып абыйсына карады. — Күсәк белән кусаң да урыннарыннан кузгала алмаучыларга! Каккан казыкларга!

— Нык утырганнар алайса, ә! Жирдә үзләрен хуҗа итеп сизәләр...

— Һәркемгә яраткан сыныгы. Әйдә, түр якка уз. Мин хәзер, биштәр авызын гына бәйлим. Атом ягулыгы бар анда азрак...

— Рәхмәт, алай омсынып тормыйм.

— Сыйлаганда су да эчәләр. Кер, әйдә, кер. Мин — момент.

Морат алгы өйгә узгач, Самат, бая әнисе керткән дәфтәрләрне тиз генә биштәренә салды да, капчыкны аяк астыннан арырак алып куйды.

...Суым салкын, эчем ялкын...

Алгы өй бусагасын атлагач, көйләп кергән җыры өзелеп калды. Мораtның йөзе бик житди иде. Ага кеше өстәл кырындагы урындыкларның берсен читкә алды да, арка терәп утырды. Уң аягын сул тезенә атландырды. Аннары каты кара чәчен сыйпаштыргалады. (Ике туган бер-берсенә шул хәтле охшаганнар, кул хәрәкәтләре, йөз чытулары,

каш җыеруларына кадәр бер төсле. Тик Морат гәүдәгә кайтышрак. Аннан соң абый кешенең чәченә инде мул булып чал кергән).

— Әйдә, абый, тын ал азрак, арыгансың. Тот, әйдә! Хәерле юл теләэнеңә...

— Кирәк чагында теләдем мин сиңа, энем. Теләдем. Аңлый идем, ир-егет өйле-көйле булырга тиеш. Морадыңа ирештең, әйеме? Ирештең. Инде нәрсәгә бу зимагурлык? Канатлы кырмыска булып йөрү нигә? Сиңа хәзер тамыр җибәреп, өеңдә яшәргә кирәк. Өеңдә! Балалар үстерергә вакыт. Бик вакыт! Дуадак каз шикелле күпме йөрерсең? Күпме йөрергә мөмкин дип беләсең?

— Ә-ә-әй! — Самат кабынып китте. — Хәерче гвардиясе үрчетеп кем рәхәт күргән әле?!

— Нәрсә-ә-ә? — Морат торып басты һәм энесенә шундый итеп карады, тегесе ихтыярсыздан телен тешләде. — Авызың ни сөйләгәнне колагың ишетәме синең? Колагың? Безне нинди елларда үстергәннәр, шыңшымаганнар. Син бүгенге тормышта шүрләп торасың. Бүгенге! Ниткән тузга язмаган фикер дә, колакка ятмаган сүз бу? Колакка!

Сабыр Морат бер кызмасын гына, дулый башласа, дулый ул. Әле дә, ике кулын чалбар кесәләренә тыккан килеш, ишекле-түрле йөренеп китте.

— Яныңа керүем боларны сөйләргә телем кычытып торганнан түгел, — диде ул нык үпкәләп. — Түгел. Аракы өметләнеп тә кермәдем. — Ул, ачу катыш гарьлектән тешен кысып, иренен тешләштергәләде, тыныш ясады. Каш астыннан карап утырган Саматка шушы сүзсезлек эт итеп тиргәүдән дә яманрак иде. Чыдамады, үзе: — Тешләнмә, тешен бетәр, — дип сүз катты.

— Синең кебекләр белән тешең дә бетәр, эшең дә бетәр, — диде Морат. — Үзең ярар да инде, өйрәнеп киттең шабашкага. Тегермән яларга өйрәнгән этнең он күрми күрсә, эче күгәрә, ди. Егор да синең парың. Кышын кибеттә рабочий, ат азгыны тайга ияргәндәй, сиңа тагыла. Күрше малаеның, Ильясның дим, нигә күңелен алгысыттың? Нигә? Әле бит ул тугызны гына бетерә. Дөньяга чыгып кына килә. Беренче атлаганы ук шабашлык юлында булырга тиешме егетнең?! Шулай тиешме? Чабак сикерсә — чуртан авызына. Хәләл тормыштан читкә сөйрисең егетне!

Морат ике өй арасындагы ишек буена барып басты, гүя энесенең дорфаланып чыгып качарыннан шикләнә һәм сакта тора иде.

— Анысында синең ни катнашың бар? — Самат та йөрәксенеп куйды. — Әтисе риза. Малай атлыгып тора. Семьяда җиде кашык алар, беләсеңдер. Мотоцикл кем алып бирсен аңа?! Алма пеш, авызыма төш дип килми ул акча...

— Акчаны адәм рәтле юл белән дә эшләп була. Чын коллективта. Мин аны җәйлеккә үзебезгә урнаштыра алам.

— Синдәге сәдакага сәгать алырга гына...

— Мал шырпысы мигә бик тиз кадала. Быелгы шабашлыкның шаукымы егетнең канына сеңеп калырын уйламыйсыңмы?

— Ансыз да уйларым буа буарлык. Син генә ул бөтен дөньяның бөкресен төзәтмәк булып маташасың. Каян килгән БМО башлыгы! Һәммә нәрсәдә аның эше бар, имеш!

Морат бу мыскыллы сүзләрне авырга алды. Бер бүртенеп кызарды, бер агарды. Яңак сөякләре калкынышты, куе кашлары сикереште. Ул җилкенеп энесе каршына килде. Ярсып кулларын бутады. Әйтерсең туганын бауга урап, хаксызга тыпырчынуыннан туктатырга тели иде. Читтән берәр кеше карап торса, бу агай-эне сугышып китәр дип уйлар иде, мөгаен. Әмма Билаловлар гаиләсендә кешегә кул ягу гадәтенең гомергә булганы юк. Морат үзенә дә сәер тоелган тавыш белән кычкырды гына:

— Бар, һәммә нәрсәдә эшем бар! Үзем белеп торган, күреп торган гариплеккә күз йома алмыйм!

Абыйсы каршында басып тору кызган табада тору белән бер тоелганлыктан, Самат түргәрәк китте.

— Йомма! Төнлә дә шар итеп ят күзләреңне. Кеше ашына гына катык катма. Өйрәт энә кызың Язгөлне, улың Балкышны...

Сөйләгәненең җилгә очуына тәмам иман китергәч, Морат чыгып китте. Самат, муенына салган элмәкне алып ташлаган, кул-аягын бәйләргә иткән бауны чишеп ыргыткан шикелле, иркен сулап куйды.

— Вәт акыл ияләре! — Ул үртәнеп сөйләнде. — Әле энкәй вәгазь укый, әле монысы үгет-нәсихәте белән сагыз кебек сыланды. Әйтмәсәм дә... Олы юлга кеше таларга чыгаммы? Хәрам акчага күз алартаммы? Эшләгез сез дә минем кебек...

Самат стаканга хәмер койды.

— Ике арага чәчәкләр утыртыйк, Алма апа. — Язгөл Зәмирәгә шулай эндәште. — Ике рәт итеп. Берсенә тюльпаннар — лалә чәчәкләре. Алар иртәрәк чәчәк ата. Икенчесенә астралар — кашкарыйлар. Алар кара көзгә кадәр чәчәктә утыра...

Язгөл, сүзләрен хуплауны өметләнеп, Зәмирәгә карады. Уналты яшен тутырган бу кызның йөзендә әйтеп бетергесез самимилек, гадилек нуры уйный иде. Дөньяга, кояшка, ак болытларга, яшел үләнгә, агымсуга, үз поселокларының Казанкага караган читендә калкып чыккан тугызар катлы мәһабәт ташпулатларга сокланып зур ачылган коңгырт күзләрендә бәхет очкыннары елтырады. Куе да, озын да керфекләре ешеш җилпенеп, шул очкыннарны сүндермәскә, дөрләтә төшәргә телиләр иде шикелле. Ул апасыннан җавап көтте, ә бармак очлары белән йомры калку күкрәге өстенә төшкән калын толым очын сүтеп тә үреп торды. Табигатьнең иң матур төсләренә манылган хыялларын толымына кушып үрә иде кебек.

— Әй, акыллым! — Зәмирә тирән сулады да сагышлы көрсенеп куйды. — Чәчәкләр дисең син, сеңелем... Шундый чагың шул әле. Гаепләп әйтүем түгел. Бәхетле вакытың, чәчәкләр белән серләшер көннәрең...

Алма апасының җете зәңгәр күзләренә мөлдерәп яшь тулганын, матур иреннәренең ихтыярсыздан калтырана башлаганын күргәч, Язгөл куркынып китте.

— Ни булды, Алма апа? — Кыз Зәмирәнең ике беләгеннән тотты. — Рәнҗеттеләрме әллә?..

— Юк... — Зәмирә күз яшен йотты. Яңагы буйлап тәгәрәшергә өлгергән тамчыларын кул аркасы белән сөртеп алды. — Рәнҗеткән кеше юк... Тамагым тук, өстем-башым бөтен. Эшлим. Кибеттә дә, өйдә дә... Чәчәкләр дисең син. Самат абыең теплицаны киңәйтик, ди. Кибет эшеннән буш көннәремдә суган сатарга куша. Озакламый редиска өлгерер... Акча корты кергән бәндә җанын аямас икән ул...

Язгөлнең аллы-гөлле хыяллары кинәт сүнде. Ул, Алма апасын ничек юатырга да белмичә, тынып калды. Зәмирә исә, эч серен сөйләр кеше табылганга шөкер иткән төсле, сөйләвендә булды.

— Чәчәкләр... Аларны сулдыру тиз, күңелне сындыру тиз... Рәшәткә тотабыз, ди, быел ике арага. Рәшәткә дә койма! Өй тәрәзәләренә эчке яктан тимер рәшәткә... Болай да җаным төрмә рәшәткәсе эчендә кебек... Тормышта, сеңелем, кычыткан бул икән, билчән бул. Ялан кул тәләсә кем кагыла алмасын икән сиңа.

Зәмирәнең кинаяле сүзләре Язгөлгә аңлашылмады. Шулай да Алма апасының семья тормышыннан канәгать түгеллеген төшенде. Шул тәэсирдән ул:

— Гомергә шулай булыр микәнни? — дигәнен сизми дә калды.

Зәмирә килешле йомры җилкәләрен җыерды һәм. Язгөл соравын җавапсыз калдырып, өенә кереп китте. Язгөл байтак ялгызы гына басып торды...

Борчылу, тынгысызлану галәмәте булса кирәк, Зәмирәнең уң күз кабагы да, сулы да алмаш-тилмәш тартып тилмертте. «Уң күз тартса — хәерлегә, — ди аның әнисе, — сул күз — күңелсезлеккә».

Зәмирә төрлечә юрап бакты. Бәлки Самат китми калыр, бу җәйне бергә җәйләү насыйп булыр. Акылына кайтсын иде дә китмәсен иде, чын әгәре! Һәр көнне күз алдында, һәр төнне янында булса, күңел утырырга яхшырак бит. Иләс-миләсләнергә урын калмый. Китә калса, ниләр булып бетәсен Зәмирә әлегә анык кына әйтә алмый. Йозак-бик, күз-колак, ныклы кул буларак кирәк аңа бүгеннәрдә Самат. Китмәсен генә иде! Ничек кенә димә, гомер сукмаклары кушылган ич инде...

Ул да түгел, Зәмирә берсе икенчесен куып килгән диңгез дулкыннарыдай уйларның бөтәннәренә күмелеп кала. Китсә, хәерлерәк булмасмы? Күз күеге кебек көн саен каршысында йөрмәс иде, ичмасам! Сулыш иркенәеп калыр. Ихтимал, айлар буе йөдәткән шик-шөбһәсенең очына чыгар, үзеп кенә бер карарга килер. Ниһаять, яшьлегендә үз сөйгәне белән очрашып, курыкмый-калтырамый гына сөйләшергә җай табар...

Кайсы хәерлерәк соң моның? Уң күз кабагы ни дип тарта да сул күз кабагы ниләр дип йолкына? Нинди куаныч көтә икән аны туар таңнарда? Кайгы-хәсрәтнең нindиләре сагалап тора икән?

Иңнәренә таш булып яткан уйларыннан авыраеп, ул аш-су ягына үтте. Чәй яңартырга ниятләп, газ плитәсенең конфоркасын кабызып җибәрде. Чыпчык томшыгыдай гына ялкын телләре зәңгәрсу тәлгәш хасил итте. Шул чак плитә өстенә өйгә кереп калган күбәләк очып килде, борчак-борчак кара таплар кунган кызгылт канатларын җилпеп, ут тирәсендә бөтерелә башлады. Зәмирә аны куллары белән куып карады, күбәләк китмәде. Аннары башындагы яулыгын салып селтәнде. Яулык җиле җитә калды бугай, күбәләк янә тәрәзәгә очып китте.

— Җүләркәем, канатыңны көйдерергә йөримсең? Кит, бар кит, урамга ук оч! Янып үлмәк буласыңмы? Синнән башка да канат-каурыйларын көйдергәннәр җитәрлек бу дөньяда!..

Үзен көйгән күбәләккә тиңләгәч, тагын күңеле тулды.

Кичке чәй янында ире эшләре уңайга барса, унбиш-егерме көннән кайтып китәрен әйтте, үзе югында Зәмирә ниләр эшләргә тиешлеген аңлатты.

— Син дә бер дә килми генә булмассың әле, — диде аннары. — Сагындыра бит, сабыр канатларың сынар...

— Син сагыныр төсле күренмисең әле. Сагына торган булсаң, болай атлыгып тормас идең. Ничәнче җәй инде... — Шулай диде дә Зәмирә боз йөрәкне дә эретерлек итеп елмайды. Аның уң бит уртасы чокыраеп калды. Әлеге мизгелдә ул гүзәлләргә тиң иде. Каршында илаһи балкыш күреп, Самат хәйран калган төсле булды. Хатынының тасвирга бирелгесез мөлаемлыгы аңа да күчте. Ул дөрес күрәмме соң дигән шикелле, утырган җиреннән бөтен гәүдәсе белән артка каерылды. Ерактанрак карап тормыш юлдашының чибәрлегенә тагын бер кат ышанырга теле иде кебек.

Зәмирә иренең соклануын шундук тойды. Самат рухының бозы эрү халәтеннән файдаланып калырга ашыкты.

— Чынлап әйтәм, әллә соң китмисеңме? — диде. Тавышында наз да, гозер дә, сизелер-сизелмәс кенә кисәтү дә, ялвару да бар иде. Мәгәр Самат күңелендәге кыллар хисләрнең бу бәйләмен кабул итәр дәрәҗәдә нечкә түгел иде шул. Тәгаенләгән сәфәренә аркылы төшәрдәй сүзләр аның кәефен кырды. Чырае тагын кырысланып чыкты, күзе-башы җимерелде, елмаюын бозлы су сибеп сүндерделәрмени!

— Нәрсә дип әле барыгыз да бер такмакны такмаклыйсыз? Хорга жыеп өйрәттеләрме әллә? Әнкәй, абый, син... Чүбек чәйнәп май чыгармакчы буласызмы?
Зәмифә дә сүрелде.
— Син шуны аңла. — Самат учы белән өстәлгә сугып куйды. — Һәр адәм баласының тормышта үзенә тигән өлеше һәм көмеше була. Әйтмәсәм дә әйтим, мин дә өлешемә тигән көмешне тиешенчә алырга тырышам.
— Беләм лә...
— Тукта, алай димә. Тормыш ул — буар елан. Мәлҗерәп торып кара. Сөякләрең ничек шатырдаганны ишетерсең. Өй кирәк идеме, кирәк иде. Булдырдым. Машина кирәк. Булдырачакмын! Моторлы көймә!.. Анысын да!.. Син кирәк идеңме, кирәк идең. Кирәк тирәкне ега, сине үземнеке иттем. Килен булып төшкәнеңне сизми дә калдың...
Самат җиңүле елмайды. Ләкин кинәнеп, ихластан елмаю килеп чыкмады.
Зәмирә аны көйдергеч карашы белән баштанаяк капшап узды. Аның ачудан кысылган күзләренә суык ятсыну чыгып өлгергән иде инде, тик Самат бу хәтлесен абайламады.
— Ерткыч! — Зәмирәнең иреннәре генә пышылдап куйды.
— Нигә, шулай түгелме әллә? Әйтмәсәм дә әйтим, синең урында булырга бер кыз да каршы килмәс иде.
Зәмирә кинәт кенә борылып, иренә карады. Акаеп карады дияргә мөмкин. Әмма ачулы чагында да сөйкемле, чибәр иде ул.
— Сиңа гына чыгыйм дип хыялланган идем шул...
— Ул-бу булмаган булса, чыкмас идем дисеңме?
— Тартма әле тел тегермәнеңне! Гарык шул сүзеңнән.
Өйләнешүләренә кагылышлы сөйләшү — өч елдан бирле Саматның күңел сызлавыгы. Электән Зәмирәнең үзен яратмаганын белә, шуңа күрә дә хатыны тирәсендә күренергә күркәм, тотарга куркам димәле хәзинә тирәсендә тулганган төсле йөри. Наз теләнеп тә максатына ирешмәгән минутларында хатынының җан җәрәхәтенә аяусыз орынудан ләззәт таба.
Зәмирә дә әчегә төче була алмый, Саматка карата еш кына кырыслана. Шул рәвешчә, матур гына башланган көннәрнең тәмсезләнеп тәмамланган очраклары сирәк түгел. Бүтән берәүнең исеме хатын-кызның күңел эчкәресендәге иң нәфис, иң нәзберек кылларына кагылып торса, күз алдыннан китмәстәй булса, газапның да газабы икән...

3

Язгөл белән Ильяс — сабый чактан күршеләр. Балалар бакчасына бергә йөрделәр, бер елны бер үк мәктәптә укый башладылар. Уйнаганнары-шаулаганнары гел бергә булды. Кыскасы, яхшы танышлар иде алар. Мәгәр бу язда үзләрен бөтенләй яңабаштан танышкан төсле хис иттеләр. Гаҗәп хәл! Әллә кайдан серләр пәйда булды, сөйләшер сүз бетми башлады, күңелләр аулак кирәксенде. Иң кызыгы — дөньяга бер-берсенең күзе белән карауучан булып киттеләр.
Ильяста, үзе дә аңлап җиткермәстән, Язгөлгә изгелек, яхшылык эшләү теләге уянды. Ул аны һәр вакыт канат астына алырга ашкынды. Кызның күзләрендә үзен күрсә, җанына канатлар үскән шикелле була иде.
Язгөлнең дә рухы йөрәк дусты, сердәш, киңәшче һәм терәк эзләгән чак иде. Кыз чын күңеленнән аның килерен көтте. Бүгенме-иртәгәме, әллә айлар, әллә еллар үткәчме — кайчан да булса бер киләсенә өмет өзмәде. Баштарак бу егетне ул хыялый бер зат итеп күзаллый иде.

Сандугач жыры аша, таңда офыкны бизәгән бихисап нурлар аша хәбәр биреп килер дип көтә иде. Алай булмады. Ильяс үзен тыйнак, әмма шактый кыю тотып, мәхәббәтен белгертте. Язгөл дә моңа шаккатмады. Аннары аптырады да: мәхәббәт дигәннәре шулай гап-гади генә башланып китә микәнни соң?

Ильяс янәшәсендә булганда, Язгөл күңеле куаныч һәм ләззәт белән тула. Икәү бергә атлаганда, аңа ташпулатлар, урамдагы агачлар, газоннардагы чәчәкләр, кошлар чыркылдашуы, кичке эңгер-меңгер — һәммәсе татлы бер серлелек белән өртелгән төсле тоела.

Җәй буена эшкә китәсе булгач, Ильяс бүген Язгөл белән мөмкин кадәр озаграк йөрергә тырышты. Гашыйкларга хас булганча, җыен юкбарны сөйләшеп һәм шуннан искиткеч зур ләззәт алып, кул тотынышып йөри торгач, алар Савиново поселогына җиткәннәрен тоймадылар да. Берничә көн элек Химиклар культура сараенда «Самоцветы» дигән ансамбльнең концертын караганнар иде. Менә хәзер шуны искә алып, Язгөл:

— «Болытлар артында»ны тагын йөз тыңлар идем! — диде.

Ильяс аны шундук җөпләп алды.

— Әйе, мин дә тыңлар идем. Ул ансамбльнең кайсы җырын гына әйтмә — во дигән! «Безнең адрес — Советлар Союзы», «Крюково авылы», алда әйткәннәребез... — Аннары ул иң охшаткан җырыннан берничә юлны кабатлап көйләде:

Не надо печалиться,
Вся жизнь впереди...

— Безнең хакта бу, әйеме?

— Ничек дип әйтим? — Кыз назлы көлемсерәде.

— Бөтен тормыш әле алда булгач...

Алар Язгөлләрнең өй турындагы бакча буендагы эскәмиягә утырдылар. Җылы, чәчәкләр исе белән тулы җәйге төн яшьләрне үз чыбылдыгы астына алды. Гүя ул аларның эчкерсез сүзләрен хәтта йолдызларга да ишеттермәскә тели иде.

Ильяс кызның кулларын үз учларына алырга чамалаган иде, Язгөл, этәреп җибәргәндәй, читкә тайпылды.

— Тик кенә, яме... — Ул моны ачулануга бик якын кырыслык белән әйтте. Шулай да, чамадан ашкан тәрпәлегеннән җайсызланган сыман, соңрак тавышын йомшартты. — Син бит футбол уйныйсың...

— Шуннан?

— Кагыйдәләрен беләсеңдер дим. Кул белән кагылмыйча гына...

— Я, ярый, үпкәләмә, Язгөл...

Кызның рәнҗүе узды. Сөйләшеп киттеләр. Сүз иярә сүз чыккач, Язгөл:

— Әйт әле, Ильяс, — диде, — яраткан кешеңне кыерсытырга мөмкинме?

Ильяс кашларын өскә чөеп елмайды.

— Аңламадым, Язгөл. «Ярату» сүзе белән «кыерсыту», «рәнҗетү», «газаплану» сүзләрен янәшә куеп булмый, минемчә.

— Мин дә шулай уйлыйм, ә тормышта киресен күреп торам.

— Нинди мисалларың бар?

Кырт кисеп сорагач, җавап бирәсе кыен булып калды. Тиктомалдан, сер тотмас үрдәк шикелле, үзенең туганнары турында сөйләргә тиеш була лабаса. Әйбәтме соң бу? Кирәге бармы мондый мисал китерүнең?

Ахырдан кыз әйләнеч юл тапты.

— Мин белгән бер семья бар, — диде ул. — Ире дә, хатыны да болай бик әйбәтләр. Тормышлары яхшы. Ире генә һаман канәгать түгел, гел акча җитми аңа. Акча дигәндә, үлгәнен дә белми... Хатыны да бик тырыш. Бал корты кебек. Эшендә дә, өйдә дә. Барына сөенеп яшисе

килә аның. Бәхетле буласы килә. Ире аңламый. Аңларга теләми. Кыерсыта...
Ильяс ияк кага-кага тыңлап торды. Аннары:
— Дөньяда төрле кеше бар,— дип куйды.— Акчасыз да булмый, билгеле... Алай да... — Егет Язгөлнең тел төбен төшенгән иде. Үзенең Саматка ияреп китәсен дә уйлап алды. Шуңа җавабы торыксыз килеп чыкты. — Алай да, әнкәй әйтмешли, акча дип үлгән аттан дага каерырга да ярамый инде...
Язгөл баш чайкады.
— Белмим, белмим. Тормыш ямен җибәрә торган булгач, нигә кирәк ул байлык? Яратуны үтергәч... Мин әткәй белән әнкәй өчен сөенеп бетә алмыйм. Акча дип һич чыгырдан чыкканнары юк. Ә үзләре гаҗәп татулар, дуслар. Бер генә тапкыр ачуланышканнарын да күргәнем юк. Әйбәт кенә эшлиләр дә... Икесе дә төзелештә...
Кинәт алар сүзләрен шунда бүлеп, үзләре дә сизмәстән тын калдылар. Бер-берсенә сыена төштеләр. Бакчада сандугач сыздырып җибәрде. Аңа күрше бакчадагылар да кушылды.
Казанка аръягында, көн чыгышында тулган айның сихри нурларыннан тукыган саргылт ефәк тасма. Башта ул тар гына иде, минут үткән саен киңәя барды. Аннары ай яктысы тоныклана төште шикелле... Әмма яшьләрнең күңеле тулы нур иде, бәхет иде.

## 4

Үзйөрешле паромда Иделне кичкәч, Югары Осланнан Балыклыга кадәр берәр юл уңае машинага эләгербез дип сүз куешканнар иде. Шул ният белән Иске Аракчинодагы кичүгә йөри торган автобуска бардылар. Егор алданрак килгән булып чыкты. Самат белән Ильясны күргә, ул пинжәк җиңен сыдырып, сәгатенә күз салды, аннары офыктан колга буе күтәрелергә өлгергән кояшка карап, баш чайкый-чайкый гаҗәпләнгән булды:
— Юл чыкканда шул хәтле йокламасагыз!..
Кул биреп күрештеләр. Егор Ильясны, Ильяс Егорны белми иде. Бер-берсенә сынаулы карашып алдылар.
Егор Кононовичка егет ошады. Ильясның кара кашлар астына кереп чумган карасу күзләре матур ялтырый. Ул күзләрдән җылылык бөркелә кебек. Каратутлы, кара чутыр егет. Кул кысуыннан ук беләгендәге куәтен чамалап була. Җилкә киң, бәдән нык күренә — төптән юан чыккан. Замана малае бит, нечкә генә мыек җибәргән. Күп сөйләшми торганга охшый. Сүзгә җавап урынына кайчак ак, тигез тешләрен күрсәтеп елмаю белән чикләнә бугай.
Егор абзасы да егет күңеленә хуш килде. Ачык чырайлы, мәзәкчән. Саргылт чәчләрен артка тараган. Йөзе тулган айдай түгәрәк. Яңак сөякләре калку. Үзе чуваш икән, ә татарчаны өздереп сөйли, татарыннан аерып алмалы түгел. Янтуганда үскән, татар авылындагы чуваш урамында. Әкәмәт агай! Юк кына кызыктан да кинәнеп көлә. Көлгәндә аның сиек зәңгәр күзләре кысылып, сызык кына булып кала. Сөйләгәндә әңгәмәдәшенең җилкәсенә зур учы белән кагылучан. («Вәт, парин, менә бит нәрсәкәй!») Хәйләсез, беркатлы булса кирәк, Саматның шаяруына да шундук ышанырга тора. Әнә бит Самат абыйсының, Ильяска күз кысып, «Паром башта Свияжскига бара, кире кайтканда гына Югары Осланга туктыйсы икән», — диюе булды, Егор хафалана калды.
— Озак була инде, алайса. Балыклыга кич кенә барып җитәбез икән, — ди. Паром гомергә андый рейс ясамый, югыйсә.
Аргы яктан төяп чыккан машиналарын, мотоциклларны бушатып, бирге якта чират көткәннәрен төягәнче шактый вакыт үтте. Җәяүлеләр

иң соңыннан кереп урнашты. Егор, ике машина арасына иске плащын җәеп, Самат белән Ильясны чакырды.

— Юл аягы! — диде ул, эре тешләрен күрсәтеп көлде. Аннары капчыгыннан шешә чыгарды, колбаса, икмәк, суган алды. Стаканнарга хәмер койгач, юлдашларына эндәште. — Төрек коньягы! Анкала. Тот, Самат, син дә, Ильяс браток!

Ильяс, гөнаһ кылган адәм төсле, кып-кызыл булды да:

— Мин эчмим, эчкәнем юк, — дип читкә китте. Аның сүзен Самат шундук ныгытып куйды.

— Шаярма, Егорушка! Дошманлашмыйк дисәң, моннан соң энекәшне кыстап авыз ачасы булма. Менә шул. Беренче и соңгы әйтүем шушы. Синең белән миңа да соңгы эчү бу, белеп тор. Эшне бетереп, тиярен кесәгә салып кайтканчы стоп-кран ябыла. Елдагыча, сухой закон! Я, сәламәт бул!

— Тау сана! [1] — диде Егор үз телендә.

Паром кузгалгач, Ильяс, бортка таянган килеш, җәелеп аккан Иделгә карап барды.

Яз иртә килгәнгәме, май азагы гына булса да, Идел җәй уртасындагы кебек иркен сулый иде. Су инде яз башындагыча болганчык түгел, чистара төшкән. Идел аръягының тау битләрендәге урманнар ямь-яшел. Соңгы елларда су кимегәнлектән сыртларын калкыткан комлы утраучыкларда яшь тал агачлары үсеп утыра, әллә нинди кыяклы үләннәр күтәрелеп килә.

Идел өсте тулы балыкчы. Көймәләреннән якорь төшергәннәр дә, кармак салып, тын калганнар. Яннарыннан моторлы көймәләр, су трамвайлары, «Метеорлар» үтеп киткәч, көймәләре бишек булып тирбәлә.

Көтәләр балыкчылар. Билгесезлек һәм өмет биләгән аларны. Чиертерме балык, биетерме калкавычны? Тартып чыгардым дигәндә генә кире суга ычкынмасмы кулга керәм дип торган табыш? Сунарчы белән балыкчының күпме гомере шул сорауга җавап эзләп үтә бит. Хәер, тормыш үзе дә гел көтү, өметләнүдән гыйбарәт бугай ла инде ул. Менә Ильясның да уенда барып урнашасы авыл, башкарып чыгасы эш. Юллары уңса, быел көз ул мотоцикллы булачак.

Җилкәсенә кул салуга әйләнеп караса, Егор дәдәсе икән.

— Вәт әйт әле син миңа, Ильяс браток, — диде ул аңа, — балык ник су өстенә сикереп чыга?

— Төрле сәбәптән булуы мөмкиндер.

— Алай да?

— Суда кислород җитми башласа...

— Аннары?

— Чуртан куып килсә... Качып котылу өчен.

— Алай гына да түгел, браток. — Егор елмая-елмая сөйләп китте. — Күптән өйрәнгәннәр, ди, балыклар бу һөнәргә. Борын заманда ук дип язганнар бер китапка. Болай булган: Балык янына кунакка бер Кысла килгән. Сәлам биргәч: «Ярга чыгып кергән идем, яңгыр ява», — дигән.

— Нәрсә соң ул яңгыр? — ди икән Балык.

— Су тамчыларының күктән коелуы.

— Ә тамчы дигәнең ни нәрсә?

Кысланың аңлата-аңлата теленә төер чыккан. Балык барыбер аңламаган. Шуннан соң: «Кая, мин үзем сикереп чыгып карыйм әле. Шунда белермен», — дигән. Шул заманнан бирле балыклар судан сикереп, дөнья хәлләрен белеп торалар икән. Мең кат ишеткәнче бер кат күрү яхшырак дигән сүз дә шуннан калган, имеш... Вәт, парин, менә бит нәрсәкәй! — Ул Ильясның җилкәсенә сугып куйды. Аннары тагын сөйләнергә тотынды: — Беләсеңме, Ильяс браток, татарлар нигә «Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер» дип җырлыйлар?

[1] Сау булыйк!

— Белмим, Егор дәдә!

— Белмәсәң, әйтим. Чувашлар сыерны «энә» диләр. Чынлап, чынлап. Бер сыерга — бер сыер булып чыга. Ягъни кая барсаң да бер кояш булып чыга.

Самат та сәфәрдәшләре янына килеп басты.

— Җитәбез...

Паром причалга килеп җитәрәк үз дулкынына үзе эләкте һәм киң корпусы суда нык утыруга карамастан, сизелерлек тирбәлеп алды. Самат сүз юктан сүз булсынныкын гына әйтеп куйды:

— Үзен-үзе бәлли-бәү итә бу...

Җәяүлеләр беренче булып чыкты. Самат, төркем башы, паромда чакта ул бер-ике шофер белән сөйләшеп караган иде, берсе Макылга кадәр генә кайтучы, икенчесе Борындыкка баручы булып чыкты. Шуңа күрә паромнан дебаркадерга, аннан ярга чыккан һәр машина хуҗасына сүз куша торды.

— Балыклыга кадәр ал безне. Өчәү без... — Ул, җәһәтрәк аңласыннар өчен, уң кулының өч бармагын тырпайтып күрсәтте. Җавапка:

— Минем тимерләр өстендә артың кабарыр, агай-эне. Кабинага берегезне генә ала алам...

— Мин ул уңайга түгел, Кама тамагына кайтам...

— Алырмын, ну столовойга кереп, корсакны алдап чыгам, берәр сәгать көтәрсез, — дигән сүзләр генә ишетте.

Йөк машинасының соңгысы чыгып килә иде. Паромга керергә дигән чират башындагы зур үзбушаткыч шоферының сабыр канатлары сынган идеме, ул каршыга кузгалды. Аз гына, бик аз гына сөзешми калдылар. Самат исә ике арага кысыла язды. Өне алынды. Шуңа җан ачуы белән үзбушаткыч шоферына акырды.

— Иманыңны алам бит мин синең, паразит! Кая ашыгасың?

Тегесе дә тозлап-борычлап җавап кайтарды.

Алар әйткәләшкән арада шофер халкы җыелып өлгерде. Паромнан чыгып баручы соңгы машинаны ашыктырдылар. Самат күтәрелеп караса, ни күрсен: ул машинаның шоферы Зиннур икән ләбаса! Менә сиңа мә! Очрашу дисәң дә очрашу! Зәмирәдән колак каккач, Савиноводагы йортын сатып, каядыр Северный поселогына күчеп киткән иде бу егет. Кыяклаган иде, гарьлегеннән күзгә-башка күренми йөри иде. Паром басмасында күрешергә насыйп икән...

Күзләр-күзгә кадалып алгач, сәлам бирми ярамый. Аннан соң Саматка ни?! Ул морадына ирешкән, сүзен сүз иткән егет. Җиңүче җиңелүчегә мәрхәмәт күрсәтә икән, оттырган кеше моңа шат булырга тиеш.

Автомашина, ярга чыгып бер читкәрәк туктагач, Самат Зиннур янына килде. Егор белән Ильяс та аңа ияртеләр.

Зиннур, кабина ишеген ачык калдырып, җиргә төште.

— Сәлам әүвәлге күршегә! — диде Самат, башлап кул сузды.

— Исәнме, Самат абый. — Шофер да сер бирми күреште. — Уһу-у, тагын бер күрше монда икән әле, саумы, Ильяс энекәш!

Аннары ул Егорга да кул бирде.

— Син дә дөньядамыни? — Самат йомышын кисәк кенә әйтеп салмады, ялыныч булып яңгыравыннан сагайды. — Кай тарафларга юл тотуың?

— Буага барам.

— Кайда эшлисең хәзер?

— Мотор заводында. Ә сезнең кая барыш?

— Шул якка. Балыклыга. Алып барасыңмы?

Зиннур берсүзсез ризалык бирде. Самат кабинага, Егор белән Ильяс кузовка менеп утырдылар. Машина, тау менәргә җилкенеп, тизлеген арттырды.

Утыргыч йомшак булса да, юлның уйдык-чокыр җирләрендә баш түбәсе белән кабина түшәменә тиеп-тиеп киткәли иде. «Кызык! — дип уйлады Самат. — Мин дә үз дулкынында үзе тирбәлгән паром хәлендә бүген, ә?! Йөрәк дулкыннары кагуын кичергән көндәш белән янәшә барам. Маңгайга-маңгай гөрселдәтеп сөзешә язган ике машина кебек бит без... Тормышның киң басмасын тар итеп очрашкан кешеләр...»

Авыз йомып бару икесенә дә уңайсыз иде.

— Ничек соң, авыл юллары бик җиләтмиме? — Самат шулай дип сорады. Зиннур бер сүз белән генә:

— Күнегелгән эш, — дип җаваплашты.

— Ярыйсы тулиләрме?

— Мин канәгать.

Шофер моны эчкерсез әйтте, тик Саматка бу сүз тәрткеле тоелды. «Мин канәгать, син генә ул комсыз, тәнкәнең зурысын эзләп чабасың» димәкче микән? «Әйе, чабам. Чабам да, табам да!» Үзалдына уртәлә торгач, эчке бер ярсыну белән, әмма аны тышка түкмәскә тырышып, тезеп китте:

— Мин юк-барга канәгать булалмыйм! Алты почмаклы өем бар, өй тулы менә дигән җиһазым бар, бакчам бар, теплицам бар... Фәрештәгә алыштырмаслык хатыным бар... — Ул күз чите белән Зиннур йөзен күзәтте. Нишләр? Үзгәрерме йөзе? Юк, бик тыныч бара. Юлга карап чекерәйгән, әйтерсең күршесенең сүзенә колак та салмый. — Инде машина кирәк. Көзгә булмаса да, яренгә «Волга» алам. Аннары шуңа утырып Кавказга! Парлашып...

Зиннур аның әйткәннәрен бик сабыр гына җөпләде.

— Ярый торган эш...

Байтак кына сөйләшми бардылар. Һәр икесенең үз уе иде. Аннары вак-төяк турында гәпләштеләр. Ике сәгать тулып узды дигәндә, осталар Балыклының урам башында төшеп калдылар.

— Сау бул! — диде Самат, шоферга кул биреп. — Имин йөр. Җырдагыча, миңа унга, сиңа сулга, язмыш кушканы шулай! Һәркем үз юлына... Сирәк очрашабыз. Көн дә күрешкән заманнар да бар иде бит, мин әйтәм. Я, хуш...

Егор белән Ильяс рәхмәт әйттеләр. Өсләренә тузан мул кунган иде. Алар, судан чыккан казлар канат җилпегәндәй, кагына-сугына башладылар.

Председатель идарәдә иде. Осталарны хуп күреп каршылады.

— Көттек. Квартир әзер. Ялгыз бер әбигә урнаштырабыз. Сөйләшенгән. Әбекәй аш-суга бик оста, туй сыйлары хәзерләргә йөртәләр үзен. Йорт-җире чиста, канәгать булырсыз, — диде. Ильяска малайсытып карады бугай каравын, тик моны искәреп өлгергән Самат без өчебез дә бер тиң эшли торганнар дигәнне аңлатып куйды.

Әбекәйнең йорты медпункттан кул сузымында гына диярлек булып чыкты. Төзисе бинаның планын-сызымын караганчы, хак мәсьәләсендә кул сугышканчы ашап-эчеп килделәр. Сүзнең зурысы аннары башланды.

Председатель ялланачак осталар алдына сызымнар куйды. Самат аларны үз каршысынарак тартты. «Боларны мин карарга тиеш. Егор белән Ильясның эше — кушканны башкару», — ди иде аның килеш-килбәте.

— «Гигант» колхозы салдырды безнең районда шундый фельдшер-лык-акушерлык пункты, — дип аңлатты Самат янына килеп баскан председатель. — Без анда баргалый торабыз, кат-кат күргәнебез булды. Үзебезгә дә шундыйны салыйк дибез. Буйга — егерме дүрт, иңе алты метр... Биеклегенә килгәндә, шәһәр квартирлары кебек кенә итмәбездер. Өч тә егерме дип билгеләнгән. Медпункт үзе, аптекасы, персонал өчен торак. Аста — склад дип атыйк — подвал ясыйбыз. Кирпечне җитәрлек

кайтарып өйдек. Матчалыклар, идән сайгаклары, түшәмлек, идәнлек такталар әзер. Кыскасы, агач материалы тулысы белән бар. Ишек, тәрәзәләрне үзегезгә ясарга. Түбәне шифер белән ябасы. Чират аңа килеп терәлгәнче кайтарырбыз дип уйлыйм. Кадак, буяу хәстәрләдек. Измә савытларын көйләп куйдылар. Җылыту үзәктән булачак. Боларын коруны да сезнең җилкәгә салырбыз дип торабыз...

— Мәктәп директоры белән сөйләшеп карарбыз. Үз үтерми, ят ярлыкамый диләр. Моңарчы ярдәмнәреннән ташлаганары юк иде.

— Сөйләшергә, сөйләшергә... Ашау-эчү гвардейски булырга тиешен әйтеп тормыйбыз инде, Гаяз Минһаҗевич...

— Бюджетыгыз рөхсәт иткән дәрәҗәдә сыйларга сүз бирә алам.

— Хуп! Яшен яшәгән бинагызны сүтәргә дигәне...

— Договорга кертәбез аны...

— Өстәмә итеп!

— Килешербез дип уйлыйм.

— Подваллап җибәрәсе булгач, аның базын машина казый дип планлаштыргансыздыр инде?

— Утызынчы еллар түгел, Билалов энем, көрәккә калмабыз. Экскаватор да, бульдозер да хутта...

— Алайса, инде түп-түгәрәк тияре турында...

Председатель әйткән бәя Саматка без булып кадалды. Ул сикереп үк торды.

— Сез нәрсә, Гаяз абый?! Көненә ун сумны мин аны хатынымның җылы кочагын ташлап китмәгәч тә эшлим. Разрядым шундый. Мәзәк яратсагыз да, чынлап сөйләшегез әле.

— Мин әйттем.

— Ихлас сүзегез шул булса, саубуллашыйк кына. Әбекәйнең чәе өчен рәхмәт әйтик тә... Безгә һәр сәгать кадерле. Күршеләрегездән дә чакыру бар иде. — Самат председатель күзенә батырып карап алдашасы итте.

— Кем, Хәйруллин чакырамы?

— Ул да...

— Кәбирев тәме?

— Ул да дип әйтик...

— Шулдыр, тараж әмәлләмәкчеләр. Җир җәя — бер бәя инде ул, Билалов энем. Бер колхозда да котырган акча юк... Күкерт булма, кабынып төшмә, синең бәяне ишетеп карыйк...

— Алдан атаганыгыз кадәр ике дисәгез, шуңа подвал стенасын өюне, ишек, тәрәзә ясауларны, иске медпунктны сүтүне өстәп түләсәгез, тотыгыз бишне — ун булсын!..

Байтак тарткалаштылар. Председатель сабырын җуймады, тешләп тартсаң да артыгын ычкындырмастай булып утырды. Самат каударланды, кызды. Ул уенсыз-мазарсыз Балыклыдан китәргә әзер иде. Кәбиревкә сугылып, бәхет сынарга ниятләп торды (былтыр бер колхозда җылы гараж салдылар, җаен беләләр).

— Без бит, Гаяз Минһаҗевич, сезнең расценка дигәнегезгә карап тора алмыйбыз. Юк, агай, юк. Тәүлегенә җиде сәгать эшләргә килмәдек чөнки. Юк! Унҗиде-унсигез сәгать эшлибез, Гаяз Минһаҗевич. Йоклап алу да чиратлашып безнең. Шимбә юк безгә, якшәмбе юк. Һәр айга сигез көнне икеләтә түләүдән чутлап җибәрегез әле. Өч айга егерме дүрт көнең куш бәядән... Муеныгызга көчләп тагылырга килмәдек. Ихтыярыгыз...

Председатель Саматның барысын исәпләп-чутлап куйганлыгына сокланды хәтта. Алай да үзенә сиздермәде. «Дөрес әйтә, каһәр! Шомарган...» Уйлана торгач, колхоз башлыгы сынды, килеште.

Кабинетка баш бухгалтерны чакырдылар.

5

Саматның җинел генә «Сүтү — төзү түгел» дип җибәргәне бөтенләй рас килмәде. Сүтү үтләтә торган шөгыль булып чыкты.

Эшне калай түбәне каерудан башладылар. Әйтерен бармы, заманында бу түбәне япкан осталар иренмәгән! Ефәк күлмәк җөйләре диярсең, калайларны берсен икенчесенә шундый итеп «ямап» барганнар — каерып алмалы түгел. Беренче табакны аеруча интегеп куптардылар һәм бернигә яраксыз иттеләр: тишеп, яньчеп бетерделәр. Кадаклары урыннарыннан кымшанмадылар да, тик тырпаешып калдылар, кләшчәләр «эшләпәләре»н генә салдырганнар иде. Әйтерсең лә кадаклар осталарга: «Сәлам сезләргә!» — дип әйтер өчен баш киемнәрен кулларына алганнар...

Самат, калай астындагы такталарга утырып, кубарылган табакны караштыра башлады.

— Күпне кичергән, күпне... — дип авыз эченнән сөйләнде ул. — Биш-алты кат буяганнар. Ә казна йортлары түбәсенә буяу дигән нәрсәнең еш тәтемәвен Мәнди анасы да белә. Шулай булгач, егерме ел гына торган да торган инде бу калай...

Тик аның максаты түбә ябылган елны ачыклау түгел, бәлки, җаен табып, калайларны мөмкин кадәр бозмыйчарак кубару иде. «Аннан күз күрер, — дип фикер йөртте ул. — Иделнең бирге ягында ук дача салучылар йөзләгән, берәрсенә куарга була... Колхоз бездән күгәргән калайга хисап алып тормас ла инде!..»

Түшәмгә салынган туфрак уалып тузанга әйләнгән: аяк баскан саен пырхылдап өскә күтәрелә, төчкертә, авыз-борынга, колак тишекләренә тула. Ә түбәдән яңгыр үткән урыннарда тузан каткалакка әйләнгән, анысын көрәк белән көрәмәле...

Көннең-көн буена майтарганнары шул булды: түбә калаен сүтеп алдылар, кайчыларны ектылар, идәнне, түшәмне сүттеләр. Тик стеналар торып калды. Аларын тиз ишәрбез дигән исәпләре дә чынга ашмады. Черүләре житкән бүрәнәләрне дә берәм-берәм алырга туры килде. Ярый әле, акылларына килеп, идәнне беренче көнне сүттеләр һәм чүпчар идән асты базына олага торды. Югыйсә, олаулап чүп көрәргә туры килгән булыр иде.

Көн төшкә кадәр нык кыздырды. Осталарның тозлы тиргә баткан аркалары кызарып чыкты. Башларына дүрт почмагын төенләп япкан кулъяулыкларын әледән-әле суга мана тордылар. Фатир хуҗасы әбекәйнең салкын әйрәнен чиләге белән чөмерделәр.

Кичке якта кояш баешында карасу-шәмәхәләнеп болыт кабарды.

— Эх, үткәзеп яусын иде хәере белән! — Егор Кононович күккә карап шул теләген әйтте. — Июнь башының җылы яңгыры бернигә алыштыргысыз бит ул, егетләр!..

Самат белән Ильяс, аруллары җиткән идеме, аның сүзенә кушылмадылар.

Җилләде, давыллады, тузан өермәләре бөтерелде, ләкин Балыклыда яумады, болытның чабу чите генә эләгеп, тамгалап кына үтте. Шулай да кайдадыр мәрхәмәт күрсәтте бугай, аллы-гөлле булып салават күпере чыкты. Шуңа сокланып карап торган Егорның тагын сөйләшү кытыгы кузгалды, авызын ерып сүз башлады.

— Карале, браток, салават күперен, — диде ул. — Матур бит, ә!.. Шәүләгән түше кебек.

— Нәрсә ул шәүлегән? — Монысын Ильяс сорады. Ул учы белән күкрәген ышкып утыра, тир катыш тузан төерләрен сыпыргалый иде.

— Татар малае үзең, шуны да белмисең. Шәһәрдә үскән шул. Кош ул шәүлегән, кош. Аны яңгыр теләнчесе дип тә йөртәләр. Урысчасы —

иволга. Яңгыр яусын иде дә салават күпере чыксын иде дип тели ди ул гелән.

— Ник алай? — Егет Кононовичның кармагына эләккәнен сизми дә калды.

— Салават күпере — аның матурлыгының башы...

— Ничек?

— Болай булган... — Егор Кононович тәмләп сөйли башлады. Ә күзләре биниһая биек, галәмәт зур күпер булып асылынган матур тасмаларда булды. — Шәүлегән соп-соры бер кош булган кайчандыр. Ну, чыпчык төсле. Ә хәзер аның кауры́й канатлары соры, яшькелт, кызгылт, күгелҗем... Каян алган ул аларны? Бер китапта язган, көннәрдән бер көнне шәүлегән күк күкрәвен ишеткән. Бүгенге кебек болыт килә икән. Шүрләгән шәүлегән. Яфраклар арасына посып боеккан да яңгыр узганны көтә, ди. Бер заман күзен ачып бакса, ни күрә: болыттан елгага кадәр төрле-төрле төстәге дуга-тасмалар сузылган! Шаккатып карап торган бичара кош моңа. Үзенең дә шул төсләр кебек матур буласы килгән. Дәртләнеп киткән дә, канат кагып, салават күперенә таба очкан. Кеп-кечкенә йөрәге, ярылырдай булып, шомланып типкән. Шулай да матур булу теләге куркуны җиңгән. Шәүлегән салават күпере тасмаларының арасыннан кат-кат очып узган һәм шундый матур кош булып калган. Вәт, парин, менә нинди нәмәрсәкәйләр!.. — Бу юлы Егор аның җилкәсенә сукмады, Ильяс ераграк утыра иде.

Кич җитте. Авыл киче. Аның ямен авыл һавасын сулап, сала ипиен ашап, яшел чирәмдә аунап үскән, басуында иген иккән, көтү көткән, болыннарында печән кибәннәре өйгән кеше генә бөтен тирәнлеге белән тошенә. Дөрес, яшел чирәм дигәнең хәзер авыл җирендә дә тансыкка калып бара. Тракторлар, комбайннар, бульдозерлар, авыр йөк машиналары тыз-быз йөргән урамнарда ничек үссен ди ул? Сандугачлы әрәмәләр дә ишәя бармый. Табигать җырчылары кешеләр үстергән бакчаларга күчә. Әмма барыбер авыл һавасы җанга рәхәт, тәнгә сихәтле.

Самат моны тәнендәге һәр күзәнәге белән сизә. Ник дигәндә, аның тамырларында ата-бабадан килгән авыл эшчәне канының дәвамы ага. Шуңа күрә эшкә керешкәндә дә ул борынгыдан калганча, крестьянча итеп, ял-тәнәфесне, нечкәреп торуны, назланып кылануны белмичә тотына. Ат урынына эшли һәм моны бик табигый хәл дип чутлый. Хәер, Егор Кононович та шундый ук токымнан. Хезмәткә муеннан чумарга дигәндә, чуваш кардәшләргә куш. Алар бериш кешеләрнең атна буе майтарганын бер тәүлектә очлап куючан халык...

Әнә офык итәкләрен алсуландырып, моң гына булып кояш батып килә, кичке салкын төшәргә итә. Юк, салкын да түгел әле ул, җирнең кинәнеп сулавы.

Самат хуҗа әбекәйнең иртәдән үк ташып куйган һәм көне буена кояшта торып җылынган йомшак суы белән ләззәтләнеп, илаһи бер тәм табып, пошкырына-пошкырына юынды.

— Үрдәк кебек, син, әй! — Егор юынып алган, хезмәттәшенә кызыгып карап тора иде.

— Һе, ни гаҗәбе бар? Әйтмәсәм дә әйтим, мин бит Зөя буенда үскән малай. Елгадан кайтып керми идек. Ат сугару дисеңме, балык каптырумы, һай-һаулап, бер-беребезне суга ташлый-ташлый көймәдә йөзүме! Без малай чакта Зөя тирән иде, күпердән сикерә идек. Ат йөзәрлек булгач инде! Хәзер генә балак та сызганмыйча аркылы чыгалар...

Юынып-сөртенеп өлгергән Ильяс сорап куйды.

— Сезнең авыл моннан әллә ни ерак та түгел бугай бит, Самат абый?

— Ерак диясе юк. Буага моннан, ну, кырык километрдыр. Аннан ун-

унике. Атың яхшы булса, сигез-тугыз... Машина гасыры өчен чепуха ара...

Шул рәвешле вак-төяк сөйләшеп, әбекәйнең кичке ашы өстәлгә килгәнне көткәндә, Самат, кинәт магнит тарткан төсле, күрше ишегалдына карап, шаккатып, авыз ачып калды. Әбекәйләрдән тәбәнәк кенә койма аерып торган күрше йортның ишегалдында иңнәреннән көянтәчиләгән дә төшерергә өлгермәгән бер хатын-кыз басып тора иде.

Самат бил тиңентен ялангач килеш койма буена китте.

— Исәнмесез! — Төзүчеләр эртиле башлыгы күптәнге танышына эндәшкәндәй сәлам бирде. — Күңелем сизә: сез — Сафдилә апа кызы. Исемегез Нурсинә. Чишмәдән кайтып килүегез.

— Дөрес әйттегез. Шулай да багучы була алмыйсыз. Әүлиялегегез бик чамалы. Медпункт салырга килгән булгач, фельдшер Сафдилә апагызны бөтенләй күрми булмагансыз. Минем әни инде кызы турында сорамасалар да, сөйләргә тора.

Самат телдәрләнә бирде.

— Һөнәрегез буенча врач инде сез. Эшләвегез Казанда. Отпускыга кайттыгыз. Шунысына гына башым җитми, мин сезне Казанда ничек күргәнем юк икән?

— Эскерттән энә табар идегезме соң? Казан, ай-һай, зур бит!..

— Хак сүзгә җавап юк, Нурсинә. Чишмә суын авыз иттермәссезме? Сусаудан гаҗиз бүген. Көне... Бер генә чүмеч... Мин чишмәгә бай авыл малае. Шул суны әллә нинди шифалы эчемлекләрдән алга куям...

— Рәхим итегез... — Нурсинә мөлдерәмә чүмечне койма аша сузды.

Чүмечтә кичке шәфәкъ нурлары тонык кына чагылып киткән төсле булды. Саматның койма аръягында үзеннән кул сузымында гына торган терапевтны да, ни сәбәптәндер, шул шәфәкъкә тиңлисе килде: мөлаем да, моңсу да. Чибәрлеккә өстәлгән мөлаемлык. Каратутлы, күзләрендә ташкүмер каралыгы. («Ак матур — чак матур, кара матур — бик матур...») Керфекләре куе, ялгап ясагандай озын, әмма табигый. Кашлары! «Ничегрәк сызыйм икән?» — дип, талантлы рәссам баш ваткандыр төсле. Кыйгачның кыйгачы. Бит очларында багалма алсулыгы. Алтын алкаларының кашларына да шул алсулык күчкәндер кебек. Гади генә чәчәкле ситсы күлмәге шул кадәр килешле тегелгән, кызның бил нечкәлеген дә, күкрәкләрнең тыгыз йомрылыгын да, җилкәләренең килешле-матур булуын да аермачык күрсәтеп тора. Җәл, толым үстермәгән! Чигә бөдрәләренең күркәмлеген бермә-бер арттырыр иде. Табигатьнең тагын бер хатасы: сул як аскы казнасында кәкрерәк үскән бер теше бар. Тик ул теш кызның чибәрлегенә һичнинди зыян китерми.

Аның бу теше — бары тик аерымлык билгесе, дөньяда аңа охшаган гүзәлләр табыла икән, алардан аерып алыр өчен тамга гына дип уйлап алды Самат.

Авырулар күңелен күреп сөйләшүдән гадәтенә кергән микән, Нурсинә бик йомшак, бик ипле сөйләшә, тавышы җанга ятышлы...

Су салкыныннан ухылдап куйды Самат.

— Суым салкын, эчем ялкын дип җырлыйлармы әле? — диде ул. — Рәхмәт, Нурсинә.

— Исән булыгыз... — Врач терәлеп калды. — Исемегезне белмим.

— Самат. Самат Билалов. Озакка кайттыгызмы дип сорасам, әрсезлек димәссезме?

— Сер түгел, бер айга. Кырымга да, Кавказга да бармадым, әни янында буласым килә.

— Бик дөрес.

Шул чак Саматны ашка дәштеләр.

— Безнең егетләр адашкан. Сау булып торыгыз, Нурсинә, — дип, шаяру аралаш җитди әйтеп куйды Самат. — Керим. Күрешербездер

әле. Ара ерак, яна йөрәк, дип торасы түгел. Безгә дә кирәгез, вакыт тапсагыз...

— Үзегез рәхим итегез.

— Була ул, рәхмәт!

Кызлар белән теш агарту түгел иде, югыйсә, исәпләре. Тамакны шәпләп туйдыргач, Егор белән Самат бина салынасы урынга янә барырга сөйләштеләр («Ильяс шактый биртелде, сафтан чыгарып ташламыйк, ял итсен», — дип килештеләр). Эш шунда: сазлык киптерү участогыннан, төнлеккә дип, председатель экскаватор кайтартты. Ул электр яктысында эшләп (багана утыртып, прожектор өчен линия тарттылар), нигез базын казыячак. Төзергә алынган кешеләрнең шунда булулары кирәк тә кирәк. Анда уйдык, монда тауҹык калса, көрәк белән ерак китә алмассың.

Колхоз башлыгы сүзендә торды. Күз бәйләнер-бәйләнмәс экскаватор эшли башлады. Аның эшен карарга авылның бөтен бала-чагасы җыелган иде. Йоклар вакытлары җитеп узгач, әти-әниләре шунда эзләп килделәр.

Самат белән Егор таң сызылганда гына кайтып яттылар. Талчыгулары җиткән иде. Егор Кононович, мендәргә башы тиюгә, йоклап китте. Йоклаганны елан чакмый. Хак икән шул. Ике хезмәттәше тирән, тигез тын алып, бер тиң йоклыйлар. Ильяс нидер сөйләнеп тә алды. Ихтимал, төш күрәдер. Ә менә Самат йоклап китә алмый. Күңеленә әллә нинди уйлар килә. Кирәге дә, кирәкмәсе дә. Мең дә бер төрлесе. Дөнья кууга бәйләнгәне дә, тузга язмаганнары да.

... Малай чакта аның үз колхозлары умарталыгына барганы булды. Анда ник аяк басканына үкенеп, ак тәүбә, кара тәүбә иткән иде. Чөнки умартачы картның корт караган чагына килеп эләккән иде. Картка ни! Йөзендә битлеге, кулында төтәткече. Кортлар аны таныйлар бугай, тимиләр. Ә Самат дигән бәләкәй малайга каныктылар гына! Әүвәле берикесе бәйләнеп изалады. Малай алардан качып котылырга теләп йөгерде, кулларын бутады. Шуннан соң тагын да күбрәк ябырылдылар. Берсе чакты, аннары икенчесе... Әрнүдән, коты алынудан бәләкәй Самат дөнья тузгытып елый башлады. Чыдаша алмыйча җиргә ауды. Ярый әле, күрше бабасы төтәткече белән бик тиз килеп җитте. Әй, «ысладызы» үзен! Шуннан кортлар китте.

Малайның бите шешеп чыкты, күзләре, пәке белән сызып җибәргәндәй, ярык кына булып калды. Кул аркалары кабарып килде. Бәгыренә әрнү төште.

Умартачы карт:

— Елама, улкаем, елама! Бал корты чагуның файдасы күп, — дип юатып та карады. Файда белән зыянны аерырлык идемени ул?!

Хәзерге Самат Билалов бот буе сабый түгел. Умарталыкта чәчәләнеп еламый. Файданың ни икәнен дә төшенә, зыян-зәүрәткә юлыкмыйм дип тә җан ата...

Уй өере, көзге болыт төсле, һич тә таралмый бит. Өйдән чыгып китәр алдыннан абыйсы Морат белән бәхәсе, әнисе сүзләре, хатыны Зәмирәнең әле җәйге кояш кебек җылынып, әле кышкы тимердәй булып сөйләгәннәре... Туган авылыннан партком секретаре язган хат... Әтисенең истәлекләр дәфтәре...

Булмады, йокыга китә алмады. Песи сыман сак кына торды да өйдән алып килгән будильнигын карады. Текелди, куа минутларны, куа сәгатьләрне, гомерне... Нәкъ иртәнге өчтә шалтырарга көйләп куелган. Инде ике тулып узган. Янә ятакка барып ятты Самат. Күзләрен йомып та карады, ике йөзгә тикле санап та бакты. Юк булгач, юк! Үз җанында үзе казына, үзе эзләнә ич. Гаепләүче дә үзе, адвокат та. Әнә тагын күз алдына Зәмирә килде. Җитмәсә, бу юлы Нурсинәне дә ияртеп килгән. Икесе ике ягында. Эндәшмиләр, сынаулы, үпкәле карыйлар гына...

Шунда Самат уйларында кинәт бер ачыклык пәйда була. Зәмирә аңа гел диярлек салкын йөри, үз итми, җанын ачмый, ят саный. Аның күз карашларында Саматка үпкә, үчлелек бетеп тормый. Аңарда үзенә җитәрлек тә, кешегә бирерлек тә җан җылысы юк. Ә менә Нурсинә... Аның белән бер сөйләшү — үзе бер гомер. Аның күзләрендә ана кайгыртучанлыгы, сеңел нәфислеге һәм нәзакәтлелеге, дусларча тугрылык, синең хисеңне, уйларыңны аңлау бар кебек. Хәйләкәрлек, хөсетлек, комсызлык, явызлыкның эзе дә юк.

Аннары Саматның күңелен вөҗдан дигән прокурор биләп алды. Аның үз хакыйкате, үз фикерләре. «Син, Билалов, — ди ул, — әкәмәт уйлап куйдың әле. Зәмирә бит синең белән парга җигелеп, тормыш йөген тарта. Дөнья көтү ул урта мәктәптәге классташ кызыңның альбомына шигырь язу гына түгел. Тормыш итүнең аяз көне бар, җил-давылы бар. Исән чак бар, сырхау чак бар. Әйтеп бетергесез сөенечләре, йөрәккә кан саудыра торган кайгы-хәсрәте бар... Бәс, шулай икән, җиде кат үлчәп бер кис. Кешегә баш дуамалланыр өчен түгел, уйлар өчен бирелгән. Йөрәк дигәнеңне йөгәнли алмасаң, нинди ир-егет син? Зирәк акыллы кешеләр: «Тормыш — көрәш», дигәннәр. Көрәштә, туганкай, каш сикертеп, күз кысып, елмаеп торып кына булмый. Синең олы гөнаһың бар, шуны онытма. Зәмирәгә ни рәвешле өйләндең? Башта кул салдың, соңыннан ул сиңа чыгарга мәҗбүр булды. Зәмирә карашындагы рәнҗү дә бәлки шуннандыр... Нурсинә бәлки изгедер, ну бит әле син аны тик бер тапкыр гына күрдең... Шул хәтлесенә дә башыңны эшләт, кирәксенерме ул сине, юкмы?..»

Ул төнне Самат керфеккә керфек тә какмады. Мәгәр шуңа үкенмәде. Нурсинәнең елмаеп иртән исәнләшүе, бер-ике авыз әйтүе аның рухында ниндидер өермә кузгатты. Кабыныр-кабынмас сүнәчәк утка сәбәп булдымы ул өермә, зур ялкынның тәүге очкынын алып килдеме? Бәлки тормышта чын-чынлап үз дигәнеңне очрату шулай була торгандыр?

Самат бик еректан, томан аша гына бер нәрсәне шәйләгән төсле булды: үз намусы каршына хөкемгә баса түгелме соң?!

## 6

Язгөл өч атналык производство практикасы үтеп кайтты. Колхозда эшләделәр. Биектау районында. Мәктәп интернатында яшәделәр.

Классташлар белән булгач, бер дә алай ямансуларга туры килмәде. Көндез басуда чөгендер сирәкләделәр. Кичләрен клубка йөрделәр: кино карадылар, үзешчән сәнгать концертына катнаштылар, бригаданың стена газетасын чыгаруда булыштылар. Ә малайлар авылдагы яшьтәшләре белән футбол ярышы оештырдылар.

Боегуын, юк, боекмады Язгөл. Кояшта кызып, җилдә каралып, чыныгып, ныгып кайтты. Шулай да Казанны бик сагынды. Күрше районда гына булсаң да, сагындыра икән ул. Дәү әнисен күрергә зарыкты, әтиәнисен сагынды, Алма апасын. Тагын... тагын берәүне юксынды. Бүтәннәрен кайткач ук күрде, сөйләште, ә «берәү» ерактарак, Самат абыйсы белән. Хат язарга кыймый инде ул. Бу кадәресен Язгөл белә. Сабан туена бер генә атна калды, шунда кайтып килмәсме? Һич югы, бер генә көнгә. Ләкин Самат абыйсы кул астыннан ычкынулары, ай-һай!..

Шулай үз уйларына уралып, кичен Волгоград урамындагы иптәш кызларына барганда, ул, чүп өстенә чүмәлә дигән кебек, кирәкмәс бер очрашуга тарыды. Гастрономнан яңа гына эшен бетереп чыккан Алма апасы кибет читендә әлек алар урамында яшәгән Зиннур абыйсы белән сөйләшеп тора иде. Үзе көлә, йөзе көлә иде Алма апасының! Басып торышына кадәр үзгәреп киткән, бүтәнен әйткән дә юк. Башын югары тотып, мактанычы бар төсле сөйләшә. Бәхетле минутлар кичерәдер, күрә-

сең. Олыларның Зәмирә элек Зиннур белән яратышып йөргән дигәне Язгөлнең колагына кергәне бар иде. Бәлки чындыр ул сүз?.. Алайса, нигә өйләнешмәгәннәр?

Язгөл, аларны күрмәмешкә салышып, читтәнрәк үтмәкче иде, аның хәйләсен бик тиз абайлап алган Зәмирә үзе кычкырып туктатты.

— Язгөл, кая ашыгасың, акыллым? — диде.— Туктап кит әле, үскәнем.

Кыз ояла-ояла гына алар янына килергә мәҗбүр булды. Алга манып алгандай, кызарды, янып чыкты.

— Исәнмесез!— диде ул, олыларга күтәрелеп карамый гына.— Дус кызым янына барышым иде.

— Озак торасыңмы?

— Әйләнеп кенә чыгам.

— Алай булгач, бергә кайтырбыз. Мин сине шушында көтәрмен, яме.

— Ярый.

— Нәкъ шушы урынга кил.

Язгөлнең аякларыннан богау салдырдылармыни! Ялт борылды да ашыгып китеп барды. Күңелендә бер сорау бөтерелде: бу ни эш? Гади күрешү генәме, әллә Зиннур абыйсының эш сәгате бетүгә махсус килеп каршылавымы? Алма апасын болай көләч итеп, бәхетле итеп күрүенә ул чын күңелдән шат. Елмаюын онытмаган икән әле. Бик әйбәт! Икенче яктан караганда, Язгөл өчен һич шатланыр сәбәп юк. Әгәр дә Алма апасы аның Самат абыйсын исеннән чыгарып, бүтән берәү белән күрешүдән тәм таба икән, моны хуплап булмый инде. Абыйсына ишеттерсәләр, эти-әнисенә, дәү әнисенә ишеттерсәләр? Ишеттермәсеннәр дә, ди. Мондый очрашулар Алма апасының абруена нур өстимени? Ире бар өстеннән... Андый хатыннарны пычрак сүз белән атыйлар ич...

Язгөл әйләнеп килгәндә, Зәмирә янында Зиннур юк иде инде. Алма апасы Язгөлне култыклап алды һәм алар Хөсәен Ямашев проспекты буйлап өйләренә юнәлделәр. Әлерәк кенә Язгөлне камап алган сорауларга җавапның зур өлешен Зәмирә үзе бирде.

— Мине Зиннур белән күргәч, аптырап калдыңмы, үскәнем?— диде ул, җете зәңгәр күзләре белән Язгөл күзләренә текәлеп. Аның чәчәк таҗыдай иреннәре читенә сәер генә елмаю кунган иде. Ул үзе дә аптыраудан арынып бетмәгән иде бугай. Аптыраган көләр, йөдәгән елар дигәннәре шул була торгандыр,— Син хәйран калма. Һәрхәлдә, мин шулай киңәш итәм. Тыңла, үскәнем. Үзегезнекеләрдән кемгә дә булса сөйләгәнче...

Язгөл аның сүзен бүлде.

— Берәүгә дә бер сүз әйтмим, Алма апа. Икмәктер менә, кояштыр!..

Зәмирә аның самимилегенә, әле чыгып бетмәгән балалыгына дикъкать итте, якын итеп, үз итеп көлеп җибәрде.

— Кит, сөйләнмә алай. Комсомолка башың белән. Дәү әниең дә алай карганмас.— Аннары, тыныч булырга тырышып, аңлата башлады.— Вакыты җиткәч, көне-сәгате белән мин барсын да өйдәгеләргә үзем төшендерермен. Чын дөресен, үз телем белән. Синнән үтенечем шул: хәзергә сер сакла. Гайбәт булып ишетелмәсен. Гайбәттән дә эшәке нәрсә юк, үскәнем. Әйткәннәре бардыр, яшьлектә Зиннур абыең белән яратышып йөргән идек без. Кавыша алмадык...

Зәмирә тынып калды. Миенә эретелгән кургаш булып ямьсез хатирәләр, шыксыз уйлар тулды. Шуларның авырлыгына чыдамаган төсле, ул башын иеп атлады. Аннары, барысын бер селтәнүдә түгеп-бушатып ташларга теләгәндәй, башын чайкап алды.

— Ул һаман да өйләнмәгән, ялгызы. Әгәр минем аның белән очрашуым Саматка ишетелсә, ул мине шул төнне үк кайтып үтерәчәк...

Мин аңа тузан бөртеге кадәр дә хыянәт итәргә теләмим. Ахырынача хәл итеп, абыеңнан китәм икән, анда да әле законлы никахсыз Зиннур өенә аяк атлап кермәячәкмен. Әнием белән сеңелем янында торырмын... Ә хәзергә... башым түнгән чак, үскәнем. Ике ут арасында мин. Нишләргә дә белмим...

Алма апасының шушылай итеп җанын ярып салуы Язгөл күңеленә яшенле давыл кузгатты. Аның тыны кысылды. Тулам-түгеләм дип мөлдерәп атлый торгач, түзмәде кыз, елап җибәрде. Зәмирә дә кайнар яшьләрен эчкә йотып килә иде.

Өйгә кайтып җиттеләр. Түр бакча тәрәзәсе ачык. Шуннан карап торган Сәрбиҗиһан түтәй онытгы белән кече килененең боегышып кайтуларына имәнеп калган иде.

— Ярабби, бер-бер яман хәл бармы әллә?— Карчык, оныгын каршыларга дип, болдырга ук чыкты.— Ни булды, бәбкәм? Нигә болай бик боек кайтасыз?

Язгөл елмайгандай итте.

— Юк, дәү әни, бер ни дә юк. Гел көлеп кенә йөрмиләр лә инде...— Шулай диде дә, кызарган күзләрен яшерергә теләп, тиз генә верандага кереп китте.

— Гел көлеп кенә йөрмәгәннәрен беләм лә мин, беләм,— дип сөйләнде Сәрбиҗиһан түтәй, тирән эчле галошларын аягына кия-кия. Кече киленен күреп чыкмый торып, күңеле урынына утырмасын белә иде инде ул.— Көлке күп булса, күңел симерә, күңел карая... Эчем сизә, ул баланың эше көлүгә калмаган әле. Иртә дә моңлы, кич тә моңлы... Ни әйтерсең бит иренә дә... Әйткәнеңә карый торган бала булса икән...

Ул Зәмирә янына керде. Килене аны гадәттәгечә олылап каршылады, җылы, йомшак, ипле сөйләште. Күпне күргән анага хөрмәте һәрчак зур аның. Кайнанасының кече күңелле, кеше җанлы, гадел булуын бик ошата иде ул. Кайберәүләр үз кызларына да мондый мәрхәмәтле, миһербанлы булмыйлар. Сәрбиҗиһан түтәй йомыркадан җөй эзләүче кайнаналардан түгел.

Кыты-мыты, юкны-барны сөйләштергәләп, Сәрбиҗиһан түтәй әйтер сүзенә юл салды.

— Иртәгә смена атнаң бетә, килен-кызым,— диде ул бик җайлап кына.— Самат янына барып кайтыр идең. Аз-маз кучтәнәч илтерсең, өстен-башын карап, юасын юарсың, типчү кирәксә, типчерсең. Ике-өч көн торып кайтканнан монда бер ни дә үзгәрмәс...

— Авылга дисеңме, әнкәй?— Килене аңлап булмый торган сүз ишеткәндәй карап куйды. Карчык моны өнәмәде.

— Балыклыга дим. Ирең шунда эшләгәч. Берәү булса, бер атнадан җыенып барып кайтыр иде инде. Чаялыгың кимеп калды әле синең, килен-кызым. Безнекен учка учлап тотарга кирәк аны, кирәгендә сыйпарга, кирәгендә кысарга...

— Мин сыйпый да белмим, әнкәй, кыса да белмим... Өйрәнмәгәнмен...— Зәмирә теләр-теләмәс кенә җавап бирде һәм, баеп баручы кояшның ян тәрәзәдән төшкән нурларына карап, күзен кыса төште, ә йөзе таш төсле хәрәкәтсез һәм суык иде.

Шәфәкъ нурлары Сәрбиҗиһан түтәйнең йөзенә дә кунган һәм аның тирән җыерчыкларын каралыбрак торган җөй эзләре күрсәтәләр иде. Карчык битен сыпырып куйганда, шул җөйләрне җуярга азапланадыр кебек тоелды.

— Өйрәнергә вакыт...— Кайнана моны тыныч, мәгәр кырыс әйтеп салды.— Бармактан балдак алмашкан көннәрегез түгел. Үзеңнекен итә бел, хатыны бит син аның. Ирләрне алгы көпчәк дисәләр дә, арткы көпчәк тирән эздә булса, алгылары әллә ни иркенли алмый. Киләсе атнаны да эшләргә кушалармы соң әллә? Эштән җибәрмиләрме?

— Кая җибәрмиләрме дисең, энкәй?— Каенанасы әйткәннәр аның аңына барып җитми иде, күрәсең.

— Сөбханалла! Самат янына дип торам бит. Ирең янына...— Карчык сискәнеп калды. Ни булган бу балага? Аннары әмер тавышы белән әйтми булдыра алмады.— Җыен да барып кайт. Иртәгә тәвәккәлләп... Мин дә бераз көчтәнәч куярмын...

Төнне Зәмирә тынгысыз үткәрде. Йокысының рәте-юне булмады. Таң алдыннан гына чын-чынлап йоклап китте.

...Таң яктысы белән ай нурлары бергә кушылган илаһи минутлар. Ай зур итеп кибән башы кисеп алынган ак калачны хәтерләтә. «Мич тулы пәрәмәч, уртасында бер калач» дигән табышмак күңеленә килә, Зәмирә аны, сабый чагындагыдай, кат-кат кабатлый: «Пәрәмәчләр» исә мич тулы ук түгел инде, сирәгәеп калган. Күк йөзе урман аланына охшаш. Гүя шул аланлыктан бик мул җиләкне җыеп алганнар, икенче катка анда-санда янә җиләк пешкән. Йолдызлар — әнә шул җиләкләр...

Яктыра. Күп тә үтмәс, әнә тегеннән, көнтуар яктан утлы алтын шар тәгәрәп чыгар да акрынлап югары үрмәләр. Үләннәрдәге чык тамчылары җемелдәшер... Поселоктагы чия, шомырт, сирень, алмагач үскән бакчалар шау чәчәктә. Йортлар ак.күбеккә чумган сыман. Инде миләш тә чәчәк атарга өлгергән. Булачак тәлгәшләр әлеге аксыл, ярмаланып торган эремчек шикелле... Кемдер шул чәчәкләрнең берсен өзгән дә (нигә әрәм иткән инде, уттай янып торган тәлгәш булыр иде!) арттан Зәмирәнең муенын кытыклый. Үзен һич кенә дә көнче күбәләк санамаса да (көнче кешенең кытыгы күп була диләр бит), түзеп тора алмый, шыркылдап көлә... һәм... ул көлеп уянып китә. Барсы да төштә генә икән! Әйе, чәчәкле яз үткәнгә байтак булды шул инде. Зәмирәнең дә язы чәчәк койды... Шулай да бу якты төш аның каефен яхшы ук авыштырган иде. Күңелдәге кара болытларны таң җиле куып тараткан диярсең. Уйларына ачыклык кергән шикелле булды. Ул яшь кыз чагындагыча җитезлек белән урыныннан сикереп торды да, тиз генә өстенә халат, аякларына йомшак туфли киде. Матурлап урынын җыештырды. Караватының бер башына мендәрләрне кабартып куйды. Алар өстенә яңа яуган кар төсле каплама япты. Аннары, бер читкәрәк китеп, каплaverдагы бизәкләргә карап торды. Әйтерсең лә күңелен ничә көннән бирле изалап торган сорауга җавапны шул бизәкләр арасыннан табып алырга җыена иде.

«Самат янына барырга!»— иртүк кабул иткән карары шул булды. Тик наз эзләп тә, керен юарга да түгел. Ачыктан-ачык соңгы кат сөйләшү өчен барырга җыенды ул.

## 7

Табигатьнең кай төбәкләргә агыласы кайнар сулышы безнең якларга ябырылгандыр, ми кайнатырдай кызу көннәр торды. Кояш колга буе күтәрелү белән, җанны тыгызлап кыздыра башлый, шабыр тиргә батыра.

Төн салкынында иркен сулап өлгергән үлән-үсемлекләр көн уртасы якынлашканда шәлперәеп, шиңеп кала. Куаклар үз алларына йокымсырап, мәлҗерәп утыра. Яшеллек хаким итәр ай булса да, юл читләрендәге, койма буйларындагы үләннәргә сырхау сарысы суга. Юлларда тузан. Җып-җылы мамык тузан... Яңгыр юк та юк. Болыт та кабарып карый, югыйсә.

Көн үзәгендә батырып эшләргә тәкать-түзем калмагач, Саматлар эшкә яктыра башлау белән тотына башладылар. Иртәнге ашка сигезләрдә кайталар. Аннары янә ике-өч сәгать эшлиләр дә хуҗа әбекәйнең салкын келәтендә хәл җыялар. Көн сүрелә башлагач, төшкелекне ашап, тагын үз эшләренә керешәләр. Кич күз бәйләнгәч кенә кайталар.

Эшләре үрчи үрчүен. Ак кирпеч стеналар күзгә күренеп күтәреләэ. Карарлыгы, сүз әйтерлеге бар инде. Колхоз председателе төзүчеләр янына сугылмый калмый. Кичә байтак күзәтеп торды. Каланыкылар кулындагы мастерокларның уйнаклавына, кирпеч араларындагы җөйләрнең чисталыгына игътибар итте. «Башлыкларының эше сәнгать — прәме! Егоры да остарып җиткән. Ильясы да олылардан калышмый, кирпечкә кирпечне майлап сылагандай итә, әй! Тизлектә генә өлкәннәргә ияреп җитә алмый. «Остазың бик булган кеше, егет! Өйрәнү үзе бер һөнәр. Өйрәнгәнең җирдә ятмас...» Ул эченнән шулай уйлады, ахырында үзләренә дә әйтте:

— Булдырасыз, егетләр! Күз генә тимәсен үзегезгә!— диде.

— Тиясе күз тигән инде, Гаяз Минһаҗевич,— дигән булды Самат, мактауга әллә ни һушы китмәгән шикелле. Чынында председатель сүзләре аның җанына май булып яткан иде. Үз бәясен үзе белеп торган кеше, фикерен читтән расласалар, үсенеп китүчәнрәк бит. Мәгәр Билалов малай-шалай түгел, мактанып күкрәк киерү тойгысын авызлыклый беләэ.— Әчке яктан басмалар куяр вакыт җитте, Гаяз Минһаҗевич. Тирәкләрнең ныгын, такталарның калынын китертсәгез икән...

— Бүген китерерләр, энем.

— Пионерларыгыз бик уңган. Шуларны ике-өч кеше итеп кул арасына куйгалый торсагыз...

— Сөйләшенгән...

Көндезге ялга кайткач, юынып-чистарынып алдылар да келәт ягын карадылар. Егор Кононович, гадәтенчә, әкият сөйләргә җыенды.

— Болай булган, Ильяс браток. Бер заман Кәҗә тәкәсе, Үгез, Тәкә очрашканнар. «Кайсыбыз акыллырак?» дип спорлашып киткәннәр. Берсенең дә ахмак буласы килми. Киткәннәр Ишәк янына.

— Әйт әле, кадерле Ишәк, кайсыбыз акыллырак?— дигәннәр...

Ильяс Егор Кононовичның әкият капчыгы әледән-әле чишелә торуга күнегеп бара иде инде, үзен баласытып сөйләмәвен дә күптән аңлады, шуңа күрә бу юлы да көлеп кенә куйды.

— Монысын да китаптан укыдыңмы, Егор дәдәй?

— Китаптан.

— Нинди:рәк китап соң ул?

— Исемен әйтә алмыйм. Кыз алып кайткан иде. Зурысы, пединститутта укый торганы. Бер бик зур укытучы турында. Шуның укучылары әкият язалар икән.

— Макаренкомы?

— Юк, ул түгел.

— Сухомлинский, алайса?

— Шул булырга мужет... Я инде, тыңлап бетер.

— Шуннан, шуннан?— Ильяс бик бирелеп тыңларга әзерләнгән кыяфәттә Егор дәдәсенә карады.

— Вәт шул. Ишәк әйткән: «Үлән ник үсә?» дигән соравыма җавап бирегез, шуннан соң кем акыллырак икәнен әйтермен», дигән.

Үгез үзенчә әйткән:

— Үлән яңгыр яуганга үсә,— дигән.

Ә Кәҗә тәкәсе:

— Кояш җылытканга үсә,— дип җавап биргән.

Тәкә бер сүз дә әйтмәгән. Ишәк уйлап алган, «Әһә!— дигән. — Тәкә акыллырак. Үгез белән Кәҗә тәкәсе әйттеләр әйтүен, ну бит аларның хаталануы бар»,— дигән. Вәт нинди нәмәрсәкәйләр, Ильяс браток. Сүзсез Тәкә акыллы күренгән...

Егор әкиятен башлаганда, Самат Сафдилә апаларына кереп китте. Чишмә суы эчәргә. Салкынын, тешне сындыра торганын. Аның «сусавы» гадәткә керде. Егор белән Ильяс моны бик үк өнәмиләр. Кистереп

каршы да төшә алмыйлар. Бригадир бик үзенекен бөгүчән, кеше сүзен күтәрми.

Саматның ишек шакуына җавап булып, өй эченнән:

— Керегез!— дигән ягымлы тавыш ишетелде. Шуны ишетер өчен генә дә Самат бу бусагага көн саен әллә ничә тапкыр килеп китәргә риза иде.

— Хәерле көн, Нурсинә!

— Исәнмесез, Самат. Узыгыз. Сезгә карап, сәгать дәресләргә була, Уникенче нәкъ унбиш минут.

— Солдат чактан калган төгәллек.

Самат түрдә укып утырган Нурсинә белән сүз алышты, ә аяклары белән нык-нык басып, идәнне тикшерде.

— Эчне пошырмыйлармы инде?

— Тындылар. Сезнең кул тигәнне генә көткәннәр икән. Рәхмәт.

— Рәхмәтлек эш юк югын. Җан кыйнап шыгырдамаулары, селкенешеп тормаулары кирәк.

Бу сүзләрнең хикмәте шунда: өченче көн Самат фельдшер апасы квартирасының идән такталарын рәтләде. Баш-башларга терәк күтәртмә куйды, такталарны шуларга ныгытып беркетте. Чайкалгалап торалар, хаста карчык сыман, аяк баскан саен ыңгырашалар иде. Шул тотрыксызлык Самат күңелленә тия һәм аның үз хәлен, үзенең рухи халәтен хәтеренә төшереп тора иде. Идән такталар ныгыгач, Саматның да күңеле утырып киткәндәй булды.

Медпункт вакытлыча авыл советының бер бүлмәсендә генә урнашып торганга, дару-дәваның яртысы Сафдилә апасының үз өендә иде. Кергән саен Самат аларның латинча-русча язылган исемнәрен укый. Бүген дә ул баш чайкап торды.

— Күпме дару!— диде, аннары Нурсинәгә каерылып карап.— Таблеткаларда, шешәләрдә, пакетларда... Үләннәр, тамырлар, төнәтмәләр, майлар... Ашаганга кадәр эчәргә... Аштан соң. Йокы алдыннан... Меңнән берен эзләп табарга кирәк инде, ә? Шагыйрь иң кирәкле сүзен тапкан шикелле, композитор кирәкле нотасын, художник иң дөрес төсне тапкан төсле...

Нурсинә, күзләрен зур ачып, Саматка текәлеп торды. Каладан килгән төзүче авызыннан беренче кат ишетә иде ул мондый сүзләрне. Һич кенә дә мондый нечкәлекләрне аңлыйдыр дип уйламый иде ул аның хакында. Чапмаган да, юынмаган да бер оста дип кенә белә иде. Баксаң-торсаң, алай гына түгел икән ич! Кайчак без кешенең иң-иң катлаулы үзе бер дөнья икәнен онытып җибәрәбез шул. Чыннан да бит кешедә начарлык яки яхшылык кына түгел, аңлавы читен, ә кайчак бөтенләй мөмкин дә булмаган үтә кызык, сәер һәм катлаулы сыйфатлар, шул сыйфатларның ничәмә-ничә төрле нюанслары сыешып яши ала...

— Хәер,— дип өстәде Самат алда әйткәннәренә,— йорт салынмый, кое казылмый кала. Дәрт иткәч тә чынга ашмый калган эшләр азмы җир йөзендә?! Шигырь, көй, картинаның тумый калуы да бар. Моны искәрмиләр генә. Шулаймы, Нурсинә?

Нурсинәнең кызыксынуы арта барды. Җавап итеп бер сүз дә эндәшмәде, җаныңны эретерлек итеп елмайды гына. «Сөйлә, тыңлыйм. Син минем өчен бөтенләй яңа ягың белән ачылдың бит әле бу керүеңдә!»— ди иде аның төн карасыдай күзләре. Самат моны аңлады, әлбәттә. Тартынмыйча сүзен очлап куярга булды.

— Әгәр инде врач авыруның серенә төшенмәсә, дәвалар җаен белмәсә, эш харап. Кирәкле дару табылмаса да — каравыл! Кеше дөньядан китәчәк. Иҗат ителгән шигырь, көй, картина аның өчен юкка чыгачак...

Аннары ул, медикаментлар белән тулы шкафка таба ымлап, кырт кисеп сорады:

— Болар арасында минем авыруыма дару бар микән, Нурсинә?
— Мондый сорауга җавап бирер өчен, сезне баштанаяк тикшерергә, тәгәл диагноз куярга кирәк,— диде врач.

Самат, беткән баш беткән дигән төсле кыюланып, хәтта беркадәр кирәксез әрсезләнүгә дә бирелеп, әйтте:

— Диагноз билгеле, доктор. Әйтмәсәм дә белеп торасыз. Мин сезгә гашыйк дип әйтсәм, куып чыгармассызмы?

Нурсинә йөзендәге көләчлек әллә кай арада юкка чыкты. Ул кулындагы китабын өстәлгә куйды һәм бер читкәрәк этәрде. Килешле кыйгач кашлар сынып киткәндәй булды, күзләрендәге ташкүмер ялтыравы сүнде. Ул нидер әйтмәкче иде бугай, ләкин Самат, аның авыз ачуыннан өркеп, тизрәк үзенекен сөйләп калырга ашыкты.

— Ни дип сүгәргә җыенганыгызны беләм, Нурсинә. Өреп очырырга исәплисез. Күреп торам. Сүгегез, түзәм. Аңлагыз гына. Мин — мәхәббәт дигән нәрсәне табалмаган малай. Бөтенесен сөйләдем бит. Яшермичә, алдашмыйча...

— Мондый темага сүз алып барырлык дәрәҗәдә танышлар дип исәплибез икән, әйдә, «син» дип кенә сөйләшик әле.— Нурсинә тавышындагы нәзакәтлелек, аһәң нәфислеге дә кимеп калган иде шикелле.

— Мин бик риза.

— Синең кебек берәү, Самат, кул сәгатен тотып, остага килгән. Сәгатьче алай караган, болай караган, ләкин ватык җирен таба алмаган һәм сәгать хуҗасына: «Сез сәгатегезне заводить итәргә онытkансыз»,— дигән. Борганнар, сәгать йөреп киткән. Шуның кебек, тормышта да без кайчак үз бәлаларыбызның сәбәбен кирәкмәгән җирдән эзлибез, төп сәбәпне онытабыз. Син дә шулай, миңа калса.

— Мин семья тормышым юклыгының сәбәбен артыгы белән беләм шул, Нурсинә. Артыгы белән, терсәк кенә ерак...

— Үз гаебең. Син ул гонаһыңнан беркайчан да арына да алмаячаксың. Сине кем ярлыкасын?! Язмыш ирониясеннән начар юл юк. Яшьлегеңдә үзеңне «Галиябану»дагы Исмәгыйль кебек тоткансың.

— Алай чагыштырма, Нурсинә. Исмәгыйль белән без икебез ике заман кешеләре.

— Каныңда Исмәгыйльләр холкы тәэсире бар.

— Мин байлык белән алдырырга маташмадым, байлыгым юк иде.

— Кыз баланың чиксез байлыгына — намусына кул яккансың. Аңа тәти товар итеп карагансың. Чын яратуның «ч» хәрефе дә булмаган синдә. Мин-минлегеңне итәсең килгән...

— Монысы хак. Ахмаклыкның төбендә шул ята...

Бу минутларда аның вөҗдан газабы акрын-акрын көчәя, үзенен үткен тырнакларын Самат йөрәгенә тирәнрәк батыра бара иде.

Сүзләре шунда өзелеп калды. Гадәттәгедән бераз иртәләп, Сафдилә әбәдкә кайтты.

— Райүзәккә барып киләсе була,— дип аңлатты ул вакытсызрак кайтып керүенең сәбәбен. Яшьләр кыенсынмасыннар дию булгандыр инде.

Нурсинә белән Самат китаплар турында гәп куертып алдылар. Врач Купринның «Гранат беләзек» повестен укый иде.

— Авызымдагы языгым,— диде Самат.— Надантыгымны яшерә алмыйм, укыганым юк бу әсәрне.

— Ә укырга кирәк иде...— Нурсинә моны шундый серле итеп әйтте, Самат аптырап калды. Аннары:

— Үзегез... үзең укып бетергәч тә миңа биреп торсаң, укыр идем, билгеле,— диде. Аны озата чыккан Нурсинә җитди кисәтүне тиеш санады.

— Бүген сөйләшкәннәргә кабат кайтмыйк, Самат. Бу — минем үте-

нечем... Тормышта мәгънәсезлек эшләүдән сак булу сиңа да, миңа да бик, бик кирәк,— диде.
Авызына сукса, җиңелрәк булыр иде. Самат, нахакка җәберләнгән кеше төсле, карашын аяк астыннан күтәрмичә хуҗа әбекәйнең келәтенә кереп ауды.
Берсе дә йокламый иде, тик берсе дә сүз кузгатмады. Күңел җәберләгеч бу тынлыктан котылырга сылтау табып, иң әүвәле Егор торды.
— Хозяйканың иң бәләкәй оныгына бишек ясап бетерәсем бар,— дигән булды Егор Кононович.— Истәлегем булыр, тирбәлсен әле бер сабый җан! Зрә дә зур кеше булып үсәргә мужет пацан. Космонавт булып, галим... Шунда әйтер, мин дияр, Егор Кононович Стрельцов ясаган бишектә үстем дияр... Бизәкләр кисәсем бар...
Ильяс та торып утырды. Каймактай ак тешләрен күрсәтеп елмая торган бу егетнең йөзен канәгатьсезлек галәмәте баскан иде. Әбисенә хәтере калган нәни бала кебек турсайган, тиз генә язылмаслык үпкәсе барлыгы сизелеп тора иде. Башта ул үзен-үзе рәхимсез сукте: «Егор дәдә сөйләгән Тәкә мин... Сүзсез Тәкә Ишәккә акыллырак күренгән... Җитәр, акыллы да, күндәм дә күренәсем килми. Икейөзлеләнү укшыта башлады...» Аннары ул мөмкин кадәр өлкәннәрчә итеп Саматка эндәште.
— Йоклап китмәдеңме, Самат абый?
— Юк, нигә?
— Сиңа сүзем бар.
— Сөйлә. Аның өчен дә гариза язып сорыйсы түгелдер бит?
— Син тыңлап бетер только, яме?
— Сайра, әйдә, сайра.
— Самат абый, син нигә дип һаман Нурсинә апа янында бөтереләсең? Килешми бер дә. Казанда хатының бар... Зәмирә апага ишетелсә, ул ни әйтер?
— Каян ишетә ди ул аны? Нәрсәсен ишетә?
— Мин кайтып сөйләсәм?
Самат йөзтүбән яткан җиреннән чалкан әйләнде дә, башын аз гына күтәреп, Ильяска карады.
— Юк, энекәш. Син мине сатып йөрмәссең. Сата алмыйсың. Хакың юк!
Хак-хокук мәсьәләсендә шул тикле кимсетеп ташлагач, Ильяс барып тешләшер дәрәҗәгә җитеп гарьләнде. Гадәттә сүзен сатып алып кына сөйләшүче егет ярсынып, кызып китте.
— Кем кискән минем хакымны? Синме? Акча эшләргә ияртеп килдем дип, хокукымны тартып алмакчы буласыңмы? Юк, Самат абый, мин тырнак белән сыта торган кандала түгел! Мин...
Шулай диде дә Ильяс терәлеп калды, гүя тончыкты. Чынлап карaганда, нәрсә «Мин»? Кем ул? Азак килеп, Саматның ике җилкәсендә бер башы бар. Кашың кара, күзең кара, үз җаеңны үзен кара дигәндәй, ул Ильяс белән чагыштырганда күбрәк яшәгән кеше. Нишләгәненә хисап бирә булыр. Бирә микән соң? Бирсә, шулай итәр идемени?! Өйдә аны көтеп торучы хатыны бар лабаса...
Егет тотлыгып калгач, Самат бастырып кына әйтеп салды:
— Мин... мин... Яшел кыяк әле син, белдеңме? Хокук дауларга остарсаң, дүрт ягың кыйбла. Минем сине богаулап куйганым юк. Бүген үк кайтып китә аласың. Эшләгән кадәреңне кесәңә сал да бигайбә! Зәмирәгә нидер лыгырдый калсаң, муеныңны борырмын. Вакыты җиткәч, тылмачсыз да барысын белер...
Ильяс бүтән каршы эндәшмәде. Саматның куып кайтаруыннан курыкты. Мотоцикллы булам дип, хезмәткә чыгып кит тә буш кул белән кайтып керме? Әтисе ни дияр? Язгөл алдында сынату ни хурлык! Ә шулай да Самат абыйсы хаксыз. Холкы авыр. Каты кеше...

Кичке якта Казанга товарга баручы машина очрагач, Саматның шәһәргә кайтып килү нияте кузгалды. Шофер белән килешеп, иске медпункт түбәсеннән төшерелгән калайларны төяделәр дә юлга җыендылар. Түбән Осланга кереп, калайны бакчачыларның берәрсенә сылап калдыру хакында да сөйләшенде.

— Иртәгә әбәттән дә калмый килеп җитәм, сүлпәнләнмәгез,— диде ул Егор белән Ильяска.—Сез сабан туена кайтырсыз, бөтен бер тәүлеккә.— Үзе шул чак бая Ильяска артык каты бәрелдем бугай дип уйлап алды һәм, гафу сораган сыман, шаяртты.— Сеңелгә сәлам әйтимме соң, Ильяс?

Ильясның ак тешләре җемелдәште.

— Әйт, Самат абый. Күп сәлам диген...

Машинаның моторы эшләп тора. Кабинага кереп утырасы да, тизлеккә салып, кузгаласы гына. Тик Самат, күкәй салырга оя тапмаган тавык кебек, әйләнде дә тулганды. Нурсинәне күреп, шәһәргә китүен әйтәсе килә иде аның. Алай гына да түгел, көндез үзелә язган җепне ныгытып ялгарга талпына иде. Теләге булгач, чарасы табылды тагын. Өченче көн, бик дустанә сөйләшкәндә, Нурсинәгә әтисенең истәлекләрен укытырга вәгъдә иткән иде ич. Шуларны кертү хәйләсе ишеккә ачкыч була ала бит әле...



## 8

Зәмирә поездда ук Балыклыдан бер хатынны очратты. Юлдашы аны тынычландырып куйды: «Тимер юл станциясендә безнең якка кайтучы машина булмый калмый, хафаланасы юк»,— диде.

Сүз йомгагы бер сүтелә башладымы, тәгәрәпме-тәгәри инде. Чирек сәгать дигәндә, Зәмирә Балыклы хатынының медпунктта җыештыручы икәнен белергә дә өлгерде, яңа салына торган медпунктның ниндирәк буласыннан да, кемнәр төзегәнлегеннән дә хәбәрдар иде инде. Сәфәрдәшенә үзенең Самат Билалов хатыны икәнен әйткәч, җыештыручы хатын әч серен чынаяклап түгел, чиләкләп түкте.

— И-и-и, җанкисәгем лә, бәгырькәем лә,— дип өзгәләнде ул.— Иделгә таянма, иргә ышанма дигәнне аңлаганың юкмыни әле синең бу фани дөньяда? Ирең фельдшерыбызның кызы белән чуала бит! Чүкердәшмәгән көннәре, серләшмәгән кичләре юк. Күрерсең әле, үз күзләрең белән күрерсең... Ирең фатир тора торган йортның күршесендә генә тегесе дә.

Зәмирә эндәшмәде, тыңлап кына барды, телен йотты диярсең. Ил авызы капчык түгел, кысып бәйли алмассың. Бу тутинең дә хакны сөйләве дә бар, нахагын кушуы да бик мөмкин... Шулай да бу хәбәр Зәмирәне башта кайнап торган су чанына чумырып алгандай итте.

Башын бер якка борып, вагон тәрәзәсеннән карап барырга мәҗбүр булгач, аңа юл буендагы телеграф баганалары җиргә авалар төсле күренде. Кызу, коры җәй ашыктырганга, сары төс җыя башлаган иген басулары да Зәмирә күңеледәй шом катыш өметсезлек белән дулкынлана-чайкала иде.

Балыклы хатыны, теле кычытуга гаҗиз булып, кирәкмәсне тыкылдап ташлавын чамаладымы, шактый гына араны сөйләшми барды. Соңыннан сөйләгән сүз дә кибеттәге сатин-ефәк, савыт-саба, кульяулык-сөлге хакында иде.

Минутлар узды, сәгать үтте. Зәмирәнең уй агышы да акрын-акрын үзгәрде: «Әгәр бу апа чын дөресен сөйләсә дә, азак килеп, мин ни җуям?! Үзем башлап араны өзәргә дип барам лабаса!»

Вагон эче яктырып киткән шикелле булды. Поездның юлы борылдымы, тәрәзәгә кояш карады. Борылышта тепловоз да тизләгән кимет-

те, күрәсең, телеграф баганалары баягыча аумыйлар, сәлам биреп кенә калалар иде...

Кыскасы, Зәмирә көнне бер болытлап, бер аязып барды.

Алар авылга кайтып кергәндә, Саматлар машинасы артыннан күтәрелгән тузан да басылып өлгермәгән иде диярлек. Бик аздан гына аймылыштылар.

Хуҗа карчык, тирә-күршеләрнең берәрсенә кергән булгандыр, өйдә юк иде. Ишеккә йозак та элмәгән, чыра гына кыстырып калдырган.

Зәмирә күчтәнәчләр салган сумкасын баскычка куйды, йортны күздән уздырды. Ир-атсыз хуҗалыкка охшап торганын абайлады. Ул үзе дә Савиновода шундыйрак йортта үсте. Әтиләре күптән вафат, ир туганнары юк иде. Гомер дигәнең агымсу, өйләрен сүткәнгә дә ике ел. Әнисе белән сеңелесенә биш катлы ташпулаттан квартира бирделәр...

Озаклады йорт хуҗасы. Бәлки Саматларның эшләгән җиренә барыргадыр?

Ул капка төбенә чыкты. Уң як күршеләрнең урам эскәмиясендә бер хатын-кыз утыра иде. Зәмирә шуның янына атлады.

— Исәнмесез!— дип сәлам бирде.

— Хәерле кич!— дип җавап кайтарды нидер укып утырган күрше.

— Медпунктны кай тирәдә төзиләр?

— Якын гына. Тыкрыктан борылгач та... Сез Самат янына килдегезме?— Нindidер эчке бер тоем Нурсинәгә каладан килеп төшкән ханымның Зәмирә икәнен әйтте. Ә Зәмирә шундук Нурсинәне чамалап алды. «Шул. Юлдаш хатын нәкъ шуның турында сөйләгән... Аннары Зәмирә тегенең кулындагы дәфтәргә игътибар итте, әйе, кайнатасының истәлекләр дәфтәре, үзенә күрә елъязмасы. Димәк, Самат аны үзе алып килгән һәм бу кешегә укырга биргән. Тиктомалдан гына нәсел-нәсәбенең серен чишеп йөри торганнардан түгел, араларында якынлык чыннан да булырга тиеш боларның...»

Зәмирә чәбәләнгән уй киләбен язып та өлгермәде, Нурсинә аңа көтелмәгән хәбәр ирештерде.

— Самат Казанга кайтып китте. Әле генә. Унбиш-егерме минут элек. Ильяс белән Егор Кононович эштә...

— Сез һәммәсен белеп торасыз икән.

— Күршеләр бит... Утырыгыз. Юл килеп арыгансыз.

— Рәхмәт. Миңа кайбер нәрсәләрне генә калдырырга иде. Китәрмен дим.

— Төнгә каршымы? Алай эшләү кирәкмәс. Самат иртәгә төш чагыннан да кичекми кайтам диде шикелле. Шулайрак ишеттем.

— Алай икән...

Зәмирә шәһәрдән килгән төзүчеләрнең кайчан ни эшләячәкләрен сәгате-минутына кадәр белеп торган чибәр күршегә текәлеп карады. Ул аның ялтыр кара күзләрендә аңлавы кыен булган нindidер көч барлыгын тойды һәм үзенең шул көчкә бирешә баруның кискен гарьлеген кичерде. Әнә шул көч алдында югала барган саен аны камап торучы, ихтыяр ныклыгыннан мәхрүм итүче газап көчәя генә иде. Зәмирә тиресенә сыймый башлады.

— Күрәм, Казанныкылар белән серегез бик килешә сезнең.

— Сөйләшми тормыйбыз. Телсезләр түгел бит. Алар да үзара аңлашалар.— Нурсинә бик тыныч кына җавап бирде. Аның сабырлыгы Зәмирәнең җенен чыгара иде.

— Мәхәббәт турында да гәпләшкәнгә охшыйсыз...

Нурсинә кулындагы дәфтәрләрне эскәмиягә куйды да торып басты, күлмәген сыпыргалап җибәрде.

— Гайбәт тыңларга өлгергәнсез, Зәмирә. Сизелеп тора. Әйтим, без Самат белән ул темага да сөйләшмәдек түгел.

— Минем яманатымны саткансыздыр.

Врач, уң кулын салмак кына күтәреп, сабыр итче дигән хәрәкәт ясады, Зәмирәнең сүзен бүлде.

— Юк, сатмадык. Белмәгән кеше хакында яман сүз сөйләүне мин түбәнчелек дип саныйм. Ә менә чын-чынлап семья тормышыгыз юклыкны Саматның әйткәне булды. Үзегезне күреп, авызыгыздан сүз ишеткәч, аның ул сүзләренә ышандым. Гаеп таягының юан башы ирегезгә төшәдер дип беләм...

Зәмирәнең күңеле тәмам тулышты. Җир астыннан калкып чыккандай, каршысында пәйда булган бу врач алдында сыгылып төшмәскә тырышу гына аны балавыз сыгудан тыеп торды.

— Хатыны барын белә торып, җан сердәшенә әйләнә алгансыз икән, әйтерсез Саматка... Зәмирә синең белән араны бөтенләйгә өзәргә килгән иде диярсез. Бөтенләйгә! Аңладыгызмы?— Аның тавышы карлыгып чыкты, нервылану үзенекен итә иде.— Мин китәм аңардан. Бүген үк китәм...

Каладан килгән яшь хатынның бу чама кайнарлануына врач булган врач та сәерсенде. Ләкин ул югалып калмады. Бу дәрәҗә тузынган кешеләрне генә күргәне бар иде. Һаман да тыныч, тигез тавыш белән сөйли бирде.

— Сез ультиматумыгызны язып калдыра аласыз. Һич югында, үзе белән бергә эшләүчеләр аша ирештерегез. Мине илче итмәгез. Андый дипломатиягә сәләтле түгелмен. Ә төнгә каршы юлга ялгыз кузгалырга киңәш итмәс идем,— диде.

Зәмирә, йөрәгенә чыдаша алмыйча, дырыс-дырыс басып, тыкрыкка таба китте.

Нурсинә өйгә керде, ут алды. Диванга аякларын бөкләп менеп утырды да укуын дәвам итәргә ниятләде. Ләкин барып чыкмады. Күзләре дәфтәр юлларын кат-кат капшый, анда теземгән юлларның мәгънәсе аңына барып җитми иде. «Ичмаса, әни райүзәктән тизрәк кайтсын иде!»— дип ачыргаланды.

Егор Кононович Зәмирәне бик хөрмәтләп, якын итеп каршылады. Ильяска калса, ул кунак кабул итүдән битәр, Казаннан килеп төшкән күрше апасын күрү сөенеченнән канатланды. Шәһәрне никадәр сагынып өлгергәнлеге шуннан аңлашыла иде.

Куанычлы сүзләргә генә озак дәвам итү насыйп түгел икән. Зәмирә үзенең бүген үк, хәзер үк китәргә тиешлеген кире каккысыз итеп әйтте. Җәяүләп булса да Ильясның озата баруын ялварып сорады.

— Мин культура йорты директоры янына барып килим әле. Фәннур абый янына,— диде Ильяс.— Мотоциклын биреп тормасмы? Дуслык юк түгел иде түгелен...— Аның моңа чаклы бер мәртәбә Фәннур мотоциклында йөреп караганы бар иде инде.

Юлы уңды егетнең. Ул Зәмирәне Каратун станциясенә төнге поездга илтә китте.

Барганда ым кагып сөйләшүдән узмадылар. Бердән, машина бик тиз элдерә, җил чыгарып бара. Әйткән сүзеңне шул җил ала да китә, күршеңне рәтле-юньле ишетер хәл юк. Икенчедән, авызга-борынга тузан тула. Юл начар урыннарда тизлекне киметтең яки туктап калдыңмы, үзең туздырган тузан өермәсе өстеңә ябырыла.

Станциягә җиткәч, кагына-кагына аптырап беттеләр.

Аннары Ильяс тиз генә кире борылырга ашыкты. Тик Зәмирәнең аны җибәрәсе килми иде. «Азрак тор инде, минем ялгызыма күңелсез бит»,— диде ул. Үзе, Саматның ниләр кылануын белергә теләп, сораулар бирә торды. Күрше абыйсы тарафыннан бик каты кисәтелгән егет ачылып төшмәде. Нурсинә белән Саматның мөнәсәбәтен күршеләрчә дип аңлатты. Хәер, шуннан артыгын ни әйтә ала иде соң Ильяс?!

Зәмирә алай уйлап бакты, болай үлчәп карады һәм Саматка язу калдырырга кирәк дигән карарга килде.

— Хат кисәге язганчы гына көт тә, үскәнем, аннары китәрсең,— диде Ильяска, сумкасындагы эчке ян кесәдән кәгазь-карандаш алып. «Шушы ак кәгазьгә үз кулым белән үземә хөкем карары язам,— дип фикер йөртте ул.— Нишлим? Башка бер чарам да юк. Самат белән яшәп кала алмыйм. Мондый корбанның икебезгә дә кирәге юк дип беләм, мәгънәсе булмасына ышанам. Аны да, үземне дә алдап көн итәсем килми. Түземем бетте. Бәлки... бәлки Зиннур белән яңа көн туар. Аның бәгыре таш түгел. Сүзләре чын булыр дип өметләнәм. Риялана белми торган иде...»

Дәфтәр битенә борчак-борчак хәрефләрдән мондый җөмләләр тезелде:

«Самат! Күзгә-күз карашып соңгы мәртәбә сөйләшергә дип килгән идем. Калага кайтып киткәнсең. Бөтенләйгә аерылышуның башы юллар аймылыннан булды.

Мин синнән китәм. Бүген үк. Йорттан үз кием-салымымны гына алам. Шырпыңа да кагылмыйм, тыныч бул. Алда бәхетем бар икән, калганы барысы да табылыр.

Әлегә әниләргә кайтам. Синнән гозерләп сорыйм, әни квартирасына да, эшкә дә килеп йөрмә. Зинһар өчен дип әйтәм.

Судлашып йөрергә дә теләмим. Менә шушы язуны аерылырга (документ өчен) ризалыгым дип сана. Бик кирәгем чыга калса, судья үземне генә чакыртып сөйләшер дип беләм.

Зәмирә».

Ильяс утырган мотоциклның кызыл уты күздән югалганчы карап торды Зәмирә. Җил уйнатып чабучы бу машина җанының бер кисәген умырып киткән төсле булды.

## 9

Сәрбиҗиһан түти кунак-төшем булырын алдан ук юрап куйган иде, ләкин Самат кайтып килер, Зәмирә аны очрата алмас дип башына да китермәгән иде.

Улының хәлләрен ана бәйнә-бәйнә сорашты: ниндирәк җиргә фатир кергәннәр, ашау-эчү җәһәтеннән хәлләре ничек, көннәр аяусыз кызу тора, эшләре авыр түгелме? Эченнән генә искәреп куйды, ябыгып, суырылып калган кече улы. Эшкә тотындымы, дуамалланып эшли. Кешегә дә аяу юк, үзен дә кайгырта белми.

Аннары җайлап кына сүзне киленгә күчерде.

— Кешегә әйтеп торып яздырасың юк, кош теледәй генә хат җибәрсәң дә артык булмас иде. Ул бит, син чыгып киткәч, иртә ялгыз башы, кич ялгыз башы. Дөньялардан үткән кебек йөри. Каңгырып көн үткәзә. Минем юату — тәк юату инде ул, ирнең юатуы — шәп юату.

Боларның барчасын Самат сабырлык белән тыңлады. Мәгәр әнисе карчык:

— Быелдан ары читкә чыгып эшләп йөрмәссең инде, улым. Син хезмәткә чытырдап ябышасың да һәммәсен онытасың, безнең күңел гел генә сызып тора,— дигәч, түземе төкәнә язды.

— Кәшәкә уйнап, шар сугып йөрмим, әнкәй! Һаман бер нарат сагызын чәйнәмәгез әле,— дип йон кабартты. Сәрбиҗиһан түтәй Кушкаеннан колхоз председателе килеп китүен, әтисенең кәгазьләрен бик үтенеп соравын әйткәч, изге эшкә кирәк икән, бирми дә булмас дигәч, Саматның холык пәриләре барысы да берьюлы аягүрә басты.

— Тотсыннар капчыкларын!— дип кырт кисте.

— Аерым битләрен карточкага төшереп алыр идек, ди ул, балам. Музейга күчермәсен куярга, ди.

— Әйтмәсәм дә әйтим, әнкәй, чишендереп, шәп-шәрә килеш бер күрсәткәч, ояты-кыяты беткән кебек була инде ул... Алар кулына тоттырып җибәргәч...

Сәрбиҗиһан түтәйнең теге вакыттагы аяк терәп торуы юкка чыккан, бүген бөтенләй үзгәне сөйли иде.

— Авылдашлар хакы бар, алар алдында йөз аклыгы дигән нәрсә бар, улым. Әткәң исән булса, ул музейны үзе башлап ясашыр иде.

— Авылдашлар!— Самат үзалдына үртәлә башлады.— Ач тамакны тук итәләрме алар, ялангач тәнгә кием киертәләрме? Председатель белән абый агарткannar сине, менә шул! Алар вәгазенә мәлҗерәп төшкәнсең.

Әнисе дә, тавышын эчкәредән алып, сынын катырак тотарга исәпләде.

— Ник дип әле син чәй янында, ризык алдында әнкәң белән ызгышасың?— диде Сәрбиҗиһан түтәй, улының каршысына ук килеп.— Хак сүз сөйләп торалар икән, ул синең башыңа да бер керергә тиеш... Без ул дәфтәрләрне тапмадык, алып киттеңме?

— Алып киттем.

— Икенче кайтуыңда тота кайт.

— Уйлап карармын.

— Аршинга куеп та, бизмәнгә салып та үлчисе юк. Кайтар. Ике сүз итмә. Аларга мин хуҗа, бик беләсең килсә...

— Таптың даулашырлык мирас...

Шуннан артыгын тәмсезләнмәделәр. Абыйсын күрергә дип, Язгөл керде.

Саматның исәбе акыллы булып, буй җитеп килүче сеңелесе белән матур итеп сөйләшергә иде, югыйсә, тик менә кәефе кырылды. Серкәсенә су тамганын Язгөлгә сиздермәскә тырышса да, «Имин эшлибез. Сау-сәламәтләр. Сәлам әйттеләр» дию белән генә чикләнүе үк яшь кызны сагайта калды. Өйдә ниндидер тартышлы сүз булганын ул шундук аңлады. Язгөлнең җылы сүз, әйбәт хәбәр өметләнүен тоеп торганга, Самат беравыктан әйтте әйтүен:

— Егор Кононович белән Ильяс киләсе шимбәгә кайталар,— диде. Дәү әнисе алдында кызый кыенсынмасын дип, Егор исемен юри алдап атады.

Аннары Самат юлга җыенды. Зәмирәнең авылда үзен көтеп торачагына шик-шөбһәсе юк иде аның.

— Абыйны күрә алмадым инде, хәерле булсын, миңа дизель-поездан калырга ярамый. Вакытның сәгате түгел, минуты кадерле чак,— диде ул, киенә-киенә. Шуңа ялгап Сәрбиҗиһан түтәй әйтте:

— Әле генә сөйләшкән әйбер хакында Моратның да үе минеке белән бер...

Самат саубуллашып чыгып киткәч, Язгөл аны кызганып калды: «Берни дә белмисең бит син, абый...»

Балыклыга әйләнеп килгәч, Самат башына күсәк белән тондырылган кеше хәлендә калды. Зәмирәнең кыска гына хаты аны катлы-катлы итеп, озын-озак уйланырга мәҗбүр итте: «Миңа килүе мәҗбүри икән, бер карыш та читкә тайпыла алмас дип хаталандым булып чыгамы? «Мин синнән китәм. Бүген үк». Бер көндә, бер атна яки ай эчендә генә туган карар түгел бу, түгел! Батыр сөйләшә, тәвәккәл сөйләшә. Таянычы бар, димәк. Тылы нык. Инде шикләнергә җир калмады, берниге дә карамастан, Зиннур белән элемтәсен өзми яшәгән... «Йорттан үз киемсалымымны гына алам. Шырпыңа да кагылмыйм, тыныч бул».

Турысын әйткәндә, мондый дәгъвасызлык баштарак Саматның аңына сыймады. Ничек була инде ул буш кул белән аерылып китү?

Бераздан ул Зәмирәнең бу сүзләренә шатланды кебек. Самат өчен бик яхшы эшли ич хатыны! Югыйсә, азмы дөньяда ирләрен бөлдереп

киткән хатыннар? Азмы мал-мөлкәттән өлештә мине рәнҗетмәгез дип, ут-ялкын чәчә-чәчә, судьяларны якадан алучы Зәһәрбикәләр? Балыкны сөзешү авыр түгел, бүлешү авыр диләр бит. Хакыйкатьнең күзенә туптуры карасаң, Зәмирә дә өч ел гомердә Самат йорты өчен аз «сөзешмәде» ич. Ә өлеш бар җирдә үлеш бар. Зәмирә бүлешергә дә, үлешергә дә теләми. Үз ихтыяры белән баш тарта. Соң бу тиклесе бит... бу тиклесе — кешене мал-байлыктан өстен итә торган бүтән бер көч, башка бер этәргеч бар дигән сүз. Нәрсә ул? Нинди тылсым, нинди могҗиза? Зәмирәнең Зиннурга, Зиннурның Зәмирәгә яшьтән уянган мәхәббәт дәртеме? Бүленгән тавыктан бүленмәгән күкәй артык... Бәхетне бүленмәс, вакланмас яратышуда күрәмени соң аның хатыны? «Алда бәхетем бар икән, калганы барысы да табылыр» дигәне шуны раслый ич инде, шуны!

Хатны кат-кат укый торгач, Саматның җанын әлегәчә бер вакытта да күңеленә килеп карамаган уй кимерә башлады: «Мал бүлешүдән баш тартуы белән Зәмирә мине кимсетә түгелме соң? Ир булган ире өстеннән югары торганын күрсәтмәкче буламы? Әллә соң мин, чынлап та, дөнья куам дип, артыгын бөгеп ташладыммы? Кайда соң аның чик баганасы? Кирәк кадәр дигәне күпме? Артыгын җыю кайдан башлана? Мәхәббәтне, үзеңә ышанычны үз хәнҗәрең белән суюданмы? Әллә иртәрәк тәме?..

Шәһәрдән көн кичке якка авышкач кына килгән иде. Караңгы капканчы өч-дүрт сәгать кенә эшләде. Ләкин эше шеш булып чыкты, тузан бөртеге кадәр дә канәгатьләнү тапмады. Я кирпече төшеп китеп ватылды, я измәсе бүлтәеп чыкты, бүгенге соңгы рәт дип тезгәннәре эчкәрәк тартылган булып чыкты. Ярсынып китеп, аларны кире кубарды, салынган измәләрен кырып ни гомер үткәрде, тигезләп янә өйде. Ахырдан чыдамы төкәнеп, кат-кат эшләргә туры килгәнгә җене кубып, тузлы-борычлы сүгенде. Кулдан эш төшү шулай була икән!..

Самат кичке чәйгә бөтенләй утырмады, келәткә чыгып ятты. Йоклар нияттән түгел, билгеле. Йөрәгенә түзә алмыйча, үзенә урын тапмаудан интегеп. Транзисторлы радиоалгычын кабызды. Мәскәү концерт бирә иде. Сергей Томинның «Молодо-зелено»сын башкардылар, аннары Александра Пахмутованың «Гайдар шагает впереди» җырын тапшырдылар. Соңгысына ул аеруча дикъкать итте. Җырчы Тимурларны, чын геройларны мактап җырлады, дуслыкны, тугрылыкны данлады, яхшы китапларны югары бәяләде, кеше бәхетен зурлады... Гайдар алдан бара, уң флангта. Җыр башлаучы. Барабаннар каккан тавышка җиңел, тукталусыз атлый. Күңелсезлекне, йомыклыкны, шәп-шәрә исәп-хисап белән гомер итүне, тук гамьсезлекне, дүрт дивар арасына җыеп тутырган зиннәтле эбер-чеберне өреп очырырдай булып атлый. Адымнары нык, ышанычлы...

Ни булды соң әле тагын Саматка? Җыр дигән нәмәрсәкәй сыкраган йөрәгенә нурлы канат очын тидереп узды да, аңа оят булып киттеме? Нилектән? Семьясы пыран-заран килүдәнме? Каныңдагы һәм җаныңдагы ваклыклар, ябышып ятарга кирәкмәгән юк-бар өченме?

Ул сикереп торды да, киенеп-ясанып, Нурсинәләргә кереп китте. Аңласа, Нурсинә генә аңлар аны бүген. Егор белән сөйләшүдән мәгънә юк. Ул хатыны белән чүкердәшеп яши, бүген генә гашыйк булганнар диярсең. Өч кыз үстерә. Җанын телем-телем кисеп балаларына өләшергә әзер. Ильяс белән ни гәпләшәсең? Гөмбә шалкан әле ул егеткә...

Шактый сагаеп керсә дә, Нурсинә аны җылы каршылады, тик Зәмирәнең килгәне, үзе белән төрпе сөйләшүе турында ләм-мим әйтмәде. Самат бу хакта әңгәмәне үзе башлады. Рәнҗүен, гарьлеген, кимсетелүен җиңәсе ансат түгел иде аңа, җәза иде, ләкин сөйләми дә булдыра алмый, эченә җыеп торса, кату чыгасы иде.

— Хатыны йөз чөергән бәндәне күрәсең килсә, миңа кара... — Ул шаярып бакты. Исе китмәгәнчәрәк елмаерга тырышып карады, артистлыгы җитмәде. Фаҗигасе йөзенә чыккан иде. — Менә моны укы. Минем бүгеннән буйдак икәнемә ышанырсың. — Зәмирә хаты Нурсинә кулына күчте.

Врач хатны бик тиз кире бирде.

— Минем белән булган сөйләшүнең конспекты, — диде.

— Күрешеп сөйләштегезмени?

— Сөйләштек, Самат. Һәм үпкәләмә, дөресен әйтим, акылсыз хатын түгел ул. Тирән нәтиҗә ясарга җыенмыйм, анлык мәгълүматым да, компетенциям дә юк. Шуны гына әйтә алам: сез икегез ике караш кешеләре булгансыз. Ахмакларча туган трагедия генә сезне вакытлыча җилемләп торган. Әйе, әйе...

Самат юан бармаклары белән өстәлгә барабан сугып алды, уңайсызланып кына Нурсинәгә карады һәм:

— Буласы булган, буявы уңган инде, — дип күрсенде. Уфтануын белдермәскә тырышуы юкка гына иде, көрсенде, авыр сулады. Нурсинә аның күңеле каты яралы икәнен белә торып, һич тә качышлы уйнамастан, фикерен очлауны кирәк санады.

— Үткән эшкә салават дию генә аз. Сабак алырга кирәк. Мин үземне кемгәдер акыл өйрәтергә хаклы кеше дип санамыйм, шулай да бу очракта ни уйлаганымны әйтми кала алмыйм.

Самат курку катыш өмет белән аңа кабат йотлыгып текәлде.

— Аңлап өлгерә алганымча, Самат, син дөньядан сыгып алырга мөмкин булганның барысын да сыгарга дип яшисең. Соңгы тамчысына хәтле. Синең үз кыйблаң. Шул якка туп-туры ашыгасың. Күлдәвекләрне дә, чыклы үләнне дә, чишмәләрне дә карап тормыйсың. Аягыңда туемсызлык итекләре синең. Яман нәфес күңеннән. Суы-юеше, ташы-комы шуңа өркетми. Ә ул күлдәвекләр, чишмәләр, чык тамчылары бүтәннәрнең күңеле, эчке дөньясы булса? Хыяллары, өметләре... Син аларны таптап узасың. Белергә тиешсең, Самат, кыйммәтле, затлы әйбер дефицитын тутыру җиңелрәк. Кече күңелле, олы йөрәкле булу авыр. Аннан да авыррагы бер-береңне аңлауга, рухи кардәшлеккә ирешү. Анысы үтә дә катлаулы эш. Зәмирә шуны көткән, көтеп ала алмаган... Мораль укый дип кабул итсәң, ялгышасың. Ихластан әйтәм. Теләктәшлек итеп...

Самат балигъ булганнан бирле мондый сүзне төрле-төрле рәвештә ишетә килде. Әнисеннән, бигрәк тә абыйсы Мораттан. Зәмирәдән дә. Шушы кадәр ап-ачык әйтүче генә очраганы юк иде. Нурсинә ярып әйтте, еллар дәвамында үлек җыйган шешне ярып җибәргән шикелле. Самат җавапка ни дияргә белми утырганда, ул янә өстәде:

— Кичә син дөньяга алты почмаклы өеңнең түр тәрәзәсеннән челтәр пәрдә аша карагансың, иртәгә «Волга»ң тәрәзәсеннән карарга ниятлисең. Катерың тәрәзәсеннән. Яшәү мәгънәсен белер өчен тормышка кинлектән карарга кирәк, минемчә. Магистраль юлга чыгып...

Әле кайчан гына бик тәмләп, хыял диңгезендә колач салып йөзәйөзә сөйләгәннәре Саматның үзенә каршы таш булып кайта түгелме соң? Нәкъ шулай. Тик ни кылсын? Хак сүзгә җавап юк. Самат Нурсинәгә ачулана да, үпкәли дә алмый иде. Шунлыктан ул бик җитди итеп:

— Чыгарыш син мине олы юлга, Нурсинә,— дип үтенде.— Бир кулыңны...

Нурсинә баш чайкады.

— Мондый сүз сөйләргә ашыкма, Самат. Ирләрчә үлчәп сөйләгәнең хәерле. Син мине белмисең бит әле. Миндә дә беренче тәэсирләр генә...

Киләчәгеңне, алдагы бөтен гомереңне хәл итә торган сәгатьләр, минутлар була. Шулчак нинди карарга килүең, нинди девизны сайлавыңнан барысы да бәйле булачак. Самат та шундый ызанда тора иде.

һәм үзенең шул халәтен секундына кадәр төгәллек белән истә калдырырга теләгән кебек, ул сәгатенә күз төшерде. Уникенчегә авышкан лабаса!

— Гафу ит, Нурсинә. Вакыт соң. Тыныч йокы телим, — дип саубуллашты.

Иртәгесен шәһәрдән телеграмма килде.

«Семьяда аңлашу өчен ашыгыч кайт. Әниең, абыең», диелгән иде анда. Телеграф бланкасы Саматка берничек тә тәэсир итмәде. Ул аны бер-ике кат укып карады да кесәсенә бөкләп тыкты. Төшкә кайтышлый авылның элемтә бүлегенә сугыла кайтты. Өйдәгеләргә болай дип телеграмма сукты.

«Кайту кирәк дип санамыйм. Эш бик тыгыз. Һәммәсе аңлашыла. Мин каршы түгел. Өйдә әни торып торсын».

Кулына квитанция алгач, Самат җанында-тәнендә бер җиңеләю тойды. Өстеннән авыр йөкне алып ташладымыни! Малай чакта тирләп-пешеп, тузанга батып, ындыр табагыннан кайткач та Зөядә су кереп чыккач рәхәт булып китә торган иде.

## 10

Төнлә яшенле яңгыр явып узгангадыр, шимбә иртәсе соклангыч иде. Болытлардан арынган күк йөзе шундый зәңгәр, гөмбәзнең бер читен кызларга яулык итеп кисеп бирә торган. Кояш көлеп кинәнә. Иртәнге сигездә күләгәдә егерме градус җылы. Ярый әле, талгын җил исә, гүя кемдер биниһая зур җилбәзә җилпеп тора. Кышкы бураннарны искә төшерергә теләгән төсле, шул җилдә тупыл мамыгы оча.

Тупыл мамыклары җиңел, Саматның уйлары авыр. Кургаш сыман. Егор, күп сөйләсә дә мәгънәсезне сөйләми торган беркатлы ир зат, бригадирның хәлен төшенә, ярдәм итә алмавына аптырый иде. Әбинең самавары кайнап чыкканчы дигән булып, ул да өйалды баскычына, Самат янына чыгып утырды.

— Уйга баттың әле син, Самат браток, башны аска идең. — Егор Кононович, гадәтенчә, иптәшенең җилкәсенә кагылып куйды. — Уйлар үрмәкүч пәрәвезе кебек. Үрмәкүчләр дигәннән, алар бер заман кояшны томаламакчы булганнар. Дөнья артык якты, кояшны бөтен яктан пәрәвез белән каплап куйыйк, дигәннәр. И кояш тирәли ятьмә үргәннәр. Бер мәлгә караңгыланып калган. Үрмәкүчләр бик шатланганнар, ялгышканнар только. Иртәгесен иртүк ачуы чыккан кояш боларның ятьмәләрен яндырган, тәпиләрен дә көйдергән. Шул заманнан бирле үрмәкүчләрнең кояштан котлары оча икән. Җирдән йөри алмый торган булып калганнар, пәрәвезләре буйлап кына йөгерәләр. Аяклары көйгән бит! Вәт менә шундый нәмәрсәкәйләр, Самат энем... Син дә яндыр ул пәрәвезләрне!

Самат Егорга күз сирпеде.

— Эх, Егорушка, Егорушка! Синең әкиятеңдәгечә генә булсачы!..

— Ничек булса да, синең кебек егеткә җебеп төшү ярамый, менә шул. Яшәргә кирәк! Честно яшәү дә бик җиңел түгел, шуны аңгарасыңмы, Самат браток? Җиңел түгел! Аның өчен дә куәтеңне җигәргә кирәк. Потому что уңда — майлы калҗа, түгәрәк көмеш таңкә, сулда — чибәр хатыннар... Кайчак үзеңә намордник кидерергә дә кирәк була.

Шулай гәпләшеп утырганда, ачык капкадан күрделәр: хуҗа әби өе белән Нурсинәләр йорты арасына «Жигули» автомашинасы килеп туктады. Кем булыр икән дип, капка төбенә барсалар, мә сиңа! Очрашуның көтелмәгәне. Машинаның алгы ишегеннән Сафдил Вафин килеп чыкмасынмы! Саматны күреп, ул да гаҗәпсенде.

— Балыклыга качар өчен шул кадәр үҗәтләнгән идеңмени, Билалов? — Аның беренче сүзе шул булды. Бер-берләренә каршы килеп, күрештеләр, исәнләштеләр.

— Шулайрак булган иде шул, Сафдил абый. Сине нинди җилләр китерде?

— Сине эзәрлекләп йөрүем түгел, тыныч бул.

— Мин казна малын урлап качкан кеше түгел лә эзәрлекләргә!

— Менә бу йортта бертуган апам яши минем. Авылның фельдшеры, — диде прораб. — Хәл белергә дип килешем.

Шул сүз һәммәсен ачыклады. Әйе, Нурсинәнең, бер абыебыз Казанда эшли, дип әйткәне бар иде шул.

Апалы-энеле ике туган — Сафдилә белән Сафдил— төскә-биткә бик охшашлар икән ич. Прораб абзасы да чандыр гәүдәле, какча озын йөзле, җирән керфекле күзләрен еш-еш йома, иягендә чокырчык.

— Безнекеләр өйдәләр микән, егетләр? — Сафдил үзенең апасы йортына таба баш какты.

— Нурсинә өйдә булырга тиеш. — Самат сүзен раславын кичектермәскә теләгән төсле, Нурсинә үзе капка төбенә чыгып килә иде.

— Ярый, егетләр, күрешербез әле, — диде Вафин...

Өйләдән соң Егор белән Ильяс Казанга кайтып киттеләр.

— Иртәгә кичтән килеп кунасыз.— Самат таләпне ике сөйләшергә урын калдырмый торган итеп куйды. — Берсекөнгә иртән-фәлән дип, икеле-микеле булмагыз. Юл белән башланган көн, аракыга дип вакланган акча кебек, бәрәкәтсез. Иртүк эшкә ябышырлык булсын!

Хезмәттәшләре киткәч, Самат байтак кыймылдады әле. Алай да көндәгедән иртәрәк, җиде тулып узгач ук, кайтты. Әллә каян гына килеп туган бер хис — үзен аяу хисе кыстап кайтарды бу юлы. «Нигә дип эшче Саматка карата эксплуататор Самат әле мин? Адәм баласының яшисе гомеренә көч-куәт дигәнең исәпләми бирелмәгән ич. Яшьлегемә булып, шул куәтне түктем, чәчтем, кызганмый сарыф иттем, ди. Килер бит бер көн, сугар бер сәгать — бик кирәген эшләргә дә җегәр калмас...»

Бу уй үзенең шыксызлыгы белән аны куркытып җибәрде. Берничә секундка Самат үзен әлсерәгән, тормыш суле сыгылып беткән, корышып калган карт итеп күрде һәм шундук, кара уйлардан арынырга теләп, җыр көйләргә тотынды:

Иртә торып суга барам,
Суның салкынын алам...

Тик җырның азагы тагын бәгырьне көйдерүгә кайтып кала иде.

...Суым салкын, эчем ялкын,
Синең утыңда янам.

Кайтып керүгә, хуҗа карчык Сафдилә энесенең Саматларны кичке чәйгә дәшкәнен әйтте:

— Өчесе дә керсеннәр дигән иде. Җәгүр белән Ильяс киттеләр, дидем. Самат керсен, арада иң кирәге ул, диде.

— Шулай укмыни? Рәхмәт, әбкәй, аманәтне тапшыруыңа.— Самат, кызып, өс-баш алыштырырга җыенды.— Кеше дәшкән икән, баш тарту ярамас. Чакырып килгәннең аты олы диләрме? Сафдил абый минем элекке начальник та бит әле, әбкәй. Казанда аның кул астында эшләгән идем.

— Бик әйбәт, улым, бик хуп. Кер. Ашның бәрәкәте кунак белән...

Хуҗалар гөрләшеп-серләшеп өстәл янында утыралар иде инде. Самат ишек шакып кергәч, һәммәсе урыннарыннан кузгалдылар.

— Әйдүк, әйдүк, энем! — Бәйрәмчә киенеп алганлыктан, яшәреп киткән күк булган хуҗа хатын Сафдилә аңа каршы атлады.

— Уз, әйдә, уз... — Монысын Нурсинә әйтте. Ул да өс-башын алыштырган. Чәчәкле кремплин күлмәк, лаклы туфлиләр кигән. Үзгәреп калган, ятрак булып. Чишмәдән су ташый торган ситсы күлмәге белән күңелгә кереп калганга шулайдыр.

— Менә монда рәхим ит. Сиңа дип саклап тордым. — Сафдил Нурсинә янәшәсендәге урындыкны күрсәтеп елмайды. — Мин апа белән рәттән утырыйм әле, сеңел каршымда булыр... Иң әүвәле Казан кучтәначеннән авыз итик.

Прораб «Абу Симбел» алып килгән икән. Табигый үләннәрдән ясалган төнәтмә.

Исәнлеккә-саулыкка, тазалыкка-байлыкка дип чәкештеләр. Ирләр ирләрчә булды. Сафдилә белән Нурсинә ирен чылатып куйдылар. Хуҗаларның шәраб тәэсиреннән башка да кәефләре әйбәт иде. Җайлап кына, тартынусыз гына гәп куертып җибәрделәр. Беркадәр сөйләшеп утыргач, Сафдил, «рөхсәт итсәгез» дигәнне аңлатып һәркайсына карады да пинжәген салып урындык аркасына элде, галстугын да чиште. Аннары Саматтан сорады:

— Эшләр ничек бара соң?

— Нормально. — Ташчы шул җавап белән барысын да аңлаттым, артык төпченү булмас дип исәпләгән иде. Мәгәр Вафин ныклап сөйләшергә ниятләгән булып чыкты.

— Шәп каезладыгызмы колхозны?

— Мунчасына күрә ташы, хезмәтенә карата ашы, Сафдил абый.

Энесенең сорау арты сорау биргүен өнәмичә, әллә чыннан да кала төзүчеләренең фидакарьлегенә хәйран булгангамы, Сафдилә аларның сүзенә кушыласы итте.

— И-и-и, бу егетләрнең тырышлыгы, энем! Исең-акылың китәр. Бал корты белән бер алар. Кояштан алда аяк өстендә, караңгы капмый торып кайтмыйлар.

Апасы сүзен прораб ияк кагып тыңлады.

— Билаловның тырышлыгын беләм, апа. Үземдә эшләде бит. Останың остасы, күз алдында әйтүдән дә тайчанмыйм. Ул яктан бозылудан үткән. Кулыннан килмәгәне юк. Дүрт-биш кешене алмаштыра. Ну... — Сафдил, кашларын сикертеп, иренен бүлтәйтте.— Ну... дәвалап булмас чире бар. Җәй җиттеме, шабашкага кача.

Капылт кына үтә җитдиләнеп, мәҗлес сөйләшүеннән бигрәк кәнсәләр сөйләшүенә охшап калган әңгәмәне иске эзенә төшерергә теләп, Нурсинә арага керде.

— Авылда да төзергә кирәк лә, абый.

Сафдил, кесәсеннән зәңгәр тирәле ап-ак кулъяулык чыгарып, маңгай тирен сөртте (Самат шунда искәрде: галстугы, оекбашлары гына түгел, кулъяулыгындагы тирә тасмалар төсе дә костюмына иш бу агайның!).

— Сүзең дөрес, сеңелем, — диде прораб. — Шәһәр ничә дистә ел буена авылдан аласы эшче кулларны алып бетерә язды бугай инде. Хәзер авылның үзенә булышлык кирәк. Ул ярдәмне шефлар күрсәтергә тиеш. Урыннарда инде колхозларның төзү оешмаларын ныгытырга кирәк. Материаль-техник тәэминат ягыннан рәнҗетүне бетерергә, коры кул хезмәтеннән арынырга. Шабашникларга гына исәп тоту — хата...

— Алар тиз генә бетмәячәк, Сафдил абый. — Самат моны кистереп әйтте.

— Быел димим, биш елдан да дип әйтмим, шулай да бетәргә тиешләр. — Прораб үз фикеренә нык ышана иде. — Рухи ягы гарип ул күренешнең. Мораль ягы. Кешенең бар булдыгын, сәләтен, акылын күп акча эшләү комсызлыгы суырып ала. Менә дигән осталарны гап-гади эш көченә әйләндерә. Атка, үгезгә, дөягә. Машинага. Шул кадәр тырышкан кеше адәм рәтле ялдан мәхрүм, культура-сәнгать җимешләреннән мәхрүм, семья назыннан мәхрүм. Шулай бара-бара политик

сукырга әйләнүе бар шәхеснең. Җитмәсә, шабашка әһелләре дәүләт билгеләгән түләү нормаларына өстән карарга күнегәләр, ертлачланалар. Монысы инде бөтенләй яраксыз.

Саматның кәефен китәрде бу сүзләр. Кунак булсаң, тыйнак булдигәнне хәтерендә тотып кына дорфаланмый чыдады. Аннан соң Нурсинә белән аның әнисе алдында да тупас булып күренүдән сакланырга кирәк. Шуңа күрә сабырын җуймый гына җавап кайтарды:

— Буяуларны куертасың, Сафдил абый. Читкә чыгып эшләүчеләрнең хайванга әйләнгәннәрен күргәнем юк әле. Сатлык җанга да чыкмыйлардыр дип беләм...

— Син дә таякны артык бөгеп ыргытма, Билалов. Мин шуны әйтмәкчемен: кешенең тормышта үз-үзен раслау өчен зур бер мөмкинлеге бар. Ул да булса — хезмәт. Хезмәт!— Сафдил уң кулының имән бармагын күтәрде; күзләрен еш-еш йомып алды. — Тик хезмәтнең теләсә нинди түгел. Кеше тарафыннан бу минем җәмгыятькә бүләк итәргә мәҗбүр өлешем дип аңлашылганы түгел! Бәлки үз-үзеңне тоту нормасы, вөҗдан бурычы, дәүләт һәм семья каршында бурыч дип аңлашылганы. Шул хезмәттә кешенең принципларгы, иманы, намусы чагыла. Менә син СМУ ярты еллык планын үтәп чыгасы иде дип ут йоткан көннәрдә бригадаңны ташлап киттең. Безнең мораль таләпләре белән сыешмаганын белмисеңмени син бу эшнең? Беләсең. Күрәләтә үз ягыңны каерганны аңлап торган коллективның ачуы чыга. Алай гына да түгел, Билалов, синең өчен әрниләр дә алар. Нигә ел бергә эшлибез, акылга утырта алганыбыз юк, диләр...

Самат, учы белән каты чәчен сыйпый-сыйпый тыңлап утыргач, рәхмәт әйтим дә чыгып китимсәнә дип, урындыктан калкынып куйган иде, күзе ирләр бәхәсен ихлас белән тыңлап утырган Нурсинәгә төште. Самат аның корым-кара күзләрендә теләктәшлек тә, гаепләү дә күрде. Үзенә өмет баглау галәмәтен да чамалады... һәм... җиңелеп кире утырды. Шулай да мондый сүз кузгалган икән инде, сорап калуны кирәк тапты.

— Яңадан бригадага кабул итмәсләр диюеңме, Сафдил абый?

Сафдил өстәл яныннан торып йөренеп килде. Урынсызрак та, вакытсызрак та сүз кузгаттым бугай дип, мәгълүм бер үкенү кичерә иде төсле.

— Алай димим, Билалов. Синең кебекләрне һәркайда көтеп торалар. Син моны бик яхшы беләсең. Үсенеп китүең дә бәяне белгәнгә. Алай да кулыңнан эш килү белән спекуляция ясарга кирәкми. Монда эшлисе эшегезне түгәрәкләгез дә кайт үзебезгә. Басылып эшләргә кайт. Иптәшләреңне дә алып кил безнең бригадага. Соңыннан рәхмәт укырлар үзеңә. Шул хәтле зур эшләр алда...

— Уйлап карармын әле, Сафдил абый. Атлаган саен күзгә төртеп торырдай булсалар, дөньяның кендеге безнең бригадага гына берегеп калмагандыр. Муен булса...

Сафдил Самат янына килеп утырды.

— Я, ярый, ярый. Кәефеңне җибәрдем шикелле. Акыл өйрәтергә чакырып керткән икән дип уйлама. Сүз уңаеннан кереп киттек бу темага. Шулай да, дөресен әйтим, үз коллективымны тузгытып бетерәсем килми минем. Синең безгә кайтуыңны телим. Әйдә, киләчәктә бергә-бергә төзү өчен тотыйк әле.

Чәкешми генә тотып куйдылар. Сүз йөгерегрәк китте.

— Ни гомер утырабыз,— диде бераздан Сафдил,— күпме сөйләштек, ни гармун уйнап күрсәтмәдең, ни җырлап бирмәдең, Билалов.— Аннары ул апасы белән сеңелесенә аңлатырга тотынды.— Бу егет шәп гармунчы бит безнең. Җырларга дигәндә дә артистлардан ким түгел.

— Чынлапмы, абый? — Нурсинә гөнаһсыз сабыйларча сорап куйды. — Каты да серле икәненә ышандым хәзер, — диде ул аннары Са-

матка. — Айга якын гомер эчендә ник бер көй уйнап күрсәтсен, ник бер җыр җырласын. Кичә үлсәм, талантыңны белми үләм икән... — Үзе эчтән генә уйлап алды: «Абый хаклы. Үлә-тора эшләү, саннан чыгып ару-талу шулай итә торгандыр. Гармун кайгысымыни аңарда, җыр хәсрәтеме?»

Самат килешмәгәнне кыланганда фаш булган кеше төсле сәер генә елмайды да иңнәрен сикертеп куйды.

— Гармунны алып килмәдем бит монда, Сафдил абый. Акча эшләргә килгән кешенең анлык вакыты буламыни? — Соңгысын прорабның үзенә карата керпеләнүенә җавап итеп, басымлап әйтүе иде. Сафдил янәдән эрепләшергә теләмәде.

— Һай, туры әйткәнне яратмыйсың да, Билалов! — дип көлде генә.

Тагын тел чарламасыннар инде дип тырышкан Нурсинә кып-кыска тәкъдим кертте:

— Алып чыгыйммы күрше Галләмнең хромкасын? Уйныйсыңмы?

Әнисе кызының сүзен куәтләде.

— Әйе шул, бар әле, бар, тиз генә кереп чык...

Хромка Самат кулында сайрады гына. Музыкантларның төрлесен тыңлаган Нурсинә исе китеп, сокланып утырды. Өздерә икән ич бу Самат. Тешләклегән кара син аның, гармун дип ник бер авыз ачсын...

— Инде җырлап та бир! — дип кыстый башладылар Саматны өчесе берьюлы.

— Кайсы операдан, нинди арияне? — Самат үз соравыннан үзе көлде. — Сез әллә мине җырчы дип уйлыйсызмы?

— Хәзинәдә бары, энем, — диде Сафдилә.

— Ялындырма инде, ялындырма. — Прораб сорый идеме, әмер бирүе булдымы, аермачык әйтүе читен иде.

Нурсинә бу юлы эндәшмәде.

Самат җиңел көйне уйный башлады. Аннары җырлап җибәрде.

Иртә торып суга барам,
Суның салкынын алам...

Нурсинә белән Сафдилә бер-берсенә карап куйдылар: «Җилле сиптерә икән!». Сафдил үзе җырлагандай горурланып башын күтәреп җибәргән иде: «Әйттемме мин сезгә!»

...Суым салкын, эчем ялкын,
Синең утыңда янам.

Шушы җырны җырлап биргәч, Самат, булган-булган кинаялэп тә җибәрим инде дип, батырлана төште һәм дәвам итте.

Алтын тояк, көмеш дага
Без атланган атларда;
Үзем үлми, гүргә керми
Калдырмамын ятларга...

Аннары шып туктады. Иңеннән гармун каешын салды. Хромканы диванга илтеп куйды.

— Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен концерт тәмам, — диде ул, радио дикторларына охшатырга теләп.

— Тагын берәрне уйнап җырла инде, энем, — дип, Сафдилә апасы чын күңелдән гозерләде. — Күңелне омсындырып кына калдырдың ич әле болай.

— «Искәндәр җыры»н, Самат. Җырла әле, зинһар. «Тапшырылмаган хатлар»дан. Уфа артистлары спектакленнән. Фидан Гафаров башкарганны...

— Көе әйбәт анын. — Монысына прораб та пичәт басты.

Самат ялындырмады, кыстатмады. Гармунын янадан иңенә асты. Әле генә күргән төсле, өйдәгеләрне күзләре белән сөзеп карап чыкты да, стенага кадакланган келәмдәге ниндидер бизәккә текәлеп, уйга калды. Көйнеме, сүзләренме искә төшерә иде. Керпеләнеп торган кара чәчле, алсулык йөгергән тулы битле егет бу минутта кызыгырлык матур иде. Аяк өсли торган килеш җыр башлады.

Сиңа килдем, иркәм...

Көй агылды, көй канатларына кунып, сүзләр агылды. Уйнап-җырлап торучының уйларында ни булгандыр да, тын калып тыңлаучылар нәрсә уйлагандыр, ачык әйтүе мөмкин булмаган хәл иде.

Каты итеп ишек дөбердәттеләр. Күрәсең, бусаганың тышкы катындагы иптәшнең беренче мәртәбә шакуы булмагандыр, гармун, җыр тавышы белән ишетмәгәннәрдер.

— Керегез, кер, — дип кычкырды Сафдилә. — Ишек ачык.

Бусагада ыспай гына киенгән озын буйлы ир-ат күренде.

— Гафу итә күрегез берүк. Миңа биш кенә минутка Самат кирәк иде...

— Керегез инде, керегез. Ишек төбендә торалармыни? — Сафдил да кичеккән юлаучыны өйгә чакырды.

— Юк, юк! Керәп тә, узып та тормыйм. Юл тузанын өйдә коясы түгел, Самат!

Самат аны шунда гына танып алды.

— Һи, Кыям абый икән ич! Хәзер... — Ул, рөхсәт сораган кебек, өйдәгеләргә аңлатты. — Безнең авылның Кыям абый. Колхозның партком секретаре...

Самат чыгып киткәч, Сафдилә энесенең колагына киртләп куйды:

— Нигә алай каты сөйләшәсең син анын белән? Әйбәт кеше күренә бит, — диде.

Энесенең җавабы әзер иде.

— Мин бит тикмәгә генә прораб түгел, апа, — диде. — Кырыкмаса-кырык төрле холыклы кеше белән сөйләшергә туры килә. Күкерт төсле кабынучан мастерлар белән дә, үз бәяләрен белүче, әмма айнымый интектерүче бәндәләр белән дә, әлегә бар казанышлары озын чәч тә модалы штан булган һавалы малайлар белән дә. Барысына да сүз табарга, җанына сукмак эзләргә кирәк. Прораб эше политрукныкына охшаган...

Самат белән Кыям баскычка утырдылар. Җиргә салкын иңә башлаган иде.

— Казаннан кайтып барыш, Самат энем, — диде Кыям агасы, сүз җаеннан аны-моны сораштыргалап хәл белешкәч. — Колхоз йомышлары белән барган идек. Кичүдә чират зур иде, шуңа соңгардык. Машина белән без... Сезгә дә кергән идек. Сәрбиҗиһан түтәйне күрдек. Моратны да. Иркенләп сөйләштек. Синең дә кайтып киткәнеңне әйттеләр. Ник килүемне чамалыйсыңдыр дип беләм.

— Беразгына.

— Шул инде, Низам абзый язып калдырганнар чүтыннан. Мин җибәргән хатны укыгансың. Колхозда музей ачарга җыенабыз. Күмәк хуҗалыкның тарихын язабыз. Әткәң материаллары — тарих үзе бит, Самат энем.

— Шулай шул.

— Аларны син монда алып килгәнсең икән.

— Әйе, миндә алар...

Сүз бозау имезә, диләр. Биш минутка дип чыккан Самат унны да торды, артыгын да. Бөтенләйгә чыгуы шул булдымы әллә? Нурсинә иртәгә абыйсы белән китәсен дә әйтмәде бит әле аңа. Саубуллашмадылар да...

Чоланга чыккач, Нурсинә Саматның авылдашы белән бик кырыс сөйләшүен ишетте. Ник болай кабынышып киттеләр икән дип, ихтыярсыздан колак салды.

— Низам абзый истәлекләре сезнең семья байлыгы гына түгел ул, колхоз хәзинәсе дә. «Яшәр»не әткәң үзе башлап йөреп төзегән, үзе ныгытышкан. Син аның изге эшен акчага әйләндермәк буласың. Оял әзрәк. Әткәң хакы турында уйлап кара.

— Кирәкмәсә алмагыз. Тарихыгыз да язылмый калмас, музеегыз да ачылмый тормас.

— Әнкәң риза. Морат берсүзсез риза, ә син шуннан файда чыгарырга маташасың.

— Маташмыйм бер дә. Мин әйткән сумманы чыгарып саласыз да дәфтәрләр сезнең кулга күчә. Аларга тулысынча хуҗа буласыз. Ап-ачык.

— Килешми, Самат энем. Илдән-көннән яхшы түгел. Авылдашлар алдында.

— Әйтмәсәм дә әйтим, авылдашлар белән читән үреп чәй эчәсем юк. Сатып аласыз икән — аласыз, юк икән — бигайбә! Хуш, Кыям абый!..

Партком секретаре капкага таба атлады, Самат өйгә кузгалды. Кәефе кырылган иде аның. Табынга кабат утырып тормады, чыгарга җыенды. Рәхмәт әйтте, тыныч йокы, тәмле төшләр теләде.

— Мин сине капкага кадәр озатып куйыйм әле. — Нурсинә, берни дә ишетмәгән, берни дә белмәгән төсле, уен-көлке аралаш сөйләнде.

— Минә бәхет! — дигән булды Самат та.

Озак сөйләштеләр капка төбендә. Нурсинә иртәгә китәсен әйтте, Самат бер көнге тәкъдимен янә яңартты.

— Булмас нәрсә белән кыстама, Самат, яме. — Нурсинә бу сүзләрне шундый йомшак, җылы әйтте, гүя ул әле генә елап туктаган нәни баланы юата иде. — Балыклыда айга якын торасың. Минем хакта байтак сүз ишеткәнсең.

— Ишетмәдем түгел, Нурсинә. Төрлесен сөйлиләр.

— Мин авыл халкына рәнҗемим. Нигездә, булганны әйтәләр. Дөресен. Нахак сөйләүчеләре дә бардыр. Анысы үз вөҗданнарына калсын. Инде аңладыңмы?

— Аңламадым, аңлыйсым да килми, Нурсинә.

— Ярый, Самат, һичьюгы бүгенгә бу сүзне калдырып торыйк. Үтенәм синнән.

— Бүгенгә генә дисәң, риза.

— Тагын бер үтенечем бар.

— Тыңлыйм, Нурсинә.

— Бая син озаклагач, чоланга чыктым. Теләмәсәм дә шымчы хәлендә калдым. Сезнең бәхәсегезнең шаһиты булдым.

Самат, исең киткән икән иске чикмәнгә дигән кебек, кул гына селтәде.

— Пүчтәк өчен баш ватма!

— Пустяк түгел шул, Самат. Дөрес аңлаган булсам, син әткәң язмаларын сатмакчы буласың...

— Әйе. — Самат үтә тыныч раслап куйды. — Ни тора колхозга мең тәңкә?! Банктагы счетларында миллион ята...

— Хәтереңдәме икән, үзенә янап, кулак Баһау әтиеңә ничек дигән? «Ни җитми сиңа, Низаметдин авылдаш? Акылың бар, үзең сау-сәламәт,

типсәң тимер өзәрлегең бар. Аша да эшлә, эшлә дә аша. Ни дип шул хәерчеләргә рәхәт эзләп кыйланасың?» дигән, әйеме. Әтиең ничек җавап биргән? «Үзем өчен генә яшәсәм шулай итәр идем дә, халык өчен тырышам шул мин. Халык хәерче булганда, мин бай булалмыйм», дигән. Син менә халыкны, авылдашларыңны уйлап карадыңмы?

Самат эндәшмәде. Нурсинәнең авырткан җиргә ничек тиясен белүенә исе китеп торды.

— Колхозны төзик дип тә, аны фашистлардан саклап та кан койган әтиең исталегән пычратма шул акча белән!

Самат сүзсез генә басып торды.

— Синеңчә нишләргә? Дәфтәрләрне бер тиенсез тоттырып җибәрергәме?

— Әгәр хокукым булса, гаделлек хакына мин сиңа шулай итәргә киңәш бирер идем.

— Һе...

— Я, хуш. Иртәгә күрешмәбездер.

Нурсинә тиз-тиз кереп китте. Җилкәсенә катлы-катлы сораулар күтәргән килеш, Самат ялгызы торып калды.

## 11

Сусаганда су тансык. Авырганда сау-сәламәт көннәр рәхәте искә төшә.

Нурсинәдән җавап хаты көткәндә, Самат шуларның һәммәсен бергә кичерде. Аның рухы «Исәнме!» дигән сүзгә сусады, «Сәлам сиңа!» дигәнне ничә кат укыса да туймас кебек булды. Хат алып килергә тиеш яктылык аңа аяз таңнарны хәтерләтер төсле тоелды. Хат аны сау-сәламәт, көчле итәчәгенә ышанып көтте. Үзенең болай нәүмизләнүенә торып-торып аптырый да иде: «Яшь егет чагыммыни? Ләйләнең Мәҗнүнеме?! Олыгаеп та акылга утырмау шушы була торгандыр...»

Килде ул хат, көттереп булса да килде. Нурсинә җавапны саран гына язган иде.

«... Турысын әйткәнгә хәтерең калмасын, хаксыз ук булсаң да, әйткән сүзеңнән авыр кайтучан син, Самат. Бигрәк тә эш акчага килеп тоташканда. Колхозга үзең кайтмагансың. Монысын аңлыйм. Партком секретаре белән шундый сүздән соң авылдашларың каршына кайтып төшү ансат түгел. Почта белән җибәрүең дә бик әйбәт. Төп максат ул язмаларның туган колхозыгызга барып ирешүе иде бит. Тотар булсаң, тагын бер киңәш: инде үкенмә. Кылган гамәлеңә үкенү, гомумән, үкенеч хисе йөрәк итен кимерә, нервларны талкый дигәнем... Минем өчен гадәти эш көннәре башланды. Алар су тамчылары кебек охшашлар дияргә мөмкин. Шулай да синең хезмәткә килүеңне, палатага кереп хәл белешүеңне көткән кешеләр барын даими тоеп тору, аларга ярдәм кулы суза алуыңны белү күңелгә зур юаныч бирә, ышанычыңны арттыра, яшәүне мәгънәле, кызыклы итә... Егор Кононовичка, «Карабатыр» Ильяска да күп итеп сәлам әйт! Армый эшләгез.

*Сәлам юллап: Нурсинә.*
*10 июль, 1975 ел. Казан».*

Хат алган көнне Самат канатланып йөрде. Кәеф әйбәт чакта, мәгълүм инде, эш тә җырлап бара, Егор белән Ильяс та иң сөйкемле дусларга әйләнә! (Нурсинәнең сәламен ул аларга дөньякүләм яңалык хәбәр иткәндәй ирештерде.) Бу көнне аның тирә-юньдәге һәммә кешегә игелек эшлисе килә иде.

Өйлә ялында Нурсинәгә хат язды ул. Ерып чыкканчы ярты дәфтәр кәгазь булды. Я бу җөмләсе килми, я теге фикере җан теләгәнчә калыпка салынып җитми. Ә сынатырга ярамый, һич ярамый! Дөнья көтү дигәндә, сүз сөйләүдә, хат язуда, укыган китабың турында фикер әйткәндә, өс-башыңа киенгәндә, галстук сайлаганда, дус-иш, таныш-белеш арасына килеп эләккәндә — барлык, барлык җәһәттән Самат Нурсинә югарылыгына күтәрелергә ант итте. Балыклыда эшләрне тәмамлап кайткач, кышлыкта урта мәктәп дәресләренә чын-чынлап ябышырмын дип аңына беркетеп куйды. Киләсе җәйгә төзелеш техникумының читтән торып уку бүлегенә гариза бирергә ниятләде. Нигә сынап карамаска ди бәхетне! Самат кемнән ким?!

Хатының юл араларына сизелер-сизелмәс кенә итеп ул шушы хыялларын да салырга теләде.

Нурсинәнең шәһәр адресы язылган конвертны почта ящигына салуга, Самат янә пошына башлады. Кайчан барып җитә әле ул? Район үзәгендә бер-ике көн тоткарланса, Казандагы почта бүлегендә берәр көн ята калса... Җомгада алмаса... Ул бит шимбәдә кайтам дип язды. Юк, хатка ышаныч зур түгел. Телеграмма бирергә кирәк. «Шимбәдә Казанда булам. Мине көт».— Һәм вәссәлам! Телеграф почта гына түгел, йөрәк тибешен яхшырак аңлый...

Ул телеграмма сукты. Адресатка барып җиткәнен үзенә хәбәр итәсе итеп сукты, уведомление белән. Аннары Нурсинә белән Казанда, Космонавтлар урамында очрашасын күз алдына китереп бәхетле елмайды.

... Казанда исә йөзеннән елмаю качты. Ишек кыңгыравы төймәсенә баскан иде, күрше хатын чыкты (Нурсинә өч бүлмәле квартираның бер бүлмәсендә уртак кухня белән яши), доктор кайтмады әле, диде. Ярты сәгатьтән әйләнеп килгәч, шул ук җавапны ишетте. Кайтыр дип өметләнеп, сәгатькә якын гомер уздырып, кабат сорады — кайтмаган иде. Шунда сөмсере коелды инде Саматның. Бу минутта аңа дөнья малы кирәкми иде. Нурсинә юри чыгып киткән дип тә юрады ул. Күңел эчкәресенең дә иң тирән бер почмагында ниндидер бәләкәй шайтан кыймылдады. Аның исеме Көнчелек иде. Аны камчылап куарга теләде Самат. «Көнләшергә минем ни хакым бар әле?»

Соңрак тагын бер сугылырмын, диебрәк китеп барганда (нәкъ төнге уникедә Казан — Уфа поезды белән ул Балыклыга юнәлергә тиеш), юлда кара-каршы булдылар. Нурсинә ашыгып кайтып бара иде.

— Билгеләнгән вакытта син монда тәки, ә? — диде ул, җанга рәхәт өстәп елмайды һәм күрешергә кул сузды.— Исәнме!

— Кайтуы бер ни түгел. Кат-кат килеп тә күрми китүе әҗәл. Өметне өзгән идем инде.

— Гафу ит, Самат. Үч иткәндәй килеп чыкты. Институтта бергә укыган дус кызымның туган көне мәҗлесенә чакырулы идем. Бармый калалмадым. Шуннан көч-хәл арынып кайтуым.

Самат томырылып аның күзләренә карады. Ләм-мим дәшми, озак карап торды. Сагыну галәмәте идеме икән? Беренче булып Нурсинә карашын читкә алды.

— Нишләргә җыенасың хәзер, Нурсинә?
— Әйтүле эшем юк.
— Алайса, киттек. Үзәк паркка кадәр җәяү барабыз. Сезнең халык, врачлар димен, җәяү йөрү файдалы дип аңлата, әйеме?
— Дөрес.
— Шулай булгач, киттек җәяү генә. «Җәй» ресторанында тамак ялгарбыз. Син кунакта сыйлангач та, минем эчтә Черкен этләре өрә.
— Өеңә кергәнсеңдер ич?

— Кердем дияр өчен кердем. Күреп чыктым. Әни белән гәпләштек. Абый, җиңги белән сөйләшкән булдык. Төзелеш кирәк-ярагына кайттым, дидем. Ә син белеп тор, мин сине күрергә кайттым!

— Рәхмәт илтифатыңа. Хат кына аз, телеграммалар белән кисәтә-кисәтә кайтасың.

— Тәртип яратам.

— Өегездә хәлләр ничек?

— Мондый чакта ничек булырга тиеш булса, шундый. Баштан сыйпамыйлар... Асып куя алмаячакларын да белеп торалар...

Рестораннан чыккач, парк аллеялары буйлап ничә чакрым ара уздылар икән? Туктап торганнары булмады, кичке унны җиткерделәр.

Сүз агышында җай килеп чыгып: «Әйдә, үзеңне Савиново поселогына кучереп калдырыйм!» — дип куйды Самат. Нурсинә бик каты үпкәли язды. Беравыктан рәнҗү бетте тагын.

— Мин сине күңелемә күчереп алып китәм, Нурсинә! — Самат инде ничәнче катка сүзне үз тәкъдиме ягына борырга ният итеп бакты. Нурсинә моңа каршы җавабында әйбәт шигъри сүзләрнең, кайнар хисләрнең тормышта кирәклеген, әмма аларны әрәм-шәрәм итми саклау зарурлыгын аңлатырга тырышты. «Мине түгел, «Кем соң бу, ниһаять?» дигән сорауны алып китәсең күңелеңдә, — диде. — Дөресме?»

Самат:

— Дөрес, Нурсинә. Ул сорауга тулы җавап тапканым юк бит әле минем, — дип килеште.

— Тыңла, алайса, берәүнең ямьсез яшьлеге турында, — диде Нурсинә. — Шул чагында аны күңелдә алып китүнең дә, хәтта аның белән бүтән очрашуның да кирәге калмас...

Самат аны бүлдермәскә тырышып тыңлап барды.

— Институтта укыганда бер маҗара да булмады. Укуда чөеп мактарлык идем димим, сүгеп ташларлык та түгел идем. Авыл мәктәбен тәмамлап килгәннәргә беренче мәлгә шәһәрдә үскәннәр белән ярышуы авыр. Мин өченче курсны бетергәнче уңга-сулга карый алмадым. Тулай торак кошы идем. Дүртенче курста укыганда әти үлеп китте. Аның үлемен әни дә, мин дә бик-бик авыр кичердек. Үзебез генә беләбез. Яшьлегем узып барганын мин алтынчы курста гына чын-чынлап аңладым дисәм дә хата булмас. Төзәтенеп сөйләвем түгел, аңа кадәр дә тирәмдә егет-җилән бөтерелгәләде, тик алары күбәләк уены гына иде әле. Эш урыннарына билгеләр алдыннан, алда дәүләт имтиханнары гына калган иде бугай инде, мин Чаллыдан килгән яшь инженер белән таныштым. Көтмәгәндә, уйламаганда.

— Кешеләр алдан төзелгән программа буенча танышмыйлар бугай шул... — Самат үзләренең беренче очрашуларына ишарә ясады.

— КамАЗ башланган гына чор иде. Ул, гашыйк мин сиңа, диде. Можга татары. Казанга еш килә иде. Гел очраша торган булып киттек. Кемне күреп, ниләр сөйләшкәндер, мине Чаллыга билгеләделәр. Икебез дә Чаллы кешеләре булып киттек. Ул бик күп укыган, гаҗәп күпне белә иде. Әдәбиятсыз, сәнгатьсез тормышны кыргыйларча җан асраугa саный, музыка дөньясы белән шәп таныш. Авыз тутырып «интеллигент кеше» диярлек...

Болар Саматны сискәндерде. Мәгәр ул моны Нурсинәгә сиздермәде. Игътибар белән тыңлый бирде.

— Танышканыбызга бер ел дигәндә, җәен ял алып, Кавказга киттек. Кавказ минем өчен җәннәттер сыман тоелды. Шул көзне мин балага уздым. Бу хәлне аңа — Рамазанга да әйттем. Шул көн безнең мөнәсәбәтләребезгә кара бер сызык булып ятты. Мин иң зур серемне ачкан минутларда Рамазан таш төсле суык һәм үзгәрешсез калды.

«Нәрсә дип әйтим, — диде ул. — Баланы юк ит дип киңәш бирә алмыйм. Сине җинаятькә этәрергә теләмим. Тудыр, үстер дип тә кыстамыйм. Мин аңа эти була алмаячакмын...» Әйе, күзен дә йоммады, вөҗдан газабы да кичермәде шикелле, тыныч кына, әдәпле генә әйтте. Табан ялтыратырга да җыенмады... Мин давыллы диңгездәге каекчы хәлендә калдым. Төзәтеп булмаслык хата ясавымны, нишләптер, атналар, айлар буе аңламый йөргән булсам, ул көнне бөтен газабы һәм хурлыгы белән төшендем. Бәгырем өшеп, ташка әйләнеп калган кебек булды... Яман хәбәр алдан йөри. Минем йөкле икәнлегем авылга да кайтып ишетелгән. Ике-өч көнгә ялга дип кайтсам, әни елый, бабай котырына башлады: «Иреңнән башка бу йортка ике аягыңның берсен басасы булма! Нәселдә булмаганны син күрсәттең», — дип акырды бабай. Аның сүзе безнең семьяда гомергә закон булып килде. Мин коточкыч адымга барырга мәҗбүр булдым... Шуннан соң азрак баш-күз алгач, министрлыкка килеп, ничек кенә булмасын Казанга күчерүләрен сорадым. Рәхмәт, ярдәмнәреннән ташламадылар... Инде монда өченче елым... Калганы — күз алдында.

Нурсинә тып-тын калды. Аннары, кич буе сөйләшкәннәргә сөземтә ясагандай, әйтте:

— Ә син мине җиңел генә «күңелемә күчереп алып китәм» дисең. Тормышта алай гына булмый ул. Үткән көннәрем иңемдә. Сау бул, Самат. Исән-сау барып җит, әйбәт эшлә...

Самат, Нурсинәне өенә озаткач, такси тотты да тимер юл вокзалына китте. Таксичы егет радиоалгычын кабызып куйган. Казан концерт тапшыра. Заказ бирсәң дә болай туры килмәс, Балыклыга сәфәр чыккан пассажирның уй-теләкләрен белгән кебек җырлыйлар иде:

«Күктә якты йолдыз яна,
Иң яктысы син күк тиясең.
Сине уйлый-уйлый мин юанам,
Бәлки әле син дә...
Бәлки әле син дә сөярсең...»

1975—1976.

## Гамил Афзал

### Чияле тау итәгендә

Чияле тау итәгенә вышка килде, —
Кунак түгел, бәйрәм түгел, эшкә килде.

Керосинга кинәнмәгән авыл чите
Электрлар яктысында балкып китте.

Мотор гөрли, ыгы-зыгы, металл чыңлый,
Металл чыңын сәерсенеп Тимәш тыңлый.

Ничегрәк бораулыйк дип киңәш сора —
Мал караган, иген иккән Тимәш тора.

Буровойда дөбер-шатыр иртән-кичен,
Каты катлам сынап карый корыч көчен.

Башны, күзне чеметтереп кисә-кисә,
Чияле тау түбәсеннән җилләр исә.

Ай моңая алка тагып, җилдә өшеп,
Чияле тау түбәсенә чалкан төшеп.

Каты ташны теше белән тишә-тишә,
Җир астына борау төшә, сорау төшә:

Бәхет тулып нефть күле көтә микән,
Юкны эзләп вакыт кына үтә микән?

Чияле тау итәгендә вышка тора,
Яз да тора, көз дә тора, кыш та тора,

Көн дә тора, кич тә тора, эштә тора,
«Булыр!» дигән ныклы өмет истә тора.

Геолог та чат әүлия түгел сезгә,
Усал йөзләр өметле дә, өметсез дә.

Катламнарның бар яманы, бар яхшысы...
Буровойга көмеш коя ай яктысы.

Бәхет булып безнең алга бер киләсе
Качып яткан ерак еллар хәзинәсе!

Вахта китә көнне кичкә авыштырып,
Төркем-төркем берсен-берсе алыштырып.

Кояш чыга тау башларын таңга манып,
Вахта килә яңа дәрткә дәрман алып.

«Булмый калмас! Чыгар!» дигән өметләр нык,
Сугыштан да үлми кайткан егетләр нык.

Тешен кысып, көн-төн эшли тимер батыр,
Вахта килә, вахта китә дөбер-шатыр.

Мотор эшли, куллар җитез, корал көчле,
Буровойда җәен-кышын урак өсте.

Чыгыр сыкрый, тимер чыңлый, ирләр өлгер,
Шәмнәр менә, шәмнәр төшә дөбер-дөбер.

Ыргак белән тотып алып шәмне кыстыр!
Киндер пинжәк, киндер чалбар чыштыр-кыштыр!

Измә килә, торба килә, әйдә, өлгер,
Әйдә, йөгер бушатырга, түзем сеңер!

Шаярталар вахтачылар ашап туйгач:
— Тот кәрәкне, галиҗәнаб эшче класс!

— Кара әле безнең бораy тешен татып,
Борынын сузып бронтазавр йөргән вакыт!

— Уян әле, нефть җене, нефть күле,
Ничә миллион ел йоклаган диңгез төбе!

— Эшкә җигел, качып ятма аста һаман,
Яры канат-аждаһалар очкан заман!

Девон картның маңгай сыры катлам-катлам,
Кинәт кенә котны алып атты фонтан.

Миллион еллар туфрак басып яткан өчен,
Бәрде фонтан күккә чөеп кыргый көчен —

Йөз ел үскән карт өянкеләрдән биек,
Җир астыннан сикереп чыккан дию кебек,

Дулап чапкан кара айгыр ялы кебек,
Күккә ашты безнең илләр даны кебек.

Атты фонтан чиксез муллык һәм дәрт белән,
Сәгатенә тугыз тонна гайрәт белән.

Бу хәлләрне язгы җилләр, җәйге җилләр
Еракларга алып китеп мактап сөйләр.

Сөенделәр вахтачылар хәйран булып,
Нефть белән битне юып, кулны юып,

Кѳлә-кѳлә, берсен-берсе этә-төртә,
Шешәләргә тутырдылар истәлеккә.

Кая әле торба белән җыю чанга,
Тутырдылар графинга, стаканга.

Берсен-берсе котладылар шашып китеп,
Аркаларны какты куллар шап-шоп итеп.

Авыл карый бу мәхшәргә хәйран калып,
Чишмә буе сукмагына тулды халык.

Кызлар килде вәкарь белән вак-вак атлап,
Әби-чәби — яулык белән авыз каплап.

Кымырҗытты егетләрнең кайнар канын,
Шушыннан бит — геройлыкка ике адым.

Картлар килде сакалларын сузып алга:
— Коммунарга бирә ходай, бәрәкалла!

Газет язды, радиолар хәбәр итте,
Эфир тулы шау-шу китте, хәбәр китте:

«Бәрәңге һәм бодай җире Татарстан
Нефть табып, иң алдынгы сафка чыккан».

Болын тулы челтәр-челтәр манаралар,
Үрләр буйлап, сыртлар буйлап бара алар,

Асфальт белән, тимер белән билен буып,
Туган җирнең малы булып, даны булып.

Анда-санда уенчыктай сиртмә тора,
Әле башын, әле түшен селкә тора.

Өскә менә, түбән төшә корыч сиртмә,
Талпына да, Девон картның кылын чиртә:

«Әлли-бәлли, әлли-бәлли, Девон батыр,
Илләр буйлап даның йөри чирек гасыр...»

Күренмичә дөнья малы ага тып-тын,
Уйсуларда уҗым үсә дулкын-дулкын.

Зур юл узган кәрван кебек арып йоклар
Чияле тау түбәсендә ак болытлар.

Юлаучыга чуклы башын иячәкләр
Чияле тау итәгендә ак чәчәкләр.

1975—76.

# Тау битендә

Мин утырам тау битендә, зур соры таш өстендә.
Бу җирдә дүрт яктан җилләр исә иртә дә, кичен дә.

Үткән еллар, киткән дуслар хәтердә, исемдә.
Кылганнар чайкала, хыяллар чайпала сөзәк тау битендә.

... Кыя башларына орынып-орынып ак болытлар йөзгән илдә,
Кыядан-кыяга сикереп, җитез тау тәкәләре йөргән җирдә,
Сикереп-сикереп чишмәләр аккан,
Кара бөркетләр канат каккан
Кыялар сыртында ачык җилдә
Батыр йөрәкле, туры сүзле, кыю дустым гомер итә иде.
Таулар-ташлар кичеп, мин сәламнәр алып килгәнне зарыгып көтә иде.

Уйлар уйлап, җырлар җырлап, айлы кичләребез үтә иде...

Күм-күк урманнар артында, бормалы сукмаклар чатында,
Кыйшайган агач өйдә
Дәртле дустым тора иде кәккүк тавышларына сөенә-сөенә.
Җилләр исә иде урманнарның яшел чәчен тарап,
Нигә без аерылыштык, нигә иртә саубуллаштык саргылт басуларга
карап?!

Ап-ак, зәңгәрсу боз таулары артында,
Төтенле, тире чатырда,
Кар өстендә туган, боз өстендә үскән,
Төньяк балкышы астында кар чүлләре кичкән
Бик акыллы дустым тора иде,
Ап-ак дала буйлап, дәртле җырын җырлап,
Болан көтүләре куа иде.
Сагынып күрешмәгәнгә күп еллар үткән.
Хәзер ул дустым буран үкергән төннәрдә
Ниләр уйлый икән?

Җылы диңгезләр артында, хөрмә ботагыннан ясаган чатырда
Кара бөдрә чәчле, арыслан йөрәкле, ирек сөяр дустым тора иде.
Мин кошлардай канат кагып,
Балыктай дулкын ярып,
Шул дустымның хәлен белергә килә идем.
Серләшеп сүзләр бетми таңнар ата иде...
Хәзер ул дустым, акыллы күзләрен йомып,
Кайнар ком астында ята инде...

Мин озын гомерле булдым.
Шул дусларымны сагынып уйлар уйлыйм һаман.
Кадерле истәлекләремне алларга манам, гөлләргә манам.

Ак сарыклар көтүедәй, болытлар күченә, болытлар күченә.
Мин утырам тау битендә соры таш өстендә.
Бу җирдә хуш исле җилләр исә иртә дә, кичен дә.
Үткән еллар, әйбәт дуслар хәтердә, исемдә.
Кылганнар чайкала, хыяллар чайпала сөзәк тау битендә.

## Әхмәт абый

Яратты ул күңелләрне
Ераклардан уратуны,
Үлемнәрне, җиңүләрне,
Вавилонны, Урартуны.

Хыялында йөргәндер ул
Ганнибаллар үткән җирдә,
Сугышларга кергәндер ул
Спартаклар белән бергә.

Рим дисен, Мисыр дисен,
Авыз суы кибә иде,
Аргиштиен, Озирисен,
Рамзесын сибә иде.

Шумер-Акат... фәлән диеп,
Авыз суы корый иде,
Усал карап, күзлек киеп,
Шуны бездән сорый иде...

Әхмәт абый дөнья куйган.
Бик ямансу булып калды.
Күңелләрдә чыңлап торган
Илләр янды, еллар янды.

## Бер сүз турында баллада

Әйтәләр миңа,
Сөйлиләр бер сүз:
— Асыл егет син,
Зифа буең төз,
Ярлылыкка түз,
Ялгызлыкка түз,
Көрәш-дулкында
Колач салып йөз!

Иртә һәм көндез
Әйтәләр бер сүз:
— Син гайрәтле йөз,
Син очкынлы күз,
Сиңа сокланып
Җилкенәбез без,
Эзлә син бер юл,
Сөйлә син бер сүз!

Мин үзем дәнсез,
Мин үзем юньсез.
Әйтәләр миңа,
Әйтәләр бер сүз:
— Берәүләр сөмсез,
Берәүләр өнсез,
Эзлә син бер сүз,
Сөйлә син бер сүз!

Әйтәләр миңа,
Тукыйлар бер сүз:
— Шауласын дөнья,
Кайнасын диңгез,
Түшең белән йөз,
Тешең белән өз,
Ялган эшне сөз,
Ялган сүзне сөз!

Әйтәләр миңа,
Сөйлиләр бер сүз:
— Син булмасаң, без
Колаксыз-күзсез,
Кояшлы көнсез,
Йолдызлы төнсез,
Нишләп торасың
Хыялсыз-нисез!

Үтте ничә җәй,
Үтте ничә көз...
Тоныкланды күз,
Боекланды йөз,
Мин һаман телсез,
Мин торам өнсез.
Мин эзлим бер сүз,
Табалмыйм бер сүз.

## Юмор

Берәүләрдә көлке гадәт, сәер холык
Күңелләргә сеңеп кала кызык булып,
Мәзәк була йөзендә дә, сөйләүдә дә,
Кызык кеше кызык була биләүдә дә.

Чытык чырай кибәк чәйни кетер-кетер,
Мыек бора аек акыл, зирәк фикер.
Бер елмаю үн ялганны сугып ега,
Елтыраган кысык күздә зиһен була.

Кайгыдан да, шатлыктан да көлә белгән,
Үлгәндә дә көлә-көлә үлә белгән —
Кешеләрдә барлык тойгылардан өстен!
Яратам мин янып торган юмор хисен.

Бу көрәштә без җиңәсе, без көләсе,
Дөнья күргән хөр акыллар тәҗрибәсе —
Ышанмыйча, табынмыйча юкка-барга,
Көр күңелле Намус көлә текә ярда.

Күчә болыт, ага сулар, үсә үлән,
Якалашып мәкер белән, хәйлә белән,
Бу дөньядан кемнәр китәр, кемнәр килер,
Көлә-көлә юмор яшәр гомер-гомер.

Гариф Ахунов

# ИДЕЛ КЫЗЫ

РОМАН

ИКЕНЧЕ БАШЛАМ

## I

Зур тормышка чыгу, ата-бабаның төшенә дә кермәгән аң-белемле булу, ялтыравыклы штиблет, затлы пинжәк киеп, шәһәр малае булып йөрүләр бөтен дөнья сугышының аяусыз корабына бәрелеп чәлпәрәмә килде.

Солтан Алабуганың земское училище укучысыннан янә дә авыл малаена, Түбән очның ярлы Садыйк малаена әйләнеп калды.

Төннәр караңгы — утсыз; көннәр, гаять зур йомгактан сүтелгән җеп шикелле, һаман бер төсле эчпошыргыч күңелсезлекләре белән узып торалар.

Сугыш халыкны икегә аерып куйды: берсен Галиция, Буковина кырларына илтеп, кара гүргә салды, икенчесен черетеп баетты. Алпавыт Халитовлар, Шакир хаҗилар, кызыл малчы Габделхәлимнәр, сугыш афәтеннән миңгерәүләнгән ярлы-ябагайның күзен ут яндырып, тулпар атларда, келәмле кашовкаларда җилләр уйнатып уза торган булдылар.

Ике ел эчендә күзгә күренеп күтәрелгән Таминдар Тураев Иш буена алты ташлы тегермән салдырды; Чаллыны, Чистайны, Алабуганы агач материалы белән тулысынча тәэмин итәргә хыялланып, такта яру заводы җиткезде.

Зартугайның урта бер җирендә, әйләнә-тирәгә еractан ук күренерлек булып кызыл кирпечтән һәм нарат бүрәнәдән ике катлы бина калкып чыкты. Түбәсен табаклы калай белән ябып, яшел буяуга буядылар, ике мәхәлләнең дә маңгай тиренә салынган биек манаралы ике мәчет белән дә ярышырдай бу бина, яңача укыту өчен салынган мәдрәсә хезмәтен дә, бер үк вакытта школа-мәктәп хезмәтен дә үти башлады.

Татар авылында мәктәп булу — бу инде һушыңны алырдай яңалык, Монда инде Югары мәхәллә мулласы Сөләйман хәзрәт белән Фатих

---

Дәвамы. Башы беренче санда.

хәлфә укыткан дин сабагына гына риза түгелләр. Таминдар Тураев яңа мәктәпкә түккән акчасын мужик балаларының башын катырып һәфтияк ятлатуга гына җибәрәсе килми, үзенең Идел-Кама пароходчылыгында эшләргә тиешле булдыклы, белемле кеше тәрбияләргә ниятләнә иде.

Мәктәп йорты зур. Урта бер җирендә урам буе коридор, сул якта — хәлфәләр, уң якта — сыйныф бүлмәсе. Солтан тәүге мәртәбә Габбас мулладан дин сабагы алган, укый-яза белергә өйрәнгән мәдрәсә, — моның белән чагыштырганда, — мунча хәтле генә. Монда утырып укый торган аяклы парталар бар, ләкин ул җиһазлы бүлмәдә матур язу белән русча дәресләр генә алып барыла. Коридорның аргы башындагы берсеннән-берсе зур ике бүлмәгә парта-мазар куеп тормаганнар. Укуны идәнгә утырып, аяк бөкләп укыйсың. Дин сабагы белән татарча дәресләр — шушында.

Кичен, мәктәп бүлмәләренә караңгылык иңгәч, кара ишек янындагы киштәләрдән эчмәкләр[1], мендәрләр, киезләр алынып, таеп егылырдай шома идәнгә җәелә. Ишегалдына чыга торган арткы ишек янында, салкын коридорда аяк киемнәре өелеп ята. Бәләкәй шәкертләр бер-берсенең чабатасын бутап, сугышып китәләр. Кухняның ачык ишегеннән шәкертләр пешергән кабыклы бәрәңгенең әчкелтем исе борыннарны ярып керә, суыкта торудан өшегән ипине җылыткан чакта, бүлмәне тутырып тәмле ис тарала. Кухняның чормасына өйдән алып килгән бер кисәк туң итне асып куялар. Аларны чукырга бетмәс-төкәнмәс песнәкләр җыела.

Иртән торгач, урын җыю, мендәр атышу йоласы башлана һәм ул Фатих хәлфә, сакалсыз саргылт йөзен чалшайтып, тал чыбыгы белән шәкертләрнең аркасына чажылдатып тамызып чыкканчы дәвам итә.

Сыйныф бүлмәләренең берсендә, парта-мазар куелмаганында, үзләренә кызыл чаршау корып, Мирзаян, Шәрифҗан, Нух Галләм яшиләр. Фатих хәлфә аш-суга киткән чакларда, хәлфә урынына дин сабагын Нух Галләм укытып тора, бу аңа, сабакның үзен укытудан бигрәк, тәртип бозган бәләкәчләрнең канынннан килү өчен кирәк. Нух Галләм намаз укыган чагында аяк бөкләп утырмасаң, яки фани дөнья сүзен китереп кыстырсаң, колакны өзеп чыгарырлык итеп бора, яңак төбеңнән чиләк төбе ясый; сыек тал чыбыгы яки ишкән сөлге белән һуштан язганчы кыйный—казыйлык вазифасын ул ихлас күңелдән, җаннары рәхәтләнеп, ярсынып-ярсынып үти. Нух дигән пәйгамбәр исемен аңа шәкертләр кансызлыгы, хәзрәт алдында гел ялагайланып йөргәне өчен бирделәр.

Шәрифҗан белән Мирзаян кечкенәләрне җәберләмиләр. Аларның үзләре генә белгән серләре бар — кайчан карама, әкрен генә сөйләшеп йөриләр. Вакыт-вакыт шәкертләрнең колагына аларның аулак өйгә, солдаткалар янына баруы, Сөләйман хәзрәттән яшереп сыра эчүләре дә килеп җитә. Хәзрәт белән алар үзләрен иркен тотып, дәрәҗәләрен белеп сөйләшәләр, вакыт-вакыт учитель Гаврилов белән дә аңгәмә корып алудан тартынып тормыйлар. Алабугада нибары бер кыш эләгеп калган рус теле Солтанга аларның кайбер сүзләрен чочлап калырга мөмкинлек бирә, тик ул «реферат» дигән, «социал» дигән сүзләрне генә аңлап җиткерми. Күрәсең, ул сүзләрдә кеше белмәскә тиешле яшерен мәгънә бардыр, шулай булмаса, Шәрифҗан белән Мирзаян аларны шыпырт тавыш белән, үзләре генә ишетерлек итеп әйтмәсләр иде...

Кышкы караңгы төннәрдә дәү шәкертләр, бәләкәчләрне җыеп, куркыныч әкиятләр сөйлиләр. Соңыннан шәкертләр ишегалдына чыгарга куркып, юрган астына поскан килеш, төне буе йоклап китә алмый азапланып яталар.

---

[1] Эчмәк — Әгерҗе ягында матрацны шулай диләр.

— Тәкмәк-Чүрәкәй кырыла безнең бер заманны, — дип, ак керфекле күзләрен зур ачып, бармакларын тырпайтып сүз башлый әкиятне иң матур сөйли белүе белән дан алган Шәрифҗан. — Ийе, прәметеки кырый йорттан кырылып килә авыл. Әҗәл дигәнең сыпырып кына бара.

Бәләкәй шәкертләр Шәрифҗан-әкиятчене уратып алганнар да, идәнгә чыпчыклар кебек тезелешеп, авызларын ачып тыңлыйлар.

— Әтүтән Пәттәхләрнең беренче көнне имчәк балалары үлде, икенче көнне инде җиде яшьлек кыз балалары гүр иясе булды. Тагын бер атна да үтмәгәндер, олы малайларын зиратка илтеп күмеп кайттылар. Шундый дагын әшәке Әҗәл иярләште авылга, бер өйгә килеп кердеме, һәммәкәйсен бер очтан кырып чыкмыйчан һич кенә дә туктамый. Бер айдан Пәттәхнең катыны җан тәслим кылды. Халык анысына аһ итәргә өлгермәде, авылда тазалыгы, гайрәтлелеге белән дан тотка: балта остасы Пәттәх үзе теге дөньяга китеп барды. Алтмыш биш яшьтә генә ие әле. Авыл исәбенчә йөзне тартырлыгы барые.

Авыл старостасы белән дисәтнек, әлеге мәрхүмнәрнең ишек-тәрәзәләренә аркылы такта кагып, өйне яптылар. Алланың биргәненә шөкер, шуның белән эш бетте дип торсалар, Әҗәл дигән явыз мөртәт-бәдбәхет, муены астына килгере, бер атнадан күрше йортны кыра башлады. Бер ай тула дигәндә анысының да ишегенә аркылы такта кадаклап куйдылар. Халык йөрәгенә шом төште. Авыл тынып, үлемен көтә башлады. Көтәргә сабырлыгы җитмәгәннәре аркасына капчык асып, Себер ягына урман кисәргә, сал агызырга, шахталардан җир күмере белән алтын чыгарырга китеп барды. Киткән берсе хәбәрсез югала — прәметеки галәмәт аптырамыш! Таминдар бай булып Таминдар бай хәсрәткә төште. Чаллыга, ди, Сарапулга, ди, Казан каласына, ди, агачны, ди, мин кем белән агызырмын?! Үлем афәтеннән куркып, Тәкмәк-Чүрәкәйләр генә түгел, Балтачлар, Салагышлар, Саранбайлар кузгалды, бөтенләй урман эченә, үлемнең буе җитмәс наратлык арасына поскан Яуморзаларга курку төште. Алабуга бояры Стахиевның тол бичәсе, Казанга, генерал-губернаторга барып, нишлик икән дип киңәшкән, имеш. Губернадан халык чыгып бетсә, мин үземнең сыра заводларыма рабучи сыйныф каян табармын дип кара кайгыга төшкән. Халыкның Әҗәлдән качуын берәр төрле әмер яки фәрман белән туктатып булмасмы, ди, имеш. Таминдар Тураев шушы арада үлем хастасыннан губерна халкын коткарып калу өчен татар байларын җыясы, ди, акчасы бер миллионнан да ким булмаганнар һәммәкәйсе бергә җыелып, дөньяның иң атаклы табипларына бик зур байлык вәгъдә итеп, гариза-үтенеч җибәрәселәр, ди.

— Шуннан, шуннан? — дип сабырсызланалар шәкертләр.

Шәрифҗан әле вакыйганың нәрсә белән беткәнен әйтеп бирергә ашыкмый. Әҗәл явыз мөртәт-бәдбәхетнең Казан заводларыннан, Ижаудан, Алабуга белән Чистайдан кешеләрне кырырга план корып ятуын озаклап сөйләп китә, тик шәкертләр тагын сабырсызлана башлагач, янә дә Тәкмәк-Чүрәкәйгә кайтып төшә.

— Әҗәл өченче йортны кырырга тотынгач, авыл халкы төрлечә юрый. Нәрсә бу? — диләр. — Ходаның нинди каргышы төште безгә? — диләр. — Югыйсәң, безнең Тәкмәк-Чүрәкәй явызлыгы белән дан алган авыл да түгел. Гомер буе иген игеп, чабата тукып, көянтә бөгеп көн күргән авыл. Язга чыксалар — бура бурарлар, көзгә керсәләр — Тәкмәк күленнән алган мунчаладан чипта сугарларые. Каныкты бит Әҗәл безнең Тәкмәк-Чүрәкәйгә. Бөтен өязгә атаклы ат каракларыда, күбенгәнче аракы эчәрдәй дуңгыз көтүчеләре дә юк бездә. Бердәнбер зимагур Байгыш барые, аны да Өфе белән Бөгелмә чуен юлында, кәртле уйнап оттырганнан соң, түләр акчасы булмагач, поездан ыргытканнар дип сөйләделәр. Озын сүзнең кыскасы — Әҗәл явыз мөртәт-бәдбәхет ник безнең авылга каныкты — беркем берни белми, и шулай ук беркем бер

ничек каршы тора алмый. Әҗәл синең йортыңны сайладымы, кыра да сала — вәссәләм. Ярман сугышы башланганга ике ел уздымы-юкмы, Әҗәл рәхимсез кулы белән Тәкмәк-Чүрәкәйнең унбиш йортын кырды да салды.

Чират уналтынчы йортка килеп җитте бит инде!

Боларның, мин сиңа әйтим, нәкъ шул көннәрдә, Ярман сугышыннан агач аягын шакылдатып, солдат уллары-җанвалит кайтып төшмәсенме! Яман хәтәр гайрәт ора бу! Юл куймам, ди. Үземнең гарип булып калганым да җитәр, ди. Ат суя торган пычакны тегермән ташында кайрый. Бер көн кайрый, ике көн кайрый, өч көн кайрый. Әллә Әҗәл мөртәт-бәдбәхет сизенгән, әллә инде адәм җанын кыеп йөрү кебек, дөньядагы иң әшәке, иң пычрак эштән җаны бизә башлаган — килми. Ярый, хуш: егет һаман да кайрый бит, җиде көн, җиде төн кайрый, пычакны прәметеки Гали пәкесе итеп кайрап җиткезә бу. Өйдәгеләр җиде төн уртасында колһу аллаларын әйтеп, ишек-тәрәзәләргә бастырык бастырып, аңа гына да риза булмыйча, кат-кат бисмилла укып, сыпырынып йокларга яталар. Солдат-җанвалит йокламый. Прәметеки күзен йокы алмый. Әти-әнисенең, энекәшләренең аяк очында утырып тора. Кулында ат суя торган пычак. Тәрәзәдән ай нуры төшә, пычак ялтырамасын дип, солдат-җанвалит аны шинель җиңе эченә тыгып асрый. Әҗәл явыз мөртәт-бәдбәхет килгәнне көтә бит инде пычак...

— Пычак турындагысы аңлашылды, әҗәл турындагысын сөйлә, — дип, сүз кыстырып җибәрә Солтан.

Нух Галләмнең иләмсез каты кулы Солтанның муен тамырына кагылып ала:

— Тик кенә утыр, хәерче бете!

Солтан куырылып килә, эш зурга китүдән куркып дәшми.

— Кай төштә туктаганыем әле? — ди Шәрифҗан.— Әһә, пычакны шинель җиңенә яшереп, сәке буенда утырып тора солдат-җанвалит. Башында папахасы, өстендә шинеле — Микулай патша армиясеннән алып кайткан. Төн урталары уза, беренче әтәчләр кычкырыр чак җитә, солдат- җанвалитның тәмаммы ачуы чыга башлый, беренче әтәч кычкырдымы — җен-пәриләр килми, куркып кача торган була бит. Солдат-җанвалит соңгы сабырлыгын җыеп көтә. Менә бер заманны ишеккә салган беләк юанлыгы бастырык «келтер-ррр!» итеп кенә китә дә тавыш-тынсыз ишек ачыла. Ишектән төенчек чаклы гына бер карчык килеп керә. Кап-карадан киенгән. Үзе, җитмәсә, бөкре, җитмәсә, күзләре, мәче күзе шикелле, ут яна, солдат-җанвалит, беренче мәлгә, шүрләп тә куя. Әмма дә ләкин шүрләгәнен сиздерми, пычакны шинель җиңенә яшереп саклап тора. Әлеге күзе ут янып торган бөкре иң кырыйда яткан малай янына килә.

— Гафият Бөкре түгел микән?! — дип кычкырып җибәрде авызын ачып тыңлаган Әптери. Нух Галләмнең аяусыз каты кулы бәләкәчне тынсыз итте:

— Тик кенә утыр, тишек борын!

Әптери борынын алача күлмәгенең җиңенә төртеп, мышык-мышык елый башлады, төрле яктан ысылдап, аны шундук туктаттылар.

Шәрифҗан Әптерине үзенә якынрак тартып сыендырды да сүзен дәвам иттерде:

— Юрганның итәген генә ачып, солдат энесенең табанын ялый башлый бөкре. Чалт-чолт ялый. Солдат-җанвалит моны ишетеп тора, йоклаганнар берсе дә ишетми бит инде... Солдатның энесе әкрен генә ыңгырашып куя, шул җитә солдатка, сикереп тә төшә сәке йөзлегеннән, пычакны бөкренең йөрәгенә тыгып та җибәрә!

Бөкре үсә-үсә, зурая, күперенә, күбенә, иллә дә мәгәр, күперенү-күбенүдән ары уза алмый, кара чапанын ачып, бөкрәеп төшә, пычак кадалган урынын озын тырнаклы кара кулы белән каплап:

— Ай, улым, хараплар иттең, хараплар иттең карчык кешене, —ди.
— Ә солдат нәрсә ди? Солдат нәрсә ди?
— Бүлдермә, кәҗә катыгы!
— Ә син әрекмән боламыгы!
— Яңагыңнан чакма кабызып алырмын, хәчтерүш, бер телеңә баш булмасаң!
— Ә нәрсә кәҗә катыгы, ди! Безнең кәҗәбез булганы да юк.
Әкренләп тыналар. Шәрифҗан, берни булмагандай, гамьсез-ялкаурак тавыш белән экиятен ялгап алып китә:
— Солдат дәшми. Ул бит белә, убыр белән япа-ялгызыңа дипломатиягә керергә ярамый. Күрдеңме, ул хәл җыя, сүзе белән сине сихерли, табан астыңны ялап, каныңны эчә башлый...
Бөкре карчык тавышсыз гына борыла, ишектәге беләк юанлыгы бастырык «келтер-ррр!» итеп кенә ала да, бүтән берни ишетелми: Әҗәл явыз мөртәт-бәдбәхет юкка чыга.
Иртән солдат гаиләсе уяна. Барысы да исән. Убыр бит малайның табан астын имеп бетерә алмады. Бар да сөенәләр инде болар. Солдатҗанвалит күршеләрен җыя. Менә шулай-шулай булды дип җиде төн уртасында күргәннәрен сөйләп бирә. Тәкмәк-Чүрәкәйләр, авыллары белән, убыр киткән юлны карарга чыгалар. Ак кар өстендә убырдан кан тамып калган икән, әнә шул канлы эздән бара торгач, күрше авылы Саранбайларга барып чыгалар. Җиргә чүгеп беткән тәбәнәк кенә бер өйгә керәләр. Керсәләр — өй шып-шыр. Мичтән башка берни юк. Ә мич галәмәт дәү, прәметеки ярты өйне алып тора. Мич башыннан ыңгырашкан тавыш ишетелә. Менеп карасалар, тау чаклы булып күбенгән-бүртенгән, җирән чәчле, җирән мыеклы, мимечкә охшаган берәү ята.
— Теге убырмы?
— Шул инде, шул!
— Ә нишләп ул мыеклы? Ул бит карчык ие?
Бүлдерүче малайга ике мендәр тондырдылар.
Пырхылдап каз мамыгы очты.
— Сөйлә, Шәрип,— диде Мирзаян.
— Ярый, хуш. Җирән мыеклы убырны мич башыннан сөйрәп төшерәләр. «Ярты авылны кырдың, бәдбәхет, синең аркада нинди әйбәт балта осталары, чыптачылар, көянтә бөгүчеләр, тугымчылар әрәм булды, басуда игеннәр чәчелми калды, күпме кеше кара җир куенында ята!»— дип битәрлиләр, битәрлиләр дә, идәнгә салып, бөтен авыл бергә таптап үтерәләр. Мәетен ерак басудагы бүре чокырына илтеп, таптый-таптый күмәләр. Ләхет-мазар алып тормыйлар, буйга өч аршын, тирәнлеге ике аршын чокыр казыйлар да, чокыр төбенә йөзтүбән каплап, башына имән казык кагалар.
— Ә имән казыкны ни өчен кагалар?
— Вәт тиле. Убыр бит ул тиз генә үлми, чокырдан чыгып йөри ала.
— Чистый! Чыккач тагын хәл җыеп авылларны кырып йөри башласа?
— Шуннан? Шуннан?
— Нәрсә шуннан? Шуннан шул инде: убыр оясыннан чыга алмый. Кешеләрнең канын имеп йөри алмый. Солдат авылны афәттән коткарып кала.
... Куркыныч вакыйга сөйләнеп беткәч, бәләкәй шәкертләр, эчләреннән тынып, әле һаман башына казык кагып күмгән убыр тәэсиреннән айный алмыйча, озак кына утырып торалар.
Мирзаян үз алдына көрсенеп:
— Кайчан килер икән ул көн? — дип, әкрен генә әйтеп куя.
Тышта, тәрәзә артында, караңгы, анда әллә ничә убыр берьюлы кузгаткан җилләр сызгырына, кайдадыр еракта шушы шәкертләрнең әтиләре, абыйлары убырлар белән сугышып йөри. Дәшми шәкерт хал-

кы. Һәм әле бик озакка чаклы ялгызы гына ишегалдына чыгарга куркып иптәшен чакырып яши, йомыш белән төркем-төркем генә чыгалар. Суыктан, суыктан бигрәк чат башларында, караңгы урамнарда сагалап торган убырдан куркып-калтыранып, барысы бергә, кумәкләшеп йоклый торган зур бүлмәгә ашыгалар.

Курку хисе мәктәп-мәдрәсәдә яңа бер вакыйга булганчы дәвам итә.

## II

Язын, кар эри башлагач, шәкертләр мәктәп-мәдрәсәдә килеп чыккан бер кыргый күренешнең шаһиты булдылар.

Мәктәп-мәдрәсә тирәсендә биек итеп бозлавык-тау ясалган иде. Тауның итәгендә әрәмәлек, әрәмәләр арасында челтерәп чишмә ага, аның суы кыш көннәрендә дә туңмый кала иде.

Чаналары булмау сәбәпле, бәләкәй шәкертләрнең күбесе бишмәт итәгенә утырып шуа, хәлфәләр күрмәгәндә мәдрәсәдән эскәмия сөйрәп чыга, я берәр тапкыррак шәкерт, абыйлары сугышта булу сәбәпле лапас астында коргаксып яткан зур чананы сөйрәп алып килә дә, дәррәү шуңа төялеп, чыр-чу килеп, юлда очраган кар көртләреннән өермәләр өереп төшеп китәләр.

Солтан белән Әптери бер көнне каравыл өе лапасында аунап яткан иске чананы сөйрәп алып килделәр. Төялде бала-чага, төялде бала-чага! Киттеләр, мин синайтим, боз тавыннан элдертеп! Ул чыр-чу, ул сөенеч! Ат чанасы, бураннар уйнатып, менә авам, менә таралам дип тау астындагы зиреклеккә кадәр төште дә, вак әрәмәләрне сыдыртып узып, юан бер зирек төбенә килеп бәрелде. Ак кар өстенә, чүлмәкләр төсле, шәкертләр тәгәрәшеп китте. Алай гына булса бер хәер иде, кар астыннан кәрзине белән сыра шешәсе шалтырап килеп чыкмасынмы!

Бала-чага, кызык ясап, кәрзинне шешәсе-ние белән күтәреп чаптылар, шешәләрне кар өстеннән тәгәрәтеп уйнадылар, аннары юанрак бер зирекне сайлап, шуның кәүсәсенә ыргыта башладылар. Моның ахыры никадәр ямьсез бетәсен башларына да китереп карамадылар.

Эш Сөләйман хәзрәткә барып иреште.

Каян килгән шешәләр?

Кем сыра эчкән?

Кем кәрзинне әрәмәгә күмеп куйган?

Сөләйман хәзрәт иң турылыклы мөрите — Фатих хәлфәне үз янына чакырып, икәүдән-икәү генә киңәште. Сыраны бүтән беркем дә түгел, олы шәкертләр эчкән, эзне яшерер өчен кәрзинне әрәмә төбенә күмеп куйган дигән ныклы фикергә килделәр. Ни чыкмаса шул шәкертләр белән ыстудиннардан чыга. Дөнья болгатучылар! Мәңгелек сабак булсын, бүтәннәрне дә әшәкелеккә өйрәтеп йөрмәсеннәр, каезларга сыртларын!

Кече атна көнне мәктәп-мәдрәсә кайнап торган кырмыска оясына әйләнде. Зур кибән чалмасын башына ураган, кулына чукмар башлы озын кара таягын тоткан, буй-буй яшел чапанлы, мәһабәт ак сакаллы Сөләйман хәзрәт шәкертләр яши торган, сабак укый торган, олы шәкертләр йоклый торган бүлмәләрне берәм-берәм йөреп чыкты.

Берәүнең дә сәламенә сәлам бирмәде.

Аңа ияреп, көтүләре белән хәлфәләр, Югары мәхәллә картлары йөри, алар да ләм-мим сүз дәшмиләр иде.

Хәзрәт әмере белән Нух Галләм бер олау тал чыбыгы кистереп, аны кайнар суда пешекләтеп куйды; хәзрәт әмере белән ике хәлфә озын ике сөлгене бау итеп иштеләр.

Төш вакытларында учитель Гаврилов, сары мыекны бик хәтәр кабартып, барлык укучылар-шәкертләр белән исәнләшеп, дин әһелләре йөргән бүлмәләрне йөреп чыкты.

Бераздан аның Фатих хәлфә бүлмәсендә:

— Әгәр сез экзекуциягә юл куясыз икән, мин бу эшне болай гына калдырмыйм, земствога хәбәр итәм, губерна газетасына язып чыгам! — дип, ачы тавыш белән кычкырганын ишеттеләр.

Бераздан ул, хәлфәләр бүлмәсеннән килеп чыкты да, тар якалы пальтосының чабуларын җилфердәтеп, коридор буйлап китеп барды. Чырае бик усал, иреннәре кысылган иде.

Кичке сәгать сигезләрдә Фатих хәлфә кечкенәләрне аерым бер бүлмәгә кертеп япты — ишекне тышкы яктан келә белән бикләде. Хәлфәнең чыгып китүе булды, Зартугай малае Шәкүр, Кече елгадан Әптери, төймә борын Әхмүш ишекне чыра пычагы белән ачтылар да аяк очларына гына басып коридорга чыктылар — стена буена тезелделәр. Алар янына Солтан чыгып басты.

Ишелгән сөлгенең ялангач аркага туп аткандай шапылдап килеп төшүе, тал чыбыгының чажылдап һаваны телүе, ыңгырашу-елау, ачыргаланып кычкырып җибәрүләр бәләкәйләрнең берсен дә тыныч калдырмады. Алар, берәм-берәм килеп, җәзалау эше барган ишек төбенә өелделәр. Бүлмәдән ишетелгән ыңгырашуларга йомшак күңелле Әптери түзә алмады — елап җибәрде. Солтан белән Әхмүш, аның авызын учлары белән каплап, киредән бүлмәгә алып кереп киттеләр.

Караңгы бүлмәдә алар кергәндә тагын берничә бәләкәй шәкерт, кыйналучыларны кызганып, мышык-мышык елап утыралар иде.

Ул да түгел, кемдер ашыгып бүлмәгә килеп керде. Шәкүр белән Әхмүш, үз почмакларына посып, башларын мендәр астына яшерделәр — Фатих хәлфә түгелме дип курыктылар.

Ләкин бүлмәгә кергән кеше хәлфә булып чыкмады. Аның әллә ничек рәнҗеп, буыла-буыла сулыш алуыннан, кармаланып, әйберләргә абына-сөртенә йөрүеннән шәкертләр аңлап алдылар — әкиятче Шәрифҗан, үз якларын саташтырып, бәләкәйләр ягына килеп кергән икән...

Идән сайгакларын шыгырдатып, тагын кемдер керде. Йөрү рәвешеннән Салагышның Усал Зариф икәнен абайладылар. Ул караңгы бүлмәне бер айкап алгач, ярсулы тавыш белән:

— Сөләйман палачның анасын өшкермәсәм, исемем Зариф булмасын! — диде. Бүтән сүз әйтмәде, ишекне каты ябып чыгып китте.

Бүлмә эче тынып калды. Айны болыт каплаганга һәм ут алмаганга, йөрәкне баса торган шомлы караңгылык бәләкәйләр бүлмәсендә бик озак сакланып торды.

Солтанның күңеле ярсыган, күзенә йокы керми, башында хәвефле уйлар, шыксыз күренешләр болгана, ул бу минутларда үзенең дә кыйналган дәү шәкертләр арасында булмавына үкенә иде.

Ул күрше бүлмәләрдә тавышлар тынып беткәнче йоклый алмады. Алабугада үткәргән көннәре, Нурия белән җитәкләшеп, Ерзовка иллюзионына барулары, биш йөз потлы бакыр кыңгырау хакында бәхәсләшүләре исенә төште. Чаң тавышыннан җиргә чүккән атлар, улап елаган марҗалар, пристаньга таба агылган халык төркеме тузан-томаннары белән, төс-бизәкләре белән, акыру-бакырулары белән күңелендә буталып күз алдында торды. Аннары ул Нуриянең инде Зартугайда булмавы, Пәнҗәр дигән урыс авылына укырга китүе хакында уйлап ятты. Үтереп эче поша, күңелен сагыш баса башлады. Нурия, Солтан кебек, ярлы баласы түгел шул, мулла кызы. Мәхдүмә диләр аны! Теләсә, әтисе аны Петербургка илтеп укыта, теләсә Таминдар бай малаена кияүгә бирә ала... Юк, Солтан аның бай малаена кияүгә чыгуын теләми. Ә ник теләми? Ул барыбер Солтан белән бергә булмый бит инде. Кемгә кияүгә чыкса да, барыбер түгелмени? Их, менә хәзер Солтан янында Шәяхмәт абыйсы булсын иде. Менә ул, ичмасам, нишләргә кирәген әйтеп бирер иде. Юк шул, юк аның янында Шәяхмәт

абыйсы, нишләтәсең аны — Иш суына баш түбән ташланасыңмыни?! Ул ерак инде Солтаннан, ул инде әллә кайларда, сугыш утларында... Хәбәр-хәтере дә юк, исән микән, сау микән?

Күзен шар кебек ачкан килеш, әрнегән йөрәген кулы белән басып, Солтан караңгы түшәмгә төбәлеп ятты. Бүлмә эче әүвәлгечә үк караңгы, таң атарга ерак иде әле.

Дәү шәкертләр ягыннан кемдер ыңгырашып куйды. Аңа теләктәшлек белдергәндәй, бәләкәйләр арасыннан берсе йокы аралаш сулкылдап алды һәм бүлмә эче тагын шәкертләрне бер-берсеннән аерым итеп сиздерә торган шомлы караңгылыгы белән торып калды.

Солтан бәләкәй йомышы белән ишегалдына чыгып барганда Усал Зарифның аяк киемнәре саклана торган салкын коридорда кара күләгә булып басып торганын күрде; култык астында талдан үргән кәрзин иде. Якынлашып килүчене сизгәч, колакчын бүреген күз өстенә үк басып, ишектән чыгып китте.

Шәкертләр арасында атна буе Усал Зариф турында имеш-мимеш йөрде. Янәсе, ул мәктәп-мәдрәсәгә ут төртәчәк, үзен кыйнаган Сөләйман хәзрәт белән Нух Галләмнән үч алачак.

Шәкертләр атна буе әнә шул өметле-шомлы хәбәр белән яшәделәр. Ләкин Усал Зариф үзе дә, ул төрткән ут та күренмәде. Мәктәп-мәдрәсә тагын көйләп-көйләп укыган догалар, мендәр атышып сугышулар, бишмәт итәгенә утырып тау шуулар кебек көндәлек мәшәкатьләренә күмелде.

Сугыш җиреннән кешеләрнең үле хәбәрләре килеп торды.

## III

Борынгылар белеп әйткән: олы каза беркайчан да ялгызы гына йөрми, үзе белән кече казаны да ияртеп алып килә.

Сугыш афәтенең Зартугай өстенә кара кайгы булып ятуы гына җитмәгән иде, уналтынчы елның язы авыл халкына яңа бер мәшәкать өстәде.

Кама иделе быел, гомердә булмаганча, иләмсез бер дуамаллык белән кузгалды: юлында очраган ярларны җимерде, йөз яшәр өянкеләрне, тирәк-карамаларны төбе-тамыры белән актарып ташлады, урман кишәрлекләрен агачлары-ниләре белән умырып алып, актарылып-шашынып аккан чоңгылына сөйрәп төшерде.

Оясыз калган козгыннар, болыт-болыт булып, ачы тавышлар белән каркылдашып, һәлакәт упкынындагы агачлар артыннан ияреп бардылар.

Баштарак, беренче көннәрне, дәрья суларының шашынып актарылуына хәтта сөенгәннәр иде. Бәлки хәерлегәдер, бәлки илгә җиңеллек килер, кайгы-хәсрәт язгы бозлар белән агып китәр дип өметләнгәннәр иде.

Китмәде хәсрәт, яңалары өстәлде.

Дөбер-шатыр килеп, ярсып-дулап бозлар агып бетүгә, Кама суы күзгә күренеп арта башлады. Арта-арта җәелде, киңәйде, болыннар, үзәннәр буйлап китте.

Кама суы Иш елгасына бәреп керде, югарыга таба күтәрелә башлады, Зартугайның болыннарын, болын буе бакчаларын күмде. Аның белән генә дә чикләнмәде, халыкның котын алып, урамнарны, ишегаллларын су басты.

Гомердә булмаган бу хәл Зартугай халкын ике кулсыз итте.

Күрше күршегә керә алмый интегә; тез тиңентен су эчендә калган сыерлар иртәсен дә, кичен дә дөнья бетереп мөгриләр; әтәчләр йокы аралаш суга егылып төшеп, яман ачы тавышлар белән кытакларга то-

тына; утыннары су эчендә калган кешеләр мич кабыза алмый интегеп бетәләр иде.

Бәла килде дип кул кушырып утырып булмый. Ындырга чыгарга, какшаган читән-койманы ныгытып куярга кирәк, югыйсә, су бөтенләй агызып алып китүе бар. Аякка кияргә күн итек юк, бөркәнеп чыгыйм дисәң кәжән юк — аптырамыш. Садыйк абзый кебек ярлы-ябагай су аз булган башка елларны гомер эчендә бер килеп чыккан тәҗел йомышын үтәргә күршесеннән көймә сорап тора торган иде, быел көймә һәркемнең үзенә кирәк, шуңа күрә аңа да Солтан белән икәүләп барлы-юклы бүрәнәдән, такта-токтадан сал әмәлләргә туры килде. Шул салны колга белән этеп күршегә керәләр. Таминдар бай кибетенә тоздыр, керосиндыр ише нәрсәләр алырга баралар.

Сунын ишәюе Таминдар байга ифрат та кулай булып чыкты. Камада сал кууны, тирә-юньдәге өяз калаларын агач белән тәэмин итүне өстенә алып, ул Тугызбуй төбәгендә урман кистергән иде, хәзер шул агачны су кимегәнче дип Иш буендагы аяклы амбары янына су юлы белән генә китертә башлады. Шунда берррәттән сәүдә эшләрен дә онытмады. Кыш буе келәттә яткызган олау-олау сабынын сигез-тугыз авылдагы кибетенә бүлеп биреп, бәясен икеләтә арттырды. Тозны чыгарырга ашыкмады, тыныч-имин елларны Урал ягыннан ташыткан тозы таутау булып келәтләрендә ята бирде, тагын бераз сабыр итсә, ул аны өчләтә кыйбат бәягә сатачагын белә иде.

Халык арасында ризасызлыклар, мыгырданулар башланды. Колга белән көчәнә-көчәнә сал этеп тә Таминдар бай кибетеннән ашка салырлык тоз алып кайта алмаган Садыйк карт бик хәтәр карганды:

— Иман юк кешеләрдә! Көпә-көндез тиреңне тунарые, валлаһи! Иех, дөньясы, эт оясы, лач итеп бер төкерерием дә, әйләнеп тә карамый китеп барырыем.

— Кая китәсең? Дөньясын су басты бит, — дип йомшак кына сөйләнә Мәүдүдә җиңги.— Киям дисәң күн итеге юк, бөркәнәм дисәң кәҗәне юк. Ашны тагын тозсыз пешерербез микәнни инде бүген?

Су атна буе китми торды. Ул арада Югары очтан да, Түбән очтан да үлгән маллар, агып киткән читәннәр, җимерелгән лапаслар хакында да сүз ишетелә башлады.

Мәзин азан әйтүне киметтe — иске көймәгә утырып мәчеткә чыгу— зур бер мәшәкать. Зартугайлар Тәкыймулла тавышын атнага ике мәртәбә генә ишетәләр. Ул да халыкка җитә калды:

— Илдән бәрәкәт оча. Изге дога ишетергә дип салдырган мәчетләребез башында козгын каркылдап утыра. Менә күрерсез, сугыш җирендә мәетне әрдәнәләп өя башларлар, аларның җаннары анда дога өмет итеп тилмереп ятыр!

Апрельнең унберендә, көндезге сәгать берләр тирәсендә, Садыйк картларга Нәбкәй староста белән Салагышның Кысык Минҗан килеп чыктылар. Аларны бик ныгытып сумалаланган зур кара көймә белән десятский Дөмеки китерә килде.

Нәбкәй старостаның капкага таяк белән суккан тавышына Садыйк абзый өйттән чыкты, улы кайтты дип уйлап:

— Нәрсә капка кагып маташасың? Ач та кер! Кулың корымагандыр бит! — диде.

Капка келәсе күтәрелеп, кече капкадан Нәбкәй старостаның кама тоткан кара бишмәте һәм ак калайлы түше күренгәч, Садыйк карт каушый калды:

— Солтан дип торам бит, кибеткә китеп Дөмекте, хәерсез, сыртына таяк белән саласы нәрсәкәй,— дип болдырдан торып сөйләнә башлады.

— Нәрсә син анда көчек кебек өреп торасын? Ач капкаңны! — диде Нәбкәй староста.

— Бик ачарыем да, Нәбиулла абзый, аягымда киез катадан башка бернәрсә дә юк шул, агач башмагымны малай киеп киткәнне...

Десятский күпме генә кӫтсәң дә, капканың ачылмаячагын, Садыйк картның язгы суга киез катадан барып кермәячәген аңлап, капка ачу әмәленә үзе кереште: тырыша-тырмаша торгач, капканың келәсенә менеп атланды, ике аягы белән капка баганасын кочаклап, бастырыкны этеп төшерергә итенә башлады.

Ләкин бастырык тыгыз итеп тыгылган, өстәвенә, дым белән бүрткән, Дөмеки кебек көчле кеше дә аны бер кул белән генә этеп төшерерлек түгел иде.

Болдырда басып торган Садыйк карт, тула чикмәненең чабуларын ике кулы белән күтәреп, очып китәргә кагынган ябалактай талпынып, Дөмекигә киңәш биреп тора башлады.

— Үзеңә тарт син аны, Динмөхәммәт. Юк ла, бер кул белән булмый аны. Ишетәсеңме, алла бәндәсе! Булмый дип әйтәләр бит инде сиңа. Күрмисеңмени, күзең чыкканмыни? Бастырык бүрткән, ике куллап тарт, сиңа әйтәм, Динмөхәммәт, ике куллап тарт, кая соң, нишләп соң... шуңа да көчең җитмимени?!

Дөмеки, Садыйк картның акыл биреп торуына соң дәрәҗәдә ачуы чыгып, артыграк тырышып җибәрде бугай, капка баганасын кочаклаган аягы шуып китте дә, үзе шапылдап суга барып төште. Җан-фәрманга кычкырып, сикереп торды:

— Өйрәтеп торган була, анаңны... бастырык белән ярасы! Хуҗа, имеш, болдырга чыккан да каткан, төшеп ачып кертсәң...

Ул, озын кунычлы күн итеге белән су шупырып, капка бастырыгына килеп асылынды, бастырык ычкынып, ике капка ике якка шыгырдап ачылып китте, һәм Нәбкәй староста белән Кысык Минҗан, зур кара көймәне этә-этә, болдыр төбенә килеп туктадылар.

Садыйк карт кунакларны каршы аласы урында никтер өенә кереп китте.

— Мәгънәсез ахмак! Хәерче танау! Әдәм рәтле каршы ала да белми, имансыз! — дип сукранды моңарчы түзеп торган Кысык Минҗан.

Садыйк карт, өйдән олтанлы киез итек алып чыгып, десятский Дөмекигә тоттырды, тегесе болдырга утырган килеш, чәрәшә-чәрәшә күн итеген салып, шобырдатып суын түгәргә, чолгавын һәм кара ямаулы ак оекбашын сыгарга кереште.

Ниһаять, Дөмеки аягына олтанлы киез итекне киеп алгач, барысы бергә күрешә башладылар. Күрешү, элекке тыныч заманнардагыча, күтәренке, шау-шулы булмады, Нәбкәй староста Садыйк картның биргән сәламен мыек астыннан мыгырданып кына кабул итте дә, тәбәнәк ишеккә башын бәрә язып, эчкә узды. Аның артыннан Кысык Минҗан белән Дөмеки дә килеп керделәр.

Өй эче фәкыйрь булса да пөхтә, мич ап-ак итеп агартылган, ак калай белән ямалган сары самавыр кучкарда тора, тәрәзә өсләренә, матча һәм колга турыларына бизәкле кызыл ситсыдан кашагалар эленгән иде. Тәрәзә пыяласы ватылган берничә өлгегә карындык тарттырганнар — ике катлы тәрәзә аркылы ул карындыклар Кысык Минҗан күзенә бәйләгән кара чүпрәк төсле күренә иде.

Садыйк карт көтелмәгән кунакларның әле һаман да нинди ният белән килүләрен аңлап җиткермәгәнлектән, ашыгып-кабаланып, түрдән узарга чакырды, корама чүпрәкләрдән теккән киез-көрпәләрне кунакларның дәрәҗәсенә карап, сәке йөзлегенә куеп чыкты.

Шуның белән ике арада иминлек урнашты шикелле.

Рәвешен китереп, кул күтәреп дога кылдылар.

— Я, Садыйк, ни эшләр җимертәсең, авырмыйсыңмы? — дип ерактан сүз башлады Нәбкәй староста.

— Авыруын авырмыйм да, шулай да хәлләр бигүк әллә кем түгел

әле, Нәбиулла абзый, — дип түшенке генә җавап кайтарды Садыйк карт һәм, сирәк сары сакалын бирчәйгән бармаклары белән аралаштыргалап, Нәбкәй старостага төбәлеп калды. Сез, янәсе, нинди йомыш белән йөрисез? Юньле йомыш беләнме? Ай-һай, Садыйк йортына староста белән десятскийның икесе берьюлы килмәгәненә биш былтыр бардыр инде...



Нәбкәй староста Садыйк карттан алай тиз генә сүз алып булмаячагын белә иде, шуңа күрә әле байтак утырырга туры киләчәген чамалап, кама якалы кара бишмәтен сала башлады. Аңар ияреп, Минжан белән Дөмеки дә кайсы кайры тунын, кайсы бишмәтен салып, сәке йөзлегенә куйды. Колакчын бүрекләр дә салынып, түбәтәйдән генә калдылар. Кышкы киемнән тирләп өлгергәнгәме, алар бишмәт-бүрекләрен салуга, болай да бөркүрәк бәләкәй өйгә тир исе мул булып таралды.

Әллә шул исне сизеп, әллә вакыты җиткәнгә, ишек катынарак бәйләп куйган үгез бозау корсак асты җебеннән нечкә генә итеп чаптыра башлады.

— Һай, мөртәт, вакытын гына көтеп тора бит, — дип, Садыйк карт идәнне юешләттермәс өчен, башта бозауның сыртына учы белән җиңелчә сугып, аны шөгыленнән туктатты, аннары чүлмәк алып килеп, бозауның эше беткәнче бөкрәеп көтеп торды. Хатыны Мәүдүдә почмак якта ир-атка күренми утыра, анысы бозауның тәртип бозганын белсә дә чыгарга базмый иде.

— Алай икән, эшләр шәптән түгел дисең инде, — дип Нәбкәй староста тагын сүзне ерактан уратып башлады, әмма аның чал сакалын гасабиланып сыйпап куюыннан һәм күпне күргән каеш түбәтәен артка чигереп, җилкә чокырын кашып алуыннан Садыйк карт бу көтелмәгән кунакларның юк-бар йомыш белән генә килмәгәнлекләрен аңлады.

— Нәүширвән картның ике малае да үлгән! — диде Нәбкәй староста.

Хәбәр Садыйк картка әллә ни тәэсир итмәде, сугышта үлгәннәрне көн саен ишетеп торганга, моны да гадәти бер хәлгә санап, ябыкконгырт кулларын — икесен берьюлы — битенә якын китерде, авыз эченнән пышылдап дога кылгач:

— Авыр туфраклары җиңел булсын. Бигрәк тә бәхетсез сәгатьләрдә туганнар икән, бичаракайлар,— диде.— Нәүширвән бабайны күрдегезме әле?

— Күрдек. Хәбәрен үзем китереп бирдем, — диде Кысык Минжан, күзендәге кара чүпрәкне рәтли төшеп.

— Нишләде? Бик хәлсезләнмәдеме?

— Нишләсен... Мин хәбәрне әйткәч тә башын селки башлаганые, мин киткәндә дә башын селкеп калды.

— Тагын нинди хәбәрләр бар? — диде Садыйк карт.

— Тегермәнче Чишмәнтәй плин төшкән.

— Анысын каян белдегез?

— Салагышның Усал Зариф аягын өздереп кайтты. Шуның белән бергә булганнар. Бер дә генә сугышырга теләмәде, берәр ай азаплангач та, ике кулын күтәреп, мимечләр ягына йөгерде, ди.

— Мимечне бик кансыз, диләр, анда чыгып отармы соң ул?

— Адәм баласына кайда да бер инде: тамагы тук, өсте бөтен булса, шуннан артыгы ни кирәк. Кем белә, еллар иминләнеп китсә, плинниләрне алмашкан чакта, бәлкем, кайтып та килер. Туп җәдрәсеннән үлгәнче, ярман җирендә исән калуың да ихтимал бит әле...— дип сүзләренә беркинди тойгы да салмыйча коры гына итеп әйтеп куйды Кысык Минжан.— Сезнең ничек соң, Садыйк? Энең Шәяхмәттән хәбәр-хәтер юкмы? — Як-ягына каранып алды. Нәбкәй староста белән десятский Дөмеки дә сабырсызлана башладылар.

— Туктагыз әле, сез нәрсәнедер әйтеп бетермисез, кунаклар. Сезгә миннән ни кирәк соң? — диде Садыйк карт шикләнеп.

Нәбкәй староста урыныннан торды:

— Бу араларда сиңа читтән берәү дә килмәдеме?

— Ул ниткән сүз? Кем миңа читтән килергә тиешле?

— Син сораганга җавап бир, Садыйк, чит кеше булмадымы синдә?— дип, чүпрәк бәйләүдән исән калган бердәнбер күзе белән акаеп карады Кысык Минҗан.

— Беркем дә килмәде, шөкер. Беркем дә килмәде. Туктагыз әле, нигә сез минем башымны катырасыз, туп-туры әйтегез: сезгә кем кирәк?

— Безгә кирәк кеше бер генә: синең энең Шәяхмәт,— диде Нәбкәй староста, Садыйк картның күзләренә туп-туры карап.

Садыйк карт җилкәсен җыерды, башын кырын салды:

— Ә нигә әле сез Шәяхмәтне минем өйдән эзлисез? Аның бит үз өе бар. Аннары килеп, сез бит аның сугышка киткәнен үз күзегез белән күрдегез. Хатыны Сара да авылда калмады, сугышка киткән чагында Алабугага китеп барды бит.

— Киткәнен күрдек, Садыйк абзый, ә менә кайтканын күрә алмадык,— диде десятский Дөмеки, сүзгә кушылып.

— Кайтканы юк бит аның!

— Кайткан ул. Синдә качып ята. Син аны безгә әйтергә теләмисең,— диде Нәбкәй староста. Ул, Садыйк картның каршысына ук килеп, сүзенә куәт өстәгәндәй, озын кара таягы белән идәнне тукылдатып куйды.

— Ни сөйлисез сез, алладан оялыгыз! Көпә-көндез нахак бәла яккан өчен, аяк-кулыгыз тартышыр! — диде Садыйк карт, тавышы калтырап китте.

— Ләчәнстуаның безгә биргән фәрманы шундый, Садыйк, без синең йортыңа тентү үткәрергә тиешле, — диде староста. Моны ул иң гадәти бер сүзне әйткәндәй әйтте. Әмма күзләре шундук бимазалы елтырый башладылар.— Десятский, нәрсә карап торасың? Ач сике астын, актар идән асларын.

Дөмеки, дәү гәүдәсе белән иелеп, сәке сайгакларын берәм-берәм әйләндереп салды, әрҗәгә утырган ана каз чит кешене күрүгә бик хәтәр ысылдап Дөмекинең иңенә килеп ябышты.

— Көш-ш-ш, нәгъләт, явыз токым! — Дөмеки куллары белән бутанды.

Идән асты капкачы почмак якта икән — Садыйк картка Мәүдүдә җиңгине аннан чыгарырга куштылар. Мәүдүдә җиңги битен яулык белән каплап, чоланга чыккач, Кысык Минҗан белән десятский өй астына төшеп киттеләр.

Садыйк карт идән ярыкларыннан фонарь утының яктысын күреп, күңелсез уйларын уйлады.

«Гомерлек хәсрәт булды бу Шәяхмәт. Кеше туганнары кеше төсле: сугыша, үлә, хәбәре килә. Моның үзе киткәч тә бәласе безгә тия. Тапмасалар, мине җавапка тартсалар, йа ходаем, бар икән күрәселәрем...»

Лапасны, чоланны, ат һәм сыер абзарларын — берсен бер калдырмый актарып бетерсәләр дә Шәяхмәт Айдаров табылмады.

— Син безгә рәнҗемә, Садыйк, ләчәнстуаның әмере белән без сине Салагышка алып китәргә тиешле, — дип башлаган иде Нәбкәй староста, Кысык Минҗан аны ярты сүздә өзде: — Нәрсә син, староста башың белән патша дошманын үгетләп торасың! Кулына богау сал да озат Алабуга өтермәсенә. Анда аның телен ача белерләр!

Садыйк карт кызганыч булып җыерылды.

— Картаймыш көнемдә нигә мине мыскыл итәсез? Шәяхмәттә минем ни дәхелем бар?

Аңа киенергә боердылар, ашарына ризык алдырып, көймәгә алып чыгып утырттылар.

Мәүдүдә җиңги картына кагылганчы ләм-мим бер сүз дәшмичә, түзеп утыра алган иде, әмма йорт башлыгын алып китә башлагач, түземе җитмәде, күз яше белән елап, кулларын сузып, ире артыннан чыкты:

— Йа, ходаем, миһырбанлы бәндәләр, Садыйкның ни гаебе бар? Алладан оялыгыз, хур итмәгез безне! — дип такмаклый-такмаклый көймә артыннан язгы суга шопырдап килеп төште.

Десятский Дөмеки аны өенә кертеп куярга теләгән, әмма зиһене чуалган Мәүдүдә җиңги, ир-ат бар дип тә тормастан, күлмәк итәкләрен күтәреп, ак ыштанлы, тула оеклы аяклары белән көймә артыннан язгы суны ерып килә иде.

Старосталар Мәүдүдә җиңги белән Солтан кайтып кергәнче азапландылар. Садыйк карт сал белән капка төбенә килеп туктаган улына:

— Әниеңне алып кер, алла хакы өчен алып кер, суык тидерә бит инде, мин хәзер кайтып җитәм, Салагышка гына барам мин, — диде.

Солтан керергә теләми карышкан әнисен өйгә алып керде, манма су булган оек-чуын салдырып, ястыкка яткыргач:

— Ни булды? Әтине кая алып киттеләр? — диде.

— Качкан бит, имансыз. Безнең башыбызга...

— Кем качкан? Кая?

— Шәяхмәт качкан. Сугыштан,— диде Мәүдүдә җиңги, сулкылдап.

Солтан шаккатып калды. Әле генә ишеткән хәбәргә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Сугыштан качкан кешеләрнең патша дошманы саналып, төрмәләргә, сөргеннәргә җибәрелүен аның ишеткәне бар иде, ул да аларны ябып кую ягында иде. Әмма абыйсы Шәяхмәт шул эшне эшләр дип башына да китерми иде. Туктале, ничек инде аның абыйсы патша дошманы булсын? Ул нинди киң күңелле, нинди эш яратучан иде бит. Ул салган «карванкаларны» берәү дә сала алмый, ул агызган салларны берәү дә агыза алмый, берәү дә аның төсле мавыгып Солтанның җырын тыңлый алмый иде. Андый кеше нишләп патша дошманы булсын?!

Солтанның дөнья бетереп кычкырасы, үрсәләнеп елыйсы, әтисен алып киткән кешеләрнең битләрен тырмап төшерәсе килә иде...

## IV

Лапас эче салкынча, эңгер вакытындагыча караңгы, зур су киткәнгә әле бер атна да узмаганлыктан, җирдән дым исе, ләм исе аңкый иде. Әтисен Салагыштан кичә генә кайтардылар. Аның күңеле төшенке, эшкә кулы бармый, сабанга чыгарга кирәкле ат тырмасының коелган тешләрен кагарга кирәк булгач та бик ыңгырашып кына тотынды. Солтан аның белән янәшә, җиргә тезләнеп, карама ботагыннан тырма теше юна, ара-тирә әтисе әйткән сүзләргә колак сала, бер генә сүз белән: «Ийе, ярар», — дип куя иде.

Урамнан кемдер ачы тавыш белән кычкырып узды:

— Каравыл өенә җыенга! Каравыл өенә җыенга!

— Бар әле, кара, әллә сугыш беткәнме? — диде әтисе.

Солтан, ямаулы чалбарына кунган йомычка чүпләрен кага-кага, капкадан чыкты. Караса — киез каталы аякларын як-якка чаптар аттай ташлап, ак тула эшләпәне баш өстендә болгый-болгый, Майттыпыра чаба, җиң сәләмәләре җилфердәп бара:

— Каравыл өенә җыенга! Каравыл өенә җыенга!

Капкадан атылып чыккан бала-чага, таякка таянган карт-коры, төркемнәргә оеша башлаган солдаткалар каравыл өе ягына таба баралар. Урамның урта бер җиреннән түшенә ак калаен аскан Нәбкәй староста атлый. Солтан аңар сүз кушты:

— Ни булган, Нәбиулла абзый, сугыш беткән мәллә?

— Баргач белерсең: нимитлинны каравыл өенә. Атаң кайттымы?

— Кайтты.

— Кайчан?
— Кичәгенәк.
— Ул да барсын. Староста әйтте диген, сәгате-минуты белән килеп житсен, ыштубы!
Садыйк абзый жыенга барудан катгый рәвештә баш тартты. Нәбиулла старостаның исемен ул ишетергә дә теләми, зимагур Шәяхмәт өчен «дапруска» тартканы, олыс өтермәнендә зинданга салып йөрткәне өчен ул аңар һәм гомумән Зартугай халкына бик ачулы иде.
— Бармыйм. Төкерим жыеннарына! — диде ул һәм лач итеп жиргә төкерде.
Солтан каравыл өенең сынык тәртәле, коргаксып беткән мичкәле пожарный арбасы тора торган лапасы янына килеп житкәндә, анда әлле-хәлле халык жыелырга өлгергән иде инде. Йорт башлыгы ирләр сугышта булганлыктан, лапас яны төсе уңган камзуллы катыннар, киндер күлмәк-ыштанлы бала-чага белән тулы, чал сакал, мескен бүрек, каешланган кәпәч анда-санда гына, сирәгешеп кенә күренә, шунлыктан Сөләйман хәзрәтнең буй-буй сызыклы яшел чапаны, кибән чаклы бохар чалмасы, кояш эссесеннән көеп беткән соргылт бер яландагы яшел утрау сыман, әллә каян күренеп тора, халык күңеленә билгесез бер шом да сала иде.
— Олы башы белән хәзрәт чаклы хәзрәт кузгалгач, жүнлелеккә булмас.
— Тапшырдык бер ходаның үзенә. Тәкъдирдә язганы булыр.
— Тәкъдир дисең син, торасың да тәкъдир дисең, нишләп соң ул үлем бай-бәтчәгә килми, безнеңише ярлы-ябагайга ябырыла? Байлар әнә чиертсәң кан тамарлык булып симерешеп йөриләр!
— Сиңайтәм, күрше, авызыңны чамалап ач, хәзрәтнең колагы очлы, олы малае Динислам Алабугада эфисәрлектә эшли диме...
— Торасың да шулай дисең, торасың да куркыта башлыйсың. Инде жаным, курка-курка куркулык кояк чиккә життек бит инде, Нурлыгаян. Үлгәнне үлгән дип әйтми тере дип әйтиммени? Югары оч Рамазанның сигез кызга бер малае барые, анысы да аяксыз калып, гәспитәлдә ята ди бит. Рамазан абзый кайгысыннан түшәккә егылган. Унбер жанга ике имана — каян тамак туйдырырга кирәк.
— Габбас мулла ни карый икән соң? Хәнифәне никахлап алды да асрау итеп тота. Алай бит гадел түгел. Ичмасам, ул булышсыные Рамазан абзыйларга.
— И дә сөйләп карыйсың инде, Хупжамал! Муллалар алар, жаным, үзенә кирәктә генә мулла, сиңа кирәктә алар юрга: хәсрәтең белән килсәң, йомры телләрен ясмак итеп жәяләр, капкаларын артыңнан өч катлы биккә бикләп калалар.
Солтан халыкны ыра-ера эчкә узды. Ике карт, корсакларын артыш таягына терәп, патшалар турында гәп сугалар:
— Безнең патшаның пурыхы беткән, эснәрәт ясый алмый икән.
— Нишләп беткән аның пурыхы?
— Ярман ышпиуннары Казан пурхаваен шартлаткан ди бит.
— Китсәнә?! Булмас!
— Булган шул менә. Тугымчы Тәуфикъ Ижауга керәчингә барганые кул арбасы тартып, шул сөйләп тордые пурхавай шартлаган дип. Яртысы күккә очкан, яртысы жир астында янып беткән. Бер дә, бер дә галәмәт булган, үзбәк-казакъ якларындагы кебек жирләр тетрәп торган.
— Менә син, хикмәти хода. Алай икән алайса. Безнең патша алай пурыхсыз да калгач, ярманнар бигрәк пырдымсыз кыланырлар инде...
Солтан Нурияне эзләп йөргән жиреннән Габбас мулланың ат караучысы Бөкре Гафиятькә тап булды. Иплэп кенә сорашу нияте белән аның янына туктады, әмма бөкре, инде атна буе кырылмаган ияген сыпыргалап, көтүче эшнәсе Ләлек мамык чыбыркының сүзен тыңлый, тегесе

җәен-кышын киеп йөрүдән юкарып, теленеп беткән сары кайры тунны җилбәгәй җибәреп, кулларын бутап сөйли:

— Безнең оклауның үнәре артты бит әле, ахири. Дерә дә хәтәр әйбәт үнәрләре килеп чыкты оклавыбызның. Башта ул токмач җәяргә бик маһир ие, сугышка хәтле дибәйтәм. Кече атна көннәрне, мин сиңайтим, теләнне йотарлык токмач җәеп бирә торганые. Ару азык беткәннән суңында, бодай онын төштә генә күрергә калгач, оклау җаныем бәрәңге төя, кер тәгәрәтә башлады. Ярман янараллары бала-чага өстендәге киндер күлмәкне дә ике малайга берне генә калдыргач, оклау малайшалайның баш түбәсенә кунып йөдәтте. Инде менә хәдергесе көнне, мин сиңайтим, оклау нишли диген? Оклау хәдер, ходаның рәхмәте, иртәле-кичле минем сыртта бии. Асылбикә җиңгәгез аны минем сыртта шундаен да оста биетә, гомер буе оклау биетеп йөргәндер диярсең!

Малайлар чырык-чырык көлә. Тешсез авызын мүкелдәтеп көтүче үзе дә рәхәтләнеп көлә. Тол катыннар, әбиләр, солдаткалар авыз читләрен яулык почмаклары белән каплагандай итенеп, күзләре белән генә ымлашалар: һай бу Ләлек мамык чыбыркыны! Булса да булыр икән дөньяда бер ялганчы, тиктормас тел хәерчесе, теле булмаса, билләһидер газим, көпә-көндез тилгән күтәреп китәсе бит үзен.

Ике улы тиң сугышта үлгән Нәүширвән карт, чатлы-ботлы артыш таягын күкрәгенә терәп, керфеге коелып беткән күзләрен кояш җылысына йомып, йокымсырап тора иде, каяндыр чабышып килеп чыккан малайлар тавышына сискәнеп күзләрен ачты.

— Киләләр! Киләләр!

Халык каравыл өе янына кысыла төште, төркем тыгызланды.

Тире-яры җыеп соңгы елларда бөлгән Әхмәтҗан, җиңел сиртмәгә җиккән һәм каты килүдән ярсыган кара алашасын дилбегәне нык тартып, нәкъ халыкның уртасына китереп туктатты. Тол хатыннар чырыйлап читкә сибелделәр. Әхмәтҗан түшне киереп сиртмә-арбадан төште. Аның белән бергә сиртмәдән десятский Дөмеки, Нәбкәй староста, Салагышның Кысык Минҗан төштеләр. Күрәсең, Кысык Минҗанны алмага Салагышка барып килгәннәр, теге — бик хәтәр закон капчыгы.

Каравыл өе янындагы баганага иске чуен кисәге элгәннәр, шул турыга иске бер өстәл куйганнар иде. Өстәл янына Зартугайның әрелеваклы түрәләре җыелды.

Нәбкәй староста түшенә таккан калаен рәтләп куйгач, кулына тоткан чүкече белән чуен кисәгенә китереп сукты:

— Җәмагать! Без, кайсыдырки Зартугай кешеләре, бүген, ягъни кече атна көнне, җыелдык авылыбызның каравыл өе янына бәк хәтәр дәү эш белән. Авылыбызның Айдар Шәяхмәте, сугышта сугышырга теләмичән, дизилтир булган. Чыннан торып әйтсәк — качып киткән. Менә күрегез: ике башлы сәмруг кош пичәте сугылган казна кәгазе алдык.— Кәгазьне сургучлы мөһереннән тотып халыкка күрсәтте. — Бу кәгазьдә әйтелгән, сугышта сугышмаган кәнитилни кешеләрнең йорт-җирен, иманасын чүкеч сугып сатарга яки мәхәллә исәбенә алырга, диелгән. Айдар Шәяхмәтенең йорты Югары мәхәлләдә булганы өченгә без, ягъни кайсыдырки Зартугай кешеләре, бу мәхәлләнең башы, указлы мулласы Сөләйман хәзрәтнең фатихасын алу мәслихәт булыр дип фекер йөртәбез.

Солтан игътибар итте: Нәбиулла староста соңгы сүзләрен халык ишетсен дип бугазны киереп, көчәнеп әйтеп бетерде. Ул сүзен тәмамлаганда, кызы Нурия һәм олы хатыны Шәмсениса белән бергә, җыенга Габбас мулла да килеп җитте. Мулланың да өстендә чапан, башында чалма; тик сакал-мыегы гына, Сөләйман хәзрәттән аермалы буларак, сумаладай кара, шешмәк кабаклы кысыграк күзләре тыныч, хәтта гамьсез дә кебек иде. Ул янында ана үрдәктәй тулышкан абыстае һәм аксыл йөзле, зифа буйлы кызы булганга тыныч иде шикелле. Солтан

Нуриянең билләрен өздереп торган ак атлас күлмәгенә, чия төсендәге кызыл камзулына, баш түбәсендә бик килешле утырып торган энҗеле калфагына, чулпы таккан озын кара толымнарына игътибар итте. Хәер, Солтаннан башка да бу асыл затка игътибар итүче булгандыр. Әнә Сөләйман хәзрәт, чукмар башлы кара таягы белән җиргә төртә-төртә, Габбас мулла гаиләсе янышнан вәкарь белән узды: Габбас мулла сәламенә җавап бирмәде кебек, иреннәрен генә кыймылдатып алды, Шәмсениса тирәсендә тамак кырды, Нурияне күзләре белән сөзеп ашыкмыйча узды. Шул сәбәпле ул өстәл янына халык көткәннән озаграк барды, кулына тоткан коръәнен озаграк ачты, халыкка карап: «Мөэмин-мөселманнар!» — дип әйтеп бетерергә дә өлгермәде, хәзрәт янында әллә каян гына Бөкре Гафият пәйда булды:

— Җәмәгать! — дип халыкны сискәндереп ярык быргы тавышы белән кычкырып җибәрде. — Җәмәгать! Зартугайда ике мәхәллә. Әгәренки без бер мәхәлләнең башлыгын өстәл янына чакырганбыз икән, икенчесен дә чакырырга онытмыйк!

Габбас мулланың аркасына чымырдап салкын йөгерде: исереп килмәгәнме чучка танау?

Халык төркеме чайкалып алды. Гөжләү, Бөкренең сүзләрен бизмәнгә салып карау китте, кайбер урыннардан хәтта хуплау тавышлары да ишетелә башлады. Габбас мулла, әгәр хәзер үк үзе катнашмаса, хур булачагын аңлап, аз гына алгарак чыкты:

— Авылдашлар! Зартугайның мөхтәбәр мулласы, чирек гасыр буена дин-мәгыйшәт юлында җанын аямыйча эшләп килгән Сөләйман хәзрәт барында мин анда чыкмам. Бүлдерми генә тыңлыйк хәзрәтне, — диде.

Урта бер җирдән дивана Майттыпыраның:

— Мәчет ауганчы таралыйк!—дип кычкырып җибәргәне ишетелде.

Халык көләргә, бер ишесе диваналы үгетләп тынычландырырга керешге.

Байтак кына азапланганнан соң халык төркеме тынды, Габбас мулланың бик вакытлы әйтелгән акыллы сүзләреннән канәгать калып, Сөләйман хәзрәт сүз башлады. Ашыгып башлады ул сүзен, тартып-сузып торуның ни белән бетәчәген ул инде абайлап өлгергән иде.

— Мөэмин-мөселманнар, дин кардәшләребез, аллаһы тәгаләнең ризалыгы һәм сезнең рөхсәтегез белән, әйтер сүземне әйтим. Ил өстендә афәт йөри. Безнең уртак Ватаныбызны хур итәргә, ата-бабаларыбыз гомер сөргән шушы мөкатдәс туфракны нәҗесләргә ярман армиясе басып керде. Өченче ел инде шул явыз дошманны безнең җир-суларыбызга якын җибәрмәскә, изге динебезне мыскыл иттермәскә дип Рәчәйнең төрледән-төрле халыклары кан коялар. Аллаһы тәгаләнең кодрәте, патша хәзрәтләренең шанлы гаскәре белән нимес янаралларын, чучка төсле итеп, борыннары белән җиргә төртмәенчә торып, аларның Рәчәй туфрагыннан эзләрен суытмаенча торып без, мөэмин-мөселманнар, җан тынычлыгы тапмабыз. Җиңгәнче, дин дошманын кырып бетергәнче сугышырга кирәк. Патша хәзрәтләренең фәрманы вә һәм дә Рәчәй мөселманнарының фатихасы шундый. Ил өстенә әфәт килде. Бәлшивикләр дигән әәҗүз-мәәҗүз токымы, нимесләр белән сүз берләшеп, илне сатарга, безнең динебезне, мөселман өммәтен мыскыл иттерергә телиләр. Иа хода, шуларның кулын кыскарт, шуларның юлын бүлеп куй дип без биш вакыт намазда тәңредән сорарга фарыз кешеләр. Менә шундый зыян-зәверле, болгавыр бер заманада безнең Зартугайның Айдар углы Шәяхмәт сугыш кырын ташлап китеп, илгә хыянәт итте. Ул, мөгаен, безнең җиңелүебезне, дин-шәригатебезнең бетүен, үзебезнең мескен бер бичара булып, явыз дошман кулында кол булып яшәвебезне телидер. Мин коръән тотып каргыйм аны. Ике кулымны берьюлы күтәреп, аның үзенә, нәселенә бәддога укыйм, аның йортының безнең авылда чекрәеп тормавын телим. Сез, мөселман кардәшләр, әгәр

дә безнең бабаларыбыз тоткан динне мыскыл итүләрен, җир-суларыбызны пычратуларын теләмисез икән, минем изге ниятемә кушылырга, минем белән бергә Шәяхмәткә бәддога укырга тиеш буласыз. Аның әтисе Айдар мәрхүм патша хәзрәтләренә егерме биш ел хезмәт иткән солдат иде. Мин, Зартугайның указлы мулласы, дин-шәригать юлында җанымны фида кылырга әзер торучы мөэмин-мөселман, Айдар углы Шәяхмәтнең йортын чүкеч сугып сатарга, үзен Зартугай иманасыннан мәхрүм итәргә фатихамны бирәм. Амин! Аллаһы тәгаләне бер дип вә бар дип таныган мөселманнар кул күтәреп дога кылыгыз. Аллаһы әкбәр!

«Аллаһы әкбәр!» — дип мөгрәде мәчет картлары.

Тол катыннар, солдаткалар кулларын авыз тирәсендә тотып үзләре белгән догаларын укыдылар, карт-коры кулын баш турысына кадәрле күтәрде, шул мәлне дивана Майттыпыраның янә дә ачы тавышы тынып калган авыл өстен ярып җибәрде:

— Мулла бабай!

— Ни булды, алла бәндәсе?

— Бер тартырлык тәмәке бир әле!

Хатын-кыз аһ итте.

Нәүширвән карт йокымсыраган җиреннән уянып:

— Ни булды? Ни булды? — дип як-ягына карана башлады.

Сөләйман мулланың мөритләре, тәкъва мәчет картлары, Майттыпыраны үгетли-үгетли халык арасыннан алып чыгып китәргә азаплана башладылар. Мескен бүрекле ике карт дивананың телгәләнеп беткән сәләмә җиңенә килеп тотынды, ә тегесе диваналарга гына хас бер дуамаллык белән картларның икесен ике якка атып, солдаткалар арасыннан чыгып чапты.

Бу күренеш халыкка авыр тәэсир итте. Дивана — хода тәгалә гыйбрәт өчен яраткан гөнаһсыз бәндә — аны рәнҗетү җүнлелеккә илтмәс дип, үзара рәнҗеп сүз башладылар. Тагын шау-шу купты. Әнә шул шау-шуга пар атны рессорлы кибиткага мичәүләп җиккән Таминдар бай килеп төште. Ул, яше инде иллеләр тирәсендә булса да, авыл кешеләре төсле сакал-мыеклы түгел, чиста итеп кырынган какча битле, җиңел сөякле бер кеше икән, кибиткадан егетләрчә бер җитезлек белән җиргә сикерде. Зартугайда мәктәп-школа салдырган, Бояр урманы дигән урманнарга хуҗа булган, Кама белән Иделгә пароходлар чыгарып җибәргән бу кешене, башка байлар төсле зур корсаклы, кып-кызыл тук чырайлы, затлы киемле итеп күз алдына китергәнгә, халык башта бераз сәерсенеп, аптырап, тынып калды. Аның башындагы җемелдәвек каракүл бүрегеннән башка татар дип әйтерлек киеме дә юк, өстенә сыланып торган яшькелт френче дә, ялт итеп чистартылган кара сафиян итеге дә, гәүдәсен төз тотып, төгәл-матур атлап килүе дә — барысы да хәрбиләрчә иде. Аның белән янәшә атлаган, күз явыңны алырдай яшел парча җиләнле, кара итекле, ефәк җеп һәм алтын ука белән чиккән кызыл бәрхет түбәтәйле Габделхәлим сәүдәгәр күңелләргә күбрәк хуш килә, аны чыннан да бай итеп танырлык бар иде.

Ләкин шул ук көнне, Шаукымлы Шәяхмәт йортын саткан чакта, зартугайлар беренче бай итеп Таминдар Тураевны танырга мәҗбүр булдылар.

Нәбкәй староста чүкеч белән чуен кисәгенә китереп сукты:

— Ил һәм халык дошманы Айдар Шәяхмәтенең йортын сатабыз. Кем күпме бирә?

Өстәл янына беренче булып атсыз Әфләтун килде.

Халык кинәт сәерсенеп тынып калды. Сәерсенергә урыны да бар: Әфләтун эттән дә ярлы иде. Ике метр озынлыгындагы бу кеше яшь чагында чамасыз гайрәтле булган. Култык астына кыстырып китәрдәй бәләкәй Бәрбәриягә өйләнгәч, казна урманыннан өйлек бүрәнәне җил-

кәсенә күтәреп ташыган дип сөйлиләр. Бу хәлнең күпмесе дөрес, күпмесе хыял җимешедер — бер хода үзе генә белә. Авылда аның йортыннан да кечерәк йорт, аның тәрәзәсеннән дә кечерәк тәрәзә, аның ихатасыннан да каралтысызрак ихата юк. Йорт буенда мунча, мунчага ышыклап ясаган лапас кисәге. Бар булганы шул. Җәен юклы-барлы иген үстереп, көзен бакчадан бәрәңгесен казып алгач, Әфләтун күршетирә авылларга чыгып китә: казан төбе ямый, самавыр төзәтә, мич капкачлары әмәлләп бирә; кара көздән китә, ташу сулары шаулап тынгач, буш бөктәрен аркасына асып, өенә кайтып керә. Кыш буена хатыны ялгыз өйне саклый. Ходай аларга ике бала биргән, икесен дә кире алган. Икәүдән икәү генә ялгыз яшәп картайсыннар дигәндер инде. Авылда алар турында сихерче дигән, убырлы дигән сүзләр йөри, зират яныннан узган чакта бала-чага бер-берсен Әфләтун убыры тота дип куркыта. Ләкин авылны таң калдырганы — аларның убырлы дигән кушаматы да, эттән ярлы булулары да, кышның кышында икесенең ике җирдә яшәве дә түгел. Ир белән хатынның дәгъвасы. Хатыны — төенчек хәтле генә бер нәмәрсә — кычкырыша башласа, әвен хәтле Әфләтунга ләтчә булып ябыша икән, кубарып ала алмассың. Әфләтун үзе Бәрбәрияне җүнле сүз белән үгетләп җиңә алмагач, мин югында сиңа жен-нәр ияләнгән, ахры, дип, самавыр кургашы эретә торган тимере белән аркасына кыздырып баса икән. Кышкы озын кичләрдә Бәрбәрия үзе янына утырмага килгән солдаткаларга сөйләп торган: быел әле Әфләтуным аркама кызган тимер белән басмый киткәние, шуңа күрә аркаҗилкәм кычытып тора, янәсе. Әфләтунның кышларын бакыр-тимер эшендә йөрүе дә ирек ачып кайту ниятеннән түгел, бер тамагын туйдыра алмаганнан, моны бөтен авыл белә иде. Бер вакытны, Таминдар бай әле яшь-җилкенчәк чакта, үзенең тегермәнендә эшләүче, уен-көлкегә бик әвәс егет белән сынап-тикшереп карарга булганнар. Күпме ашый ала, янәсе! Әфләтунны чакырып алганнар да уракка ялланган көннекчеләргә дип пешерелгән ике чиләк сыешлы табак белән аш һәм тегермән ташы чаклы күмәчне алдына китереп куйганнар:

— Ашап бетерә аласыңмы?

— Алам, — дигән Әфләтун.

Ашның өресен күмәч белән җыеп ашаган, токмачы белән итен кулы белән табакка кереп ашап бетергән.

Егетләр сынамак өчен аны Аксагыз тавына менгергәннәр, таудан йөгертеп төшергәннәр, берни булмаган. Өйләренә кайткач, Әфләтун төн уртасында мунча артына чүмәлә салып куйган, шуңа күрше тавыгы батып, чыга алмыйча үлгән, ди.

Менә шушы Әфләтун, киндер күлмәк өстеннән кигән төймәсез чикмәнен кулы белән каплаштырып, бер аршынлы чабаталары белән җиргә лаштырдатып басып, өстәл янына килде, чикмән кесәсеннән янчык тартып алды, янчыктагы вак акчаны өстәлгә аударып салды һәм:

— Шәяхмәт йортын үзем алам, менә сезгә ун тәңкә акча — көмеше дә, бакыры да, барысы бергә, — диде.

Мәзәк күрергә ниятләнгән халык алгарак узды, өстәл янына балачага ябырылды.

— Әфләтун абзый ун тәңкә бирә. Җәмәгать, ун тәңкә! Кем бирә артыгын? — диде Нәбкәй староста.

— Егерме тәңкә!— диде тире сатып бөлгән Әхмәтҗан һәм кешеләр бакырчы Әфләтунның йөзе сабый бала йөзе кебек бозылуын һәм аның алыптай зур гәүдәсе белән Әхмәтҗанны каплап куюын күрделәр.

— Син, Әхмәтҗан, минем юлыма аркылы төшмә. Мин бу акчаны төннәр буе самавыр ямап җыйдым, әдәм рәтле йорт алырмын дип. Син, Әхмәтҗан, алладан курык!

Нәбкәй староста чүкеч белән ватык чүен кисәгенә орды:

— Егерме тәңкә көмеш! Артыгын кем бирә?

Габделхәлим берьюлы илле тәңкә вәгъдә итте.
Әфләтун абзыйның чырае кара болыт булып каралды, һәм ул калтыранган куллары белән бакырларын янчыгына тутырып, халык арасыннан чыгып китте.
— Җәмәгать, илле тәңкәгә җиттек! Илле тәңкә, илле тәңкә, кем артыгын бирә? Әгәр дә артыгын бирүче булмаса, йортны илле тәңкәгә Габделхәлим куписка сатып җибәрәбез!
Өстәл янына төп-төгәл адымнар белән, күн итекле аяклары белән каты-каты басып, Таминдар Тураев килде:
— Бер йөз тәңкә. Халыкка игълан ит: Шәяхмәт йортын сатканнан килгән акча солдаткаларга, сугыш ятимнәренә бүленеп биреләчәк.
— Бер йөз тәңкә! Җәмәгать, ишеттегезме, Таминдар бай бер йөз тәңкәсен дә кызганмый. Йортны сатудан килгән акча солдаткаларга бүлеп биреләчәк. Бер йөз тәңкә, кем артыгын бирә?
Тирече Әхмәтҗан йортның урынына — авылның урта бер җирдә булуына, бакча тулы шомырт, миләш, балан үсүенә үлеп тә кызыга иде, өстәвенә, сал куучы Шәяхмәтнең йортны агачның бер дигәненнән, кала суккан төсле итеп җиткезгәнен белә иде ул, кинәт икеләнә башлады: әллә тәвәккәлләргәме? И беткән баш беткән, бөлгән баш бөлгән! Җаныннан кадерле итеп саклаган соңгы акчасына бу йортны эләктереп калырга ниятләде:
— Бер йөз дә илле тәңкә! — диде бәяне бик кинәт күтәреп.
Монысы инде иң югары бәя, шәт каршы килүче булмастыр.
— Ике йөз тәңкә, — диде Таминдар бай тыныч кына.
Нәбкәй староста чүкеч сугып, ике йөз тәңкәне халыкка игълан итте.
— Ике йөз унбиш тәңкә! — диде ярсынып киткән тирече Әхмәтҗан.
— Артыгын бирүче юкмы? Ике йөз дә унбиш тәңкәгә сатам йортны!
Монысы инде йортның тиешлесеннән күп артканы иде. Шәт иншалла, берәү дә хәзер миңа каршы чыкмас дип фикер йөртте тирече, ләкин ул Таминдар байның Габделхәлим сәүдәгәр белән алдан ук сүз беркетеп килгәнен белми иде.
Сөйләшкән буенча Габделхәлим сәүдәгәр ике йөз дә илләне бирде. Халык арасында тел шартлату, күпсенү, соклану тавышлары ишетелде.
Таминдар бай алгарак чыкты:
— Өч йөз тәңкә. Соңгы бәя. Җитте!
Шуннан артыгын бирүче табылмады. Шул сәгатьтән башлап Шәяхмәт Айдаров йортына Таминдар бай хуҗа булды.
«Хәзер инде бу йорт сүтеләчәк,— дип уйлады Солтан.— Инде болайга киткәч, аның агач бакчасын да кисеп ыргытырлар. Күрәсең, салчы Шәяхмәтнең нигезен корытырга исәпли болар. Нигә шулай гаделсез син, дөнья?Ник син берәүне баетасың, берәүне талыйсың?»
Солтан бу көнне җанын айкаган әнә шул сорауларга җавап бирерлек түгел иде. Ул Габбас мулланың Шәяхмәт абыйсын яклап бер генә сүз дә әйтмәвенә, халыкның да ризасызлык-мазар белдермичә, сарык кебек көтүедәй өелешеп торуына каефе китеп, үз алдына ярсынып, өйләренә кайтты.
Теше коелган зур агач тырма лапасның урта бер җирендә ята, әтисе агач бүкәнгә ничек утырып калган булса, әле һаман шул урында башын иеп утырып тора иде.
— Я, ни булды? — диде ул, башын күтәрми генә.
— Саттылар, — диде Солтан.
— Нәрсә саттылар? — Карт бу юлы башын күтәрде, сирәк сары сакалы дерелдәп китте.
— Шәяхмәт абыйның йортын саттылар. Акчасын салдаткыларга өләшергә диделәр.

— Күңелем үк сизгәние аны...— тавышы рәнҗүле, сүлпән һәм боек булып ишетелде.

...Йорт сату вакыйгасын Габбас мулла үзенчә кичерде. «Адәм баласы төрлечә яши,— дип фикер йөртте ул.— Зыялылар китап укый, граммофон уйната, театр карый. Көндез кичергәннәрен төнлә төшендә күрә, ягъни бер үк тормышны ике мәртәбә күңеленнән уткәрә, шуңа күрә йоклый алмый интегә. Ә менә крәстияннең эш башкачарак: ул ашый, сабан сөрә, вәгазь тыңлый, өенә кайта да төш-мазар да күреп тормастан, изрәп йоклый. Бу хәтлесе аңлашыла. Ә менә Айдар Шәяхмәтенә ни җитмәгән? Сугышка тикле урман кисте, сал агызды, әргән уйнатып күңел ачты. Инде менә сугыштан качкан. Качып кая бара? Җир казып, җир астына керәме? Әллә качкын булып урманда ятаргамы исәбе? Гомер буе ничек җир астында ятмак кирәк? Ул бит үзенне терелә төрелә кумеп кую, якты дөньядан үз теләгең белән исән чакта ук ваз кичү дигән сүз. Ярабби, әллә мин аңламаган икенче бер хикмәте бармы соң бу дөньяның?»

Шәмсениса абыстай бүгенге хәлләрдән үзенчә бик төгәл нәтиҗә ясады: «Нурияне Айдар Садыйкларына керүдән тыям. Патша дошманы булган нәсел белән аралашу җүннелеккә түгел. Нуриянең теләндә Солтан. Солтаның, болай булгач, олтан булып куймагае...»

Язгы көн сүнеп бара. Кояшның соңгы нурлары мәчет тәрәзәләрендә, Габбас мулла йортының өске кат өлгеләрендә учак утыдай дөрләп яна. Шәфәкъ нурыннан офык читенә җыелган болыт өемнәре яна, ләкин инде офыкта тар бер тасма гына булып калган яктылык отыры кими, кара-кучкыл болытлар офыкны күмеп киләләр, шәфәкъ алсуы отыры югарыга, отыры биеккә үрләгән саен эңгер куера, әрәмәләрдә кошлар чыр-чуы тына, җир өстенә салкынча канатын җәеп, төн килә.

Габбас мулла йортында язның бу төнен дә артык хәвефләнмичә, тыныч вә имин каршыладылар. Мулланың яшь хатыны Хәнифә түбән өйнең тәрәзә капкачларын ябып, тупыл белән карт каенның бергә кушылып шаулавын, кайдадыр аргы очта этләр өрүен тыңлап торды. Бөкре Гафият кола бия белән сабанчы күк-турының бурабзар ишекләрен түбәтәй чаклы йозак белән бикләп куйды. Ат караклары керә алмас инде. Аргы аранда көндез күрешкән яшь үгезне сагынып башмак тана мөгрәп куйды. Аннары тавышлар тынды. Мулла йорты иртәнгә тикле өнсез калды...

Иртәгесен өйлә вакытларында Зартугайның ике диванасы — Майттыпыра белән Вәсвәсә Вәли, урам бүлешә алмыйча, Түбән мәхәллә мәчете каршысында җан-фәрманга сугыштылар. Тавыш ишетеп капка төбенә чыккан Габбас мулла аларның бер-берсенә оча-оча кунуын, «Югары очка менмә, минем урамга кермә!» — ди-ди, ачы тавышлар белән бер-берсенә кычкыруларын җаны тетрәп карап торды. Барып аерырга базмады. Диваналар бер-берсенә йодрык күрсәтә-күрсәтә, канаган авыз-борыннарын сәләмә җиңнәре белән сөртә-сөртә, икесе ике якка китеп баргач, күңелсез уйларын уйлады: «Иа алла, кая бара бу дөнья? Тиләләр булып тиләләр дөнья малын бүлешә алмый сугышкач, акыллыларга ни кала?..»

Шул көнне үк Шәяхмәт йортын саткан акчаның бер йөз тәңкәсен солдаткаларга бүлеп бирделәр. Артык та түгел, ким дә түгел, өчәр тәңкә тиде. Кырык тәңкәсе йортны сатарга фатиха биргәне өчен Сөләйман хәзрәткә, ун тәңкәсе сатуны оештырганы өчен Нәбкәй старостага эләкте, калган йөз илле тәңкәсе Таминдар байның үзенә әйләнеп кайтты.

Күкрәп торган бакчалы Шәяхмәт Айдаров йорты урынына нәкъ бер айдан кыр ташыннан салынган шыксыз зур соры кибет калкып чыкты. Агач бакчаны кисеп товар складлары ясадылар.

# V

Язгы су яткан болыннарда чалгы белән каерып ала алмаслык печән унган. Бояр урманы, Саклау урманы, Тугызбуй яклары үз гомерләрендә күрмәгәнчә куерып, кара-кучкылланып утыралар.

Болын өлеше алырга барган Садыйк карт Иш буеннан күңелләре нечкәреп кайтты. Болынның аңар аеравык үләнлесе эләкмәде эләгүен, шулай да юлда барганда күргәннәре картның әллә кайчангы истәлекләрен кузгатып, яшь чакларын, гайрәтле чакларын искә төшерде.

Герман сугышы чыкканчы егетләр печән өстен гармуннар уйнап, атларын эшлия-чуклар, җиз тәңкәләр белән бизәп каршы ала торганнар иде. Быел болын күрке булган таза беләкле егетләр дә, печән өстенә дип печтергән яшь тәкә симертүче йорт башы ирләр дә юк. Алар кайдадыр чит-ят җирләрдә, окопларда бет туйдыралар, чит-ят җирләрдә вәйран булып, газдан тончыгып үләләр. Алар өлешенә кызлар сөлге сукмый, Салагыш базарыннан бизәкле тырмалар кайтартмый, калага баручылар артыннан алъяпкыч һәм кулъяулык чигәргә тамбур җепләр кушып җибәрми — күңелсез узачак печән өсләре...

Печән өсте, сабан туе, кыр җыены вакытларында яшь-җилкенчәккә чабатаны тугызлыдан, унберледән үреп дан алган, нәкъ менә шул вакытларда еллык керемен дә алып кала торган Бикәмәт карт быел:

— Кая китте бәйрәм-сабан туйларым? Кая китте ярминкәләргә чыгарып сатарлык чабаталарым? — дип аһ орды.

Быел ат аягы кыздырырга чыгучы да күренмәде. Урамнарны, абзарларны баскан язгы салкын су мал-туарның, шул исәптән чабыш атларның да аякларына китереп сукты. Көтүгә терлек-туар бермә-бер кимеп чыкты, хайван зиратына озатылган аттыр, сыердыр, сарыктыр үләксәсенә көн саен ач бүреләр җыелып, аларның җиде төн уртасында үләт базы ягыннан ишетелгән улау тавышлары йөрәккә шом сала иде.

Таминдар Тураев кызыл малчы Габделхәлимне Зартугайда, Яуморзада, Саранбайларда, Салагышта, Тәкмәк-Чүрәкәйдә ачкан яңа кибетләренә күзәтче-башлык итеп куйды. Мәркәз каласы Петербургтан укып кайткан улы Һашимны куй тиресе җыярга кыргыз даласына юллады. Бояр урманы эченә рус алпавытлары төсле итеп салдырган ак таш пулатлы, җимеш бакчалы, Иш буена таш баскычлар ясап төшә торган террасалы утарына Ырымбур миллионерлары Хөсәеновлар үрнәгендә «Тәфтиләү» дип исем куштырды, аның управляющие итеп башкорт ягыннан немец Клаусны китертте. Ниһаять, житте бер көн: Чистай, Чаллы, Алабуга кебек өяз калаларын дер селкетеп үз кулында тоту, Алабуганың кораб төзергә яраклы нарат урманнарын бөтенләе белән үз кулына төшерү, Идел-Кама пароходчылык компаниясен кинәйтү уе белән янып яши башлады. Моның ише зур эшкә тота-каба гына тотынып булмый, Казан, Уфа, Ырымбур, Сембер байлары белән киңәштабыш итәргә, аларның фәтвасын алырга, тәгәрмәчкә таяк тыкмаслык итеп үз арбаңа җигеп куярга кирәк иде.

Башкортның иркен даласында ничәмә-ничә ел җиргә кинәнеп яшәгән зирәк акыллы, педант дәрәҗәсендәге төгәл Клаустан ул Россия капитализмының тууы, үсүе, тамыр җәюе турында мәгълүмат җыйдыртты, бөлгенлеккә төшкән фабрикантларның, алпавытларның, эре сәүдәгәрләрнең хезмәт исемлеген өйрәнде, пароходчылык компаниясен киңәйтү өчен казна кәгазьләре хәстәрли башлады.

Уналтынчы елның маенда ул «Тәфтиләү» утарын Казан губернасындагы теләсә кайсы байның күзе ут янарлык итеп төзеп җиткезде. Европа зәвыгы белән көйләнгән гөл түтәлләрен, газоннарны управляющий Клаус солдаткалардан, сугыш ятимнәреннән, үсмерләрдән эшләтте; шулар ук сарык йоны алдылар, туку станнарында палас суктылар, милли орнамент белән тәрәзә-ишек япмалары, шторлар әзерләделәр.

Кыскасы, Таминдар Тураев, колачны җәя алган кадәрле җәеп, Идел-Урал байларына үз тәртибен тагарга әзерләнде.

Кунак җыелу көнен 15 июньгә билгеләделәр.

Тугызбуй якларында нәкъ шул көннәрдә ел саен кыр җыены үткәрелә торган иде. Ач-ялангач халыкның күзенә кылчык булып кадалмас өчен, бәйрәмне урман-кырларга чыгып түгел, биек коймалы утар эченә бикләнеп, аулак итеп уздырырга тиеш таптылар.

Таминдар Тураев, бүгенге дәрәҗәсенә ирешкәнче, җитмеш җиде кат тир түгеп, җиде пот тоз ашап, мең дә бер мәртәбә алдап һәм үзе дә аяусыз алданып, дөньяны таный белергә өйрәнгән иде шул.

Әтисе торф байларында эшләде — Чакалтайда. Гайрәтенә бөтен Чакалтай баш орадырые. Ял көннәрендә алып кайтырларые Кама аръягыннан көмешкә. Утырып алырларые өчәүләшеп сәкегә: Сабир, Хәтмулла, Борһан — анысы Таминдар әтисе. Бер чиректе каплап кына куярларые. Өчесе тиң кып-кызыл: чиертсәң кан тамарлык. Тамуын да тамган, әтисе бер төкергәндә ярты үпкәсен төкереп ташлаган. Чакалтай торфында чахут алганнар. Башта Хәтмулла үлде, аннары Сабир. Таминдарның әтисе өзгәләнә: яшәргәе гүли кырыкка, аннары табатын яши белерием. Иех, күке кукәе, тукран кабыргасы, инәңнең калак сөяге! Сугенүнең нәрсә икәнен белмәгән кеше җитмеш җиде катлы итеп сүгенде. Яши алмаслыгын белеп сүгенде. Утыз җиде яшь туларга ике көн калганда үлеп тә китте шул.

Әкәмәт икән ул — адәмнең үлеме. Иртән иртүк торды, хатынын уятты. Тыкырдатып, сабырсызланып, тәбикмәк пешертте. Бер үзе утырып, тау чаклы тәбикмәкне ишеп салды — бурлат та бурлат, әтисе дә бурлат. Мыегына тамган майны кап-кара тырнаклы, көрәктәй дәү кулы белән сыпырып алды:

— Улым Таминдар,— ди,— Тәкыймулла мәзин белән кендекче Сафураны чакыр.

Таминдарга уникe яшь ул чагында. Аны-моны чочларлык малай: мәзин белән кендекчене үлем түшәгенә ятканда гына чакыралар, ясин чыгарга кирәк булганда гына.

Таминдар баскан урынында катып калды.

— Бар, улым, йөгер, үләм мин бүген.

Тәкыймулла мәзин белән кендекче Сафураны алып кайтканчы әтисен борып та куйганнар.

Иртәгесен зиратка илтеп күмеп тә кайттылар.

Сабанга абыйсы чыкты, үзе белән Таминдарны да алды. Әтисе көйли дә беләдерие соң суканы. Үләрен сизептер инде, бер атна элек көйләп куйган бу. Кызыл алаша белән кола бияне җигеп җибәрделәр — абыйсы Таминдарга сука башын тоттырды. Көйле сабан яра җирне, сука тимереннән кара балчык агылган чакта күзләр әлҗе-мөлҗе килә. Җир башы кыен: суканы кулга күтәреп чыгарга кирәк. Уникe яшьлек малайның сука чаклы суканы кул өстендә тотарлык җегәре юк, ике иң башына куеп, күтәреп чыгарга туры килә; күтәреп өлгермәсәң, таза пар ат сине сукаң-ниең белән буразнага аударып, сөйрәп алып китә.

Ике көн азапланганнан соң, иңбашлары суелып чыкканга нишләргә белми әрнешеп, тешне кысып сабан сөреп ятканда, җир башына Чакалтай бояры килде — Таминдарның әтисе чахут алган торф заводының хуҗасы. Узып барышы дип уйладылар. Юк! Боларга атап килгән. Тройкалы, рессорлы тарантастан киерелеп җиргә төште — картузын салып, эчен кулъяулыгы белән сөртте: баш зур, маңгай карбыз шае, бүртеп-бүртеп тора, авыз тирәсе бөтенләй күренми дә, җирән сакал баскан, аякта күн итек, көзге кебек ялтырый.

Сәлам бирде, боларның бер тапкыр әйләнгәнен сабыр гына көтеп торды. Малай шәп: сабанны иңбашына салып, ыңгылдап күтәреп бара.

— Ну, сынок, миңа эшкә кирәсеңме?

Иң әүвәл абыйсы каршы чыкты. Дөньяда бер юаш ие, каян кыюлыгы житте, каян сүзе табылды диген:

— Юк инде, гаспадин Фидрич, әтинең канын эчкәнең дә житәр! Синең баткак-сазлыгыңны ерып, кырык яше дә тулмастан теге дөньяга китте! Хәтмулла абзыйны, Сабир абзыйны йотты синең сазлыгың!

Күрәләр, Чакалтай боярының мыек очы да селкенми.

— Байлык кыйбат йөри, балам. Кара-каршы йортны Борһанга кем бирде? Алаша белән байталны кем алдыртты? Абзар тулы терлектуарны кем сазлыгы бирде? Минем торф сезне кеше итте, сез аны белеп торыгыз, оланнар!

Бу юлы Таминдар алга чыкты.

— Саз эчендә үләргә кушмады миңа әти! — Иреннәрен кысып әйтте, башны бүредәй текә тотып үҗәтләнеп әйтте.

Чакалтай бояры үгетләмәде.

— Булдырачак бу. Кеше чыга бу көчектән! — диде. Сиртмәле тарантасына утырып, тузан туздырып китеп барды.

Китте. Сүзләре Таминдар күңелендә уелып калды.

Җирне Таминдар үҗәтләшеп сөрде. Әтисеннән калган пар ат белән алмаш-тилмәш урман урлады. Бүтәннәр таң йокыларын йоклаганда ул инде казна урманыннан бер йөк утын урлап кайткан, аны Салагышның хәллерәк кешеләренә сатып килергә дә өлгергән булыр иде. Бервакыт ул әлəкте — усаллыгы белән крестьянның котын алып торган каравылчы аңа мылтык күтәреп чыкты. Салкын бер чымырдау Таминдарның тун эченнән кереп, йөрәгенә кадәр барып житте: ул тәзи башлаган матур дөньяны каравылчы бер селтәнүдә чәлпәрәмә китерәчәк! Таминдар газраиленә буйсынды — атын ул кушкан якка алып барды. Каравылчының аңын томаларга, юаш һәм куркак булып күренергә кирәк иде аңа. Каравылчы тәмам тынычланып, утын төягән арба өстенә менеп утыргач, мәче өлгерлеге белән газраиле өстенә сикерде, тартып алган мылтыгы белән баш түбәсенә орды, күкрәгенә тезе белән басып, ике куллап буып үтерде.

Таң алдыннан башланган буран атна буена котырынды: эзләрне, юлларны, җинаятьләрне күмде,— давыл Таминдарның баш түбәсеннән узды.

Җәзасыз котылу аңа тагын да ныграк әрсезләнергә ирек бирде, көч бирде. Абыйсын ул хуҗалыктагы арзанлы хезмәтчегә әйләндерде, картаеп хәлдән тайганчы ат абзарыннан чыгармады.

Егерме биш яшенә житкәндә Борһан Таминдары тирә-як авылларга даны таралган гайрәтле ир иде инде. Шакир хаҗиның төпчек кызына өйләнеп, бирнәне алтын-көмештән алгач, тынычланып калырга да мөмкин иде, югыйсә. Таминдармы тынычланыр кеше! Бабай тиешле кешедән ул бирнәгә җир өлеше дә суырттырып алды, аннары Шакир хаҗи тәкъдиме белән Стахеевларның аракы заводына барып керде. Стахеев аның ныклыгын, зиһенен бәяләп, белемле зур инженерына ярдәмче итеп билгеләде. Якын-тирә авыллардан җыелган сала мужиклары белән уртак тел табу өчен рус промышленнигына җирле халыктан, турыдан-туры әйткәндә, татарлардан үз кеше кирәк иде.

Таминдар ышанычны бише белән аклады. Төгәллеге, мужиклар белән мөгамәләдәге кансызлыгы өчен, Стахеев аны үләр алдыннан өстәмә җир белән бүләкләде, Алабугада аның өчен махсус таш кибет ачтырды.

Аеруча җан ачып сөйләшкән бер мәлне Стахеев аңардан:

— Әтиең кем булган? — дип сорады.

— Чабаталы түрә,— дип җавап кайтарды Таминдар.

— Тураев булырсың. Таминдар Тураев — көчле яңгырый.

Әйе, яңгырады яңа фамилия. Ике-өч елдан авыл саен кибет ачып җибәрде, Иш буена аяклы амбар салды — Айдар Шәяхмәтен һәм гүәрдин кебек ун егетне сал куарга яллады; Зартугайның урта бер җирендә, калай түбәле итеп, ике катлы йорт салдырды, Алабуга гимназиясен тәмамлаган улын мәркәз каласына политехник институтка озатты. Ул аның барлык коммерция эшләрен эшләргә, аның үзеннән дә уздырып эшләргә тиеш иде.

Ундүртенче елны башланган бөтен дөнья сугышы татар буржуазиясенең яңа йолдызы булып калыккан Таминдар Тураевны олы юлга чыгарып, аның кул-аягын бөтенләй чишеп җибәрде.

Дөнья хәзер — аныкы.

## VI

Габбас мулла болын өлеше бүлгән җирдә булып, өенә кайтып кына җиткән иде. Кыңгыраулар зеңгелдәшкәнне ишетте. Кулын колагына куеп, тыңлашып торды. Зеңгелдәшкән тавыш алар йортына якынлаша. Хәвефләнә калды. Сабан туена да, кыр җыенына да кеше чакырмаганые лабаса! Кем булыр бу? Печәнгә төшәргә торганда кем шулай кыңгыраулы атлар белән җил куып йөрер икән?

Кояш нуры ишегалдының мал-туар таптамаган чирәмен, язгы яшь үлән төсле, ямь-яшел итеп күрсәтә, келәт белән ак мунчадан төшкән күләгәдә ала бозау күшәп тора, йорт нигезендәге комда тавыклар коена иде.

Капка аръягында, урамда кыңгыраулар зеңгелдәшеп тындылар. «Тпрууу!» дигән яңгыравыклы тавышка атлар ярсып пошкырына башлады.

Сары буяулы биек урыс капканың бер бүлемендә шалтырап келә күтәрелде. Кече капка шыгырдап ачылды. Ишегалдына кызыл сәхтиян читектән, аксыл бизәкле парча җиләненең чабуларын җилфердәтеп, җептәй нечкә мыеклы, чал сакаллы, ыспай каракүл бүрекле берәү килә башлады. Бик җәһәт атлап килүеннән дә, затлы киемнәреннән дә әле һаман кем икәнен танымый тора иде Габбас мулла, килүче кинәт яңгыравыклы шат тавыш белән: «Әссәләмәгаләйкүм, хәзрәт! Әллә кунак көтмәгәниеңме?» — дип сәлам биргәч, хуҗаның йөзенә, кара бөдрә сакал-мыегын балкытып, елмаю җәелде:

— Вәгаләйкемәссәләм. Ярабби, Габделхәлим кайнагай түгелме соң? Таныр хәлләр дә юк. Менә син, фаразан. Беренче гильди купец төсле киенгәнсең бит. Әллә, мәйтәм, Мәскәүләр бик баетып җибәрделәрме үзеңне?

Келәт алдына утырып, кул күтәреп дога кыла гына башлаганнар иде, каяндыр келәт астыннан килеп чыккан ата күркә, усал коркылдап, туп-туры Габделхәлим кайнагайга ябырылды: кызыл сәхтиян читек ачуына тиде бугай. Габбас мулла, догадан бүленеп, күркәгә кәвешен атып бәрде:

— Көш, нәгъләт, көш! Кунак килеп тә котылыр хәл юк шушы зимагурдан.

Габбас мулла, догасы бүленүгә кәефе китеп, ашык-пошык кына хәл-әхвәл сорашып алды, аннары кайнагасын өйгә керергә кыстый башлады.

— Өйгә үк кереп торалмам, хәзрәт. Таминдар байның йомышын йомышлап килдем. Шәмсениса, Нурия, үзең кече атна көнне Таминдар Тураев утарына килеп җитәргә дигән әмер бар!

Габбас мулланың кара тутлы түгәрәк йөзеннән кан качты:

— Т-т-туктале... Ни сәбәп? Мотлак безме?

Габделхалим кайнагай Габбас мулла гаиләсен Таминдар байга үзе көчләп такканын әйтергә теләмәде. Хәтерләре калуы бар иде. Кояш эссесеннән тирли башлавын сизеп, бөркүлектән котылу өчен, аксыл парча җиләнен ашыкмый гына өстеннән салды, терсәк тиңентен бөгелгән беләгенә элеп куйды, сары хәтфә камзул өстеннән ныгытып буган киң яшел билбавын да бушатты, шуннан соң яңгыравыклы ачы тавышына шелтәле рәнҗеш өстәп әйтте:

— Син инде, менла кем Габбас, борыныңны бик күтәрмә. «Ни сәбәптән, нилектән?» дип, авыл гыйбаты кебек төпченеп тә маташма. Таминдар хәтле Таминдар бөтен гаиләң белән кунакка чакырган икән, син аны мәртәбәгә сана. Ярый, диген, барырым, диген. Анда, туганым, нитукмышты Иш буйлары, ничәмә-ничә өяздән җыелган татар байлары булачак.

— Аһ, кунаккамыни әле ул?! — Габбас мулла кинәт тирләп киткән маңгаен ак сатин күлмәгенең лоптырдап торган җиңе белән иркенләп сөртте; кайчанга, ничә көнгә барырга, куна барыргамы, атны үзең тотып барыргамы, әллә булмаса, ат йөртүче ялларгамы — барысын төпченеп сорашты.

Вакытның бушка узуына пошына башлаган Габделхалим сүзне бик коры тотты:

— Хәзрәт башың белән үзең дилбегә тотып йөрмәссең. Бөкре Гафиятне тарантас башына чүмәштереп кую да килешеп бетмәс. Аллага тапшырып, берәр малай ялла. Чибәррәк булсын, кеше куркып качмаслык! Кешечә киенгән булсын, теләсә кая борынын тыга торган булмасын. Төшендеңме?

Габбас мулла, ат тотарга кемне чакырырга икәнен уйлап, башын кашып торды, кәләпүшен рәтләп куйды, аннары кинәт кабалана башлады: кайнагасына бер чынаяк чәй дә эчертмәде бит әле. Габделхәлим абзый берниндн кыстауга да күнмичә, китәргә дип кузгалгач кына, югары кат балконыннан Нуриянең энҗе калфаклы башы күренде: озын толымнарына таккан көмеш чулпылары чылтырап балкон рәшәткәсенә бәрелделәр:

— Әти, әни әйтә, абзыйны сүз боткасы белән сыйламасын, карабодай боткасы белән сыйласын, ди.

Нурия балконнан юкка чыкты — һавада көмеш чулпы тавышы гына эленеп калды. Кызыл малчы Габделхәлимне бу йортка китергән нәрсә дә әнә шул чулпы тавышы иде! Чулпының иясен — Нурия сылуны — Таминдар байның килене итеп, шуннан үзенә мул гына өлеш каерып алырга җыена иде сәүдәгәр.

Чулпы тавышына ияреп ул өйгә керде.

Шәмсениса абыстай Габделхәлим абзыйсына чәйне үзе ясап эчертте. Кунакка барудан ул үзе катгый рәвештә баш тартты — Габбас янында олы абыстай карт күренәчәк, аны кызганып караячаклар. Хәнифәне җибәрүгә дә теше-тырнагы белән каршы төште — Рамазан хәерче кызына байлар йорты тәтеми торсын. Ул фәкать Нурияне генә әтисе белән җибәрүгә берсүзсез ризалашты — буй җитеп килгән кызны байлар белән таныштыруның зыяны тимәс.

Кучерга Садыйк малае Солтанны сайладылар. Садыйк абзый улын җибәрергә тешен кысып кына риза булды: халык бер көннән печәнгә төшә, ә аның өендә бердәнбер чалгы тота торган үсмер кунакта йөрсен, имеш! Килеп чыга бит кирәк түгел чагында! Кәкре китерә дә куя. Ләкин ул аяк терәп каршы килергә дә курка, ник дисәң, Габбас мулла алар мәхәлләсеннән, фатихасын-мазарын сорап барасы булыр. Азмыни крестьянның мулла-мәзиндә йомышы? Өстәвенә, Солтанга кул җилеше дә бирермен диде бит әле, мондый ябык елны анысы да ярап торыр...

Габбас мулла йортында ике көн буена туйга барган кебек әзерләнделәр. Шыңгырдап ачыла торган борыңгы сандыктан Шәмсениса абыс-

тай Гыйматдин мәрхүмнең иң затлы киемнәрен чыгарды, сандыкны иелеп актарганда, күзләре дымланды: боларның кадерен беләчәк кеше түгел инде Габбас. Мужикның мужигы бит. Бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карый.

Аның каравы, кызы Нурия сандыктан алган бер әйбергә тыны-көне бетеп сөенде. Сәйлән тезгән озын чуклы кызыл калфакны кулына тоттыргач:

— Әле минем мондый калфагым да бармыни? — диде.

— Синеке түгел алар, минеке, тилекәй. Миңа аларның кирәге шул кадәр генә инде, синңа калырлар. Юлда барганда ук монысын кимәссең, бизәкле, биек үкчәле читегеңне дә юлда кимәссең, байлар йортына баргач алыштырырсың. Ишетсен колагың, байбикә янында гына бул, тиешле-тиешсез ир-ат белән чыр-чу килмә, олылар алдында күп сөйләмә, матур гына йөре, матурлыкның чиге юк...— Шәмсениса абыстай авыр бер көрсенде, сандыгын япмаган килеш калдырып, балконга чыгып китте.

Ике көн тоташ пешеренеп узды. Кош теле, бавырсак, чәк-чәк, гөбәдия әзерләделәр. Шәмсениса абыстай, мәшәкатьле булса да, боларына Ханифәне чакырмады, аның кызына әйтеп бетермәгән сүзләре күп иде.

— Анда, бәлкем, яшь әнкәң ничек дип тә төпченерләр, тешеңне агартып, начар сүз әйтәсе булма, мине көлкегә калдырма. Байлар сынаучан була, өс-башыңны читтән килгәннәр янында алыштырма, байбикә янында гына алыштыр, миннән Таминдар хаҗи хатынына сәлам әйтергә онытма. Ник килмәде дип сорасалар, авырып тора әле, диген, яме, балам...

Габбас мулланың да мәшәкате муеннан иде. Ул садака-мазар бирергә кирәк булса дип, бер янчык көмеш акча әзерләде, берәр тәңкәлек көмешләрне аерым портманега җыйды; иртәгә кузгаласы дигән көнне кичтән авылның иң оста чәч алучысы Кәрәми картны чакыртып, чалгы пәкесе белән чәчен алдыртты, сакал-мыегын озаклап төзәттерде. Аның муенына ак сөлге салып, әле һаман аяклы көзге каршысында утырып торуына ачуы кабара башлаган Шәмсениса абыстай:

— Бик артыгын тырышма, анда синең Нурияңнән башка яшь-җилбәзәк килмәс әле,— дип, хәзрәтнең авырткан җиренә кагылып узды. Шуңа күрә Габбас мулла ул көнне мунчага да карт абыстай белән бармады, аңа үч итеп арка юарга Ханифәне чакырды.

Кече атна көнне иртән иртүк Садыйк малае килеп җитеп, каратуры айгырны чыбык тарантаска җикте. Кеше-кара кузгалганчы авылдан чыгып китәргә тырыштылар.

Нурия, башына энҗеле яшел калфак кадап, өстенә юл җиләне бөркәнеп, әтисе белән янәшә, мамык ястыкка аркасын терәп утырган, ат кузласындагы Солтанның искерә төшкән кара пинжәге, ак якадан күренеп торган көрәнсу йомры муены аны чиксез дулкынландыра иде.

Авыл урамын атлатып кына чыктылар. Басу капкасын йөгереп барып ачкан ялан аяклы, түбәтәйле ике малайга Габбас мулла бишәр тиенлек бакыр тоттырды; саранлансам, юлым уңмас дип, чирәмгә кушучы белән кызыл билле прәннек сибеп җибәрде; капка ачкан малайларның, әүмәкләшеп, чирәм арасыннан прәннекне җыйганнарын ат капкадан чыккач та әле каерыла-каерыла карап барды, үзенең дә еракта калган бала чагы искә төште — күңелен сагыш биләп алды.

Көн бик иртә иде әле. Кара-туры айгыр атлатып кына барган уңайга, юл уртасында ике буй булып сузылган үләннәрдән чык коелып, тарантас көпчәкләрен кара-кучкыллата. Тау битенә урнашкан сөзәк бакчаларда, Иш елгасына кушылган Төчкәнеч инеше үзәннәрендә тал-тирәкләрне бил тиңентен күмеп, иртән сауган җылы сөт сыман төтәп, куе аксыл томан җыелып тора; кайдадыр әрәмәләр арасында,

кояшны чакырып, ашыга-ашыга тартар кычкыра; ерак офык читендәге сирәк болытлар лимон сарысы, әфлисун сарысы, кытай алмасы кебек кызыл төсләргә кереп, балкып яналар.

Габбас мулла белән кызы Нурия янәшә утырып кунакка бара. Нуриянең кызыл малчы Габделхәлимнәрдә кунакта булганы бар, байлар йортында кунакны ничек каршы алуларын, ничек сыйлауларын ул беркадәр чамалый, аны кунакта буласы көннәр, ризык өйгән табын янында атлас-ефәккә төренгән байларның шаулап сөйләшүләрен тыңлап утырасы минутлары түгел, Солтан белән бергә, бер тарантаста утырып барулары, аны ике-өч көн гел үз янында итеп тоячагы дулкынландыра иде.

— Әйдә, энем, рәхмәт яугыры, куалый төш,— диде Габбас мулла.

Солтан иренен очлайтып, атка чөңгереп җибәрде, каеш дилбегәне матур гына итеп кагып куйды. Кара-туры айгыр, йөрәк кагып, тарантасны тигез такыр юлдан элдертеп алып китте.

Юлның ике ягыннан сары йөгергән арыш басуы, куе яшькелт бодай корамалары, алсу төстәге карабодай кишәрлекләре йөгереп-йөгереп артта кала бардылар. Җемелдәвек кара дугага тагылган көмеш кыңгырау иртәнге тын һавада зеңләп, күңелдә матур көйләр кузгатып бара. Нурия дугадагы кыңгырауны, дугадан өстәрәк күгелҗем төсләрдә балкыган күк йөзен, чыгып килә торган кояш нурыннан ялкынланып янган үтә күренмәле кисея болытларны дәртле күңеленә җыеп бара иде.

Ярты юлны узгач, Аксагыз тауларының итәгендә, уйсу урында чылтырап агып яткан изгеләр чишмәсе янына тукталдылар. Габбас мулла чишмәдә битен юар алдыннан чүпрәк кисәге ертып суга салды, яшел чүпрәкне су агызып алып киткәнне тын гына карап торды, аннары тәһарәт алды, яшел чирәм өстенә чигүле намазлык җәеп, иртәнге намазын укыды. Аның изге гамәлен көткән арада, Солтан кара-туры айгырның камыт бавын ычкындырып, камыт киезе белән ат муены арасына кулын тыгып карады — камыт сукмаганмы икән ен белде, атның аркалыгын бушатып, йөгән тезгенен чишеп, айгырга хәл алдырды: тарантас артына таккан чиләгеннән пумала алып, күчәрне майлады — юлга чыккан чакта майларга вакыт тимәгән иде. Шул эшләрне үтәгән арада ул Нурия белән бергә булуның, аның хәзер ул башкарган эшләрне карап торуының бәләкәй генә бәхетен күңеленнән кичерә иде.

Дөньяга кояш чыкты. Юлчылар, эшләрен бетереп, кузгалып киттеләр. Дугага тагылган көмеш кыңгырау зеңгелдәвенә күктә талпынган тургай сайравы килеп кушылды. Болын буйларында көтүләр, чалгыларын иңбашларына күтәргән ирләр, җиңел сиртмә-арбаны тутырып төяләп барган хатын-кызлар төркем-төркем булып күренеп калдылар.

Юлда, кара-каршы очрашкан чакта, тула чикмәнле, киез эшләпәле авыл агайлары, чалгыларын иңбашларыннан алып, Габбас муллага сәлам биреп китәләр, яшь үсмерләр, күзләрен тасрайтып, уттай печән өстендә бу тәти кошлар нигә әле киенеп-ясанып йөриләр, дигәндәй, әрсезләнеп карап калалар иде.

Инде печәне чабыла башлаган болын буеннан узган чакта, Габбас мулла, эш кешеләре яныннан тизрәк үтеп китәргә теләп, тагын бер мәртәбә Солтанның исенә төшерде:

— Куа төш булмаса, энем!

Таминдар бай утары янына килеп җиткәндә, кояш инде шактый югары күтәрелеп, нык кына кыздыра башлады. Түбәсенә эре кара хәрефләр белән «Тәфтиләү» дип язылган таш баганалы челтәр капка янында аларны ике кеше: кайнагайлары Габделхәлим абзый һәм җирән мыеклы, чичүнчә курткалы Клаус каршы алдылар. Габбас мулла белән кызына тарантастан төшәргә булыштылар. Габделхәлим абзый аларны үзе белән ияртеп, кунак йортына алып китте.

Солтанны кинәт сагыш басты. Ятимлек тойгысы, йөрәген тимер бөҗра белән кыскандай, кысып китерде. Энҗеле яшел калфагын баш түбәсенә кадап, чугын ян якка кайтарып төшергән Нуриянең, көмеш чулпыларын чылтыратып, озын кунычлы сары ботинкалары белән вак-вак атлап, билләрен сыгылдырып китеп баруын ул моңсу күзләре белән озатып калды — ник килүенә үкенә башлады.

Ярлы язмышы яр читендә шул. Бер үк тарантаска утырып килделәр, югыйсә, бер үк кояш аларны җылытты, бер үк тургай аларга җыр бүләк итте; чишмә буйлары да, яшел болыннар да, — барысы-барысы уртак иде, сәлам биреп печәнгә киткән авыл агайлары да уртак иде, инде менә ул уртаклык бетте, аларның сукмаклары аерылды. Мулла кызы байлар ягына китеп барды. Солтан ат караучы, ат җигүче, ат туаручы булып, шушы җирән немец Клаус янында торып калды. Ник килде ул монда? Ник печәнгә чыкмады? Хәзер аның яшьтиләре, Иш буйларын яңгыратып, чалгы яный, каерылып-каерылып печән чаба, ә ул Габбас мулла тарантасының дегет исен иснәп, Таминдар байлар лапасында ятсынмы?

Башына бохар чалмасы, өстенә яшел атлас чапан бөркәнеп, озын кара таягын үзе белән алып, алмачуар байталда Сөләйман хәзрәт килеп төшкәч, Солтанга кызыграк булып китте. Хәзрәтне Фатих хәлфә үзе китерә килгән иде. Хәзрәтне шул ук ике кеше, Клаус белән Габделхәлим абзый каршы алдылар, ат лапаска китереп кертелде, тарантастан әрҗә, чуар ашъяулык белән төргән күчтәнәчләрне алып, Фатих хәлфә хәзрәт артыннан юырттырып китте, ләкин ул бирегә, Солтан уйлаганча, кунак булып килмәгән, кучер булып кына килгән икән — тиздән әйләнеп тә кайтты. Атын туарышырга Солтанны да чакырган иде, тегесе күңеленнән: «Бик кирәгең барые», дип уйлады, әмма теленнән:

— Чит ат янына барырга куркам мин, тешләп атса, я тибеп җибәрсә... — дип, юаш кына җавап кайтарды.

Шулай итеп, шәкертләргә тал чыбыгы ашаткан кансыз хәлфәдән үч алды. Хәлфә кыска буйлы иде, аңар Солтан алдында, озын торыклы байталның камыт-иңгырчагын салдыру өчен, атны тарантас янына китерергә туры килде. Тарантас өстендә үрмәләп, корсагы белән шуышып йөргән хәлфәне күреп торган, аның көлкесенә шаһит булган Солтанның җаны канат какты.

Солтанның аты тарантаска бәйләп куйган җирдә печән утлап тора иде, җирән мыеклы Клаус кучерларга — Солтан белән Фатих хәлфәгә — атларны алып, үзе артыннан барырга боерды.

Тарантаслар капка төбендәге лапаста торып калдылар, Солтан белән хәлфә, атларны җитәкләп, Клаус артыннан киттеләр.

Утар бик зур иде — бара-бара арып беттеләр.

Утарның урта бер җирендә кызыл калай түбәле, ике катлы ташпулат буйдан-буйга сузылып китә, аның гөмбәзле чарлагында, аллыяшелле төсләргә буялган вак кына тәрәзә өлгеләрендә, салават күпере төсле булып, кояш нуры уйный иде. Алабугада укып йөргән чагында Солтанның икешәр-өчәр катлы купец йортларын, зур-зур ташпулатларны күргәне булды, никтер алары Таминдар бай ташпулаты хәтле тәэсир итмәгәннәр, күрәсең, аларның тузанга баткан, буяулары уңган булуы аларны күрергә комачаулагандыр, ә Таминдар байның ташпулаты әле генә житештерелгән, энәдән-җептән генә чыккан булганга күрә, кояш күзендә чекерәеп, балкып-масаеп утыра иде.

Солтан озакламый бу зиннәтле йортның өске катына байлар килеп тулачагын күз алдына китерде. Алар бәбәкләрен бәгърәйтеп Габбас мулла кызына төбәлерләр, аны мактап төче сүзләр әйтерләр, ә ул, шул мактаулар белән килешеп, мактаулардан башы әйләнеп, эрепизелеп утырыр...

Шул турыда уйлагач, аңа күңелсез булып китте, аның кара-туры айтырны да житәкләп барасы килми, Таминдар бай утарындагы бер генә каралтыны да күрәсе килми башлады. Аның хәзер үк, менә шушы минутта ук, бирелән чыгып китәсе, чалбар балакларын сызганып, чыклы үләннәрне ерып, Иш болыннарында йөрисе килеп китте.

Ләкин ул, инде монда бер килеп капкач, жирән немец Клаус артыннан барырга тиеш иде, ул ни әйтсә, шуны үтәргә тиеш иде.

Ике катлы ташпулатның аскы катында ишекләрнең күп булуы Солтанның игътибарын җәлеп итте. Анда кибетләр, келәтләр, келәт саен затлы товар, мануфактура, җиләк-җимеш вареньелары, олавы-олавы белән тоз өелгәнен, әтиләренең соңгы тиеннәрен суырып алган тоз тауларының шушында ятканын ул белми иде. Ул, атын житәкләгән көе, тимер күгән, тимер араталар белән беркетелгән ишекләргә карап барды, бу ишекләрнең хуҗасы нинди каты куллы кеше булырга тиешлеген уйлады, шул хуҗаның хуҗабикәсе итеп Нурияне күз алдына китергәч, җаны өшеп китте.

Бояр утарының урта ихатасын хуҗаларга аш-су пешерә торган бүрәнә йорт, ак мунча, кыргый колмак чорнап алган беседка, күкрәп үскән чәчәк түтәлләре биләп тора, утарның бу өлешендәге каралтылар барысы да тәбәнәк булып, ике катлы ташпулатның зурлыгын, мәһабәтлеген аерыбрак күрсәтер өчен салынган төсле тоелалар иде.

Клаус кучерларны ашыктыра башлады. Аның яңа кунаклары килеп житүе бик мөмкин иде. Тик мәдрәсәдә көннәр буе коридор таптаудан ары китмәгән Фатих хәлфә, күпме генә ашыктырсаң да, барган кадәреннән кызурак бара алмый, шуңа күрә Солтан ашыгудан гына бер файда да юк иде.

Бара торгач, алар утарның хезмәтчеләр яши торган ихатасына да килеп життеләр. Кичләрен кучер халкы, ат караучылар, пешекчеләр, ишегалды себерүчеләр, кибетчеләр, тагын әллә ничә төрле һөнәр ияләре тыгызланып тула торган такта түбәле агач йорт тәбәнәк булса да, нарат бүрәнәләрдән нык итеп салынган, аның янында ат абзары, сыерлар абзары, бозаулар араны, кош-корт кетәклекләре, утын лапаслары, тагын әллә ниткән каралтылар тезелеп китә, бу утардан инде урта утардагы кебек таш һәм акшар исе түгел, майда пешкән итле бәлеш һәм кабартма исе дә түгел, тирес исе, тавык тизәге исе, тагын ниндидер ачы-төче исләр килеп тора иде.

Утарның аргы ихатасына чаклы барып житмәделәр. Егерме-утыз гектар жирне биләп, Иш буена хәтле төшеп житкән алма-чия бакчасын, зәңгәрле-сарылы умарталар илен, жиргә сеңдереп эшләнгән пыялалы парникларны ерактан гына күрә алдылар. Хезмәтчеләр ихатасыннан Иш буе болынына чыгып, атларын тышаулап җибәргәч, Фатих хәлфә борынына яшькелт вак «насбай» салды, рәттән ике тапкыр бик каты төчкерде, кайдадыр ярсый-ярсый эт өргән тавышка колак салды, аннары буй житмәс бер нәрсә турында сөйләгәндәй, серле итеп:

— Вәт, ичмасам, яши кешеләр! — дип, кызыл фәсле башын озак кына селкеп торды.

— Үзләре тапканга яшәми бит алар. Ярлы-ябагайның канын суыра, — диде Солтан. Ул кайчандыр, сал агызган чакта, абыйсы Шаукымлы Шәяхмәт әйткән сүзләрне исенә төшерде.

Фатих хәлфәнең төсе качты. Озын бармаклы ябык кулы белән битен каплап, ачулы гыжылдады:

— Көфер сүз сөйләп торасың, фасыйк! Таминдар байга әйтсәм, муеныңны борып ташлар.

— Анысы булыр синең эше шымчыдан, — диде Солтан тыныч тавыш белән, ләкин шуннан соң кинәт ярсып китеп, хәлфәгә күзенең агын әйләндереп карады. Киң җилкәле, үзеннән бер башка олы үсмер егеттән шүрләп, Фатих хәлфә читкәрәк тайпылды...

Өйлә вакытында кунакларның зурраклары килә башлады. «Тәфтиләү» утарына мичәүләп аргамак җигелгән тарантаслар, кибиткалар, фаэтоннар килеп туктады. Европача костюмнан, галстуктан, штиблеттан, тук чырайлы, юантык гәүдәле ирләр нәфис хушбуй исләрен бөтен утарга тараткан, асыл күлмәкле, хәситәле хатыннарын кулларыннан тотып җиргә төшерделәр. Хәзер боларны Клаус белән Габделхәлим кибетче генә каршылап тормый, чәчне кирпе кебек кыска итеп алдырган, ярым хәрби яшькелт френчлы, биек кара күн итекле бер кеше каршылый, фаэтоннардан төшкән кунакларына кул сузган чакта аның кырыс чыраена елмаю куна, усал йөзе аз гына булса да яктырып китә иде.

Солтан аның теге көнне Шәяхмәт абыйсы йортын сатып алган Таминдар бай икәнен таныды. Ат туарышкан сылтау белән Солтан кунакларның барысын да каршы алды, барысын да күздән үткәрде, адәм баласы киеп йөри торган киемнең никадәр затлы, никадәр елтыравыклы булуына, аннан да бигрәк, шушы зиннәтле киемле кешеләрнең гадәти яшькелт френчлы, кырыс чырайлы кешегә буйсынып, юашланып калуларына, яки шундук мактау сүзләре яудыра башлауларына хәйран калды. Килгән кунакларның чамадан тыш байлыгы, җигеп чыккан атларының баскан җирләрендә биеп-тибенеп торулары аны янә дә Нурия өчен хафаланырга мәҗбүр итте.

Солтанны чынлап торып курку алды. Ул хәзер килүчеләрнең үзләрен генә түгел, алар белән янәшә Нурияне дә уйлый, Нуриянең чибәрлеге аларның күзен яндырыр, Габбас мулланы кайсы да булса бер бай үз ягына аударып куяр дип курка башлады.

«Алтын күргәч фәрештә азган».

Һәм ул чыннан да шулай иде. Таминдар бай хатыны — әтәч кикриге төсле кызыл калфаклы Латифа бикә, Габбас мулла кызының кулын үзенең җылы йомшак учыннан җибәрмичә:

— Исемең кем, гөлием? Нуриямени? Бигрәк матур исем? Кайсы чишмә сулары шулай килеште? Ничек шул тиклем дә чибәр булып үстең? — дип оялтты. Ак эскәтер япкан түгәрәк өстәл янына утыртып, гөбәдия белән, өйдә пешкән баллы тәм-том белән сыйлаган чакта, кызга ава төшеп:

— Син шундый чибәр, шундый тәрбияле кыз күренәсең, үз өемә генә алырыем,— дип пышылдады.

Нурия бит очыннан кызара башлап, колак яфракларына чаклы ут булып кызарды. Шуны күреп торган Латифа бикә аны мактап бүтән бер сүз дә әйтмәде, үзе белән бергә кунак йортларын күрсәтергә, кунаклар җыеласы залның бар җире дә әзерме икәнен икәүләп белешергә алып китте. Күңелендә: «Бу минем Һашимыма иш булыр, иншалла. Менә моны ходай үзе китереп тоттырды. Тәрбияле йортта, мулла өендә инсафлы булып үскән, тизрәк улымны өйләндерергә дә Мәкәрҗә ярминкәләрендә тәтәйләр янында буталудан туктатырга кирәк. Таминдар байның азгынлыгы да җитәрлек булды. Монысына да этисе юлыннан китәргә ирек куймам?» дигән уй бик ныклап күңеленә кереп урнашты.

... Ир-ат хезмәтчеләр яши торган якта ат караучы Гата — утыз яшьләрдәге чулак — Солтанның күңелендәге шомны тагын да көчәйтеп җибәрде. Газета кәгазенә тәмәке төрергә җыенып:

— Байлары җыелсын да ди. Ә ул Габбас мулла кызына монда ни пычагым калган? — диде.

— Ә нигә? — Солтан аның мәче күзе төсле яшькелт, әрсез күзләренә төбәлде.

Гата чулак кулының кисентесенә кыстырып «ә» дигәнче тәмәке төреп алды, кәгазьне тәкерек белән чылатып ябыштырды, кул кисентесенә кысып, чакма таш сызды, череккә үрләгән утны тәмәкесенә кабызды, тирән итеп эчкә төтен суыргач, ике борын тишегеннән самавыр торбасыннан чыккан төсле ике агынты аксыл төтен чыгарып, әйтте:

— Байларның үз иманы үзе белән. Үз закуны үзе белән. Сусыз юа, җилсез киптерә. Үсмер кызга мондый җирләргә килеп йөрергә иртәрәк әле, туганым.

— Син нәрсә? Ул бит этисе белән! — Солтан, чамадан тыш дулкынлануын сиздерергә теләмичә, битараф-салкын тавыш белән, гамьсез генә әйтергә маташса да, тавышы калтыранып чыкты.

— Әтисе дисең. Габбас мулла бит буй җиткән кызын үз янына яткызып йоклата алмый. Аның белән бергә бәдрәфкә дә бара алмый. Козгынның тавыкны кай урында тотып басканын каян беләсең...— Гата тәмәке төтененнән саргайган сап-сары эре тешләре арасыннан «тычт» итеп идәнгә төкерде, Солтанга таба яны беләнрәк борылып:

— Нәрсә, мәхдүмәгә әллә үзеңнең күзең төштеме? — диде.

— Төшмәде.

— Нигә, алайса, калтырана башладың?

— Авылдаш бит. Бергә килдек, бергә кайтасы...

— Чыпчык күгәрченгә иш түгел.

Солтанның җен ачуы чыкты, тамак төбендә нидер готгылдап тора башлады:

— Нәрсә син туктаусыз бер сүзне каркылдыйсың? Салып торып җибәрермен!

— Чү-чү, егетем, бик кәперәймә. Гата абзаңның кирәк булып чыгуы бар. Күреп торам, мулла кызына күзең төшкән, сыбызгы! Ярар, булдыра аласың икән, этмәллә. Мин, кирәк булса...

Солтан күзенең агын әйләндереп бер карады да, тыны кысылудан гыжылдап, чулак өстенә килә башлады:

— Туктыйсыңмы-юкмы, кабәхәт?! Тагын бер генә сүз әйтеп кара... бер генә сүз! Җыланны сыткан кебек... шакшы телеңне тешләп катарсың!

Чыннан да ат караучы тел тибрәтеп тагын бер генә яман сүз әйтсә дә, Солтан аңа ташланырга, умырырга, ертырга, уңлы-суллы яңакларга, исән кулын сындырып чыгарырга әзер иде. Ат караучы абзый моны аңлады, күрәсең: сабыйларча саф бер елмаю белән елмаеп, әле бүген генә танышкан үсмер егетнең җилкәсенә исән кулын китереп салды:

— Яшь шул әле син, аягыңа сыер басмаган. Байлар җәберен дә татымагансың. Күңелең синең ак болыт кебек. Миңа җикеренмә син, егет булсаң, Таминдар байга җикерен. Аның халуйлары сине бик озак ярсытып тормаслар, өстеңә овчарка җибәрерләр дә җеннеңне өздереп чыгарырлар. Белдеңме? — Ул кинәт шыпырт тавышка күчте:— Менә нәрсә, үскәнем... Мин синең мәхдүмәгә муеннан гашыйк икәнеңне күреп торам. Шулай булгачыннан, авызың белән кош тотып йөрмә, сак бул. Таминдар байның олы малае, үләксә козгыны кебек, кайда чибәр, кайда яшь — тырнагын батырырга гына тора. Әгәр дә мәгәр, алай-болай кыр җыенына мулла кызы белән һашим чыгасы булсалар, берәүгә дә ышанма, тарантас башына кучер булып үзең утыр, аңладыңмы? — Шул сүзләрне әйткән чакта аның җыерчыклы какча бите әллә ничек чалышаеп китте һәм ул чулак кулы белән янә дә күз ачып йомганчы тәмәке төреп кабызды.

Шул минуттан башлап Солтанның җан тынычлыгы югалды. Кайдадыр эт өргән тавышка да, ярсып айгыр кешнәгәнгә дә ул ихатага йөгереп чыгып, көннең икенче яртысын кешеләрне күзәтеп үткәрде...

Бәйрәмне Таминдар бай нигезен изгеләндерүдән башладылар.

Башына бохар чалмасын урап, яшел атлас чапанын кигән мәһабәт ак сакаллы Сөләйман хәзрәт; кара хәтфә түбәтәйле, ак күлмәкле, кара кәзәкиле һәм кара бөдрә сакаллы Габбас мулла; тар балаклы кара чалбары, сары ефәк жилеткасы, зәңгәр кәзәкие белән, бөтереп куйган чибәр кара мыегы, ияк очында гына калдырып алдырган очлы кара сакалы белән аерылып торган, муллаларның икесеннән дә яшьрәк Даут мулла ташпулатның югарыгы катында, гыйбадәт кылу өчен дип билгеләнгән аулак бер бүлмәдә, һәркайсы үзе алып килгән намазлыгы өстенә аяк бөкләп утырып, өчесе берьюлы бөтен коръән чыктылар.

Коръән чыгу йоласы ике сәгатьтән артык вакытны алды. Муллаларның берсе дә хәрамлаша алмый, ник дисәң, алар, көндәш хатыннар сыман, бер-берсен бик нык күзәтәләр, шуның өстәвенә, әле Таминдар бай үзе шушы вакыт эчендә, «әһ» тә димичә, алар белән бергә утырды; коръән укылып беткәч, буй-сынын егетләрчә ыспай, эшкуарларча житди итеп күрсәтә торган ярым хәрби френчының чалбар кесәсеннән калын гына бумажник чыгарып, шытырдап торган өр-яңа николайкаларны муллаларның кулына тоттырды. Үзе алар белән бергә утырып, кычкырып дога кылды, доганың бер генә сүзен дә бозмады, эштән беркайчан да курыкмый торган көрәктәй кулларын кара тутлы ябык бите алдында ышанычлы итеп тотуы, гомумән гыйбадәт кылу кануннарын дин-шәригать кушканча жиренә житкереп үтәве һәм үтәтүе белән өч мулланың өчесе алдында да ихтирам казанды, алар хәзер аның теләсә нинди гозерен теләсә кайчан үтәргә әзер иделәр...

Йортны изгеләндергән арада кунакларның беришесе, Клаус белән бергәләп, Таминдар Тураевның утарын карады, кайсысы Иш буена чыгып, озак юлдан соң хәл алды. Бай улы Һашим, энисе Латифа бикәнең әмерен үтәп, Габбас мулла кызы Нурияне иң яхшы фаэтонда кыр-болыннарны әйләндереп кайтырга ниятләде.

Орлов юртагын бахромалы фаэтонга жиктеләр. Кучерлыкка Габделхәлим сәүдәгәр көндезге матур киемнәре белән үзе менеп утырды.

Солтан хезмәтчеләр йортыннан ихатага чыккан иде. Башны югары чөеп, гайрәт орып килгән Орлов юртагы аны таптап китә язды. Солтан ат карауччы чулакның киңәшен исенә төшерде — аркасы чымырдап китте. Яшен тизлегендә уй туды: болынга! Әйе, әйе, болынга чабарга! Хәзер үк сәгате-минуты белән. Ул, алдын-артын абайламыйча, болынга йөгерде, кара-туры айгырның тышавын чишеп, өстенә менеп атланды да, фаэтон киткән якны шәйләп, басу юлына чыгып чапты.

Фаэтонны эзләп озак йөрде. Тапмады. Инде атны кайтарып куеп, Гата абзый белән ат карауччылар йортына ятып йокларга да уйлап бетергән иде, шул мәлне Иш буена төшеп менү никтер исенә килде...

Орлов юртагын ул ерактан ук күреп алды. Күз бәйләнә башлаган офык читеннән бүре уты төсле өермәле тәгәрәп фаэтон килеп чыкты, минуты-секунды белән якынлаша башлады. Солтан каушады, кара-туры кушаяклап чаптырып китте, ләкин Орлов юртагы аны бер-ике минуттан куып житте. Солтан үз артында ярсып пошкырган атның арт аякларына чүгеп туктавын, Габделхәлим сәүдәгәрнең яңгыравыклы ачы тавыш белән кычкырганын ишетте:

— Тукта!

Туктады. Читкә чыкты. Фаэтон аның белән тигезләште.

— Син нишләп монда йөрисең, малай актыгы?!

— Айгырны сугарып кайтам.

Фаэтон кузласыннан кучерның ярты гәүдәсе сузылды, тавышы ысылдап чыкты:

— Кем рөхсәт итте сиңа, эттән туган йолкыш?

— Берәү дә рөхсәт итмәде.

— Хәзер үк кайтарып куй атны, юкса...
Солтанның киреләнәсе килеп китте:
— Кайтармасам?
Габделхәлим сәүдәгәрнең ярсудан буылып гыжылдый башлавына фаэтон ишеге ачылып, башта аннан ир-ат башы, аннары... энҗеле калфак күренде.
— Кагылмагыз Солтанга...
Нурияне ул шундук таныды, аңа бүтән берни кирәкми иде. Чит ир-ат белән икәүдән-икәү генә утырып торган, сәхрә гизеп йөргән Нуриягә карата аның күңелендә гарьлек уты, көнчелек уты, нәфрәт уты — барысы берьюлы кабынды. Аның, чәчләрен йолкый-йолкый: «Хыянәтче!» — дип кычкырасы килде. «Кагылмагыз», имеш! Табылган монда яклаучы! Тик ул кычкырмады, ат өстеннән иелә төшеп:
— Рәнҗемә, Габделхәлим абзый, хәзер кайтарып куям мин аны, — диде. Кара-турыны камчылап, бай утарына турыдан ярып чыкты. Сүзендә торды: айгырны тышаулап, болынга җибәрде, аның җир тетрәтерлек кешнәп, бияләр янына барып кушылганын тыңлап торды, аннары, Таминдар бай утарына кереп тә тормастан, кулындагы камчыны койма аша тондырып, Иш елгасы буйлап әңгер-меңгердә каралып күренгән өянкеләр, кара таллар яныннан түбәнгә, Зартугайга таба китеп барды...

Күз тәмам бәйләнеп, Таминдар бай утарына күгелҗем күләгәләр яткач, кунаклар килүгә махсус алынган бәллүр люстралы кәндилләрне, стена буйларына тезеп чыккан шәмдәлләрне кабызып җибәрделәр. Төтен сыман җиңел өрфия пәрдәләр аша, биек тәрәзәләрне балкытып, урамга ут көлтәләре бөркелде.
Кунакларны зәңгәр залга чакырдылар. Фирүзә төсенә буялган биек диварларга, балавыз белән ялтыратылган паркет идәннәргә, залның буеннан-буена сузылган ак эскәтерле, шәраб-нигъмәт тулы өстәлләргә күз төшергәләп, кунаклар залга керә башладылар.
Таминдар бай, көндезге киемен үзгәртмәгән, яшькелт төстәге ярым хәрби френчтан иде. Тутый кош кебек киенгән, бәхетле тук тормыштан тулыша башлаган Латифа бикәне ул кулыннан җитәкләп килеп керде:
— Кадерле кунаклар, табынга рәхим итегез, — диде.
Кибетләр башлыгы Габделхәлимгә һәм хуҗа улы Һашимга кунакларны утырту вазифасы йөкләнде. Европача киенгән, изүенә кара бант таккан, милләткә ихтирам йөзеннән башына кара кәттәши утыртып куйган җиңел сөякле, этисе төсле зур борынлы Һашим мәҗлес көйләүнең рәтен белә булса кирәк, ул бик тиз арада кунакларга урын табып бетерде.
Таминдар байның бер ягына Ырымбур байлары Хөсәеновлар утырдылар, икенче ягына Габдерахман Ишморатов хатыны белән урын алды, аннары өстәлнең ике ягына, кара-каршы Сөләйман хәзрәт белән Габбас мулла утырдылар. Габбас мулла янына, әдәп белән генә, рөхсәт сорап, Һашим әфәнде үзе утырды һәм, үтә дә нәзакәтлек белән иелеп, кулын күкрәгенә кушырып, Нурияне үзе янына утыртырга рөхсәт сорады.
Уфа бае, атаклы матбагачы Кәримов үзенә юлдашка Даут мулланы сайлап алды, ул ханым-әфәнде белән килмәгән, шуңа күрә аңар иптәш кирәк, Даут мулланың ул шигырьләр язуын белә, нәфис әдәбиятны бик ихтирам итә икән. Аннары калган кунаклар утырыштылар.
Кунаклар утырышып беткәч, табын яны кинәт бик тын булып калды. Башларына энҗеле калфак кадап куйган, үтә дә сылу һәм яшь өч кыз шампан шешәләреннән хрусталь бокалларга шәраб коеп чыктылар.
Таминдар бай урыныннан күтәрелеп:

— Әфәнделәр, минем йортымны олылап килгән өчен сезгә тәшәккердән гаҗизмен. Мөлдерәмә тулы шәрабләрне, кадерле вә могтәбәр кунакларым, сезнең рөхсәт белән, милләтебез саулыгына тәкъдим итәм, милләтебез яшәсә, без яшәрбез, — диде.

Кунаклар урындыкларны дөбердәтеп аягүрә бастылар. Хрусталь рюмкаларны, кызлар биленнән тоткан кебек, сак кына тотып, бәллүр чыңы белән чыңлатып чәкештеләр дә күтәреп куйдылар.

Нуриянең уналты яшькә җитеп шәраб дигән нәрсәне эчеп караганы юк иде, әтисе рөхсәт иткәч, Һашим әфәнде дә кыстагач, әз генә авыз итеп куйды. Бераздан аның рәхәт кенә, җиңелчә генә башы әйләнә башлады, хрусталь люстраның бәллүр чуклары аңа нур җепләре суздылар, күз кысышып җемелдәштеләр. Аңа хәзер мондагы кешеләрнең барысы да матур, барысы да әйбәт булып күренә, ул менә хәзер Иш елгасы тугаеннан, караңгыдан кармаланып кайткан Солтанны башына да китерми иде...

Шәраб рәхәте кешеләрнең әкренләп башларына китә башлады. Торып басучылар Кама буенда татар буржуазиясенең яңа йолдызы калкып чыгуы, аның киләчәге зур булуы турында тост әйтеп, үзләре әйткәнгә үзләре ышанып, кул чаптылар. Хрусталь бокалларда шампан күбекләнде, бәләкәй рюмкалардан каңга күчкән француз коньягы тамырларны кымырҗытты; барысы да кыюландылар, барысы да үзләре әйткән сүз Таминдар Тураев күңеленә сары май булып ята дип уйладылар. Таминдар — мактау сүзенә исерә торган кеше түгел, ул әйткән сүзнең һәркайсысын үз үлчәвенә салып карый, чиреген кабул итсә, өч чиреген, стенага бәрелеп атылган борчак кебек, кирегә атып тора иде.

Ниһаять, мактау сүзләре дә бик күп әйтелеп, байның яңа утары тәсбих урынына тартыла башлагач, ул кунакларны ни өчен чакыруының сәбәбен әйтер вакыт җиткәндер дип уйлады, музыкаль сәгать игъълан итте, ханымнардан ирләрен аерып, үз конторына алып кереп китте. Анда да табын бар иде, ләкин анысы бәлешләр, гөбәдияләр, бламажилар, тортлар белән бизәлгән озын өстәл түгел, күзгә бәреп торган купшы табын түгел, шкаф эченә бикләнгән эшлекле җитди табын иде.

Таминдар әфәнде үз кулы белән буфеттан француз коньягы алды, үз кулы белән бөкесен ачты, чытыр ак, тотылмаган салфетка белән шешә башын сөртте, алдан ук турап куелган лимонны, вазасы белән алманы табынга куеп, рюмкаларга коньяк салып чыкты, берничә минутка гына игътибар итүләрен сорады. Ул башта утырып сөйләмәкче иде, әмма сөйләр минут җиткәч, дулкынлана башлады: нинди олы эшләргә тотынып янганын, ничәмә-ничә мең кубометр бүрәнәне үз гомерендә Кама дулкыннарына агызып җибәргәнен искә төшереп, уфтанып куйды.

— Без, әфәнделәр, бик авыр заманда бер табынга җыелдык. Ырымбурның күрке булган бертуган Хөсәеновларның, Рәсәй чаклы Рәсәйдә сүзләре үтә торган хөрмәтле кешеләрнең минем табынымда булуларына мин шатмын. Троицкины дер селкетеп торган Яушев әфәнде минем табынымны бизәде. Габдерахман әфәнде Ишморатов мин әле капитал дөньясына борынымны гына суза башлаган заманда меңәр гектарлы урманы, Казанда һәм Санкт-Петербургтагы мануфактура фабрикалары белән, Себер ягындагы алтын приискалары белән, ат заводлары, агач эшкәртү заводлары белән дан алган кеше иде. Ул минем табыныма килеп, мине олылады. Мәдәниятебез мәйданында ат уйнаткан Кәримов әфәнделәрне мин үз табынымда күрү бәхетенә ирештем. Олуг Сөләйман хәзрәт, хөрмәтле Габбас мулла, Даут мулла минем йортыма изге дога иңдерделәр. Мин моның өчен сезгә, әфәнделәр, мең рәхмәтле. Әмма безнең җыелуыбыз Рәсәй язмышы кыл өстендә торган чакта, немесләрнең корыч полклары Рәсәй халкын меңәрләп кырган заманда, берберебезне макташу өчен, шәраб сөремендә күңел ачу өчен генә дип уй-

ласак, зур хата ясаган булырыек. Безгә, татар буржуазиясенә, күзләребезне зуррак ачып, Стахиевлар, Крестовниковлар, Алафузовлар эшенә карарга кирәк түгелме икән? Безгә хәзер тире иләүче, күнче Фәхриләр, бәвел исе килеп торган бетле бәс тукучы, Казанның йолкыш байларыннан үрнәк алыргамы? Безгә патша сарайларында үз өендәге кебек йөри ала торган, патшаның унөч киңәшчесеннән берсе була алырдай алпавыт Ишморатовлардан, Сембер капиталистлары Акчурин әфәнделәрдән үрнәк алырга кирәк түгел микән? Моннан мең ел элек Шәһри Болгарда сафиян күне ясый белгәннәр икән, йөз ел моннан элек Казанда кәҗә тиресеннән иң затлы күн ясап Яуропага чыгара белгәннәр икән, ни өчен без бүген йоклап ятарга тиешле?

Ул эчке киеренкелектән тирләп чыкты, сулышын буган френч якасын чишеп җибәрде, кесәсеннән кулъяулыгы чыгарып, озаклап маңгаен сөртте, шуннан соң тавышындагы борчылуны киметә төшеп, ышандыргыч-эшлекле тавыш белән җай гына алып китте:

— Тянь-Шань тауларыннан башлап Ока елгасының урта агымына тикле, Архангельдан Әчтерханга тикле кыргызлар, башкортлар, татарлар яши. Кыргызлар шушы көнгә тикле күз күреме җитмәс дүрт далада: Урал, Тургай, Акмулла, Семипалат далаларында күчмә тормыш алып баралар, исәбенә-санына чыга алмастай ишле куй көтүләре асрыйлар. Кыргызлар күптән ислам диненә карасалар да, коръәнгә бик исләре китми, үз гадәтләре, үз белдекләре белән яши бирәләр. Капитал дигәнне белмиләр, белергә дә теләмиләр. Кыргызлардан бире таба, Урал итәгендә, Урал аръягында башкортлар яши. Алар хәзер тоташ күчеп йөрүчеләр түгел, алар утрак тормыш алып баручылар. Җирне сука белән сукалый беләләр, әмма иген үстерергә атлыгып тормыйлар; ат көтүләре, болыт-болыт сарык көтүләре аларны туендыра. Уралның чуен-бакыр кою заводларында рус белән татар бил бөгә. Урал байлыгы белән рус капиталистлары сәүдә итә. Безнең татар — җиргә ябышкан халык, сәүдәне савaплы ике шөгыльнең берсе дип санаган халык. Милләтебезнең күбесе авыл җирендә яшәсә дә, Идел буе калаларында безнең сәүдә кварталларыбыз бар. Ул гынамы! Касыйм татарлары, Сергач мишәрләре, нижгарлар Россиянең төрле калаларында, шул исәптән Мәскәүдә дә, Петербурда да сату-алу итәләр, безне, Казан татарларын, Урта Азия товарлары кызыктыра, мишәрләр турыдантуры русның үзе белән сәүдә итәләр, тимер юл буендагы барлык зур калаларда аларның буфетлары бар. Ә нигә безгә алардан файдаланмаска? Нигә безгә шул мөмкинлекләрне кулдан ычкындырырга?

— Нәрсә тәкъдим итәсез, Таминдар әфәнде? — диде Габдерахман бай, утырган җиреннән кузгалмыйча.

— Берләшергә кирәк, әфәнделәр. Мөселман кардәшләребезне цивилизациягә алып чыгарга кирәк.

— Капиталны гына берләштерергәме? — диде Даут мулла.

— Капитал белән генә булмас, дини бердәмлек кирәк. Сәүдәгәрләр белән муллалар башкорт белән кыргыз даласында йөриләр. Казан каласында басылган китаплар кыргызга, башкортка гына түгел, Һиндстанга, Дунай буйларына барып җитә. Кыргыз даласыннан, башкорт даласыннан күпме кеше татар мәдрәсәләрендә укып, татар-мөселман гыйльмен үз халкы арасында тараткан. Болар барысы безнең тегермәнгә су коя түгелме?

— Берләшү өчен!

— Ныклык өчен! — дип ду килделәр милли хисләре куерып киткән кунаклар. Таминдар әфәнде аларның тойгыларын тагын да көчәйтеп җибәрде. Ул мех эшенең татар байлары кулыннан герман еврейлары кулына күчүен, Луи Зальмның Казанда сәүдә конторасы ачып, Себердән, Урта Азиядән китерткән мехларны Германиягә озату бәрабәренә

сугыш чыкканнан башлап ике ел эчендә генә дә ундүрт миллион сумлык тире сатуын йөрәге ярсып, күзеннән очкыннар чәчрәтеп сөйләде.

Берләшү өчен, капиталны арттыру өчен, Идел-Камада компанияләр ачу өчен, француз коньягы күтәрделәр. Боларны кулында капитал булган кешеләр эшләде. Өч мулланың өчесе дә я баш селкеп, я аларның сүзен җөпләп кенә утырды. Ләкин аларга да үз сүзләрен әйтергә кирәк булды. Монда зәңгәр томаннар артында яшәүчеләр түгел, кирәкле сүз әйтергә тиешле кешеләр җыелган иде.

Беренче сорауны Таминдар бай Сөләйман хәзрәткә бирде. Ул ни уйлый, янәсе.

Сөләйман хәзрәт, атлас камзулының төймәләрен ычкындырып маташа иде, сорауга башын күтәреп:

— Мин риза, фатихамны бирәм, — диде.

Габбас мулла:

— Бу эшкә минем башым җитеп бетми, балалар укытырга кушсагыз, мин шунысына риза, — диде.

Даут мулла, әйтер сүзен ашыкмыйча, нык уйлап әйтте:

— Хыялларыгыз зур, ярсынуыгыз көчле, ләкин соңгарак калдыгыз, әфәнделәр. Ил өстенә инкыйлаб килә. Иртәме-соңмы ул безнең барыбызны да үз чоңгылына сөйрәп төшерәчәк.

Даут Гобәйди имзасы белән шигырьләр бастырган бу муллага Таминдар Тураев үзе дә, аның могтәбәр кунаклары да беренче мәртәбә төбәлеп сәерсенеп карадылар...

## VIII

Ул төнне Мәскәү күгендә болытлар куерды. Ул төнне җил Измаил паркындагы куакларны бөкте, юлларга, агачлар арасына сибеп җибәргән өндәмә-кәгазьләрне очырып, җиде төн уртасына тикле котырынып йөрде.

Аннары тынды.

Ләкин Мәскәү тынмады.

Дагалы атларга атланган полицейскийлар, жандарм офицерлары, җылы ояларыннан кузгатылган шымчылар (әле вак һөнәрче, әле мөгаллим, әле сукбай киемнәренә төренеп) Мәскәүнең аркылысын-буен айкадылар. Алтатардан, ау мылтыгыннан, берданкадан аткан тавышлар Мәскәүнең үзәк урамнарында да, чат-тыкрыкларында да ишетелеп торды.

Җиде төн уртасында мылтык тавышлары да тынды.

Ләкин Мәскәү тынмады.

Тәрәзә капкачлары ябылган, авыр соры шторлары төшерелгән зиннәтле йортлар эчендә, фәкыйрьлектән интеккән кысан баракларда якынлашып килгән давылның дәһшәтен тану яки танымаудан, килешү яки килешмәүдән туган өермәләр бара, әнә шул хәл кешеләрнең тынычлыгын алып, йокыларын качырган иде.

Мочальский урамының ике катлы йортында Бонакер акционер җәмгыятенең төнге каравылчысы Нуриман абзыйның да йокысы качкан иде бу төнне.

Көндезен ул татарлар җыела торган урынга — Измаил паркына барды. Анда алар ат маклеры Тазюк белән очрашырга сүз куешканнар, Тазюк аңа алты яшәр алмачуар байтал табып бирергә вәгъдә иткән иде. Нуриман абзыйның нияте зурдан: кулга ат төшерсә, төнге каравылчылыктан чыгар иде. Олаучы булып йөрүгә ни җитә! Кайчандыр әле Сембердә, ат базарларында үзенең дә арадашчы булып йөргән чакларын, берсеннән-берсе усал мишәр әшнәләрен искә төшерә-төшерә, Измаил паркына килеп җитте, ләкин... Тазюкны очрата алмады.

Бик тә сәер иде бүген парк. Вак товар сатучылар энә-җепкә, уймак-төймәгә дөньяда булмаган бәя сорыйлар; олаучы кузлаларына кәләпүшле татар агайлары түгел, картузлы урыслар утырган; күрәсең, алар монда сату-алу итәргә, кеше йөртергә килмәгәннәр, ниндидер башка йомыш белән җыелганнар.

Аңгы-миңге килеп торганда, Нуриман абзый яныннан фуражкалы, күн итекле эшчеләр белән уратылган хәлдә, яшь бер егет узып китте. Нуриман абзыйга үзәк өзгеч якын булып, үз булып тоелды ул егет. Бакчи, улы Шәймәрдән ләбаса! Нишләп йөри ул малакасус. Куып җитәргә, җилкәсеннән умырып тотарга кирәк! Нуриман абзый куып җитәргә теләп, улы артыннан дырт-дырт йөгерде, ләкин җитә алмады, әлеге төркем, егетне үз эченә ураган килеш, паркның конторына кереп юкка чыкты.

Нуриман абзый дөнья күрмәгән кеше түгел, конторга барып керергә дә күп сорамас иде, ләкин аны анда кертмәделәр. Көрәк сакаллы ике урыс: «Вам кого, гражданин?» — дип кенә сорадылар да, Нуриман абзый кем кирәген өзеп кенә әйтеп бирә алмагач, монда торырга ярамаганын, эшсез селкенгән кешеләрне полиция җыеп алып китәчәген хәбәр итеп, контор яныннан иплән кенә озатып җибәрделәр.

Һай, шул иплe кылanулары! Әгәр алар җикеренгән булсалар, усал сүзләр әйтеп, тупаслана башласалар, Нуриман абзый алар белән сөйләшә белер иде. Сембер базарларында ат маклеры булып йөргәндә дә, Бонакерлар фабригында төнге каравылчы булып торганда да ул кешене кешедән аерырга, кирәк икән, «права яклап», тавышлана белергә дә өйрәнгән иде. Мишәрнең дә мишәре, усалның да усалы иде Нуриман абзый. Сусыз юып, җилсез киптерә алырлык кеше иде. Менә син хикмәти хода, көрәк сакаллы ике урыс сине контор ишеге төбеннән ләм-мим бер сүз әйтмәслек итеп озатып җибәрсеннәрче!

Абзыйның сулкылдап йөрәге сызлый башлады. Йөрәк сызлавы фуражкалы урыслар уртасында конторга кереп киткән яшь егетнең үз улы Шәймәрдән икәнен таныган минуттан башланды. Нишләп йөри ул монда? Дөньяларның болгавыр чагы, тычканның таяк белән йөргән чагы, ә ул үнҗиде яше дә тулмаган аңгыра бәрән, урыс-үнтагай белән аралашып, күзе-башы әйләнеп йөри. Юк, туктатырга кирәк аны, чик куярга кирәк бу эшкә! Өйгә генә кайтсын, ул аның белән сөйләшә белер, ул аны утлы табага бастырыр. Ормас-сукмас, Нуриман өендә балаларга сугу гадәте юк, ул аңа каршы әнисе Хафизаны аякландырыр, күз яше койдыртыр. Ә хатыннарның күз яшенә каршы тора алган ирләр бармы дөньяда? Ай-һай!

Абзыйның алдан күрә белергә өйрәнгән зирәк акылы дәһшәтле күренешләрне күз алдына бастырды. Аяк-куллары чылбырланган кешеләр атлый. Богау зыңнары ишетелә. Алла сакласын, өтермән дигәннәре дә, себер дигәннәре дә ерак түгел. Себер киткән малаең өчен канлы күз яшьләре түгеп утырыргамы — шул гына җитмәгәние...

Нуриман абзый адәм баласының ни күрәсе үзе туганчы ук тәкъдирдә язып куелган була дип гөман кылган диндар бер адәм иде. Ул көннең-көнендә биш вакыт намазын укый, өйдәгеләрне дә изге ниятле итеп үстерергә тырыша, әмма динле булу аңар сату-алу, арадашлык итү белән шөгыльләнергә дә, нәселле берәр аргамакны сатып җибәргәндә, маклерлык хезмәте өчен, мул гына кул җилеше алырга да комачауламый иде.

Мәскәүгә ул Сембер губернасының Питрәкчә авылыннан күчеп килде. Бер мең дә сигез йөз дә туксан сигезенче елның апрель ахырларында булды бу хәл. Яңа гасыр башланырга бер генә ел кала аның беренче ир баласы дөньяга килде. Татар гадәте буенча әтисе исеменә ятышлы итеп, Шәймәрдән дип ат куштылар. Нуриман үзе бик тә таза, бик

тә көчле ир иде әле ул чакта, бер генә төрле шөгыльдән дә куркырлык түгел иде — фатир табу бәрабәренә урам себерүче булып ялланды. «Артыңнан эшең көлеп калсын!» дигән кагыйдәне күңеленә беркетеп, тырышып-тырмашып эшләде, аның тырышлыгын хуҗалар күрделәр, бер ел узар-узмаста йорт хуҗасы Бонакерлар аны үзләренең фабрикаларына төнге каравылчы итеп билгеләделәр. Мочальский урамындагы ике катлы йортның икенче катына шактый иркен фатирга күчерделәр. Нуриман отыры олыгая барып, эшләгән урынында хөрмәт казанып, тагын ике малай, ике кыз үстереп, тыныч кына, үзалдына карап кына яши иде. Төнге каравылчылык янына Мәскәү байларының бик тәҗел йомышларын үтәп, аннары үзе дә базар көннәрендә Измаил паркында сату-алу эшләрен җаелдереп җибәргәч, Нуриман Ибраһимов Мәскәүнең хәллерәк мишәрләре арасына да керерлек дәрәҗәгә иреште. Дәрәҗәле мишәр, мәгълүмдер ки, беренче баласын аңгыра итеп, кара мужик итеп үстермәс бит инде! Шәймәрдәнгә — баш баласына — ул дин гыйлемен бирүне максат итеп куйды. Башта ул аны танышлары — укымышлы хәлфәләр кулына тапшырып, ун яшенә тикле коръән ятлатты. Шәймәрдәннең тавышы тигез, сулышы киң, зиһен дигәне беркемгә биргесез булып чыкты. Ун яшьлек малай кара хәтфә түбәтәйдән, сары сатин күлмәктән, ялан аякны муллалар кебек бөкләп утырып, яттан коръән укып җибәргәндә, мәҗлескә җыелган мишәрләр таң калып торалар, эти кешенең галибанә горурлыктан күңеле нечкәрә иде. Улының киләчәген ул бер дә бүтән түгел, указлы мулла итеп күрә, татар мәдрәсәләренең кайсысына бирсәм отармын икән дип, таныш-белешләре, туган-тумачасы, дус-ишләре белән киңәш кора иде.

Әллә дөньялар бик кинәт үзгәреп китеп, мулла-мунтагайның кадере беттеме, әллә үзе төсле ат маклерлары, алып-сатарлар белән гәп корган чакта дөньяга урысча белүчеләрнең көннән-көн күбрәк кирәк булуы турындагы сүзләр күңеленә коткы салдымы — ни булса да булды — Нуриман абзый коръәнне су кебек эчкән улын, елына өч тәңкә көмеш түләп, дүрт сыйныфлы урыс мәктәбенә — шәһәр училищесына илтеп бирде.

Ялгышы әнә шуннан башланды да инде аның. Югыйсә, аның Шәймәрдәне бүген урыс-улак белән әвәрә килеп йөрмәс иде. Малай коръәнне ничек тиз ятлаган булса, урысчаны да шундый тизлек белән күңеленә сеңдереп, Мәскәү китапханәләреннән чыкмый ята башлады. Ишле гаиләгә булышырга тиешле баш баланы кулдан ычкындырмаска кирәк иде. Нуриман абзый дүртьеллык училище бетергән улын Бонакерлар конторына йомышчы малай итеп урнаштырды. Сугыш чыккан авыр заманда улының трай тибеп урамда йөрмәве, ай саен йортка аз булса да акча алып кайтып торуы йорт җанлы атаның күңеленә сары май булып ягылды. Шуның өстәвенә, эти кешенең күңелен яңадан-яңа ниятләр җылытып тора: байлар кибетендә эшләгән булдыклы малайлар берәр елдан ук приказчик булып китәләр. Бакчи, улың берәр елдан мая туплап, үз кибетен ачып җибәрсә! Ә бит аның улы йолкыш бер бай кибетендә сабын сатмый, бөтен Мәскәвенә атаклы Бонакерлар фабригында эш йөртә. Ходайга шөкерана кылып, сабыр гына көтеп торсын әле менә Нуриман абзаң, аның улы Бонакерлардан әллә ниткән осталыкларга өйрәнер. Әйе, абзыйның ният зурдан, өметләр яктыдан. Ләкин ул бер нәрсәне онытып җибәргән: аның акыллы зирәк улы кибетчеләр арасына түгел, меңләгән эшче кайнап торган фабрикага килеп эләккән иде шул! Еллары да байбәтчәне, фабрикантларны тыныч кына симертеп яткан еллар түгел, эшче сыйныфы адым саен үз хокукын даулаган, урам уртасына чыгып, митинглар җыеп, әйтер сүзен бугаз ертылганчы кычкырып әйтә торган еллар. Аустрия кырларында, Аршауда, тагын әллә кайларда адәм башы меңәрләп кырылган заманда, уналты яшьлек Шәймәрдән йомышчы малай булып кына калырмы? Нуриман абзый

күңеле белән нидер сизенә, әмма сизенүдән артыгына башы җитми, йомышчы малайдан хисапчы итеп күчерелгән улының аена унике тәңкә акча алып кайтуы — аны кискен уйларыннан туктата, улын тиешле юлда дип гөман кылырга мәҗбүр итә иде.

Юк, аның улы дөнья болгатучылар белән түгел! Аның улы азар-бизәр килеп йөрми! Менә шул бик җитә Нуриман абзыйга, шуннан артыгы кирәкми. Шушы хәл аңа таныш-белешләре арасында мактангалап куярга да сәбәп була. Ул бер нәрсәне башына китерә алмый... Аның зирәк акыллы улы, кемнәрнеңдер киңәше белән, кичке якшәмбе мәктәбенә барып керде, ә ул кичке мәктәптә, Шәймәрдәннән тыш, төрле завод-фабрикалардан җыелган эшчеләр укып йөри, чибәр булып үсеп килгән акыллы егетнең алар күзенә ташланмый калуы мөмкин түгел иде.

Һәм ул шулай булып чыкты да.

Шәймәрдән Андрюша Меркулов белән танышты. Кара мыеклы, күзлекле, ыспай киемле Меркулов иптәшләре белән тәмәке тартырга чыккан чакларда үзалдына елмаеп тора, вакыт-вакыт авыр гына көрсенеп куя... Башкалар әйтмәгәнне дә әйтеп ташлый. «Карәле, сугышның эшче халкына файдасы юк икән ләбаса! Фабрикантлар, завод тотучылар кесәсен калынайту өчен генә кирәк икән сугыш». Болар көн саен Шәймәрдәннең колагына керә. Кышкы озын төннәрдә үсмер егет әнә шулар хакында баш вата. Күршеләре, Мочальский урамындагы кварталларда яшәгән эшче гаиләләре, җитмәүчелектән, тормыш кысынкылыгыннан зарланалар. Шәймәрдән эшчеләр сөйләгән сүзне Меркулов сөйләгән сүз белән чагыштырып карый — су бер үк тегермәнгә коела. Шунлыктан Шәймәрдән тәмәке тарту булмасена телəбрәк чыга, Меркулов сүзләрен телəбрәк тыңлый. Шәймәрдәннең танышлыгы Меркулов белән генә калмады, үзе дә сизмәстән, ул тагын бер кеше белән танышып алды. Монысы Иван Смирнов. Аксыл-сары чәчле, якты зәңгәр күзле, гомумән, якты холыклы бу кеше үз тирәсенә «ә» дигәнче бер дистә егет җыеп алды. Смирнов Благуша-Лефорт районындагы публичный земский китапханәдә сүзе үтә торган кеше икән, анда үзенең якыннары — «ышанычлы егетләр» өчен яшерен бүлек ачтырган, ә ул яшерен бүлек бик сайлап җыелган социал-экономик китаплардан гыйбарәт икән.

Китапханәче Галкина (большевик Галкин хатыны) Шәймәрдәнгә иң башлап Дикштейнның «Кем ничек яши» дигән китабын тоттырып җибәрде. Шәймәрдән, этисеннән яшереп, төн уртасында, сукыр лампа яктысында китапны укып чыкты һәм өр-яңа дөньяга килеп эләккәнен, ул дөньяның хәвеф-хәтәрле икәнен, үз тырнагыннан ычкындырмыйча, гел алга әйдәп, мавыктырып торуын аңлады.

Шуннан бирле Шәймәрдән этисе теләмәгән тормыш белән яши башлады.

Унбишенче ел башында Андрюша Меркулов Шәймәрдәнне Павел Щербаков белән таныштырды. Ронталлер төймә фабрикасында мастер ярдәмчесе булып эшләгән шактый олы яшьтәге Павел Андреевич күптәннән большевиклар партиясе члены икән: аңар китапханәгә йөргән иң сәләтле, иң аңлы егетләрне большевиклар партиясенә тарту бурычы йөкләтелгән. Башта ул Шәймәрдән Ибраһимовка прокламацияләр тарату, аларны урамнарга, халык күбрәк җыела торган урыннарга ябыштыру кебек йомышлар кушты, аннары атнасына икешәр-өчәр тапкыр очрашып, тыелган китаплар бирә башлады.

Нуриман Ибраһимов, этн кеше, боларның берсен дә белми, улының әйбәт юлда йөрүенә шөкерана кылып, бик зур тәгаллек белән, биш вакыт намазын укып бара иде.

1915 елның урталарында Мәскәүдә, бигрәк тә Ибраһимовлар гаиләсе яшәгән Благуша-Лефорт районында буталыш-болганышлар бик ки-

нәт күбәеп китте. Баш күтәрүләр, эш ташлаулар гадәти бер нәрсәгә әйләнде. Полицейскийлар, атларын ак күбеккә батырып, районның бер башыннан бер башына чаптылар.

Ачы сызгы тавышыннан, полиция атларыннан коты чыгып кайткан Нуриман абзый Шәймәрдәнне бер көнне бик каты кисәтеп куйды:

— Бакци, малай, син нишләп апаздайт итеп катәсың? Ата булып атәм мин сиңа, ишетсен кылагың, ярамаган эшкә катышып, үгә бәлә китерсәң, рәхим-шәфкать көтмә. Выт, шул, матри, малай...

Шәймәрдән этисен тыныч кына тыңлап торды, ак дип тә, күк дип тә әйтмәде, үз юлына китеп барды.

Сентябрь урталарында трамвай йөртүчеләр эш ташлады. Бер атнага сузылган чуалышны көч-хәл белән туктатып, башлыкларын берәмберәм чүпләргә керештеләр. Андрей Меркуловны армиягә озаттылар. Павел Щербаковны төрмәгә яптылар.

«Аллага шөкер, минем улымның катнашы юк икән, җил-давыл безнең үгә кагылмый узды», — дип сөенде Нуриман абзый.

Шул көнне өметле яшь революционер Ибраһимовны карт большевиклар җәмгыяте члены Александр Селивановка тапшырдылар. Мәскәүдәге хәлләр уналты яшьлек егет өчен баш әйләнгеч тизлек белән китте. Сентябрь кузгалышында гади эшчеләрне төрмәгә ябып тормадылар (төрмәләр инде болай да дыңгычлап тутырылган иде!). Өч йөз житмеш бер кешене, солдат шинеле һәм папаха киертеп, аркаларына мылтык астырып, сафка тезделәр. Җиз торбалар дәртле бер марш уйнады, патша хәзрәтләренә исәнлек-саулык теләгән дога җыры мәйдан өстендә яңгырап торды, аннары алтын погонлы офицерлар бу кешеләрнең туп-туры фронтка озатылачакларын әйтеп, нотык сөйләделәр. Моны халыкка күрсәтеп, махсус митинг җыеп, тантаналы итеп үткәрделәр. Фронтка китәсе солдатларны атлы полиция саклап торды: янәсе бу үз теләгең белән бару түгел, бу штрафнойга китү — үлем авызына туптуры барып керү. Кем дә кем киреләнә, кем дә кем котко тарата, баш күтәрә, эш ташлый, алар әнә шул язмышка дучар булачак.

Шуннан соң бер атна урамнар тын торды. Полиция участокларында, жандармерия кабинетларында эшебезне җиренә җиткереп эшләдек дип лаф ордылар, фәрманнар яздылар, мактанышып шәраб эчтеләр. Ләкин аларның шапырынулы хыялларын чәлпәрәмә китереп, «Динамо», «Гном и Рон» заводларында стачка башланды. Эшчеләр аерым оешмаларга, җәмгыятьләргә тупланырга телиләр, көн саен йөзләгән эшче профессиональ союзларга алуны сорап, конторларга килә иде.

Шәймәрдән Ибраһимов металлистларның «Бердәмлек» союзына член булып керде. Башка гамәлләрен әйтмәгән кебек, монысын да әтисенә әйтмәде: идарә утырышларына, делегатлар җыелышына, полицияне алдау өчен үткәрелә торган концертларга катнашты. Эшче иптәшләре аның артистлык сәләтен күреп алдылар. Аның бу сәләтенә гашыйк булган Сергей Плаксин — Пелка заводы мастеры — аны бер дә бер көнне үз өенә чакырды, штофлы шешәдән салып, аракы белән, кайнар щи белән сыйлады, тормышын сорашып, җирән бөдрә сакалы эченнән ипле генә, мөлаем гына елмаеп утырды. Алар тагын ике мәртәбә идарә утырышында очраштылар. Урамнан бергә кайттылар. Соң иде, аулак иде. Плаксин Шәймәрдәнгә большевиклыгын рәсми рәвештә билгеләргә тәкъдим итте, артык бер генә сүз дә әйтмәде, үсмер егетнең кулын каты итеп кысып үз юлына китте.

Һәм менә — Сембер губернасының ат маклеры улы, әтисе аны кайчандыр мулла итәргә хыялланган Шәймәрдән Нуриман улы Ибраһимов, уналты яшьлек егет — Пелка заводы каршында оешкан большевистик түгәрәкнең члены булып язылды.

Узар еллар, үзгәрер дөньялар, кешеләр шул чагында Шәймәрдән Ибраһимовның уналты яшеннән большевик булуын горурланып, ачыктан-ачык әйтерләр, ә бүгенгә әле ул бик күпләргә әйтелми торган, шаулап сөйләнми торган бер сер булып кала иде.

Шәймәрдән өлкән дусы, инде хәзер партиядәш иптәше большевик Плаксинга Благуша-Лефорт төбәге металлистларын профсоюзга туплауда булыша башлады. Туплану алгы көннәр өчен, киләчәк көрәшләр өчен кирәк иде. Өч-дүрт ай эчендә алар икәүләп Устав проектын төзеделәр, профсоюзларның Мәскәү Үзәк идарәсендә шул Уставны раслатып, градоначальниктан оешманың оештырылуына рәсми рәвештә рөхсәт кәгазе дә алгач, 1915 елның азакларында учредительләр җыелышын җыйнадылар.

Плаксин идарәнең председателе, Ибраһимов секретаре итеп сайланды. Профсоюзларның Благуша-Лефорт бүлеге ярты ел эчендә районнагы эшчеләрне бер йодрыкка туплап, иң алдынгы, иң аңлы эшчеләрне большевиклар партиясенә тартырга тиеш иде.

Боларын инде Ибраһимов әтисенә генә түгел, бергә эшләгән кайбер иптәшләренә дә әйтә алмый, моны Плаксин белән үзе генә белергә тиеш иде ул.

Әтисенә тора-бара шик төште. «Нишләп әле ул гелән-гелән эштән апаздайт итеп катә, минем белән сүләшергә келәми?» дип уйлады. Уйлап кына калмады, улыннан өзеп кенә сорады:

— Кайда ерисең син, малай актыгы?

— Бонакерлар җәмгыятендә тәртипсезлек күбәйде. Үзең дә күреп торасың бит, әти, эшчеләрне үгетләргә, тәртипкә чакырырга туры килә. Бонакерлар миңа ышаналар, — дип җавап бирде Шәймәрдән.

Үгетләү дигәне дөрес, ләкин нәрсәгә үгетләү — анысы башка мәсьәлә. Плаксин белән Ибраһимов эшчеләр үз хокукларын даулаудан туктамасыннар өчен, әледән-әле идарәнең җыелышын җыеп, атмосфераны кыздырып торалар, сөйләшергә җайлы булсынга концертлар, спектакльләр, төрле-төрле тамаша әзерлиләр, ике ай эчендә эшчеләрдән оешкан драматик труппа үз вазифасын менә диган итеп үти иде.

Идарәнең кыюлануы шул кадәргә барып житте, ул Благуша китапханәсен үз карамагына алды, Николо-Покровский, Преображенский потребительләр җәмгыятенең эшенә катнаша башлады һәм 1916 елның башында Пелка профсоюзы эшчеләрен ике мәртәбә стачкага күтәрә алды. Бу инде җиңү иде. Чөнки стачка экономик таләпләр генә куеп калмады, сәяси демонстрациягә әйләнеп китте.

Благуша охранкасы Сергей Плаксинның эшчеләр сыйныфын киләчәк көрәшләргә әзерләве белән риза булып торырга теләмәде — аның артыннан шымчылар куйды. Көннәрдән бер көнне, уналтынчы елның гыйнварында аны төрмәгә илтеп тыкты, әмма яңа бер чуалыш башланудан куркып, суд ясарга ашыкмады: Плаксинны Благуша заводларындагы һәрбер эшче белә, аның өчен утка-суга керергә әзер торучылар күп иде.

Плаксин төрмәгә эләккәннән соң, Үзәк идарә Ибраһимовны Пелка профсоюзына җитәкче итеп куйды, шушы төбәкнең завод-фабрикаларында күпләп эшләгән татарлар арасында аңлату эшләре алып барырга киңәш бирде. Аның белән генә дә бетмәде. Плаксин кулга алынып, Селиванов Петроградка партия эшенә күчерелгәч, Лефорт төбәге бөтенләй ялангач калды. Шуңа күрә Мәскәү комитеты Благуша-Лефорт төбәгендә партия эше белән җитәкчелекне дә Ибраһимовка тапшырды. Моңарчы ул район исеменнән өндәмәләр чыгару, прокламацияләр тарату, эшчеләрне профсоюзга туплау эшләрен тәҗрибәле өлкән иптәшләре ярдәмендә алып барган булса, хәзер ул боларның барысын үзе белеп, мөстәкыйль рәвештә башкарырга тиеш булып чыкты.

1916 елның июнендә аңа Измаил паркында массовка оештыру, массовкага башка районнардан да эшчеләрне катнаштыру, шул рәвешле күмәк чыгышларның оеткысын Мәскәү буйлап тарату бурычы йөкләтелде.

Шәймәрдән, Бонакерлар җәмгыятендә үзе белән бергә эшләгән иң ышанычлы егетләрне сайлап, массовканы әзерли башлады. Полиция күзенә ташланмасын өчен, массовканы 15 июньгә, Мәскәү мишәрләре ел саен Измаил паркында сабан туе үткәрә торган көнгә билгеләделәр.

Нуриман абзый эче пошып Измаил паркында йөргән чагында, аның улы Шәймәрдән Ибраһимов, иртәгә буласы массовканы кайгыртып, паркка килгән иде, ул әзерләгән «сәүдәгәр» мишәрләр иртәгә буласы массовканың генеральный репетициясен үткәрәләр иде.

Нуриман абзый улының контордан чыкканын көтеп-көтеп тә көтеп бетерә алмагач, өенә кайтып китте. Хатыны Хафиза җиңги авырыбрак тора икән: июнь челләсендә мамык юрган ябынып караватта ята, өчкелләп ак яулык бөркәнгән башы гына агарып күренә иде. Нуриман абзый карават янына килеп иелде дә хатынының маңгаена кулын куйды.

— Ни булды сиңа, кортка? Башың кайнар, жарың бар бугай,— диде ул борчылып.

— Белмим. Эцем пыша. Шәймәрдәннең күзгә күренгәне юк. Кицке ашны ашарга да катьмады. Син дә цыгып киттең дә югалдың...

— Югалмадым мин, матавык белән ердем ие.

Шәймәрдән өчен борчылуын ул хатынына белгертергә теләми иде, шуңа күрә сүзне тагын авыруга борды:

— Дуктыр цакыртырга кирәк төгел микән сиңа, кортка? Яман цир булып безгә дә йоктырып куйма тагын...

— Урамга цыгып ергәнем юк ла минем. Яман цир дип тифне атәсеңдер. Аны бит сугыш ереннән апкайталар дир. Безнең сугышка барган кешебез дә юктыр да...

— Ярар, әбижәйт ителми генә ят шылай. Хәзер цәй ясап китерермен. Бал белән эцсәң узар шай.

Нуриман карт кешелеккә кия торган кәзәкиен, ак күлмәген, укалы яшел түбәтәен чиста ак яулык белән төреп, сандыкка салды, көн саен кия торган эш киемнәрен: зәңгәргә манган бәс күлмәген, төсе уңган кара чалбарын киде, башына каешланып беткән түбәтәен чәпәде, читеген кәвешкә алмаштырып, йорт эшенә тотынды. Самавыр торбасына чыра телеп яндырып салуга озак та үтмәде, Хафиза җиңги хафалана башлады:

— Ай аллам, нәрсәне яндырдың инде тагын? Самаварыңны сусыз куйдың шае, мәтәм...

Нуриман абзый әтәләнеп-кабаланып самавыр капкачын ачты, зәңгәрләнә башлаган самавырга су коеп җибәрде һәм чажылдап битенә бәргән пардан артка чигенде; самавырның борыны эреп төшкәнгә бик хәтәр кәефе китеп, урамнан кайтып кергән бәләкәйләренә чәйсез генә, май ягып ипи ашатты. Чәйнектә көндездән калган салкын чәйне эчертеп, йокларга яткызды. Өстәлдәге унлы лампаны кысыбрак куеп, улы Шәймәрдәннең кайтканын көтә башлады.

Шәймәрдән бик озак кайтмады. Ниһаять, төнге сәгать унберләрдә каты гына ишек кактылар.

Йокымсырап барган Хафиза җиңги куркып уянды, урыныннан башын күтәреп:

— Ни булды? Кем бар? — диде, шабыр тиргә баткан, бурлаттай кызарган битен яулыгы белән сөртергә тотынды.

— Берни дә булганы юк. Шыпырт кына ят, Шәймәрдән катте.

Ишекне тагын да катырак дөбердәтә башладылар. Нуриман абзый тәрәзә пәрдәсен ачып, аска, ишегалдына карады, чолан төбенә бер төркем кеше җыелганын күреп, эче җу итеп китте, тиз генә кәзәкиен киде, җилкәсенә иске бишмәт салып, ишек ачарга чыкты.

Хафиза җиңги, ниндидер яман хәл барын сизенеп, урын өстеннән төшмәкче иде, хәле булмады, башы әйләнеп китеп, киредән ятты.

Өй ишеген каерып ачып, шпорлы итекләре белән каты-каты басып, ике жандарм офицеры, кулына фонарь тоткан полиция чиновнигы, мылтыклы ике солдат, гадәти киемдәге пүнәтәйләр килеп керде.

Мыеклары зәһәр тырпайган, күзләре тасырайган, яннарына кәкре кылыч аскан погонлы кешеләрне күрүгә Хафиза җиңгинең йөзе көл кебек агарды, куркып кычкырып җибәрмәс өчен, авызын кулы белән каплады. Нуриман абзый туп-туры хатыны караваты янына килә башлаган жандарм офицерының юлын бүлеп:

— Авыру, нилҗә! Шәригать ни вилит. Бонакер әфәндегә жалу итәм, — дип, авыру янына керү юлын гәүдәсе белән каплап куйды.

Жандармерия офицеры аны җиңелчә генә читкә какты:

— А ну в сторону, князь!

Хафиза җиңги, мыеклары тырпайган погонлы кешенең үзенә таба килгәнен күреп, чырыйлап кычкырып җибәрде.

Пүнәтәйләрнең берсе арага кереп, жандармга шәригать канунналарын аңлатты, тегесе кул селтәп, икенче бүлмәгә борылды. Нуриман карт офицерга аңлаткан кешенең бүген үзе очрашырга тиешле ат макләры Тазюк икәнен танып, өнсез калды. Ул бит аңар кичтән генә өен күрсәткән һәм алар икәүләп чәй эчеп утырганнар иде. Имансыз ук мишәр икән, бер дә бүтән түгел, йортны «җантимерләргә» шул Тазюк күрсәткән. Үз мишәрен сатып йөрмәсә, сатар кеше беткән микәнни аңар? Ат сатучы түгел, адәм башын сатучы булып чыкты инде бу болай булгач...

Нуриман абзый, зур бер бәлагә тарыганын аңлап, тешен кысты.

Төнге кунаклар ярты сәгать эчендә өйнең астын-өскә китерделәр. Өстәлләр ауды, урын-җирдән мендәрләр очты, аларның сүрүе ертылып, өй эче мамык белән тулды. Нуриман абзый белән Хафиза җиңгинең Сембердән башлап җыйган мал-мөлкәте идәнгә чүп итеп өелде. Камзулларга, кәттәшигә, кәзәкигә, бала итәкле, шлафырлы күлмәкләргә бер дә хөрмәт булмады, барысы да очты, барысы аяк астына салып тапталды.

Йокыларыннан вакытсыз уянган балалар, куркышып, сарык бәтиләре кебек, бер почмакка өелделәр, төрле тавышка еларга тотындылар.

Бу хәл тентүгә килүчеләрнең җен ачуларын чыгарды. Баш турысына фонарь күтәргән полицейский белән бергә, жандармерия офицеры Хафиза җиңги яткан караватка ягына юнәлде. Ләкин шул мәлне ат макләры Тазюк тагын жандармның юлын бүлде:

— Ваше высокородие, сак булыгыз: татарлар динне мыскыл иткән өчен кан үче алалар. Сабыр итик, башка җирдән эзләп карыйк, — диде. Ул моны русчалатып әйтте.

Нуриман абзый хәл җыярга өлгергән иде инде. Ул килүчеләрне өен рөхсәтсез туздыруда, авыру хатынын, балаларын куркытуда гаепләп, Бонакер әфәндегә, губернаторга жалу язу белән яный башлады.

Жандарм офицеры Нуриман абзыйның каршысында ук мыегын тырпайтып тора иде, караватка кырыеннан бер адымга чигенеп, полицейский янына басты. Эчкәреге бүлмәне тузгытып ташлаган күзлекле офицер, мылтыклы солдат белән бергә чыгып:

— Берни дә табылмады, ротмистр әфәнде. Ни эшләргә боерасыз? — диде.

Котырып ачуы чыккан ротмистр:

— Матрацларны сүтәргә, сандык-чемоданнарны яңабаштан актарырга! — дип боерды, үзе ул арада фонарьлы полицейскийны чакырып, яктыртып торырга кушты.

— Документ! — диде жандармерия офицеры, Нуриман абзыйга төбәлеп.

Нуриман абзый эшкә кия торган иске пинжәген әйберләр өеменнән көч-хәл белән актарып алды. Пинжәкнең эчке кесәсе төймәләп куелган иде, төймәне ычкындыра алмыйча аптырап бетте, ниһаять, ычкындырды, паспорт салынган иске бумажникны жандарм офицеры кулына бирде.

— Яктырт! Нәрсә катып торасың? — дип кычкырды ротмистр полицейскийга. Тегесе фонарьны якын ук китерде.

Ротмистр документларны актара-актара:

— Улыгыз кем? — диде.

— Шәймәрдән, — диде Нуриман абзый.

— Кайда ул хәзер?

— Алла белсен, кайда йөри торгандыр, — диде Нуриман абзый, шушы шомлы минутларда улына рәнҗеп.

Ротмистр документларны карап бетерде, хуҗасына кире кайтарып:

— Беләсезме, князь, улыгыз Шәймәрдән Ибраһимовның кайда икәнен әйтмәсәгез, яки крамольный китапларын безнең кулга тапшырмасагыз, сезне төрмәгә утыртырга туры килер, — диде. Үзе янында басып торган эшләпәле Тазюкка дорфа гына дәште.

— Аңлат князьгә.

Тазюк, Нуриман абзыйның йөзенә туры карамаска тырышып:

— Малаеңның кайда икәнен сорый. Яшергән китаплары юкмы, ди. Яхшы чакта әйтеп кал, эшнә...

— Дуңгыз синең эшнән, сатлык җан! — диде Нуриман карт, батыраеп, аннары ротмистрга таба борылып, татарчалап тезеп китте:

— Минем улымның ярамаган эш белән шөгыльләнгәне юк. Минем улым алланы бар дип һәм бер дип белә, патша хәзрәтләренә турылыклы ул, нахакка рәнҗеткән өчен аллаһы тәгалә сезне ярлыкамас.

Ротмистр Нуриман абзыйга: «Молчать!» дип кычкырырга авыз ачкан иде, эчке бүлмәдән:

— Ваше благородие, таптык! — дип кычкырдылар.

Эчке бүлмәдән зур гына чемодан күтәреп чыктылар. Чемодан ике төпле икән. Ротмистр чемоданның икенче төбеннән фамилияләр язылмаган паспорт бланклары, прокламация итеп бастырачак язуларның төп текстын тартып чыгарды да, Нуриман абзыйның борын төбендә селтәп, яшелле-күкле тавыш белән:

— Ә бу нәрсә, карт боргыч?! Бу синә атаң башымыни?! — дип кычкырды. — Оһо! — диде ул икенче мизгелдә. — Башкаланың страховой присутствиесына большевистик наказ проекты. Канальялар! Алдакчылар!! — Ротмистр, кизәнеп торып, Нуриман абзыйның яңагына сукты, карт чайкалып китте, битен тотып ыңгырашып куйды.

Ротмистр яшь офицерга:

— Ибраһимовның почеркын күрсәт! — дип боерды.

Тегесе планшетыннан ашыгып кына бер кәгазь бите алып бирде. Ротмистр әлеге кәгазь белән проектны чагыштырып карады.

— Точно. Ике тамчы су кебек! — дип, сөенечен баса алмыйча, кычкырып куйды. — Ә син, мерзавец, алла белән ант итәсең. Улымны патша хәзрәтләренә турылыклы итеп үстердем дисең! Дурак! Негодяй!

Чемодан төбеннән 1916 елгы революцион җырларны актарып алганда, ишектән Шәймәрдән кайтып керде. Өй тулган халыкны күреп, ашыгып чигенә башлады, полицейский, кулына тотып йөргән наганын аңа төбәп:

— Кузгаласы булма! Кулыңны күтәр! — дип акырды. Солдат белән яшь офицер, Шәймәрдәнгә ташланып, кулын артка каерып бәйләделәр. Пинжәк кесәсеннән револьвер табып алдылар.

Хәвеф-хәтәр калмаганга ышанган ротмистр Шәймәрдән янына килде.

— Фамилия? — Аксыл фуражка астыннан бүре кебек карап торган уналты яшьлек үсмернең ныклыгына аптырый төшеп: — Фамилия? — дип кабатлады.

Шәймәрдән фамилиясен әйтте, тирләп киткән зур маңгаен җыерып:

— Алып китегез мине тизрәк! — диде, әтисенең рәнҗүле авыр карашын күтәреп торасы килмәде.

Нуриман абзый улы янына килде.

— Шәймәрдән... Улым... Бу нәрсә инде бу? Син нигә безне шылай...

Полицейский белән яшь офицер аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәделәр, читкә алып аттылар. Әти кеше урыныннан кузгалып канаган борынын сөртергә дә өлгермәде, аның улын, мылтык түтәсе белән төрткәли-төрткәли, ишектән алып чыгып киттеләр.

Ат маклеры Тазюк, чыга башлаган җиреннән борылып килеп:

— Кара аны, мөэмин-мөселман, минем монда килгәнне Измаил паркында сүләп ерсаң, сине дә улың артыннан Себергә озаттырырмын, цукындырып ябып куярлар, телеңне тешлә дә май кап,—дип ыжылдады.

Шапылдап ишек ябылды.

Нуриман абзый тузгытып ташланган өе, чирле хатыны, куркышып бер почмакка өелгән балалары белән торып калды...

*Дәвамы бар*

## Зөлфәт

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Елтыр гына елтыр

«Елтыр гына елтыр утлар яна,
Юлаучыдан калган бер күмер...»

*Башкорт җырыннан.*

И җыр гынам, җырым! Сөйгән җырлар!
Бирсен язмыш сезгә мең гомер...
Җыр бар — димәк, җан бар! Һәр моңлы җыр —
Юлаучыдан калган бер күмер,
Елтыр-елтыр янган бер гомер...

Гашыйкларның кайнар сулышлары
Шул күмергә килеп кагылса,
Таң җилләрен капыл уятырдай
Сагыш яки бәхет табылса,

Иле өчен яуга чыккан ирнең
Акбүз аты чапса далада,
Ил атасы соң догасын кылса,
Исем кушылса яшь балага,—

И җыр гынам, җырым! Сөйгән җырым!—
Елтыр-елтыр янган бер күмер!—
Уянасың, дөрләп кабынасың...
Бирсен язмыш сиңа мең гомер!

И җыр гынам, җырым! Кыргый атны
Йөгәнләгән батыр шикелле
Бик ерактан алып килдең безне,
Киләчәккә кадәр илт инде...

1976

## Табыну

Ялгыз ат кешни кырлар түрендә...
Юксыну микән, сагыну микән?—
Сәер бер кошның канат җилләре
Бөтен дөньяма кагылып үткән.
Яфрак явымы туган җиремдә,
Ялгыз ат кешни кырлар түрендә.

Кошлар кунмаган тирәк бар микән?
Кулларым белән орындым таңга,
Карашларыма үрләде ялкын,
Кабындым дөрләп — ут капты канга!
Чагылып күлдә торналар үткән...
Кошлар кунмаган күлләр бар микән?

Кырларны иңли кылганнар җиле...
Дүрт ягым кыйбла! Табынам — моңга!
Моңсу бер илгә чакырган кебек
Ялгыз ат кешни туган ягымда.
Шул атны эзләп табасы иде...
Кырларны иңли кылганнар җиле!

Ялгыз ат өне — бөек моң бугай,
Синең рухыңа багышлыйм җанны!
Моңым син — Илем, Илем син — моңым,
Кабул кыл берүк минем догамны.
Күзгә томанга төренгән тугай,
Ялгыз ат өне — бөек моң бугай...

Илемнең моңы! Табынам сиңа!
Якты тойгымны кабул кыл, вакыт.
Илкәем моңы — иң олы кайгы,
Илкәем моңы — иң олы шатлык.
Килер дәверне сагынган сыман,
Илкәем моңы, табынам сиңа...

1975

## Янабыз!

— Янабыз! Янабыз! Янабыз! Янабыз!
...Ялмады ут сусыл болыннарны.
Тонык чишмә парга очты чажлап —
Урманнарны айкый газаплы ут,
Биек күккә ургый утлы газап.

Үлем ялмый яшел каусәләрне,
Ятып ауный гөлләр арасына:
Җир астыннан — коры саздан гүя
Гүләп килеп чыкты Хиросима.

Сылу кәрван иде кырмыскалар —
Күрмәделәр алар гарасатны.

Купты дулап кайнар көл бураны:
Һәрбер күзәнәктә — Нагасаки.

Күпме чорлар буе җиде төннең
Кыл уртасын көткән абагалар
Төш күрәләр иде... Төшләрендә
Балкып чәчәк аткан иде алар!

Чатнап күккә очты якты төшләр...
Кызыл тиен — чынлап утлы йомгак.
Төптән, астан тамырланып, янып
Үсә, чәчәк ата кайнар колмак!

Заманадай куе шаулы урман...
Өстә — ялкын, ут үрмәли астан.
Сайрап торган килеш яна былбыл —
Утлы алма — кыргый алмагачта.

Киек яна тозактагы килеш...
Тозак салган аучы, кайда хәйләң?
Кузлар чөеп «бишташ» уйный афәт
Һәм фаҗига уйный «әйлән-бәйлән».

Кем ут салды сиңа,
Заманадай
Шаулап торган биек, көчле урман?
...Күктән янып төшкән самолет күк
Янып төшеп калды
җавап
чордан...

1975

## Казан шәһәренең 39 нчы кварталы янындагы сазлыкның төнге бәхилләшүе

И Бөек төн! Син — мәңгелек сердәш!
Серне көнгә сөйләү — язык ләкин, язык...
Газабымны сиңа сөйлим, Төнем.
Тыңла мине, аңла.
Бу мин — Сазлык.

Ишетәсеңме: дәшәм талларыма,
Түмгәктәге тәкәрлеккә дәшәм,
Уйдык күлләремә, камышларга
Эндәшәм мин,
Дәшәм — бәхилләшәм.

Ташпулатлар җитми кешеләргә,
Тыгыз туфрак җитми,
Җитми азык —
Мин китәргә, мин кибәргә тиеш,
Юл бирергә тиеш —
Бу мин — Сазлык:
— Бәхил булыгыз!

Бәхил булыгыз сез — мең тавышлы,
Мең очышлы шаулы саз кошлары!

Мин яраттым сезне бу дөньяга —
Кемнәр язар сезнең язмышларны?—
Бәхил булыгыз!
Нинди җилләр сезне кайсы җирнең
Кайсы якларына таратырлар?
Кайда булыр сезнең җылы оя —
Автострадада, чүлдә, кратерда?
Бәхил булыгыз!

Ишетерсезме зирек кәүсәләрен
Юа-юа яңгыр сибәләвен,
Юаларым! Нинди гөлгә кунып
Тибрәнерсең син, саз күбәләге?—
Бәхил булыгыз!

Болыт булырга дип хыялланып
Таңда уянучы ак томаным!—
Бәхил! Бәхил! Тирәндәге суым,
Кара суым минем — тере каным!

И Бөек Төн! Йөрәгемә кадәр
Экскаваторлар керә казып.
Мин юл бирәм комга. Китәм. Кибәм.
Бәхил бул, Төн. Я, хуш.
Бу мин — Сазлык...

...Тыңлады Төн. Биектәге йолдыз
Тетрәп-тетрәп серле төнгә дәшә:
— Әйтче, Төнем, әйтче: нәрсә булды?
Нәрсә булды? Ник җир бәхилләшә?!.

1976

## Кайчан сәфәр?

*Әмирхан ага Еникигә*

Кеше диган чаткы кабынганда,
Балкып киткән чакта серле эңгер,
Иштеләдер сорау: «Кайчан сәфәр?
Көтеп тора сине озын гомер!»

Җиргә түгел, күккә карар вакыт...
Тәпи басу ләкин биграк хәтәр!
Әмма дөнья һаман ашыктыра:
— Кайчан сәфәр, улым? Кайчан сәфәр?

Туган йортның капкасыннан чыгып
Күз йөгертсәң офыкларга кадәр,
Кабаланып дәшә офыгарты,
Балкып-балкып дәшә:— Кайчан сәфәр?

Дәшә шулай хикмәт, билгесезлек,
Түгелгән кан һәм коелган яшьләр,
Яшәвеңнең бар мәгънәсе дәшәр,
Биниһая ерак киңлекләрдән,
Үрелеп буй җитмәс биекләрдән:
— Кайчан сәфәр?

Соң сәфәргә кеше җыенганда
Әдәп саклый дөнья — бер сүз дәшми.
«Балкыдык та сүндек... Язмышлар бер...» —
Дигән сыман күктә яшен яшьни.

«Китәм...» димәс Кеше.
— Киләчәккә
Китәсең...— дип дөньялыкка дәшәр,—
Я, хуш, дөнья... Юлчы юлда булсын...
Имин булсын юлың!.. Кайчан сәфәр?

Бар җылымны сиңа калдырам мин,
Бүтән байлыгым юк, гаеп итмә...

...«Балкыдык та сүндек... Язмышлар бер...»
Дигән сыман йолдыз очар күктә.

1976

## Курку

Ничәнче төн бер үк төш күрәм мин,
Мин — исемсез нәни кош икән...
Кемдер мылтык төзи астан миңа —
Тын алганын хәтта ишетәм.

Йолдыз серен аңламакчы идем,
Серен төшенмәкче болытның —
Кемдер мылтык төзи астан миңа! —
Сайравымны хәтта оныттым.

Кемдер мылтык төзи, мылтык төзи!
Очам кичке нурда ялтырап.
Күтәр мине, канат, биеккәрәк!
Янчы, кичке кояш, яктырак!..

Күкнең кеме соң сез, сак йолдызлар?
Чиксез ерак ялтыр ташлармы?
Әллә инде афәтләрдән куркып
Артык биек менгән кошлармы?

...Ничәнче төн күрәм бу төшне мин,
Шомландыра ул төш, тетрәтә.
Мин уянам. Шомлы курку белән
Хош сулкылдый эчтә — күкрәктә.

Ничәнче төн шомлы төш күрәм мин
Һәм куркудан каба сулуым:
Кош булуың хәтта шомлы чакта
Җинаятьтер — кеше булуың...

1976

## Туган тел хакында

Тел ачылгач әйтә алсаң: «Әни!»— дип,
Тел ачылгач әйтә алсаң: «Әти!»— дип —
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.

Соң минутта әйтә алсаң: «Әни!»— дип,
Соң минутта әйтә алсаң: «Әти!»— дип —
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр...

1976

## Моң

Ерак тарих сыман серле яклар!
Моңның туган иле, синме бу?
Нинди төшләр күреп йоклый гөлләр...
Җирдә төнге гөлләр тынлыгы...

Мин оныткан идем бу якларны,
Кошлар өнен, каен чукларын,
Учакларның кызыл канат җилпеп
Таңга кадәр янган утларын.

Шул учакка бүген кагылдым мин,
Тузгып-тузгып очкын сирпелде.
Калыкты моң — мең кат яндырылып
Исән калган дастан шикелле.

Сәлам сиңа, сәлам, серле төбәк!
Мин адашып йөрдем гел читтә:
Кабул ит син, кичекмәгән булсам,
Кабул ит син — хәтта кичексәм.

Без алдыйбыз сине, Моңстаным,
Алдаган күк тугры ярларны,
Аерабыз гүя яздан — назны,
Ак кышлардан — ап-ак карларны.

Алданабыз алдап, Моңстаным,
Сүнмәс җаның синең — матурлык!
Матурлыкны исән саклау өчен
Җиткән, имеш, бары батырлык...

Алданабыз алдап, адашабыз.
Йөртә дөнья, талкый, эндәшә.
И матурлык! Дөнья ваклыклары
Әверелә синең көндәшкә.

...Юлыгабыз сиңа кө тмәгәндә —
Изге моңның туган җиренә,
Юлыккан күк иң дәһшәтле сергә —
Мәңгелекнең бөек серенә.

Онытабыз кайчак сине, и моң —
Канда дулап купкан диңгезне...
Кабул ит син безне — соңармасак,
Соңарсак та кабул ит безне!

1975

## Бәгырь янында

*С. Есенин туфрагына орынгач*

Яратасызмы аны чын күңелдән?
Яратасыз икән
Кайсысын —
Шатлыкларын кайгы иткәненме,
Шатлык иткәненме кайгысын?

...Фаҗигале бәхет көз төсендә.
Кабер түгел бәгырь өстендә,
Кабер түгел, бәгырь өсләрендә
Шигъри сүзгә көзге төс керә.

Җилфердиләр җырлар көзге җилдә.
Алтын сүзләр оча кыйгачлап.
Көмеш аваз куна җаннан-җанга —
Ял итәргә эзли кунача.

Кабер түгел, бәгырь гөлгә мохтаҗ —
Чәчәк куйыйк бәгъре өстенә.
Сизәсеңме, безнең карашларга
Сиздермәстән көзге төс керә...

Син кайда соң аның яфракташы,
Чәчәктәше, нурдаш, кардашы?
...«Вермут»олог мескен яшен түгеп
Зар елады: «Безнең кардәш ул...»

Кичерегез аның яздашлары!
Хакыгыз бар сезнең еларга.
...Кара кеше йөри елашырга!
Калкып чыгып кара еллардан.

Кара кеше күләгәсен еллар
Бүгенгегә кадәр китерде.
Гүли алар һаман: «Яраттым!!!» дип,
Кайтавазы кайта: «Ү-т-е-р-д-е-м...»

Фаҗигагә гашыйкмыни шагыйрь!—
Ә фаҗига аңа гашыйк шул.
Кара тросć оча һава ярып
«...Прямо в морду... переносицу!»

Кара кеше йөри, кара кеше!
Кулларында — кара пәрдәсе.
Уйлый шыпырт: «Минем корбан, корбан...»
Һәм кычкыра:— Минем кардәшем!

...Каен төсе булып карый шагыйрь:
«Куыгызчы шуны» дигән күк.
Шагыйрьме ул, җилме? Тетрәп яуган
Яфракларның җаны гүяки...

1975

## Кәк-күк!

Үткәннәрдәнме бу: «Кәк-күк! Кәк-күк!»
Бүгенгедәнме бу: «Кәк-күк! Кәк-күк!»
Киләчәктәнме бу: «Кәк-күк! Кәк-күк!»

...Тынып калды Идел култыгында
Акчарлаклар һәм су кызлары.
Тынып калды чыршыларның каны —
Гәрәбәдәй пакь сагызлары.
— Кәк-күк!

Тезләремә башың салган килеш,
Син дә тынып калдың. Кулыңда
Сыңар тажы калган чәчәк тынды
Һәм күкләрдән иңде моң гына:
— Кәк-күк!

Сәгать эченә үк качты вакыт.
Очып барган йолдыз туктады.
Айсберглар сыман өнсез калды
Иделнең ак пароходлары...
— Кәк-күк!

Болытлардан төшеп килгән тамчы
Ярты юлда калды эленеп.
Самолетлар — чыршы уенчыгы,
Шушы өнсезлеккә күмелеп:
— Кәк-күк!

Туктап калды кәфен кискән кайчы...
Һәм, капсюльгә тияр-тимәстән,
Туктап калды чакма. Тын урманның
Түрендәге ялгыз миләштән:
— Кәк-күк!

Приговорга куеласы имза
Баш хәрефтә калды. Үрмәләп
Нәкъ йөрәккә килеп җиткән килеш
Бөгәрләнеп тынды хыянәт.
— Кәк-күк!

Шигырь инде канат җәйгән иде
Күкрәгемнән очып китәргә.
Җил сыенып тынды канатына.
Ашыкмачы, сүзем, иртәрәк...
— Кәк-күк!

Җирне сүтеп карамакчы булып,
Формуласын таптым дигәндә,
Туктап калды фикер... Чиксезлектән —
Бик биектән, бик тә тирәннән:
— Кәк-күк!

Үткәннәрдәнме бу: «Кәк-күк! Кәк-күк!»
Бүгенгедәнме бу: «Кәк-күк! Кәк-күк!»
Киләчәктәнме бу: «Кәк-күк! Кәк-күк!»
Туктый гына күрмә,
Кәккүк! Кәккүк!

1976

------------

## Диләра Зөбәерова

# СЫЗГАН БАЛДАК

ХИКӘЯ



Гамбәрия аш-су исемнәре язылган менюга үрелгәндә, аптырап калдым: уң кулында алтын балдак... Янәшә бармагында чәүкә башы кадәр кашлы йөзеге дә бар. Үзе дә, минем нәрсә уйлаганымны абайлаган кебек, кашлысын уйнаклатып алды:

— Янтарь! Матурмы?

— Гәрәбә,— дидем мин, аны төзәтеп.

— Була алай әйтергә дә, — дип килеште.

— Мәсьәлә гәрәбә кашлысында түгел, Гамбәрия,— диде мин, мәгънәле генә елмаеп.— балдакны уң кулга кию ярәшү билгесе түгелме соң?

— Христианнар җоласы гына икән ул кияүгә чыкканчы балдакны сул кулга кию. Гарәп, поляк яшьләре аны загска чаклы уң кулда йөртәләр. Ә мин — интернациональ. Ничек телим, шулай киям.

— Җаный балдагын гына сул кулга кияләр дисең инде?

— Шулайрак. Сул кул йөрәккә якынрак,— диде ул, сөрмә яккан күз кабакларын бер җыеп, бер йомып. Аннары иреннәрен турсайтты:

— Әй, моның балдаклыгы да инде... Әллә кайчангы ла ул. Әни аны миңа ридикюль дип йөрткән иске сумкасыннан диплом яклаган көнемдә алып кигертте. Яңа бүләк аласы килмәдеме шунда...

— Бүләкнең кечесе, алтынның искесе булмый.

— Нигә булмасын,— диде ул, атсыз бармагын тырпайтып,— менә ич тузып, нечкәреп беткән.

Мин сискәнеп киттем. Бу бит, бу бит шул... Мираска калып, кулдан-кулга күчеп сызган шул балдак. Хәтеремдә онытыла барган бер сагыш яңарды.

Табын алдында төс бозарга ярамас — әлеге уйлардан котылырга теләп, алдымда томырап яткан әфлисунга үрелдем. Карап торуга матур гына күренсә дә, кабыкка гына калынайган икән. Көньякта үскән әлеге тансык җимеш белән каршымда утырган назлы сеңел арасында ниндидер уртаклык барын тойдым мин бу минутта.

Гамбәрия белән күрешмәгәнгә елдан артык вакыт үткән иде инде. Башта ул миңа узган шушы арада уңайга үзгәргәндәй тоелды. Олыгаеп киткәндәй. Сүзчәнләнгән. Өстендә балтырларын япкан озынча

күлмәк. Болай да нечкә биленда аеллы каеш та күргәч — жәлләп тә куйдым үзен. Изүенә чәйгүн капкачы чаклы брошка каптырган. Фасоннан калышмыйм дип «мөгез чыгарып» маташуы да үзенә күрә килешеп тора. Йөзендә, буй-сынында апаның яшь чактагы чалымнарын күрү кардәшлек хисен арттырды.

Апаның да чәчләре шундый коңгырт иде. Чал төшә башлагач кына хна белән юып җирәнәйтте. Ул да шулай нәзек гәүдәле иде, соңгы елларда гына юанаеп китте. Ул кыз чакта да озын күлмәк кияләр иде. Әмма кыланып, ыспайланып үсмәде безнең апа. Заманасы башка, тәрбиясе үзгә иде шул. Әйбәт кияүгә чыккач кына муллыкка, тынычлыкка иреште ул. Җизни сабыр табигатьле, максат куеп яши торган кеше булып чыкты. Институттан аспирантурага калды. Фәннәр кандидаты дәрәҗәсен алгач, ике йөкне бергә тартты: көндез эшләде, кичләрен докторлык диссертациясе язды. Хәзер ул калабызның күренекле профессоры. Апа да, яшьли эшләп үскәнгәдер, профессорша булып өйдә генә утырмый. Баш киемнәре ательесында — хисапчы. Менә бик кадерләп кенә икесенә бер кыз үстерделәр. Аның бәхетле булуын өмет итәләр. Бәхет капкасы кызлары ачачак ВУЗ ишеге дип уйланылды. Югары белем алсын өчен аңа бөтен шартлар тудырылды. Гамбәрия беркайчан да өй эшләренә бөгелмәде. Кием-салым нужасын белмәде. Гәүдәсенә ятышлы күлмәкпальто ишеләрне кырыкмаса кырык җирдән кайтарта тордылар. Ә үзенә китаптан баш күтәрмәскә куштылар. Гамбәрия исә, китапханәгә киттем дип, теләсә кайда йөрде, дәрескә хәзерләнү сылтавы белән, тетелеп беткән мәхәббәт романнары укыды. Шулай да үз көенә генә унынчыны түгәрәкләде. Аны җизни эшли торган институтка кабул иттеләр. Каникул вакытларында, «кешечә ял итсен» дип, курортларга озаттылар. Шулай итеп, тарта-суза, академик яллар алаала институтны да ерып чыкты кызый. Тәҗрибәсез белгечкә калада урнашу чамалырак булдымы, әллә, чынлап та, дөнья күрсен диебрәкме, кызларын поселок тибындагы бер район үзәгенә эшкә җибәрделәр. Мин шул якка командировкага барышлый, апаның гозерен үтәп, уч тутырып эш хакы ала торган кызына бүләкләр белән «акчалата ярдәм» алып килдем. Гамбәрия озын куныччлы итеккә бер аягын гына тыгып карады да, ярап тора бу дип, бүләкне шкаф тартмасына яшерде. Куен кесәсеннән шәмәхә бишлекләр чыккач та башы күккә тимәде, әҗәткә биргән акчасын гына алгандай, челт итеп кошелогына салып куйды. Аннан соң чәйнек-мазар кузгатып мәшәкатьләнәсе килмәдеме, әллә очрашу-күрешү сылтавы беләнме — мине ресторанга алып китте.

Сеңел чынлап та әзер табыннарга күнеккән икән шул. Чәчләрен калфак астына җыйган официантканы исеме белән генә чакырып алды. Шул арада өстәлгә, ипидән алда баш булып, муенын сузган мөһерле шешә килеп кунды. Ярый әле, бу юлга шөбһәләнүем урынсызга булган, монысын фасон өчен генә кыланган икән.

Шуңа охшашлы бер вакыйга искә төшеп, үз алдыма гына елмаеп куйдым. Мондый «фасонлы» табынны мин беренче мәртәбә аларда күргән идем бит.

Каникул вакытында әнкәй мине, пароходка утыртып, Казанга озатты. Өстә бөрчекле яңа күлмәк. Аягымда бәрән йонынннан бәйләнгән оекбаш, сары ботинкалар. Кулымда бер төенчек күчтәнәч: шешә белән бал, әнкәй үзе пешергән күкәй күмәчләре. Җизни белән апа пристаньга ук төшеп каршыладылар. И сагынганнар, и әзерләнеп көткәннәр. Өстәл башына утырттылар үземне. Табын тулы тәмтом. Шунда җизни, мыштым гына үрелеп, шкафтан уенчык стакан нар алды да шуларга нидер салып каршыбызга куйды. Борынга әч келтем конфет исе бәрелде.

— Бу ни бу? — Мин әйтәм.
— Кызыл аракы, — ди җизни.
— Абау, әллә мине Әшрәф абый дип белдегезме?

Апа белән җизни бер-берсенә карап көлемсерәштеләр. Югары очтагы чөгендер борынлы Әшрәф абыйны онытмаганнар икән әле. Әүзем шул арада күз кырыем белән генә апаны күзәтәм:

— Кабып кына кара менә, кайту белән әнкәйгә әләклим.

Эчмәде бу. Уенчык стаканга иренен генә тидерде дә әчкелтем нәрсәне читкә куйды. Җизни алай итмәде. Моңарчы гел оялып тора идем үзеннән, аракы капкач, минем алда дәрәҗәсе төште китте моның. Исерә бит, табын бозып җырлап кына җибәрмәсә ярар иде инде, дим эчемнән генә. Әле үзе мине сөендереп: — Бүген кинога да барабыз, — дигән була тагын. Кая ди ул, бараммы соң хәзер, аңа ияреп кеше көлдерергә.

Бәхеткә каршы, җизни җизни була белде. Исермәде дә, сүзендә торып кинога да алып барды.

Ул чакта миңа унбиш яшь иде. Гамбәрия бу яшьтә инде буе белән дә, кыланмышы белән дә миннән күпкә уздырган иде. Шул елны аның туган көненә җыелдык. Кайчандыр миңа уенчык стакан булып кына тоелган рюмкалар бу көнне дә өстәлдә мөлдерәп утырдылар. Гамбәрия, теге чактагы үсмер яшьтәше кебек, алдына куелган сыйдан борын чөермәде. Минем гаҗәпсенүемә каршы, апа да колагыма: «Балигъ булды инде, шәһәр кызы бит, әйдә барысын да күреп утырма», — дип кенә пышылдады.

Быел Гамбәриягә егерме алтынчы китте. Әнисе өчен ул әле һаман да олы сабый.

— Я,— диде миңа әлеге дәү сабый, исемем белән генә дәшеп,— йоклап киттеңме әллә, ник дәшмисең, Казанда ниләр бар?

— Олыларны исеме белән атаган кешене «озын тел» дия иде безнең әнкәй.

— Апалар, абыйлар алар базарда, стаканлап көнбагыш сатып утыралар, белдеңме? Онытылып бетәсе архаик сүзләр...

— Бәлки син атаңның җитмеш яшьлек агасына да исеме белән генә дәшәсеңдер. Нургаличек, хәлләр ничек, дигәнең юкмы соң?

Гамбария иренен кыйшайтып мине үртәп куйды:

— Нургаличек, имеш! Әллә нинди сүзләр чыга сезнең авыздан. Бер ачуын китергәч, әни мине тилебәрән орлыгы ашагансың дип орышты. Ярый инде, мин әйтәм, сарык үзе тиле булгач, баласына акыл каян килсен. Монысы белән килешәм. Ә причем монда зерно? Логика җитми сезгә кайчак, логика!

Мин ул төшенмәгән сүзләргә аңлатма биреп утырырга ирендем дә астыртын гына елмаеп куйдым.

— Әйдә көл, көл, — диде бу исе китми генә, — искелек белән яңалык һәрчак көрәшеп яши. Диалектика! Менә син үзең карап торуга интеллигентный кеше. Парикмахерскийга йөрисең, кино карыйсың, мода журналлары да алдырасың, ә эчең тулы искелек.

Үзен шулай сөйләндереп утырудан бер кызык табып, дәшми генә тыңлап торуымны «сүзләремне җөпли бу» дип уйлады булса кирәк, тагын да дәртләнебрәк өйрәтә башлады. Тора-бара киенү зәвыгыма да тел тиде. Күлмәгемә ваграк сәдәф такканмын, туфлямның үкчәсе нәзегрәк икән. Тырнакларыма кына салмаганмын. Кешенең күзе башта кулына төшә, имеш.

— Болай булгач, минем искелек тышыма да бәреп чыккан икән,— дидем мин уфтанган булып.— Ничек төзәлергә соң, ә?

Ул, башын артка ташлап, яңгыратып көлеп җибәрде.

— Без үсәндә кыз балага шаркылдап көлү килешми диләр иде.

— Моны миңа өйдә әйткәннәре бар. Пәрәнҗәме әле, шуны бөркәнгән надан әбиләр сүзе бу. Көләрлекләре булмаган шул аларның. Елатканнар гына ул әбиләрне, дигән идем, әни үзе, «синең белән сүз көрәштереп булмый» дип, кычкырып көлде.

— Анаң синең үзеңчә фикер йөртә башлаганыңны гына хуплаган. Татар хатыннарының пәрәнҗәдән йөрмәгәннәрен белә ул. Надан дип хәреф танымаган кешеләрне атыйлар. Ә синең әбиләрең үзләренә күрә мәгълүматлы булганнар. «Таһир белән Зөһрә»ләрне шатырдатып укый иде безнең өнкәй.

— Беләм, — диде Гамбәрия ияген кагып, — әлеге балдак яткан ридикюльдә анның хатлары да саклана иде. Стенографистлар кебек чолдин-болдин гына язган, гарәпчә итеп.

Официантка тәлинкәләр өләшкән арада сүз икенчегә борылды.

— Монда шундый инде,— диде кыз, алдына яткан чәнечкесенә ымлап, — салатына да, гуляшына да бер генә прибор куялар. Сала сала инде...

— Әти-әниләрең, анда кызыбыз үзе теләп авылда яши, дип мактанып утыралар, ә син инде аннан туйгансың да икән.

— Әй, — диде ул авызын кыйшайтып, — ни провинция түгел, ни кала түгел, әллә нәрсә шунда. Рәсемнәрдәге калфаклы кызларыгыз, аля прическа ясап, мини итәктән твист сикерәләр. Түбәтәен кыңгыр салып атка атланасы егетләрегез шлем киеп мотоциклда чаба. Артларыннан тузан кубып кала. Кошлар сайрасы багана башында репродуктор гүли. Кинематографлар өчен заповедник авыллар тоталар, ахры. Кайда икән алар, барып күрәсе иде, ә? Адресларын сорап Мосфильмга мөрәҗәгать итми булмас. Соңгы кинолары да ошамады, унынчы класстагыларның кочакланышулары турында. Анысын да языйм әле. Рецензия итеп. Мәхәббәт турында бер солидный фильм караган юк.

Аның тотрыксыз фикерләрен ишетмәмешкә тырышып, уйларым белән яңадан бала чакка кайттым. Апага ияреп кинога йөргәннәрем искә төште. Егет белән кыз үбешкәнен мин беренче мәртәбә экранда күреп шаккаттым. Кайсыдыр пырхылдаган булды, апа оялып башын аска иде. Иптәшләреннән ядкарьләр яздыра торган истәлек дәфтәре бар иде аның. Шундагы мәхәббәт җырларын миннән качып кына күңеленнән ятлап утырганнарын да хәтерлим. Кич утырырга кергән күрше апаларның аннан кызыклы китаплар укытканнары да истә. Шундагы геройларның яратышуларын тасвирлаган урыннарны кызарып, пышылдап кына укый иде ул. Менә шундый оялчан, хисчән ападан туганмы соң бу белдекле шаталак кыз?

Йокыдан соңарып торса да, түр башынарак үрмәләгән шул Гамбәрия. Дөньяны да шуннан гына күзәтә, җәяү атласы араны машинада уза. Идел буйларын тарсынып, Кара диңгез ягына юл салды. Актрисалар белән бергә кояшта кызынып, яшьлектә әти-әниләренә тәтемәгән рәхәтлек эчендә яши. Дөнья гизгәндә кызыклы юлдашларга тап булган ул. Күренекле бер шагыйрь үз имзасын куеп китабын бүләк иткән аңа. Озын чәчле художник рәсемен ясарга кызыккан аның, Алтын Йолдызлы агай перронга чемоданын күтәрешеп чыккан. Өйдәгеләрнең күз өстендә кашка әйләнгән иркә сеңелебез атаклы шәхесләрнең үзенә карата булган бу мөлаемлыкларын һаваланыбрак кабул итә, үзен шул ихтирамга бик лаеклы итеп саный, ахры. Йомшак туфракта суга туенып үскән яшелчә сабакка котыра... ди бит халык.

Официантка чәйгүн белән кофе дә күтәреп килде инде. Гамбәрия аны кечкенә чәшкәләргә агызып авызына тидерү белән кире тәлинкәсенә куйды.

Минем сораулы карашыма чыраен сытып:

— Әллә әчегән чәй инде, — диде.

Табынның яме, авызның тәме китте. Егерме алты яшьлек сабыйны сайратып утыруы башта күңелле сыман иде, тора-бара кәеф кырыла башлады. Ул шуны сизенде, ахры, игътибарымны башка нәрсәгә җәлеп итәргә тырышып, баш бармагын күрсәтте дә авызын очлайтып «во» дип куйды.

— «Во»сы нәрсә инде?

— Күлмәк. Менә дигән күлмәк тектердем, әйтми дә торам тагын. Яңа елда телевизордан «Зәңгәр огонек»ны карадыңмы?

Фасонын шул кичәне алып барган диктордан күчереп алдык. Аныкы төсле пряжкалы туфлям да булды. Киенеп көзге каршына бассам, экраннан үземне карап торгандай булдым. Зерә дә килешә!

— Ал-а-ай,— дидем мин башымны чайкап,— өс башың, буйсының белән экран йолдызларына охшагансыңдыр да бит, йөрәгең белән тиңме соң син аларга?

— Минем йөрәк нормаль — минутка алтмыш удар. Аларныкын санаганым юк.

— Бөтен хикмәт тә шунда шул. Кешеләр йөрәгенең тибешен аңлаудан мәхрүмнәр — тере мәрхүмнәр, дигән бер зирәк.

Кыз, мәхрүм, мәрхүм сүзләренең мәгънәсенә төшенергә теләгәндәй, бераз уйланып торды да яңадан ачылып китте:

— Кешеләрне берсеннән-берсен аерып бәяләү искелек калдыгы, ди әти. Бу — профессор сүзе. Үзе нинди зур кеше, ә аның янында әни кем инде безнең? Ничек кенә яхшы яшиләр әле!

— Сиңа әниең дәрәҗәсенә җитәргә ерак әле, бик ерак, сеңелем. Әйбәт хатын булу үзе бер сәләт. Тик менә әни буларак ул йомшаграк.

Күңелдә баядан бирле ургып торган бу сорауга җавап эзләгәндәй, мин тагын баягы сызган балдакка карап алдым. Гамбәрия, куера барган үзара мөнәсәбәтебезне җиңеләйтәсе килеп, ахры, матур гына итеп елмайды да үзе дә алтынлы бармагына күз салды:

— Исең китте инде шуңа, бик ошый икән — җәл түгел, әйдә махнем! Я, күпме тора дисең шуның бәясен?

— Бер телем арыш ипие!

— Ә?!

Кыз бармагыннан шудыра башлаган балдагын кире урынына утыртты да, хәйләң барып чыкмас дигәндәй, сул күзен кысып кычкырып көлде.

— Әйе, — дидем мин сүземне куәтләп, — кайчандыр бераү синең дәү әниең янына «Чирле балам ачка тилмереп ята, шушы алтын бәрабәренә бер телем ипи бирче» дип килгән булган.

Гамбәрия күзләрен түгәрәкләндерде:

— Һы, алайса, бушка килгән мал бу?

Өзелеп дип торган нечкә билле, назлы тавышлы туташтан ычкынган бу тупас сүз мине тетрәндереп җибәрде. Кайда утырганымны онытып, үзем дә сизмәстән тавышымны күтәрдем:

— Нәрсә? Бушка дисеңме? Ачлыкның нәрсә икәнен беләсеңме соң син? Кара ачлык елны булган бит бу хәл! Андый чакта икмәк бәясе алтыннан өстен йөри! Яхшылыгын металлга алмашмаган әбиебез! Авыру сабый хакын хаклап авызыннан өзеп соңгы ризыгын бушлай биреп җибәргән, бу балдакны алып калмаган ул! Тик үлем түшәгендә яткан нарасыйга бер кыерчык ипи әҗәл даруы була алмаган алуын. Шулай да ашап бетерә алмаган сыныгын хәлсез куллары белән йомарлаган килеш җан биргән сабый.

Тамагыма төен тыгылгандай булды, тавышым алышынды, салмаклана төштем.

8*

Бердәнбер баласын җуйган бичара ана сагышлы минутларында «ярый әле, шунысы үкенечтә калмады — тилмереп сораган ризыгын авыз итеп үлде бәбекәем» дип юана торган булган. Җае гына чыксын, мин бу мәрхәмәткә каршы бер яхшылык эшләми калмам, дип нәзер дә әйткән, бичара.

Бу вакыйгадан соң күпмедер вакыт узгач, еллар иминләнгән. Яңа ашлык өлгергәч, исән калганнар хәлләнеп аякка басканнар. Көзге муллыкта ике еллык туй бергә гөрләгән. Безнең әнкәйне дә кияүгә биргәннәр. Никах мәҗлесе узгач, бүләкләр өелгән подноска баксалар, ни күрсеннәр, иң аста алтын балдак ята икән. Кем салган бу затлы бүләкне? Уйлашып карыйлар, сорашып карыйлар, иясен таба алмыйлар. Шунда күрше карты Хәйбери бабай бүләкне «сөбханаллалап» әнкәйнең учына салган:

— Я күктән иңгән бу, я булмаса Хозыр Ильяс хәзрәтләре кереп чыккан монда. Хәләл бүләк бу сиңа, кызым, кулыңнан төшермә, югалтма, бәхетле юлдашың булыр.

Әнкәй мәрхүмнең хорафатларга, дини әкиятләргә ышана торган гадәте булмаса да, олы кеше сүзен тотыпмы, балдакны кулыннан бер дә салмады. Әткәй белән тату гомер итүен дә, балаларыннан игелек күрүен дә гел шушы рәхмәтле бүләккә юрый иде. Үләр алдыннан васыять итеп ул аны баш баласына — синең әниеңә тапшырды.

Сәер бүләкнең серенә без соңыннан гына төшендек. Аны безгә шул ук Хәйбери бабай үзе сөйләде. Балдак, әлбәттә, күктән дә иңмәгән, «Хозыр Ильяс диган изге мосафир да» калдырып китмәгән аны. Бичара хатын үзе туйда катнаша алмаган, кемнән һәм ни өчен икәнен әйтмәскә кушып, бүләген шул Хәйбери карт аша тапшырткан икән. Менә шул балдак хәзер...

Гамбәрия агарынып китте дә, миңа тутырып караган килеш, бер мәлгә телсез калды. Моңа чаклы моң-зар әсәре күрмәгән фирүзәдәй зәңгәр күзләр «җитте, калганын сөйләмә, түгеләм, түгеләм» дигәндәй мөлдерәгәннәр иде.

Миңа да моңсу булып китте. Кызның ялга каршы иркен көне иде бүген. Шуңа апасы белән күрешү шатлыгы да өстәлгәч, кәефе күтәренке, теленә ни килә шуны минем белән уртаклашып, иркәләнеп утырасы килгән иде. Үпкәләттем, турырак әйттем... Туры әйткән туганына ярамаган, диләр.

Әнә ул дәресен хәзерләмәгән мәктәп баласыдай турайган да турсаеп алдына караган килеш дәшми утыра. Әйдә дәшмәсен, уйлансын. Кабатланмас истәлекле көннәр кебек васыятька калган истәлекләр дә үзләрен искәртеп торсалар гыйбрәтлерәк булалар.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**ФЕВРАЛЬ, 1976**

1976 елның 16 февралендә, меңнәрчә кешеләрнең алкышлавы астында, Кама автомобиль заводының баш конвейерыннан автогигантның беренче машинасы төште. Аның киң кабинасына «КамАЗ № 0000001—КПССның XXV съездына», бортларындагы транспарантларга «КПССның XXV съездына безнең хезмәт бүләгебез», «Кабул ит, Ватан, беренче «КамАЗ»ны!» дигән сүзләр язылган. Конвейер әле хәзергә җибәрү-көйләү режимында гына эшләсә дә, алда әле комплексның барлык технологик линияләренә күп төрле сынаулар үтәргә кирәк булса да, «КамАЗ» маркалы беренче автомобильләр инде күз алдында! Бу — комплексны төзүчеләрнең, монтажчыларының, аның барлык заводларындагы эшчеләрнең һәм белгечләрнең генә түгел, партия чакыруы буенча тугызынчы бишьеллыкның бөтенсоюз төзелешендә актив катнашкан йөзләрчә коллективларның да зур җиңүе. Бирелә социализм илләре арасындагы экономик интеграциянең уңай принциплары ачык чагылды. КамАЗны җиһазландыруда, һәр ике як өчен файдалы нигезләрдә, чит ил фирмалары да катнаштылар. Димәк, бу — КПССның XXIV съезды тарафыннан эшләнгән Тынычлык программасының җиңүе, партиянең ленинчыл Үзәк Комитеты, аның Политбюросы һәм КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш Л. И. Брежнев үткәрә торган үзара тыныч яшәү политикасының җиңүе.

ТАСС, Яр-Чаллы.

... ВЛКСМ Үзәк Комитеты Бөтенсоюз удар төзелешенең барлык коммунистларын, комсомолларын, төзүчеләрен, монтажчыларын һәм эшчеләрен зур хезмәт җиңүе — «КамАЗ» автомобильләренең беренче колоннасы конвейердан төшү белән чын күңелдән һәм кайнар котлый. Бу җиңү — Ватаныбызга, Коммунистлар партиясенә, КПССның XXV съездына зур бүләк. Мәскәүдән, Ленинградтан, Татарстаннан, барлык союздаш республикалардан килгән комсомолецларның һәм яшьләрнең шәһәр партия оешмасының, төзелеш һәм завод коммунистларының сугышчан ярдәмчеләре булулары белән горурланабыз. Эштә үз-үзләрен аямаган комсомолецлар һәм яшьләрнең героик хезмәте белән Ленин комсомолының КПССның XXV съездына Рапортына якты сәхифә язылды. Коллектив тарафыннан яулап алынган бу җиңү — КПССның XXIV съезды карарларын, КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш Л. И. Брежнев күрсәтмәләрен тормышка уңышлы ашыруның ачык дәлиле.

ВЛКСМ Үзәк Комитеты комсомолецлар, яшь төзүчеләр, монтажчылар, завод эшчеләре КПССның XXV съезды карарларын уңышлы үтәү буенча социалистик ярышны тагын да киңрәк җәелдерерләр... Кама автомобиль заводлары комплексының беренче чиратын 1976 елда эшләтә башлау өчен үзләренең көчләрен кызганмаслар дип ышана...

Е. Тяжельников, ВЛКСМ Үзәк Комитетының беренче секретаре.

«КамАЗ» маркалы авыр йөк машиналары эшләп чыгару заводлары комплексының төзелә башлавына әле биш елдан аз гына күбрәк вакыт узды. Ә автогигант төзүчеләр инде бихисап күп эшләр башкарырга өлгерделәр... Төзелешнең төп подрядчигы — «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсе коллективы бишьел-

лыкта билгеләнгән 1 миллиард 632 миллион сум күләмендәге төзү эшләрен срогыннан әлек 1975 елның 3 октябрена үтәде... Соңгы вакытта төзүчеләр һәм автозаводчылар җиһазларны монтажлап, станокларны һәм механизмнарны урнаштырып кына калмадылар, ә бәлки баш конвейерда беренче авыр йөк машиналарын КПССның XXV съезды ачылу көненә җыеп өлгертү өчен кирәкле детальләрне һәм автомобиль узелларын әзерләшүгә дә булыштылар.

16 февральдә КамАЗның баш конвейеры моңарчы күрелмәгәнчә җанланып китте. Ул эшли башлады! Дөрес, бу әле заводның бөтен чираты да эшли башлады дигән сүз түгел иде. Белгечләр телендә бу комплексны җибәрү-көйләү дип атала. Быел әле тагын 200 миллион сум күләмендә төзү-монтаж эшләре башкарыласы бар. Менә шуннан соң инде Кама автомобиль комплексының беренче чиратын дәүләт комиссиясенә тапшырырга мөмкин булачак.

**«Комсомольская правда», Мәскәү.**

«КамАЗ» эмблемалы яңа, махсус киемнәр кигән авто-җыючылар эш урыннарына гадәттәгедән иртәрәк килделәр. Барысының да күңелләре шат, кәефләре күтәренке. Съезд алды ярышында ирешкән хезмәт җиңүе хөрмәтенә күтәрелгән флаглар җилферди, транспарантлардагы сүзләр алда торган бурычлар турында сөйли. Мәскәү, Горький, Тольятти, Ярославль, Минск предприятиеләрендә чыныгу алган тәҗрибәле эшчеләр автомобиль җыю линиясенең 72 позициясенә урнашалар.

Бу күренекле вакыйгада катнашучылар — Татарстан АССРда авыр йөк автомобильләре комплексы һәм яңа шәһәр төзү буенча КПССның XXIV съезды карарларын тормышка ашыручылар: социалистик ярышта җиңеп чыгучылар, алдынгы төзүчеләр, монтажчылар, завод эшчеләре алар белән янәшә басалар.

КамАЗны бөтен ил төзеде һәм төзи. Чаллының бер үзендә генә дә 60тан артык милләт кешеләре иңгә-иң торып эшлиләр. Комплексны төзүдә йөзләрчә предприятие, уннарча фәнни-тикшеренү һәм проектлаштыру институтлары коллективлары катнаша...

... Фараларның күз чагылдыргыч яктылыгы... һәм менә конвейердан беренче машина төшә. Автомобиль җыю заводының 40 гектар мәйданлы корпусы эчендә көчле «Ура!» авазы яңгырый.

«КамАЗ» үзенең барлык сыйфатлары ягыннан иң яхшы машиналарның берсе булачак. Кама автомобиль заводы тулы куәтенә эшли башлагач, илебез автомобиль промышленносте чыгара торган машиналарның йөк күтәрешлеге чама белән бер тапкыр ярымга үсәчәк.

«КамАЗ» машинасын конструкторлар да, сынаучылар да һәм тәҗрибә модельләрен йөртеп карау бәхетенә ирешкән башка барлык кешеләр дә мактый. «Бу йөк машинасы — сыйфат бишьеллыгы дәрәҗәсендә» — аларның уртак фикере әнә шундый. «КамАЗ» автомобиле йөк авырлыгының күчәргә аз төшүе белән аерылып тора. Бу исә аңа авыл юлларында да хуҗаларча йөрергә мөмкинлек бирәчәк.

**«Правда», Мәскәү.**

КамАЗ... ул — хәзер пресс-рам заводы урнашкан җирдән экскаватор беренче чүмеч балчык алган көннән башлап 1508 көн буена барган төзелеш. Ул — алты завод: кою, тимерчелек, пресс-рам, автомобиль, двигательләр, ремонт-инструментал заводларының тулы комплексы, күршедәге Яңа Зәй шәһәрендә төзелгән дистанцион идарә аппаратлары заводы.

Кама автомобиль заводының мәйданы 100 квадрат километр, конвейерларның озынлыгы 300 километр. КамАЗ түбәсе астында — ике миллион квадрат метрга якын производство мәйданы.

Заводның беренче машинасы — «КамАЗ-5320» модельле автомобиль. Өч күчәрле бу машина автопоезд составында 16 тонна йөк ташый ала. 0000001 номерлы «КамАЗ»ның экипажы съезд алды социалистик ярышында җиңеп чыгучылар: КПССның XXV съезд делегаты Р. Сабирҗанов, Д. Загребальный, В. Перетолчин.

1976 елда КамАЗ илебезгә авыр йөк машиналары бирә башлады.

Х ө р м ә т л е  у к у ч ы л а р! Журналыбызда соңгы өч ел буена даими рәвештә «КамАЗ елъязмасы» рубрикасы бирелеп барылды. Анда Чаллыдагы автомобиль гиганты төзелешендәге иң әһәмиятле вакыйгалар чагылдырылды, төзүчеләр һәм автозавод эшчеләре тормышы турында сөйләнде. Бу язмаларны без КамАЗның баш конвейерыннан беренче йөк машинасы төшкән көнгә кадәр алып бардык. Безнең уйлавыбызча, әлеге язмалар тугызынчы бишьеллыкның Кама буенда барган бөек төзелеше белән якыннан кызыксынган әдипләребез өчен бай иҗат материалы булып хезмәт итә алачак.

## Кояш Тимбикова

# КАРА ЮРГА



Авыл бүген башка көннәрдәгегә бөтенләй охшамаган иде. Бала-чага чыр-чуы да, каз-үрдәк гайгылдашуы да, көтүгә чыкмый калган бозауларның бакыруы да ишетелми. Тып-тын. Эссе.

Инсаф, өйләр яныннан узганда, һәр нәрсәне җентекләп карый барды. Алдан ул фермаларда йөреп чыккан иде. Терлекчеләр иптәшләре арасыннан бер җаваплы кеше билгеләгәннәр дә, эшләренә тел-теш тидерерлек урын калдырмыйча, бәйрәмгә киткәннәр. Илдә — сабан туе. Эч пошырып, йокы качырып бимазалаучы мәшәкатьләр беткән, тантана итәр чак җиткән бит!

Кара юрга, салмак кына атлап, авыл читенә чыгып җитте. Юл монда Суыксуга таба борылган иде. Ат шактый биек булып үсәргә өлгергән арыш басуы буйлап җай гына юыртып алып китте. Салам селкетерлек тә җил юк. Бөтен тирә-юнь җылы кояш нурына да тургай моңына күмелгән.

Һич көтмәгәндә алда бер җәяүле күренде. Тарантас атлының үтеп китүен көтеп юл читендәге зәңгәр чәчәкләр эченә кереп күмелгән кыз бала янына килеп туктады.

— Кая барыш, сеңел?

— Суыксуга, мәйданга, абый.

— Ә-ә, алайса, әйдә утыр! Мин дә шунда, сабан туена барам.

Бер-берләренә «абый», «сеңел» дип дәшсәләр дә, түм-түгәрәк алсу йөзле кыз белән ат тотып баручы егет — «Алга» колхозы председателе Инсаф Камалетдинов бер чама яшьтәге кешеләр иде. Кыз, йөгереп килеп, тарантаска менеп утыргач, икесе дә сүзсез калдылар. Инсаф кызның сылу гәүдәсеннән, матур йөзеннән күзләрен ала алмый торды. Тегесе, уңайсызланып, яңа гына тегеп кигән бизәкле ситсы күлмәгенең итәкләрен тарткалады, аякларын яшерде, тутый кош сурәте төшерелгән ефәк кыекчасын төзәткәләгәндәй итеп, маңгаендагы тәлгәш бөдрәләрен җыештырды. Инсаф аның һәр хәрәкәтен күзәтеп барды: «Карасана, дөньяда мондый җан ияләре дә бар икән бит әле! Сугышы да, җимерекләкләре дә, ачлыгы-ялангачлыгы да бу асыл затларны харап итә алмаган икән ләбаса!»

Егерме биш яшенә җиткәнче Инсафка тормышның әчесен-төчесен шактый татырга туры килде. Шаулы, күңелле ял кичәләрендә кыз-кыркын белән шаярулар, айлы төннәрдә ләззәтле уйлар тәэсиреннән йоклый алмыйча таң аттырулар әллә бөтенләй булмаган, әллә булып та хәзер инде хәтердән үк чыкканнар...

Әтиләре Заһертдин абзый дөнья куйганда, гаиләдә иң олы бала саналган Инсафка нибары ун яшь була. Ярый әле, ата кеше, алда ни буласын сизенгәндәй, хатынын укырга үгетләгән.

— Яшь аермасы зур безнең, карчык, — дигән ул аңа. — Сабый балалар белән сиңа тол калырга туры килмәгәе. Аларны кеше итү өчен бераз укымый булмас сиңа!

Колхозлар төзелгән чорда Мәфтуха апага укырга җае да чыга: аны бригадирлар хәзерләү курсына җибәрәләр. Өйрәнгәне бик вакытлы булып куя. 1933 нче елны ук инде аны уңган бригадирлар рәтеннән телгә ала башлыйлар, зурлап, Мәскәүгә, колхозчылар съездына җибәрәләр. Аннан ул күкрәгенә медаль тагып, эшкә тагын да дәртләнебрәк кайта. Колхоз хуҗалыгындагы бөтен мәшәкатьне үзенекедәй кабул итә ул һәм барына да өлгерергә тырыша: кешеләрне дә җитәкли, урагын да ура, тимерчелегендә дә эшли, ат та җигә, хәтта трактор да йөртә. Утыз биш яшендә дүрт бала белән тол кала, әмма гомере буе беркемгә дә күз яшен күрсәтми. Нинди генә авырлыкларга чыдамый бу хатыннар, бу сеңелләр?!. Әнә бит, елларның кырыслыгына баш имәгән, сулмаган-саргаймаган шул кызларның берсе, гөл кебек балкып, басу киңлегенә матур бер бизәк булып бара!

— Исемең ничек иде әле, сеңел? — Инсаф шулай дип сораугa, чибәр туташның кем икәнен белергә теләгәндәй, кара юрга да, адымын акрынлатып, башын артка борып алды.

— Клара.

«Аһ, Клара, Клара! Нинди генә көн булып чыкты соң әле бу? Нәрсәгә генә кагылма, нинди генә сүз башлама — бөтенесе үткәнне искә төшерә дә тора.

Клара! Клара! Немец кызларының исеме бит бу! Шул бер сүз әле төзәлергә дә өлгермәгән күңел яраларын кабат яңартты да куйды. Мең тугыз йөз илленче ел бит инде, кайберләрен оныта башларга да бик вакыт, югыйсә. Юк, булмый, хәтердә бары да ап-ачык саклана».

... Сугыш башланганда Инсаф колхозда агротехник булып эшли иде. Ул чорда агротехник — җирнең, ашлыкның төп хуҗасы. Нибары унбиш яше тулган Инсаф әнә шул җаваплы йөкне тарта. Игенченең бар байлыгы — атлар да ике төрәнле сабан. Тракторлар әле сирәк-мирәк кенә күренгәли башлаган чак. Чирү авылында төзелгән колхозга тракторлар 1942 нче елда гына килде. Алары да МТС карамагында. Ике-өч тракторлы отряд килә дә үзе теләгән кадәр эшләп китә дә бара.

Әмма ашлык ишелеп уңа иде. Инсаф агротехник булып эшли башлаган 1940 нчы елны да икмәкне кая куяр урын тапмадылар. Хезмәт көненә сигезәр килограмм бүлделәр. Йорт саен ашлык өләшеп йөрү авылның зур бәйрәменә әйләнде. Иң шәп атларны җигеп, «кызыл олау» ясап, олау башына гармунчылар утыртып, музыка белән озатылса, бөтен авыл икмәкнең Шәмсемөхәммәт яки Гыйльфанетдин агайлар кебек уңганнар йортына баруын белә. Ялкауларга исә андый зур олаулар һәм хөрмәтләү эләкми. Аларга тигән икмәкне иске арбага җигелгән арык ат илтә бара. Бөтен колхоз әнә шулай бер булып, олы максатларга омтылып яши иде. Бер җәй хәтергә мәңге онытылмаслык булып кереп калган. Авыл, әүвәлгечә, сабан туена әзерләнә иде. Берәүләр атларын чыныктыра, чабышка катнашырга ниятли. Икенчеләре көрәштә көч сынашмакчы. Кызлар, яшь киленнәр тегү тегә, кульяулыклар чигә. Бәйрәм июньнең егерме өченә билгеләнгән. Хәерсез хәбәр өлгеррәк булып чыкты. Авылда радио-мазар юк. Ул хәбәрне ат менгән малай авыл буйлап кычкырып таратты: «Сугыш башланган, сугы-ыш!..»

Их, Клара, Клара! Ул көннәрне хәтерлисең микән син?

— Әтиең кем исемле, сеңел? Мин белгән кеше түгелме икән?

— Әти сугыштан кайтмады безнең, абый...

Инсаф үз колакларына үзе ышанмый торды. Менә нинди асыл затларны япь-яшь килеш ятим калдырды бит бу сугыш!

... Ул елны авыл бөтенләй бушап калды. Ләкин эш тукталмады. Мул булып уңган игенне урып-җыярга, суктырырга кирәк иде. Кыш-ның-кыш буе ындырда сугу машинасы тавышы гөрләп торды. Аны-сы ат көче белән эшләүгә корылган иде. Сортировка машинасын ха-тын-кызлар кул белән әйләндерделәр.

Мәфтуха апа үзенең бригадасын ничек кенә булса да башкалар рәтеннән төшереп калдырмаска тырыша. Таң беленер-беленмәстән, өстенә озын бишмәтен киеп, колхозчылар съездында бүләк итеп би-релгән шакмаклы шәлен бөркәнеп, өеннән чыгып китә. Аның кайчан кайтуын, хәл алыр өчен башын бераз мендәргә төртеп торуын өйдә-геләр күрми дә калалар.

Инсафның үз кайгысы. Җирнең, киләчәк ел уңышының язмышы аңа тапшырылган. Ул армиягә алынырлык яшьтә булмавына үртәлә. Үртәлсә дә, кемгәдер үпкәләп утыра торган заман түгел. Колхозның төп эше аның яшендәгеләр: Мәхтүмә, Мөслимә, Тимер, Сәлимә, Рәи-сә, Хәтмуллалар җилкәсендә. Кайсы тракторда эшли, кайсы — завхоз, кайсы — бухгалтер. Кирәк булса, барысы да ындырга чыга, атын җигеп, ашлык тапшыру пункты Җамалыга китә.

...Ул көнне алар барысы да ындырда ашлык суктыралар иде. Егетләргә күптән көтелгән чакыру хәбәре килеп төште. Эшләп торган җирләреннән алып киттеләр. Бу көнне авыл сугышка берьюлы алты егетен озатты. Абыйларының, әтиләренең фронтка китүенә кызыгып калган яшүсмерләр, чират инде үзләренә килеп җиткәч, кинәт уй-чанланып калдылар. Бер-берләре белән кочаклашып, җырлый-җыр-лый урам әйләнделәр. Шәйхулласы башлап җибәрде, Хәтмулла сузып алып китте.

...Кара юрга, кара дуга
Менеп бара урләргә.
Онытмам сезне, дусларым,
Кермәенчә гүрләргә...

Инсаф күңелендәге бөтен уй-хисләрен гармунына ышанып тап-шырган — сыздыра да сыздыра. Күзе — озата килүчеләрдә. Алар арасында башкалардан аерылып торганы, үзәкне өзгәне — Энисе. Аңа текәлеп карарга Инсафның көче җитми, күзләре күзгә очрашса, еламый түзүләре авыр булыр. Энисенә дә, Инсафка да. Ә еларга ярамый. Мәфтуха апа балаларына һәр вакыт әйтә килде. «Җебеп төшмәгез, күз яшегезне миңа күрсәтәсе булмагыз!» Әнинең бу сүз-ләре канга сеңгән. Аның алдында яшь коярга ярыймы соң?!

Клара, Клара! Ул кара кайгылы көннәрдә син кайда булдың икән соң, чибәр кыз? Әгәр шунда, авылда Инсафка кул болгап кал-ган булсаң, сугыш кырында егеткә никадәр җиңелрәк булыр иде.

Сугыш кыры дигәннән, Инсаф башта коры җирне күрмәде дә диярлек. «Комиссар» дигән хәрби катерга эләкте ул. Астрахань бе-лән Сталинград арасында хәрби йөк ташучы пароходларны озата йөрделәр. Аларның катерына пароходларны дошманның һава һөҗү-меннән саклау бурычы йөкләтелгән иде. Су өсте тулы мина. Дошман самолетлары аларны төнге караңгылыкта борчак сипкәндәй коеп китә. Миналарның бер өлеше магнитлы. Берәр метр чамасы су астына күмелеп торган бу миналар якынлашучы пароходка, бер-ике метр ара калгач, үзеннән-үзе килеп ябыша. Шушындый шартларда кораб-ларга юл ярып йөзделәр алар.

Сталинград операциясе уңышлы тәмамланганнан соң, егетне көнбатышка озаталар. 1945 нең 9 нчы маенда ул Берлин янында ук була. Белоруссия, Польша, Румыния аша узып, Рейхстагка кадәр барып җитә. Шул елларда ул яңа һөнәргә — радистлыкка өйрәнә, радиостанция начальнигы булып эшли.

...Тарантасны көр күңелле яшьләр урап алганын Инсаф сизми дә калды.

— Әйттем ич! Инсаф сабан туена килми каламы соң?! Нихәл, малай!

— Никтер соңладың син!

— Ярый, башланмады ич әле!

— Көрәшергә исәп бармы?

Инсаф егетләр белән исәнләшеп чыкты. Аннары, кырт борылып китеп баруны килештермичә, әле һаман ат ялын сыйпаштырып торучы Кларага: «Син, сеңел, бераз ат янында торып тор әле, мин егетләр белән бер генә җиргә барып килим, яме?!» — дип, кешеләр арасына кереп югалды.

Сабан туе мәйданында уен-көлке, җыр-бию, көч сынашу көне буе дәвам итте. Күләгәләр озая башлагач кына халык акрынлап тарала башлады. Кайту ягына борылган бер төркем эченнән, ниһаять, Инсаф та күренде. Муенына, беләкләренә ул тастымаллар, яулыклар аскан, бер сөлгене аның биленә үк урап куйганнар.

— Әллә чынлап та көрәшкәнсең инде, абый?!

Егет сискәнеп китте. Юрга янында калган кыз, әле булса шунда басып тора иде. Кулында — каз күкәе кадәре генә төенчек, үзе бертуктаусыз елмая. Атны туарып ашарына биргән дә көнен шуның янында үткәргән.

— Клара?!.

...Алар шул ук елны өйләнештеләр. Бу мең тугыз йөз илленче ел иде, ә илле бернең тугызынчы мае көнне Мәфтуха апаның уңган килене тупырдап торган бер малай тапты. Аңа Давыт дип исем куштылар.

...1972 нче елның җәендәге кебек корылыкны табигать дошманына да күрсәтмәсен. Яз башында теләр-теләмәс кенә сибәләп киткән яңгыр җәйге айларда бөтенләй кабатланмас булды. Инсафның йокысы качты, тамагыннан аш үтми башлады. Төн урталарында урыныннан торып чыга да Агыйдел ягыннан дымлы җил исми микән дип өметләнә, озак итеп күккә карап тора. Җылы-йомшак юргандай кабарып, бөтен җирне шифалы тамчылар белән рәхәтләндереп китә торган болытлар кая китеп югалдылар соң?! Чалт аяз. Зәңгәр күктә бер-берсе белән сөзешергә торган тәкәләр шикелле эре-эре йолдызлар тертәйгән. Яфракларга хәтта чык дымы гына да кунмый. Көндездән кызып калган җир аз гына суынырга да өлгерми, уңган киленнәр кирпеч вагы ышкып ялтыраткан зур җиз таз кадәр кояш тау артыннан тагын тәгәрәп килеп чыга. Инсаф, кеше-кара күзенә чалынырга теләмичә, кара юргасын җигеп, кырга ашыга.

Шыкыраеп кипкән басуларның йөзен киң-киң ярыклар ергалап бетерде. Бичара председатель вакыт-вакыт куркынып кала: «Бу җир дигәнең, әгәр сабырлыгы бетеп, кипшенүдән чарпаланган шушы ярыкларыннан ыңгырашу авазы чыгара башласа, үзәгең өзелүгә ничек түзәрсең?!.»

Әмма җир түзде. Игеннәр дә, бу ни хикмәт, яшеллекләрен шактый озак сакладылар. Дөрес, биеклеккә әллә ни сузаеп китә алмадылар, башаклары да бик бөтәймәде, шулай да арыш белән бодай

төптән үк сыгылып төшмәде. Борчак кына борештә: җир ягалый яфраклары саргаеп калды, үсүдән бөтенләй туктады. Аптыраган председатель Уразайның өлкәннәре, башларыннан төрле хәлләрне кичергән аксакаллар белән киңәшеп чыкты.

— Шушы гомер яшәп, мондый корылыкны күргәнебез юк иде безнең,— диделәр картлар.— Егерме беренче елда да шушы кадәр үк шәфкатьсез яндырмаган иде. Әле дә гаҗәп: көеп бетмичә, игеннәр үсеп утыра. Борчакның да бу көнгә хәтле куырылып бетмәве сәер...

Колхоз идарәсендә киңәшләшә торгач, бөтенләй үк кипшенгәнче, борчакны чаптырырга, яшел азык урынына силос базларына тутырырга булдылар. Инсаф ул көннәрдә тешләрен кысып, үз-үзен кая куярга белмичә йөрде. Кешенең табигать көчләре алдында шул дәрәҗәдә чарасызлыгын тою аның җан тынычлыгын алган иде. Йөзләрчә гектарга чәчелгән борчакның, бер мыскал да табыш бирмичә, яшел азыкка чабылуы аңа бик сәер тоелды. Нинди куәтле техникалары бар: трактор, бульдозер, комбайн, йөк ташу машиналары — барысы да үз кулларына тапшырылган. Бу байлык белемле һөнәр ияләре булган хуҗалыкта ут уйнатырга тиеш иде бит! Агроном Зәкәрия Шәехов, бригадир Илүс Исламов, баш бухгалтер Фәридә Исламова — институт тәмамлаган белгечләр. Колхоздагы башка кадрлар да махсус белемле кешеләр. Кыскасы, бар да бар, һәммәсе җитеш. Табигатьнең болай ямьсезләнүе менә шуңа күрә ачуны китерә дә. Хуҗалыкта мең дә бер җитешсезлеге тулып яткан әүвәлге еллар булса, бәлки болай ук үзәк тә өзелмәс иде. Бөтенесе Инсафның күз алдында, аның катнашы белән булдырылды бит!..

...Ул сугыштан кайтып кергәндә урак өсте иде. Җамалыга ашлык илткән атка утырып кайтты ул. Авылда аның кайтасын берәү дә белми иде. Шуңа күрә көтеп торучы да, каршы алучы да булмады. Мәфтуха апа кырда, энекәшен шахта эшенә озатканнар, өлкән сеңелесе Фәһимә идарәдә бухгалтер, кечесе авырып түшәктә ята.

Инсаф бусагадан атлап керсә дә керде, кермәсә дә керде. Өй шып-шыр иде. Тел өстенә салырлык ярма бөртеге, ут үрләтерлек шырпы юк. Шулай да кечке аш табыны ярыйсы гына хәзерләнде, колхоз идарәсе сугыштан кайтучыларга бирәр килограмм арыш бирә икән...

Кайтуының өченче көнендә Инсаф басуга лабогрейка белән ашлык урырга чыкты. Хатын-кыз, карт-коры эшләтә белми изаланган икән. Басуга уру машинасы кергәч, бары да билләрен турайтып, бер мәл җиңел сулап куйдылар. Иген каерылып уңган, кул белән генә аны ничек җыеп бетерер идең?! Көлтәгә бәйләп баруы да шактый көчне ала...

Менә шулай башланып киткән хезмәт бит ул. Узган еллар белән хәзергене чагыштырып сөйли башласаң, кеше ышанмас. Колхозчыларга авыр, алар белән җитәкчелек итүчегә тагын да авыррак.

Сугыштан кайтуына биш-алты ай да үтмәгәндер, Инсафны бригадир итеп куйдылар. Тагын ел да узмады: «Синдәге осталыкка бригадирлык кына аз!» дигән булып, «Алга» колхозына председатель итеп сайладылар.

— Туктагыз әле, җәмәгать, бераз өйрәним! — дип, киреләнеп караса да, егетнең сүзенә колак салмадылар.

— Сиңа, Инсаф туган, өйрәнәсе-нитәсе юк, кендегең шушы җиргә береккән, әйдә, җигел дә тарт! — дип кырт кистеләр.— Синдәй егетләр дә булдыра алмаса, бу колхозны кем аякка бастырыр?!.

Җир өстенә айлар буена бер тамчы яңгыр төшмәсен әле, мин шул туфракта тәпи басып киткәнмен, дип кенә әйбәт уңыш үстерә алыр-

сыңмы икән? Бүгенге авыл хуҗалыгын җитәкләүче кешегә барыннан да элек белем кирәк. Бичара җир, алдын-артын карамыйча, һичнинди тәртәгә сыймый торган боерыкларны үтәргә тырышучы надан кешеләр кулында шактый җәфа чикте инде. Уңдырышлы итү өчен, җиргә ни кирәклеген уйлап тормаганнар, аның бөтен ашын сыгып бетергәннәр. Болай да әллә ни уңдырышлыдан саналмаган көлсу туфраклы бу басудан, аны ашламый-нитми торып, күпме ашлык күтәргә мөмкин?!

Мөмкинлекләр барын бар икән ул үзе. Инсафның мондый җирдә түгел, ташлы тау түбәләрендә, туфракны кәрзин белән ташып, гөлбакча үстергән халыклар турында ишеткәне бар. Җирнең серен аңлый белергә кирәк. Әйе, кая гына барып төртелмә, һәрнәрсә белем таләп итә.

— Әни, мин укырга китәм! — бу сүзләрне әйткәндә Инсаф үзе дә тәвәккәлләп бетермәгән иде. Әнисенең хуплавына ышанып, теләгенә бер таяныч табу өчен, элек әнисе белән киңәшергә булды ул.— Казанда колхоз председательләре өчен ачылган өч еллык мәктәп бар икән, мине шунда җибәрмәкчеләр...

Мәфтуха апа бер киленгә, бер бишектә яткан балага карый. Улының ни өчен нәкъ менә үзенә мөрәҗәгать итүен дә шундук аңлый. Яшең утызга якынлашып килгәндә, яңа оешкан гаиләңне ташлап, ерак шәһәрдә укып йөрүләре — уен эш түгел. Ана, гадәтенчә, ашыкмый гына җавап кайтара:

— Җибәрүләренә рәхмәт әйт, улым. Үзең башлап укырга тотынсаң, мөгаен, тиз генә урнаша алмас идең әле.— Аннары ул, килененең күңелен табу өчен, өстәп куя: — Безнең өчен борчылма, ничек тә чыдарбыз. Әле мин дә эшләп йөрим... Әйдә, тәвәккәллә, улым. Бер-ике айлык курс белән бригада тартып мин дә аз интекмәдем. Хәзерге колхозны алай гына тарта алмассың, шулай бит, килен?

Шушы кадәр сөендереп сөйләгән сүзнең кайсы ягыннан килеп, килен каршы төшә алсын соң?! Менә елыйм, менә үксеп җибәрәм дип торган Клара, яшь тулы күзләрен Инсафка таба борып, елмайгандай итә.

— Шулай шул, әнкәй,— ди ул. Тик аның күзләрендә мөлдерәмә сагыш, үпкә: «Их, син, өчәр елга ташлап китәр өчен өйләндеңме син миңа?! Монда, әнкәң янында өч айлык бала күтәреп калдырырлык булгач, ни пычагыма хатын иттең мине?! Бергә чакта да, таңнан чыгып китеп, төн уртасында гына кайтып кереп, шашар хәлләргә җиткерүең аз булгандыр шул. Инде Казанга ук җыенасың икән!..»

Клара үзенең бу күңелсез уйларын Инсафыннан яшерергә тырышты. Ник дисәң, беренчедән, акылы белән ул иренең укырга ниятләвен үзе дә дөрес дип таба. Икенчедән, Инсаф, хатын «кәҗәләнүе»нә карап кына, ниятеннән барыбер кире кайтмаячак. Эндәшми калуың яхшы, хуплап куюың тагын да әйбәтрәк. Клара бик яхшы белә Инсафның холкын. Бергә яши башлаган айларында нииндидер уңай белән үз сиксәнен сиксәнләп караган иде ул. Әлеге дә баягы шул өйдә ялгыз утырып туюдан башланып киткән иде бугай. Инсаф гел өйдә тормый: әле идарәдә, әле кырда, әле җыелышта, әле райкомда... Хатын аптырый калды. Я, бу нинди гаилә була ди инде? Иртән кара-каршы утырып озаклап бергә чәй эчмә, эшенә бергәләшеп йөрмә, ял иткәндә тагын бергә булма, ни кызыгы кала соң бу дөньяның? Көннәрнең берсендә, нәкъ төшке аш вакыты җиткәндә, Инсафының басу аръягына, тракторчылар янына китеп баруын белгәч, Кларaның аеруча ачуы чыкты. «Аңа минем бер тиенгә дә кирәгем юк икән,— дип чәпчи ул.— Яшәсен әнә кара юргасы белән!» Шулай җиңел генә уйлап алды да, төенчеген кыстырып, туган авылы Әтәскә кайтып китте.

Авыл җирендә телефоннар юк чак иде, әмма хатыны китү турындагы сүз председательгә бик тиз килеп ирешә. Көне буе бер валчык ризык капмый кырда йөргән Инсафка шул гына җитмәгән иде! Ул, тарантасын идарә ишеге төбендә азга гына туктатып тора да, нибар тавышына:

— Кайсыгыз бар анда? — дип кычкыра.

Ишектә яшь кенә бер кыз күренә. «Исеме ничек соң әле? Кем булып эшли? Ә-ә, бухгалтериядә бугай...» Мондый вак-төяк сорауларга җавап эзләп торыр ара юк.

— Әйдә, утыр менеп тизрәк! — ди Инсаф.

— Кая барабыз, абый?

— Әтәскә!

— Нинди эш белән, берәр төрле документ кирәк булмасмы?..

Кыз аны-моны абайларга өлгергәнче, юрга инде элдереп авылдан чыгып та чаба. Ике авыл арасын кушаяклап чабып узган атын, Әтәс урамына кергәч, Инсаф үз җаена җибәрә. Салмак кына атлатып урамның кыл уртасыннан үтәләр. Юл буенча бер сүз эндәшми килгән председатель, кызга таба борылып, елмая-елмая нидер сөйләргә тотына. Ә күзләре Кларалар өенең яран гөл белән тулы тәрәзәләренә юнәлгән. Әһә, кызыл чәчәкләр арасыннан берсенең башы күренә түгелме? Шул үзе, Клара! Зәңгәр крепдишин яулык бер аңарда гына! Актанышка баргач, бүләк итеп алып кайткан иде...

Сүз, ничек башланган булса, шулай ук кырт өзелә. Берни аңламый калган бухгалтер кыз, очып барып төшмәс өчен, ике куллап тарантас кырына ябыша.

Инсаф ничек кенә ашыкмасын, Клара аннан барыбер өлгеррәк булып чыга. Ире атын туарып йөргәләгәнче, Клара инде өйгә кайткан, самаварны табын түренә үк чыгарып утырткан була. Әтәс белән ике арадагы иң кыска юлдан — бәрәңге бакчалары артыннан салынган тар сукмактан кайтып керә Клара: «Мондый киту-кайтуларны кеше-кара күрмәве хәерлерәк». Менә хәзер, Инсаф Казанга китәргә җыенганда, шулай кырлы-мырлы йөреп кара — бөтен өйнең яме китәчәк. Барсын, укысын, хәерле юл!

Тәвәккәл кешеләрнең «башланган эш — беткән эш» дигән сүзе бик белеп әйтелгән икән ул. Алдан исәпләп торганда, өч ел вакыт бик озак булып тоелса да, дөнья мәшәкатенә муеннан кереп чумгач, сизелми дә уза икән. Ул еллар хәзер инде төштә күргән кебек кенә. Галимнәрнең һәр тәгълиматын хәрефен-хәрефкә кабул итеп, күңелгә сеңдерергә тырышып йөргән чаклар! «Чәчүлек җирнең һәр гектарына фәлән хәтле ашлама кертсәң...» «Һәр гектар җиргә нисбәтән фәлән баш терлек асрасаң...» бары да яхшы булырга тиеш. Колхозга кайтып, шул әзер кагыйдәләр буенча гына эшләп кара — мең каршылыкка очрап, маңгаеңны ярыр хәлгә җитәсең. Иң кыены — китап кушканны үз мөмкинлекләреңә чамалау, үз җиреңә яраклаштыра белү икән аның! Галимнәр үзләренең өйрәтүләрендә безнең якларда июнь-июль айларында булырга тиешле явым-төшемне күздә тоталар. Ә менә табигать дигәнең бер генә тамчы да яңгыр бирмәсә?!.

Инсаф рәт-рәт булып тигез генә шытып чыккан, ләкин дымга сусап, хәлсезләнгән арышлар арасында утыра. Игеннәрне мондый хәлдән коткару өчен берни дә эшли алмавына ачуы килеп, бармакларын җиргә батырып, учына туфрак ала. Комга әйләнгән кайнар туфрак кулны көйдерер төсле.

Хуҗалыкны ышанычлы нигезгә бастырырга файдасы тияр дип күпме укыды, күпме тырышты председатель. Махсус курсларны тәмамлап кайткач, аңа берсеннән-берсе җаваплырак вазифалар йөкләделәр. Бу тормышта бер мәшәкать икенчесен тартып китерә. Инде анысын да җиңеп чыксаң: «Әһә, моның көче җитәрлек икән әле!» —

дип, сиңа тагын да авыррак бурыч йөклиләр. Дөрес, аяк терәп баш тартсаң, я булмаса берәр эшне ярты юлда калдырып үтсәң, икенчесен ышанып кушмаслар иде. Юк, ир-егет горурлыгы Инсафка артка чигәргә ирек бирми. Киресенчә, ничек кенә булса да заманадан артка калмаска иде!

Инсаф Камалетдинов тагын уку турында уйлана башлый. Моны елдан-ел катлаулана барган хуҗалык эшләре үзе көн тәртибенә китереп бастыра. Җирне дә, мал-туар затларын да колхозга файдалы итү өчен белем кирәк. Агрономнарыңнан, зоотехникларыңнан, бригадирларыңнан эш таләп итү өчен иң элек үзеңә белергә кирәк. Димәк, туктаусыз өйрәнергә һәм укырга!

Хакыйкатьне аңлау бер хәл, ә менә аның тайпылмас законына үзеңне буйсындыру — монысы инде икенче нәрсә. Авыл хуҗалыгы институтын тәмамламыйча, колхоз белән идарә итүнең кыенлаша баруын бик яхшы аңлый Инсаф. Әмма ул йөкне иңбашыңа ничек итеп күтәреп салмак кирәк? Моеннан эш, өй тулы бала-чага, хатын, әни карчык...

— Клара, миңа читтән торып кына булса да тагын укымый ярамас...

Хатын сүзнең уйланмый гына әйтелмәгәнен яхшы белә. Шуңа күрә мондый чакта ул җавапны да тиктомалдан гына бирергә ашыкмый.

— Миңа әйтмә, әнә, улларыңнан сора! — Хатын Инсафны нәрсә белән «йөгәнләп» калырга мөмкин икәнен чамалый. — Алар ни дисә, шул булыр!

Ә балалар әле ни генә аңларлык соң?! Шулай да олы уллары Давыт эти белән әни арасында куерып килгән болытны таратырдай сүз тапкандай әйтеп куя:

— Эти, китапларың миңа булыр, яме! Мәктәпне бетергәч, мин дә шул син укыган җиргә китәм, мин дә председатель булам.

Инсаф мәсьәләне шуның белән хәл кылынган дип кабул итте, сүзне улы кузгаткан икенче якка борды.

— Укуын укырсың, улым, тик председатель булу өчен институтта уку гына җитми әле.

— Тагын ни кирәк соң, эти?

— Үс әле, үс, белерсең! Халык алдында имтихан тот, аннары бөтенесен төшенерсең. Сынатмасаң, председатель итеп тә сайларлар.

Ата белән малай үзара аңлашканда, Клара, иренең аркасына борынын төртеп, сүзсез калды. Иреннәрендәге елмаюын да, күзендәге яшь бөртекләрен дә күрсәтәсе килмәде аның. Балалар бераз тернәкләнгәч, аның үзенең дә җиң сызганып эшләп йөрисе килгән иде бит! Аларның берсе аякка басып өлгерми, тагын да матуррагы, сөйкемлерәге дөньяга килә. Һәркайсына әни кирәк, наз кирәк. Бишектәгесен әйткән дә юк. Аны сөйгәндә, имән баганасыдай Инсаф үзе дә вакыт-вакыт сабый балага әйләнеп кала. Йөзең караңгыланганны да, кәефсезләнеп йөрүеңне дә һич яратмый...

Институтны тәмамлар алдыннан гына Инсаф Камалетдиновка «Таулар» колхозын тапшырдылар. Гаилә Уразай авылына күченде. Әкиятләрдә генә сурәтләнә торган гаҗәеп матурлыкка ия авыл бу: таулары да, басуы да, көтүлекләре дә, урманы да үзендә.

Колхоз, чыннан да, бик рәхәт, бик мул яши. Ел саен байлык өстенә байлык өстәлеп тора. Мал-туар, кош-корт меңәрләп исәпләнә. «Таулар» — Актанышның көлсу туфраклы колхозлары арасында иң зур уңыш бирә торган хуҗалык. Һәр басуның «холкын өйрәнеп», кайсына нинди «ярдәм» кирәген аңлап, фәнни нигездә эшләү нәти-

җәсе бу. Моны председатель үзе дә, агрономнар да, зоотехник һәм бригадирлар да тирәнтен аңлый. Колхозда яшьләрне укытуга, белемле җитәкчеләр хәзерләүгә күп көч куела. Яшьләр үсә. Колхоз идарәсе аларны, үзе стипендия биреп, махсус уку йортларында укыта. «Укысыннар, үссеннәр! Колхоз ярдәмендә кеше булып чыксалар, авылны онытмаслар». Яшьләрне авылда калдыру өчен председатель төрле чаралар эзли. Егетләр армиягә киткәндә, аларны озатуга багышланган тантаналы кичәләр оештырыла, бүләкләр тапшырыла, акыллы киңәшләр әйтелә. Егет, хәрби хезмәтен тутырып, туган авылына кайту белән колхоз идарәсе аны тагын үз канаты астына ала: өйләнәм диючесенә өй салып бирә, укырга китәргә теләгәненә дә юл ачык, тәвәккәллә генә!

Бу колхозга берләшкән биш авылның һәркайсында клуб, Шәрип, Уразай, Куян авылларында өч йөз иллешәр урынлы культура сарае бар. Авыл җирендә яшәргә теләгән кешегә «Таулар»дан да кулайрак колхоз юктыр кебек. Биредә хезмәт тә елдан-ел җиңелләшә. Фермалар өр-яңа, һәркайсы механикалаштырылган, хезмәт хакы акчалата айныкы-айга түләнеп барыла. Күз җиттеме, колхозның әле бер авылында, әле икенчесендә туйлар башлана. Председательне мәҗлесләрнең төрлесенә: колхоз ярдәмендә җиткерелгән өй котлавына да, бәби тугач та, ике яшьнең яңа тормыш башлап җибәрүенә багышланган бәйрәм табынына да беренче итеп чакыралар. Аларның һәрберсендә утырырга ничек өлгерәсең?! Шулай да яшьләр туена кереп чыгарга, мәҗлесне ачып җибәрергә бармый калмый ул. Бердән, сүзләрен кире кага алмый, икенчедән, гаилә корырга җыенучыларның күңелен күрми дә ярамый. Юктан гына кәефләре кырылуы мөмкин. Кечкенә генә авылда гөрләтеп яшәргә мөмкин икәнне тагын бер мәртәбә раслап алуның зыяны тимәс.

Кешелеккә генә тотыла торган кримплен костюмын киеп, иң «модный» галстугын буып, калын табанлы ботинканы ялтыратып, Клара җиңгәләрен иплән кенә култыклап, туй буласы өйгә килеп керә ул. Табындагыларның йөзләре тагын да яктырып китә. Өлкәннәр, Инсаф улым, дип киңәш-табыш итәргә тотына. Яшьләр председательнең күкрәк турына күрсәтеп, үзара ымлашып алалар, карап кал, янәсе. Сугышчан бүләкләре дә җитәрлек аның, колхоздагы хезмәте өчен бирелгән Хезмәт Кызыл Байрагы ордены да ялт-йолт итеп тора. Акылың булса, үзең фикер йөрт: гомерен авылга багышлаган ир-егетне халык, ил әнә ничек зурлаган! Ә председательнең үзеннән беркайчан да яңгыравыклы сүзләр ишетмәссең, андый сүзләрне ул доклад-фәлән ясаганда да кыстырмый, монда, туй мәҗлесендә исә бигрәк тә. Монда ул яшь гаиләгә матур-матур теләкләр юллый, гармунчы арыса, аны да алыштыра. Яшь чагыннан гармуннарның төрлесен сыздырып үскән, яраткан гармунын Вараксин агаеңның үзеннән килеп алган, егет чагын «гармунчы Инсаф» дигән исем белән үткәргән. Бию түгәрәгенең дә уртасына керә. Авылда әйтелә торган иң гади такмакка да тыпырдата, кирәк тапса, яшьләр «шаукымы»на бирелеп китеп, «твист»ны да бик килештереп бии. Иң яратканы — җыр. Баянчылар белеп торалар: аны җырлатасылары килсә, «Туган авылым»ны сыздырып җибәрәләр. Инсаф әллә каян, күңеленең иң-иң түреннән чыккан моң белән җырларга тотына.

...Туган авылым минем, куеныңда синең
Шаулап үтте яшьлек елларым...

«Таулар»ның бүгенге муллыгына ничек ирештең?» — дип сорасалар, председатель, мөгаен, хуҗалык эшләренә бәйле мең мәшәкатьнең берсен дә телгә алмас, озак кына дәшми торыр да:

— Кешеләр бик әйбәт бит монда! — дип куяр.

Ә берсеннән-берсе четереклерәк холыклы ул кешеләр белән ничек уртак тел тапканын хәзер ул үзе дә сөйләп бирә алмас. Беренче елларда аптырап калган чаклары аз булмаган аның. Әйтик, өлкән генә яшьтәге агай килә дә:

— Инсаф энекәш, әйт әле хисапчыга, ике-өч тәңкә язып бирсенче! — ди.

— Була ул, агай! — ди председатель. — Олы кешенең болай вакланyын килештереп бетерми, хисапчы кызга әйтә: — Сеңел, абыеңа илле-алтмыш сум язып тор, ай азагында исәпләрбез!

Ә менә шушындый мөнәсәбәт ярап куйды. Бераздан вакытлы-вакытсыз акча сораучылар, эчкән килеш идарәгә килүчеләр күренмәс булды. Хәзер авыл кешеләре белән председатель арасында нык татулык хөкем сөрә. Колхоздагы муллыкның да төп чыганагы — әнә шул дустанә мөнәсәбәт.

Уңыш яулап алуда алга баскач, терлекчелектәге кыенлыклар үзеннән-үзе артка чигәр, дип уйлаганнар иде дә, алай килеп чыкмады. Шактый озак баш ватырга туры килде Инсафка. Азык мәсьәләсен хәл итүдә фән кешеләренең ярдәме кирәклеген эчке бер сиземләү белән тоя иде ул. Бервакыт Инсаф авылга кайткан университет галиме Айрат Габидовский белән сөйләшеп утырды.

— Кышка керсәң, язга кадәр азык җитәрме-юкмы, дип дер калтырап яшибез. Ничек кенә менә шул хәлдән котыласы?! — дип, сүзне Инсаф үзе башлап җибәрде.

Айрат, әлбәттә, Инсаф абыйсының мондый олы сүзне бер дә юктан гына башламасын белә. Ялгап алып китү өчен:

— Ни җитми соң сезгә? — дип сораган булды.

— Беләсеңме, энекәш, минемчә, иң ышанычлы азык — печән оны. Силосы, бәрәңгесе-чөгендере, саламы-башагы аның янына кушып ашатырга шәп...

— Аңладым мин сине, Инсаф абый, син үз колхозыңда печән оны тарттырырдай җайланма булдырырга чамалыйсың.

— Нindirәк булачагын да чамалыйм, материалын да табам, төгәл итеп ясалган сызымнар кирәк!..

Шул көннән башлап, Казан дәүләт университетының физика факультеты галимнәре белән Актаныш районының «Таулар» колхозы арасында эшлекле элемтә урнашты. Печән киптереп тарттыручы агрегат ясау фикере Айрат Габидовскийны да, молекуляр физика кафедрасы доценты Владимир Николаевич Подымовны да мавыктырды. Эзләнүләр, тәҗрибәләр башланды.

Республика колхоз председательләре Казанда еш булалар. Алар бергә җыелган көннәрдә башкаланың үзәк кунак йорты үзара гәпләшүдән шау итеп тора. Бер-берләренең бүлмәләренә кереп чыгып йөриләр, шәһәрдәге дус-ишләрен искә төшереп кайталар, бәхәсләшәләр, көлешәләр. Инсаф Камалетдинов бүлмәсе исә фәнни лабораториягә әйләнә: сызымнар, исәп-хисап, тәкъдимнәр. Монда яңа фәнни ачыш бөреләнә. Председатель хыялында туган агрегат инде галимнәргә тынгылык бирми. Аларның сызымы буенча колхозда төзелеш бара. Доцент Подымов:

— Сынарга үзем дә киләм, — дип ашкынып тора. — Зинһар ашыктырмагыз гына, Инсаф Заһертдинович, бергәләп эшләтә башларбыз! Ярыймы?!

Председательгә нәкъ менә шул — галимнәрнең үз кызыксынулары уяту кирәк тә. Алар янында булса, ышаныч күбрәк, килеп җитмәгән төшен үз күзләре белән күрсеннәр, төзәтүе җиңелрәк булыр.

— Әлбәттә, әлбәттә! — ди ул. — Төзелеш түгәрәкләнүгә, мин шундук хәбәр итәрмен.

— Сезнең бу идеяләрегезне кандидатлык диссертациясе итеп теркәргә мөмкин! — Подымов, гадәтенчә, галимнәр үстерүне дә читкә куймый. — Фәндә иң кирәклесе — идея, Инсаф Заһретдинович. Исәп-хисапны гына машиналар да ясап бирәләр хәзер, идеясе кыйммәт, идеясе!

— Сабыр итәек әле! — ди председатель. — Кирәксә, колхоз хуҗалыгында мондый идеяләр шактый. Әйтик, бу агрегат эшли дә башлады, ди. Аның сәгатенә ике-өч кенә тонна он тарттыруы замана темпларына бик үк туры килми бит, сез шуны чамаладыгызмы?..

Галимнәр бер-берсенә карашып алалар. «Менә сөйләшеп утыр син аның белән! Агрегат әле эшли дә башламаган, председатель инде аны ялкаулыкта ук гаепли!»

Инсаф уйларын галимнәрдән яшерергә теләми.

— Сезгә тизрәк диссертация яклау кирәктер, эшегез шуның белән бәйләнә, аңлыйм.— Ул сабыр гына сөйли дә сөйли.— Ә миңа колхозның сизелерлек файда күрүе кирәк. Бу агрегатны эшләтә башласак, икенчесенә, ашлык киптерә торган агрегат салуга тотыныр идек. Ясаган ясаган, анысын куәтлерәк итәсе иде. Колхоз саен завод корып булмас, күрше колхозлар ихтыяҗын да канәгатьләндерерлек итеп, тизрәк, күбрәк, яхшырак эшләсен иде, яхшырак! Табигатьнең «холкы бозылган» чакта килсеннәр дә киптерсеннәр! Колхозга бераз табыш та керер!..

— Ә аннары, аннары? — Галимнәр председательнең сүзләрен кызыксынып тыңлыйлар.

— Аннарымы? — Тегеләрнең шаяртырга теләвен аңлап, Инсаф та елмая. — Аннары мин дә диссертация якларга тотынырмын, менә шул! Нигә, хәзер фәннәр кандидаты булган председательләр күп ул. Әнә, Балтик буе республикаларында...

Уйлары да, эшләре дә саллы аның: «Булган икән, олыдан булсын!» Ике-өч көннән әһәмияте бетә торган эш артыннан эштер-өштер генә йөрүне вакытны әрәмгә уздыру дип кенә саный ул. «Заманасы ул түгел. Эшлисең икән, синнән соң килгәннәргә дә рәхәт китерерлек файда калсын!»

Бу хакыйкатьне һәркем белә белүен, тик иская генә алып бетермиләр. Аннары әле икенче буынга калдырырлык эш башкарырга иртәрәк кебек тоела. Башта үзебез өчен яшик, картая башлагач, күз күрер, дигән фикер тынычландырып тора. Ә, инде картаям бит, диярgә тел әйләнми. Гомернең өзлексез алга үрләп торуын Инсафның да һич сизәсе килми, әмма моңа күз йомып калырга да мөмкин түгел. Чәчләрнең агарып китүен сизмәмешкә дә салышыр идең әле — хәзер аны унсигез яшьлек кызлар юри дә чалартып йөриләр. Менә Давытның әзмәвердәй ир булып җитүен күреп, аптырыйсың да каласың! Әле кайчан гына туган иде бит, Клара белән Инсаф әле кайчан гына, карале, без дә әти белән әни булдыкмыни инде?! — диеп сөенешкәннәр иде. Хәзер Давыт — үзе әти.

Давыт, Давыт! Үсеп тә җитте, әтисе укыган институтны да тәмамлады, агроном булып та эшләде, инде хәзер үзен Актаныштагы 12нче авыл хуҗалыгы училищесына мөдир итеп билгеләгәннәр. Минем улым бу, дисәң, кеше ышанмас. Сабан туйларында мәйдан тота!

Әле бер Давыты гына шундый булса, олыгаеп калуыңны ул кадәр үк тоймас та идең. Ул нәрсә, китсә — ерак, кайтса — кунак, дигәндәй. Якын бер дустыңдай күреп, кунак-кунак йөрешеп яшәргә дә була. Давыты артыннан, без дә аңардан калышмыйбыз, дигәндәй, эзгә-эз басып үсеп килүчеләре тагын бар. Гөлүс — армиядә, Рәмзия кияүгә чыкты, Әлфия Казанда укый... Барысының да шөгылен санап бетерә торган түгел, җыенысы ун бала бит ул. Теге чакта:

«Мәйданга барам, абый!» — дип, тарантас читенә менеп утырган «сеңелкәш» хәзер районның мактанычына әйләнде. «Безнең герой ана Клара Камалетдинова!» дип кенә йөртәләр үзен. Өендәге ун баланы тәрбияләү генә җитмәгән, «Таулар» колхозының балалар бакчасына эшкә кергән. Игезәкләре Рәшит белән Фәритне, төпчек кызы Гөлназны ала да һәр иртәдә бакчага ашыга.

Шулай итеп, айлар, еллар ага тора, ә күңелнең анда-монда эше юк, элеккедән болайрак гайрәтләнә, очына, талпына. Алда тагын да күңеллерәк икенче яшьлек бар сыман. Балалар да гел яшьлекне искә төшереп тора. Инде энә иң кечкенәсе — Гөлназы да мәктәпкә керү турында сөйләнә.

Юныс — хәзер йортта төп хуҗа. Эти кеше гел юлда булганга, ир-ат эшен аңа тапшыралар. Кече туганнары аның сүзеннән чыкмый. Кемгә кайчан уйнап алырга, нинди эшне кайчан үтәргә — бөтенесе Юныс кушуы буенча башкарыла.

Олы кызлар Казаннан хат кына җибәреп яталар. Әлфиясе:

— Эти, карале, Уразайда зуррак больница салып, аптека ачып булмасмы?! — дигән. — Училищедан соң шунда кайтып эшләр идем.

Баксаң, бөтенләй буш сүз түгел ләбаса. Идарә утырышында кузгатсаң, хуплаучылары да табылыр, мөгаен. Нигә, «Таулар» колхозының үз больницасы, үз врачлары, үз фармацевтлары булса начармыни?!

Иң олы кызы Рәмзия Казан кешесе булды. «Эти, әни! Рөхсәт итсәгез, кияүгә чыкмакчы идем!..» — дип хат җибәрде. Озак та үтмәде, туй ясадылар. Аннары кияүдән чакыру килеп төште. «...Эти, миңа заводтан квартира бирделәр, өй туена килегез!»

Армиядән кайткач, Гөлүсе дә өйләнер. Әнә бит Давыт та инде ир уртасы булып килә. Очрашканда да гел эш, хуҗалык, гаилә турында сөйли. Өйрәткәнне бик үк өнәми. Райкомга йомыш белән баргач, хәл белергә дип аларга да сугылып чыккан иде Инсаф.

— Бер кайтып китегез, ичмаса. Гөлназ сагынды, әниегезнең дә күңеле булыр, — диде ул Давытка. Давытның моңа да җавабы әзер икән:

— Менә ялга чыгыйк инде, исәп юк түгел! Эш бит. Сагынуга карап кына өйне ташлап чыгып китеп булмый, эти, үзең беләсең.

...Белмәгән кая, белә Инсаф, барын да белеп тора. Тик шулай да кара юрга җигелгән тарантасына менеп утырып, басу юлына чыктыңмы, күңелне аңлатып бетерә алмаслык сөенеч биләп ала. Җылы яңгырдан соң мөлдерәп тулган иген кыры, баш очында чутылдап торган тургайлар, очсыз-кырыйсыз булып күренгән озын юл — һәммәсе җанны рәхәтләндерә. Уйлар яңадан яшьлеккә әйләнеп кайта. Гүя ул әнә, каршыда гына, күзеңне йомып кулыңны алга сузсаң, аның белән кабат очрашырсың сыман...

Зәки Әхмәтҗанов

# ЕЛЛАР ҮТКӘЧ



Кеше тормышында гомер буе онытылмый, истән чыкмый торган көннәр була. Бөек Ватан сугышының дәһшәтле көннәре безнең буын кешеләренең генә түгел, киләчәк буыннарның хәтерендә дә онытылмас легенда булып сакланыр. Сугышның мең газаплы авыр юлларын үткән һәр кеше кебек үк Сәлимә Гыйлаҗетдинова да ул көннәрне бик яхшы хәтерли.

...1942 елның апрель ае. Әгерҗе станциясе аша бер-бер артлы эшелоннар уза. Алар көнбатышка — фронтка ашыгалар.

Ике дус кыз, Сәлимә белән Гарифә, станциягә килеп, еш кына шул эшелоннарга карап торалар. Перрондагы кешеләргә кушылып: «Исән-имин җиңеп кайтыгыз, егетләр»,— дип, эшелондагыларны кул болгап озатып калалар.

Яралы сугышчылар төялгән поезд килгәндә, халык мәш килеп ала. Олы яшьтәге агайлар һәм апалар, вагоннан-вагонга йөгереп, үзләренең туганнарын, улларын эзлиләр. Яралыларга сөт, пешкән бәрәңге, тозлы кыяр кебек ризыклар сузалар, фронт хәлләрен сорашалар. Әмма куанычлы хәбәрләр килми ул көннәрдә.

Мәскәү янында тар-мар ителгәннән соң, фашистлар, һичнинди югалтулар белән исәпләшмичә, Кавказга, Иделгә омтылдылар.

— Күрдеңме, Гарифә, — диде Сәлимә, көннәрнең берендә ахирәтенең күзләренә карап,— безнең кебек яшь кенә кызлар яралыларны сугыш кырыннан алып чыгалар, аларга беренче ярдәмне күрсәтәләр. Ә безнең кай җиребез алардан ким?

...1942 елның 3 мае. Чалт аяз, матур көн. Перрон фронтка китүче яшьләр, аларны озатучылар белән тулган. Китүчеләр арасында Әгерҗе кызлары Сәлимә Гыйлаҗетдинова, Гарифә Ваһапова, Наилә Габдиева һәм башка авыллардан тагын биш кыз да бар. Менә саубуллашу минутлары килеп җитә. Бу якларда беренче колхозлар оештырып йөргән коммунист, Сәлимәнең әтисе Мулланур абзый кызларга соңгы наказларын әйтә.

Паровоз озын гына итеп кычкырта да, вагоннар өстенә күе кара төтен юрганы җәеп, акрын гына кузгала. Бераздан, берсен-берсе этәтөртә, вагоннар яныннан йөгерүче озатучылар да туктап кала.

— Ничава, карчык, кайгырма, — ди Мулланур абзый, яулык чите белән күзләрен сөртә-сөртә янында атлаучы Нәсимә апаны тынычландырырга тырышып...

Мәскәүдә кызларга өр-яңа киемнәр бирделәр. Сәлимә белән Гарифә, Наилә белән башкорт кызы Фатыйма Таймасова 95 нче аерым элемтә полкына билгеләнде. Кызларның сугышчан юлы әнә шул полкта башланып китте.

Сугышта элемтә... Әйе, элемтә — ул фронтның нервлары дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр. Бер-берләреннән йөзләрчә километрларда урнашкан хәрби берләшмәләр, армия, корпус, дивизияләр арасында ныклы, ышанычлы элемтә булдыру яшь кызлар өчен җиңел эш түгел иде, әлбәттә. Пулялар сызгыруы, мина, снарядлар шартлавы астында әледән-әле өзелгән элемтә чыбыкларын ялгарга туры килде аларга. Командование белән һөҗүм итүче частьлар арасында өзлексез элемтә булдыру өчен урман-сазлыклар, күп санлы елгалар кичәргә туры килде.

Сугышның һәр көне күп корбаннар сорый. 1943 елның җәендә Сәлимә дә яшьлек дусты Гарифә белән мәңгегә саубуллашты.

Солдат киеме кигәч үк дуслашып алган башкорт кызы Фатыйма Таймасова белән Сәлимә бу фаҗигане бик-бик авыр кичерделәр.

— Һич уйламаганда-көтмәгәндә һәлак булды шул Гарифә, — дип сөйли хәзер Сәлимә. — Май аеның кояшлы матур бер көнендә төшке ашка кузгалак җыярга дип бишәүләп урманга киттеләр. Шунда немецлар минасына эләгеп һәлак булдылар...

— Шатлыклы очрашулар да булгалый иде фронтта, — дип сөйли Сәлимә.— 1943 елның җәе иде. Көн кичкә авышып бара. Фатыйма, Наилә, яңа гына дежурдан кайткан тагын берничә кыз, землянкада утырабыз. Кайсыбыз хат яза, кайсыбыз китап укый. Ә без — Фатыйма, Наилә һәм мин — туган якларны искә төшереп, акрын гына «Сагыну» көен сузабыз. Шул чак кинәт землянканың ишеге ачылып китте һәм татарча: «Исәннәрмесез, кызлар», — дигән ирләр тавышы ишетелде. Гаҗәпләнеп ишеккә таба борылдык. Безнең каршыбызда пөхтә генә киенгән, каешларын иң өсләреннән үткәреп, уң ягына пистолет, сул ягына кыр сумкасы таккан яшь кенә ефрейтор басып тора иде.

— Комачауладым, ахры, — диде ул, ягымлы тавыш белән.

— Юк, юк, иптәш ефрейтор, — дидек без беравыздан. — Әйдәгез, түрдән узыгыз, безнең смена ял итә бүген.

— Алай булгач бигрәк тә яхшы, — диде ефрейтор һәм өстәл кырындагы патрон тартмасы өстенә килеп утырды. Аннары землянкабызга күз йөртеп чыкты да:

— Таныш булыйк, кызлар, мин фронт газетасыннан Шәрәф Мөдәррис дигән кеше булам, — дип өстәде.

— Без мәктәптә укыган чагында ук «Яшь ленинчы» һәм «Пионер каләме»ндә шигырьләр бастырган Шәрәф Мөдәррис сез буласызмы инде?

— Әйе, нәкъ үзе.

— Ничек инде, язучыларны да сугышка алалармыни?

— Нишләп алмасыннар, ди. Ил өстендә шундый давыл ажгырганда язучылар бер читтә кала алмый, кызлар. Татарстан язучыларының күбесе хәзер хәрәкәттәге армиядә, алгы сызыкта сугыша.

— Ә бирегә, безнең янга ничек килеп чыгасы иттегез?

— Газетага материал туплау өчен. Башта Армия штабына килергә әйтелде. Анда генерал Чанышев белән очраштык. Ул минем татар шагыйре икәнемне белгәч: «Бик шәп булды әле бу, минем монда бик яхшы элемтәче татар кызларым бар, шулар турында язарга кирәк»,— дип, сезнең янызгыза җибәрде.

Аннан Шәрәф Мөдәррис безгә күп кенә сораулар бирде, һәркайсыбыз белән аерым-аерым да сөйләшеп чыкты. Безнең сөйләгәннәрне куен дәфтәренә терки барды.

— Булды, кызлар, — диде ул соңыннан, пилоткасын кия-кия. — Үзегез турында берничә көннән соң фронт газетасында укырсыз, ә соңрак «Кызыл Татарстан» газетасыннан туганнарыгыз да укыр. Сезнең кебек батыр кызлары белән бөтен татар халкы горурланырга хаклы. Әйе, бик хаклы.

Кунагыбыз шулай диде дә ишеккә борылды. Без утырган урыннарыбыздан дәррәү сикереп тордык.

— Юк инде, якташ, язучы булсагыз да, аштан олы булырга ярамый, — дип, аны өстәл янына кыстарга керештек.

Шәрәфнең: «Караңгы төште, кызлар, соңга калам ич», — дип әйтүенә каршы да кызларның җавабы әзер иде. Арадан кайсыдыр: «Курыксагыз, үзебез озатып куярбыз», — диде шаяртып.

Шәрәф килеште. Яңадан урынына барып утырды. Наилә снаряд гильзасыннан ясалган сукыр лампаны кабызды. Землянка эченә, бензин исе чыгарып, саргылт-кызыл яктылык таралды.

Солдатлар «шрапнель» дип атаган арпа боткасы һәм чәй китерелде. Алгы сызыкта снаряд, миналар шартлавы көчәйде, моторлар гүләве ишетелде: самолетлар алгы сызыкка «төнге эшкә» юл тоттылар...

Шагыйребез дә күп рәхмәтләр әйтеп, безнең белән саубуллашты.

...Берничә көннән генерал Берзарин командалыгындагы 34 нче Армия сугышчылары фронт газетасыннан үзләре арасында шундый кыю татар кызлары булуы турында укыдылар. Аннары алар батырлыгына багышланып «Кызыл Татарстан» газетасында да Шәрәф Мөдәррис язган зур гына очерк басылып чыкты.

Бу күңелле очрашудан соң күп тә үтмәде, кызлар тормышында тагын бер онытылмас вакыйга булды.

...Сәлимә Армия штабының элемтә бүлмәсендә аппарат каршында утыра иде. Аның бөтен игътибары аппаратка юнәлгән. Төрле төстәге сигнал лампалары бер-бер артлы кабынып тора. Фронт штабы Армия штабына төрле күрсәтмәләр бирә, Армия штабы корпус, дивизияләр белән, дивизияләр исә бригада, полклар белән сөйләшә. Аларны һич тоткарлыксыз бер-берсе белән тоташтырып торырга, һәр җөмләнең, һәр сүзнең ачык ишетелүен тәэмин итәргә кирәк.

Менә Сәлимә наушнигын салды да тир бөрчекләре бәреп чыккан маңгаен, битен сөртеп алды.. Тагын звонок. Кыз, ашыгып, наушнигын тагын киде. Бу юлы ул: «Исәнмесез, кызлар, ни хәлләрегез бар?» — дигән саф татарча сүзләр ишетте.

Сәлимә шунда тавышыннан ук Армия командующие урынбасары генерал-лейтенант Якуб Чанышевны таныды. Татар кызларын ул, гадәтенчә, минем кызлар дип йөри, очраган саен аларның хәл-әхвәлләрен сораша иде.

— Хәлләр әйбәт, иптәш генерал, бер көе эшләп ятабыз, — дип җавап бирде Сәлимә.— Хәлебезне белешеп торуыгыз өчен рәхмәт сезгә.

— Алай булгач, сүзне озакка сузмыйк, кызым,— диде генерал.— Бүгенге сменагыз бетү белән барыгыз да җыелып Армия штабына, минем күзәтү пунктына килегез.

— Ничек барыбыз да, иптәш генерал?
— Мин татар кызларын күздә тотып әйтәм. Сезнең сменада гел Казан'кызлары гына эшли бит?
— Әйе, иптәш генерал.
— Менә шул, кызым, сәгать дүрттә машина сезнең янда булачак.

Сәгать икедә сменасын тапшырып, Сәлимә үзләренең землянкаларына ашыкты. Землянка эчендә ыгы-зыгы башланды. Кызларның кайсы гимнастерка-юбкасын үтүкләргә, кайсы чәчен-башын рәтләргә, кайсы кирза итекләрен ялтыратырга тиеш. Һәрберсе шулай үз эше белән мавыгып, землянканың ишек төбенә сержант-шофер килеп басканын да сизми калдылар алар. Сержант ачык ишектән бераз вакыт карап торды да:

— Я, кызлар, күпме көтәргә була сезне, театрга җыенмыйсыздыр ич, — дип көлеп куйды. — Генерал көтә, җәһәтрәк булыгыз...

Берничә минуттан машина, снаряд һәм мина ярчыкларыннан теткәләнеп-сынып беткән куаклыкларга сыена-сыена, Армия штабына таба чаба иде. Ярты сәгать чамасы баргач, машина куаклыкның куерак урынында туктады.

— Булды, кызлар, машина белән шушыннан ары барырга ярамый, — диде шофер. — Хәзер җәяүләп китәбез.

Генерал землянкасы... Өсте өч кат юан бүрәнә һәм туфрак белән түшәлгән шактый зур бүлмә. Түрдә, телефон аппаратлары тезелгән кечерәк өстәл артында, элемтәче кыз утыра. Бүлмә уртасындагы озын өстәлгә җәеп салынган карта өстенә иелгән генерал, кызлар керүгә, карандашын куеп, аларга таба юнәлде.

— Әйдәгез, кызлар, рәхим итегез, — диде ул елмаеп. Аннары кызларның һәркайсы белән кул биреп күрешеп чыкты һәм өстәл янындагы утыргычларга күрсәтте. Кызлар кыймыйча гына өстәл кырына утырыштылар.

Исеме авылда чакта ук, мәктәптә укыганда ук таныш булган, үзенең бөтен тормышын илгә хезмәт итүгә багышлаган генерал егерме-егерме бер яшьлек солдат кызларның һәркайсыннан өйдәге тормышлары, аннан килгән хатларданиләр язулары турында сорашты.

— Фронт газетасыннан Шәрәф Мөдәррииснең сезнең хакта язган мәкаләсен бик шатланып укыдым, кызлар, — диде генерал.— Рәхмәт сезгә, ил каршындагы бурычыгызны намус белән үтисез. Ул мәкалә Армия командующие генерал Берзарингә да бик ошады.

Генералның шул сүзләрне әйтеп бетергәнен генә көтеп торган кебек, землянка өстеннән дошман ягына авыр снарядлар сызгырып үтте. Берничә секундтан аларның еракта һәм якында гөрселдәп шартлаулары ишетелде. Күп тә үтмәде, кызыл йолдызлы истребительләр озата барган бер төркем «Илюшин»нар очып узды.

Генерал һәм кызлар, землянкадан чыгып, аларны күздән югалганчы карап тордылар. Аннан соң кабат землянкага кереп бик тәмләп чәй эчтеләр. 1917 елның октябрендә Казанда Совет властен урнаштыруда актив катнашкан, Беренче Идел буе татар укчы бригадасының хәрби комиссары булып ак казакларга, Дутов, Колчак бандаларына һәм басмачыларга каршы сугышчыларга җитәкчелек иткән генералның төрле батырлык эпизодлары турында сөйләвен кызлар кызыксынып, онытылып тыңладылар. Татар хатын-кызларыннан беренче булып, М. И. Калининның үз кулыннан Сугышчан Кызыл Байрак орденнары алган бертуган сеңелләр — шәфкать туташлары Мәрьям һәм Әйшәнең Оренбург далаларындагы батырлыклары ту-

рындагы истәлекләр кызлар күңеленә һичбер кайчан онытылмас сәхифә булып уелып калды.

Штаб машинасы кызларны үз землянкаларына китереп җиткергәндә инде караңгы төшкән, аяз күктә йолдызлар җемелди иде.

Еллар үтте. 1972 елның яз башларында Сәлимәгә Фатыйма Таймасовадан хат килеп төште. Ул күп еллар күрмәгән дустын бик сагынуы, аны бик-бик күрәсе килүе турында язган.

Һәм менә күптән көтелгән көн. Дүрт ел буе күп тапкырлар үлем белән күзгә-күз очрашып, иксез-чиксез авырлыкларны бергә кичергән, дуслыклары окопларда чыныккан полкташ кызлар Таганрог вокзалы перронында очраштылар. Фатыйма Сәлимәне курорттан кайтканда шунда каршы алды.

Үткән юлларны, үткән елларны, булган үзгәрешләрне искә төшереп, алар ике тәүлек буена бергә булып, бергә йөреп үткәрделәр. Икесенең дә чәчләренә чал үрмәли башлаган. Сәлимәдән аерылгач, Фатыйма белән Иван, икесе дә бер үк заводта эшләп, матур гына тормыш корганнар икән. Ике кыз үстергәннәр... КПССның Әгерҗе район комитеты пропаганда бүлегендә эшләүче Сәлимә Гыйлаҗетдинова (Галләмова) тормышында да үзгәрешләр шактый күп: кызы Светлана, техникум тәмамлап, Ленинград текстиль туку фабрикасында эшли. Улы Илдар Ижевск шәһәрендә механика институтында укый.

Бу ике коммунист хатын хәзер дә тормышның алгы сызыгында атлыйлар.

Леон Небенцаль

# ҖӘЛИЛ РУХЫ

Берничә көн генә элек дөнья халкының игътибары Кремльнең якут йолдызларына юнәлгән иде, анда КПССның XXV съезды булып үтте. Съезд тугызынчы бишьеллыкка йомгак ясады, илнең коммунизмга таба үсеш юлын билгеләде һәм бер совет халкының бүгенгесе, киләчәге өчен генә түгел, ә бәлки бөтен дөнья язмышы, уртак революцион эшләребез өчен зур әһәмияткә ия булган карарлар кабул итте.

Партияле журналист буларак, мин съездга хәзерлекне һәм аның эшен игътибар белән күзәтеп тордым, аның материалларын — революцион тәҗрибәнең коммунистларны, җир йөзенең барлык прогрессив кешеләрен идея байлыгы белән коралландырган бу хәзинәсен җентекләп өйрәндем.

Әмма шулай да, герой шагыйрь Муса Җәлилне яратучы кеше һәм татар халкының якын дусты буларак, мин Татарстан республикасының казанышларына һәм үсеш перспективаларына кагылышлы нәрсәләрнең һәммәсен:

— кирәк төзүчеләрнең һәм монтажчыларның, конструкторларның һәм проектчыларның 120 меңлек коллективы катнашкан КамАЗ төзелеше булсын;

— кирәк Түбән Кама комбинатының таң калырлык бурычлары һәм перспективалары булсын;

— кирәк Чаллы кебек 230 мең кешелек яңа шәһәрләрнең үсеп чыгуы булсын;

— кирәк Советлар Союзын нефть җитештерүнең күләме ягыннан дөньяда алдынгы урынга чыгару эшенә зур өлеш керткән Татарстан нефтьчеләренең гүзәл уңышлары булсын — барысын да аерым бер канәгатьләнү белән укыдым.

Шуларның һәммәсе хакында укыганда, мин еш кына Муса Җәлил хакында уйландым. Инде өлкән яшьтә булса да, ул халкының өлеге казанышларын үз күзләре белән күрә алган булыр иде, дип уйладым. Әйе, күрә алган булыр иде, әгәр аның гомерен утыз елдан артык элек фашист палачлары вакытсыз һәм фаҗигале төстә өзмәгән булса...

Мусага безнең көннәргә кадәр яшәү насыйп булмый, әмма ул үз халкының якты, бәхетле киләчәген алдан күрә һәм алдан хәбәр итә, хәтта, үлемгә хөкем ителеп, фашист төрмәсендә утырганда да алдан күрә... «Моабит дәфтәре»ндәге күп кенә шигырьләр сугышта совет халкының җиңеп чыгачагына тирән ышану хисе белән сугарылган. Тагын шул кадәресе гаҗәп, Җәлил җиңү хакында тормышка ашкан реаль факт кебек яза. Һәм безне шул нәрсә таңга калдыра, ул сугыштан соң совет халкыннан яңа героик тырышлык соралачагын алдан күрә, илнең якты киләчәгенә чиксез ышана.

Муса, билгеле, мистик мәгънәдәге «күрәзәче» дә, «пәйгамбәр» дә булмый. Ул бары чын марксист-ленинчыга хас тарихи оптимизм хисе белән сугарылган гади кеше була. Ахыр чиктә нәкъ шул оптимизм хисе аңарда алдынгы көчләрнең котылгысыз төстә реакцияне, фашизмны җиңәчәгенә ышаныч уята...

---

Мәскәү шәһәренең Колонналы залында Муса Җәлилнең 70 еллык бәйрәменә багышланган тантаналы кичәдә ясаган чыгыш.

«Алман илендә» исемле шигырендә Муса Җәлил немец халкының да җиңәчәген алдан күрә. Совет сугышчыларының фашизмны җиңүе һәм немец халкының антифашистик, прогрессив көчләренең көрәше нәтиҗәсендә Германия территориясендә эшче һәм крестьяннар дәүләте барлыкка килде. М. Җәлил хыялланганча, Алман җиренә социализм кояшы чыкты, Маркс, Гейне үз иленә әйләнеп кайтты.

1975 ел ахырында бу яңа дәүләтнең күренекле вәкилләре, дуслык, хезмәттәшлек һәм үзара ярдәмләшү турындагы килешүне яңарту, шул юл белән Советлар иле белән союзны ныгыту максатын күздә тотып, Советлар Союзында булып кайттылар. КПССның XXV съездында Германия социалистик бердәм партиясе Үзәк Комитетының беренче секретаре иптәш Эрих Хонеккер әйткәнчә, бу договор тыныч хезмәтнең, халкыбызның иминлеге һәм бәхетенең тормышчан нигезе булып тора һәм шулай булып калачак та.

Безнең хөкүмәт һәм партия делегациясе бу юлы Татарстанда да булды. Германия Демократик Республикасының Дәүләт Советы Председателенең урынбасары Генрих Хоман Казанда ясаган чыгышында: «Без авыр яралы килеш фашистлар тарафыннан әсир ителгән, лагерьга ябылган һәм нацист төрмәсендә һәлак ителгән татар шагыйрен, Советлар Союзы Герое һәм Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилне беркайчан да онытмабыз. Без шулай ук бөтен илләрдәге һәм бөтен милләтләрдәге фашизмга каршы көрәшкән кешеләрнең батырлыкларын беркайчан да онытмабыз»,— диде.

Германия Демократик Республикасы халкы исеменнән Генрих Хоман әнә шулай сөйләде.

Герой шагыйрь Муса Җәлил халыклар хәтеренә мәңге урнашты.

# ШАГЫЙРЬНЕҢ ДУСТЫ

Шушы көннәрдә мин Мәскәүдән кайттым, анда Муса Җәлилнең тууына 70 ел тулуга багышланган тантаналы кичәдә катнаштым. Шул кичәгә чакырган, анда чыгыш ясарга мөмкинлек биргән өчен, Язучылар союзына тирән рәхмәт белдерәм, моны үзем өчен зур хөрмәт саныйм. Мәскәүлеләрнең бу кичәгә ифрат зур әһәмият бирүе миндә тирән тәэсир калдырды. Союзлар йортының Колонналы залында бер генә буш урын калмаган, ишек төбендә, очраклы рәвештә билет табарга өметләнеп, йөзләгән кеше басып тора иде. Муса Совет халкының йөрәгендә яши икән, кичәдә шул сизелде... Бу кичәдә хөрмәтле Әминә ханым һәм Чулпан белән, Мусаның көрәштәшләре һәм җәлилчеләр белән очрашу бик күңелле булды. Мине алар белән герой шагыйрьнең иҗатын һәм батырлыгын ярату хисе, күпьеллык язышу, ә күбесе белән — мин моны кыю рәвештә әйтә алам — күпьеллык дуслык җепләре бәйли.

Шуңа да алар арасыннан иң зур хөрмәткә лаек кешенең әлеге тантанага килми калуы, хәзер инде беркайчан да килә алмаячагы миңа аеруча авыр тәэсир итте. Алар арасында шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын армый-талмый өйрәнүче, җәлилианага нигез салучы Гази Кашшаф, 1965 елдан, Казанга беренче тапкыр килгәннән бирле минем шәхси дустым булып киткән Гази Кашшаф юк иде.

Мәскәүдә миңа Җәлил шигырьләренең юбилейга чыгарылган яңа басмасын бүләк иттеләр, мин Мусаның шунда бирелгән хатының факсимилесен озаклап карап утырдым. Анда ул Кашшафны «иң эчкерсез, иң якын һәм игътибарлы дустым» дип атый. Ул Мусаның үзенең генә түгел, аның бөтен иҗатының да шундый ук дусты булды һәм шулай булып кала да. Ул авыр елларда да, шулай ук үлемнән соң Мусаның даны шаулаган елларда да аның дусты булып калды.

Әлеге юбилей басмасы Кашшаф башкарган соңгы эшләрнең берсе булып калды, юбилей белән бәйле күп мәсьәләләрне хәл итү юлында армый-талмый эшләп йөргәндә үлем аны безнең арадан тартып алды. Ул Муса Җәлилнең 70 еллыгына хәтле дә, үзенең 70 яшенә хәтле дә яши алмады — 15 апрельдә аңа 69 яшь тулачак иде...

Әйдә, бу язма Мусаның якты истәлеген, аның иҗатын мәңгеләштерү юлында башкарган эшләре өчен, шундый чын дус булганы өчен, Гази Кашшафка рәхмәт белдерергә бер сәбәп булсын.

**2 апрель, 1976 ел, Берлин.**

# СОРЫ ПЛИТӘЛӘРДӘ АЛ КАН ТАПЛАРЫ

Кыйгачлатып яуган җепшек кар тәрәзә пыялаларына сылана. Тәгәрмәчләр сыек измәгә әйләнгән балчыкны як-якка чәчрәтәләр. Вакыт әле бик иртә булуга да карамастан, каршыга килүче машиналарның күбесе өстәмә фараларын кабызганнар. Урамның ике ягы буйлап бер-берләренә тыгыз кысылып утырган коңгырт-сары төстәге биек йортлар тезелеп киткән. Без әйтерсең лә караңгы, тирән тарлавык төбеннән барабыз.

— Һава шартларына килгәндә, Берлин өчен гадәти күренеш, — ди мине озатып йөрүче юлдашым, Германия Демократик Республикасындагы совет илчелеге вәкиле Юрий Анатольевич Бармичев.— Көзме ул, кышмы, язмы — һаман шул ук җепшек кар, пычрак һәм... ысланган стеналар. Безнең Россиядә бит бөтенләй башка...

Безнең машина Көнбатыш Берлинның Альт-Моабит урамы буйлап чаба. Уң якта биек кирпеч стена сузылган. Ишек алдындагы зур тәбәнәк бинаның тәрәзәләрендә тимер рәшәткәләр күренә. Бу — Эрнст Тельман, Эрнст Буш һәм башка күренекле антифашистлар газап чиккән каһәрле Моабит төрмәсе. Аннан ерак түгел тагын бер төрмә. Монысы да Моабит төрмәсе дип атала. Бусында хәрби тоткыннар утырган. Муса Җәлил һәм аның иптәшләре үлем көткән бу төрмә хәзер инде җимерелгән.

Тагын берничә квартал узуга, элекке Плетцензее төрмәсе урнашкан бинага килеп җитәбез. Өстән чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган һәм тирән тынлыкка чумган кирпеч стена янында безне дистә ярымлап машина һәм бер төркем кешеләр каршы ала. Аларның күбесенең кулларында канәфер һәм ләлә чәчәкләре бәйләмнәре. Мине шакмаклы пальтосының якасын күтәргән уртача буйлы, базык кына гәүдәле бер кеше белән таныштырдылар. Ул — Германия-Совет дуслыгы җәмгыятенең Көнбатыш Берлин бүлеге председателе Рольф Элиас икән. Үз нәүбәтендә ул мине җәмгыятьнең совет шагыйрен искә алырга килгән актив членнары белән таныштырды. Берегә шулай ук элек фашист төрмәләрендә һәм концлагерьларда утырган кешеләр дә килгән иде. Нацистлар тарафыннан эзәрлекләнгән антифашистларның Көнбатыш Берлин берләшмәсе председателе, күренекле җәмәгать эшлеклесе Курт Майнхольд миңа пөхтә итеп басылган калын гына бер китап сузды. Аның соры киндердән эшләнгән тышлыгына кара хәрефләр белән «Фашистлар төрмәсе Плетцензее корбаннарының истәлек китабы» дип язылган иде. Бу китапта гитлерчы палачларның җинаятьләре турындагы документлар урнаштырылган һәм әлеге төрмәдә җәзалап үтерелгән тоткыннарның исемнәре саналган. Алар барысы мең сигез йөз кешедән артык булган.

— 1944 елның җәендә һәм көзендә бирәдә Гитлерга каршы заговорда катнашкан югары чиндагы офицерлар җәзалап үтерелгән, — дип аңлата Курт Майнхольд. — Ләкин Көнбатыш Берлинның рәсми властьлары бүген әнә шулар турында гына сөйләүне кулайрак күрәләр. Ә без фашизмга каршы көрәштә корбан булганнарның һәркайсын олылап искә алуны үзебезнең изге бурычыбыз итеп саныйбыз. Менә бу китапта сез чех патриоты Юлиус Фучик, батырлыгы алдында без барыбыз да тирән ихтирам белән баш ия торган сезнең милли героегыз Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең исемнәрен очратырсыз.

Плетцензее төрмәсе янында без Көнбатыш Берлин газеталары хәбәрчеләрен дә күрәбез. Аларның берсе, Көнбатыш Берлин Социалистик Бердәм партиясе органы «Ди Вархайт» газетасының культура бүлеге мөдире Эберхард Шмидт миннән кыска гына интервью ала.

Тантаналы церемонияне башларга хәзерлек барган арада Рольф Элиас миңа 1966 елның февралендә, Муса Җәлилнең тууына алтмыш ел тулу көннәрендә, ул җәзалап үтерелгән урынга үзләренең беренче тапкыр чәчәк бәйләмнәре куюлары турында сөйли.

— Ул вакытта хәл ифрат киеренке иде. Көнбатыш Берлинны ул чакта юкка гына фронт шәһәре дип атамадылар. Реакцион газеталар советка каршы пропаганданы киң колач белән җәелдерделәр. Шуңа да карамастан, Германия-Совет дуслыгы җәмгыятенең актив членнары һәм көрәшче-антифашистлар Җәлилгә багышланган митингка

җыелдылар. Безнең җәмгыять клубының җитәкчесе фрау Шипански, Көнбатыш Берлин территориясендә беренче тапкыр буларак, совет шагыйре Муса Җәлил турында речь белән чыкты. Митинг зур күтәренкелек белән үтте. Ләкин анда катнашучылар өйләренә таралышуга, бирегә полицейскийлар килеп җитте һәм алар шагыйрьнең исеме язылган тасмаларны кисеп ташладылар. Күрәсең, властьлар Плетцензее тирәсенә күпләп килүче кешеләрнең тагын бер яңа исемне белүләрен теләмәгәннәрдер.

— Шуннан бирле,— дип дәвам итә Рольф Элиас,— Көнбатыш Берлинның прогрессив җәмәгатьчелеге вәкилләре герой-шагыйрьне һәр ел саен зурлап искә алалар.

Германия-Совет дуслыгы җәмгыятенең Көнбатыш Берлин бүлеге тарафыннан чыгарыла торган «ДСФ Джорнал» журналы баш редакторы Франц Румпның Муса Җәлилнең алтмыш еллыгы көнендә ясаган чыгышы Рольф Элиасның хәтеренә аеруча нык сеңеп калган. Франц Румп шагыйрьнең үз Ватанының азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен генә түгел, немец халкының якты киләчәге өчен дә көрәшеп корбан булуы турында сөйләгән. Муса Җәлил, дигән ул, җиргә нацизм алып килгән коточкыч дәһшәтләр яңадан беркайчан да кабатланмасын өчен һәлак булды.

Германия-Совет дуслыгы җәмгыяте членнары, шагыйрьнең һәлак булуына утыз ел тулу көнен билгеләп үткәндә, ул җәзалап үтерелгән урынга чәчәк бәйләмнәре салуда да актив катнашканнар. Ул чакта Көнбатыш Берлинга шагыйрьнең тормыш иптәше Әминә Җәлилова һәм кызы Чулпан да килгән. Җәмгыятьнең кино залында «Моабит дәфтәре» исемле совет нәфис фильмы күрсәтелгән.

Тантаналы церемония нәкъ сәгать унбердә башланды. Менә без «1933—1945 еллардагы Гитлер диктатурасы корбаннарына» дигән сүзләр язылган таш стеналар буеннан, элеккеге концлагерьларның һәркайсыннан берәр уч туфрак китереп салынган зур гына таш урна яныннан үтәбез. Ә ул туфрак бер гаепсез кешеләр каны белән сугарылган, яртылаш янып көлгә әйләнгән чәч бөртекләре белән аралашкан.

Җәзалау бүлмәсе — караңгы һәм салкын. Монда бөтен нәрсә 1944 елның август көнендәгечә — Муса Җәлил группасындагы унбер герой үлемне батырларча каршылаган көндәгечә калган. Идәнгә җәелгән соры таш плитәләр әле дә шагыйрьнең һәм аның көрәштәшләренең ал кан тапларын үзләрендә саклыйлар кебек.

Шагыйрь җәзалап үтерелгән урынга совет Язучылары союзы исеменнән чәчәк бәйләмнәре куйганнан соң, монда җыелган кешеләргә мин Муса Җәлилнең тормышы һәм героик үлеме, аның поэзиясенең интернациональ әһәмияте турында сөйләдем.

Рафаэль **МОСТАФИН.**

# ОНЫТЫЛМАС КЕШЕМ

Тормышта кемнәр белән генә очрашырга туры килми! Аларның кайберләре аерылып китү белән онытыла, сөйләгән сүзләре дә, килеш-килбәтләре, хәтта исемнәре дә хәтердә калмый. Ә икенче берәүләре исә күңелгә гомер буена онытылмаслык булып кереп урнаша. Муса Җәлил дә нәкъ әнә шундый кешеләрнең берсе иде.

1924—1926 елларда мин Мәскәүдә, СССР халыклары үзәк нәшриятының удмурт секциясендә корректор булып эшләдем. Татар секциясе безнеке белән янәшә урнашкан иде. Шунлыктан без, һәр ике секциянең хезмәткәрләре, үзара якыннан аралашып яшәдек. Соңыннан күренекле язучылар булып киткән Хәсән Туфан һәм Габдрахман Әпсәләмов миңа шул вакыттан ук таныш. Ә Муса Җәлил белән без Үзәк нәшрият каршындагы бер үк комсомол оешмасында член булып тордык.

1920 елда мин Мәскәү дәүләт университетына этнология факультетының әдәбият бүлегенә укырга кердем. Шунда укыганда 1927 елның көзендә университетта Муса Җәлил белән без кабат очраштык. Ул да шул ук бүлеккә укырга кергән булып чыкты. Уку белән бергә пионерлар өчен татарча чыгарыла торган «Октябрь баласы» журналында редактор булып эшләвен дә дәвам иттерде. Ләкин безгә еш очрашырга туры килмәде, ә төрле курстагылар өчен уртак лекцияләр укылмый иде.

1928 елның июлендә миңа университетның Кара диңгез буендагы Балаклавский ял йортына путевка бирделәр. Безне, кырыклап кешене, зур гына бер бүлмәгә ур-

наштырдылар. Минем койкам Муса һәм аның дусты, тарих факультеты студенты (фамилиясе хәтеремдә калмаган) койкалары белән рәттән туры килде.

Шулай бервакыт иртәнге аштан соң:

— Беләсеңме, Муса, минем бит беркайчан да татар авылында булганым юк,— дидем мин.— Әйдә, барып кайтабыз.

Муса, тарихчы дусты белән киңәшкәннән соң, без өчәүләп ял йортыннан әллә ни ерак булмаган авылга юл тоттык. Башта тар гына сукмак буйлап биек тауга күтәрелдек. Каршыбызда зәңгәрсу томан эченә күмелеп утырган авыл һәм ямь-яшел бакчалар пәйда булды. Арырак тагын тау тезмәләре сузылып киткән иде. Без, боларның һәммәсен тизрәк якыннанрак күрергә теләп, адымнарыбызны кызулатканнан-кызулаттык. Төшке ашка да кайтып өлгерергә кирәк бит әле!

Татар дуслар үз телләрендә сөйләшәләр. Әңгәмәгә бик-бик кушылырга теләсәм дә, татарча белмәвем миңа бу теләгемә ирешергә ирек бирми. Шунда мин сүз арасында гына шаяру катыш әйтеп куйдым:

— Муса, өйрәт әле мине үзегезчә сөйләшергә. Әгәр теләсәң, мин сине удмуртчага өйрәтермен.

Муса елмаеп җавап кайтарды: «Ярый, иптәш Аркаш, ярый. Син дә шагыйрь, мин дә. Менә мин сиңа хәзер татарча бер җыр язып бирәм. Әгәр шундый йөз җыр ятласаң, безнеңчә сөйләшергә өйрәнүеңне үзең дә сизми калырсың».

Барган җиреннән туктап ул миңа татарча бер җыр әйтеп яздырды. Кызганычка каршы, ул җыр язылган куен дәфтәрем сакланмаган. Ул чакта ничек откан булсам, хәзер мин аны нәкъ шулай күчереп язам. Менә ул җыр:

**Зюграй, зюграй зиляк зиям,**
**Зангар талинкалярга.**
**Исән булсак, без кайтырбыз**
**Кузгы ярминкалярга.**

Муса җырлап күрсәткән көйгә ияреп, бу юлларны мин ничәмә-ничә тапкырлар кабатлаганмындыр, анысын хәзер инде ачык кына әйтә алмыйм. Әмма ул җыр күңелемә шул кадәр кереп калган, аннан бирле кырык елдан артык вакыт узгач та, мин аны һаман хәтеремдә саклыйм. Ул җырның сүзләрен татар дуслар өйрәткәнчә дөрес әйтергә күпме генә тырышып карасам да, моңа барыбер ирешә алмадым. Җырда сүзнең ни турыда барганлыгы тыңлаучыларга аңлашылса, миңа шунысы бик җиткән, дип үз-үземне тынычландырдым.

Үзара гәпләшеп бара торгач, тәбәнәк кенә таш койма белән әйләндереп алынган бер йорт янына килеп туктадык.

Ишегалдында җәйге мич яна. Аның тирәсендә урта яшьләрдәге ханым аш-су әзерләп йөри. Муса исәнлек-саулык сорашты да ир-ат белән сөйләшә башлады. Күп тә үтмәде, безне төрле яктан авыл кешеләре сырып алды. Хуҗа безне әллә ни зур булмаган ике катлы йортка алып кереп китте...

Юлда Муса безгә Кырым турында, аның халкы, бай тарихы турында дәртләнеп, илһамланып сөйләп кайтты. Гомумән, ул беркайчан да үз эченә бикләнүне, нинди генә хәлгә юлыкса да, зарлану һәм төшенкелеккә бирелүне белми иде.

Шундый бер вакыйга искә төшә.

Зур гына катерга төялеп, Ялтага экскурсиягә киттек. Югыйсә, диңгез өсте тыптын: дулкын диган нәрсәнең әсәре дә юк. Ләкин безне нишләптер бик нык айкый. Экскурсантларның күбесе, күңелләре болганып, катер төбенә сузылып ук яттылар. Бу озын сәяхәтне берничә генә кеше җиңел уздырды. Аларның берсе, әлбәттә, Муса иде. Безне үртәп, ул һаман шаярудан туктамады:

— Их, сез куян йөрәкләр! Ныграк булыгыз, бирешмәгез!

Әйе, шул чакта ул инде аның: «Ныграк булыгыз, бирешмәгез!» дип әйтергә тулы мораль хокукы булган. Бу сүзенә ул үзе дә соңгы сулышынача тугры булып калды.

Сүз ахырында тагын шуны әйтеп үтәсем килә. «Муса» дигән сүз удмурт телендә «кадерлем», «якыным», «онытылмас кешем» дигән мәгънәне аңлата. Шуңа күрә шагыйрь Мусаның исемен мин аеруча якын итеп, яратып кабатлыйм.

**АРКАДИЙ КЛАБУКОВ,**
**удмурт язучысы.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ХЕЗМӘТ



*Ибраһим Гази — республикабызның нефть якларына беренчеләрдән булып эз салган язучы. «Мин шунда барам» дип, алдан телеграммалар бирмәде, «фәлән нәрсә язам» дип, кычкырып та йөрми иде. Сиздермәстән генә килеп чыга, исәнлек-саулык сорап, берәр мәзәк сүз әйтә дә каядыр китеп юк була. Танышлары күп иде. Дөньяны ул үзенчә танып, кешеләрне үзенчә якын итә белде.*

*«Татнефть» берләшмәсе яңа оешып килгән еллар иде. Бөгелмә шәһәрендә республика нефтьчеләренең зур киңәшмәсе бара. Ораторлар трибунада самавар сыман кайныйлар. Кәгазьгә карап сөйләмиләр, ә күңелдәген күзгә карап әйтәләр. Трибунага берләшмә начальнигы — чегәнгә охшаган Шмарев күтәрелә. Сумала сыман елтыравык чәчләре, дулкынланып, маңгаена төшкән. Һәр сүзе — масштаблы, еракка ата, бөтереп ала...*

*Залда, кырыйдагы урыннарның берсендә күзлеген елтыратып, Ибраһим ага Гази утыра. Ара-тирә блокнотына нидер сызгалап ала. Тыштан сабыр күренә, ә эчендә ниләр янадыр...*

*Бу кадәресен бераз соңрак, аның «Гади кешеләр» исемле романын укып чыккач белдек. Дөньяда тиңе булмаган Ромашкино нефть чыганагы ачылган. «Кара алтын» республикабызның индустриаль йөзен тамырдан үзгәртергә, революция ясарга тиеш. Күмәк акыл, гади кешеләр кулы белән башкарылачак эш бу. Ибраһим Гази үзенең романында шул үзәк мәсьәләне мөгезеннән тотып алган, чорның кайнар сулышын биргән, баш әйләндергеч «ыгы-зыгы»ларның иң кирәклесен үзенең калын күзлек пыялалары аша гүя бер фокуска җыйган...*

*Ибраһим Гази ул чагында «Онытылмас еллар»ын дәвам итә иде. Гражданнар сугышы, Совет властеның урнашу чоры. Үзәк тема. Яз да яз. Әмма язучының гражданлык сиземе аны яңа ачылган нефть фронтына дәшә. Бүген бармасаң, иртәгә соңга калуың ихтимал. Ул, беренче чиратта, үзен һәм үз үрнәгендә башкаларны шуңа мобилизацияли.*

*1970 елның октябре хәтердә. Әлмәттә киңәшмә: «Әдәбиятта хезмәт кешесе образы». Партия өлкә комитетыннан җаваплы кешеләр, Казаннан танылган язучылар килгән. Нефть төбәгендә яшәүче яшь әдәбиятчылар да чакырылган иде. Эчтәлекле докладлар булды, шул исәптән, Татарстан язучылары союзы җитәкчесе Ибраһим Гази да чыгыш ясады. Андагы тәэсирләргә бирелеп тормастан, кечкенә ике эпизодка тукталасы килә.*

*Киңәшмәдән соң, гостиница номерында, Ибраһим Гази миңа мондыйрак сүз әйтте:*

*— Җыйналып сөйләшү ярый торган нәрсә. Ләкин минем төп эшләрем эшләнмәгән бит әле. Иртәгә Яңа Кәшер урта мәктәбендә булырга кирәк. Депутатлык вазифасы. Аннары — Лениногорскида. Шамил бу турыда белә, бәлеш пешереп көтәрбез, диде.*

*Бераз тынып торганнан соң, Ибраһим абый уңайсызланып кына:*

*— Минем белән бара алмассыңмы, Әдип? — дип сорады.*

*Белә идек: Кәшер урта мәктәбе кызганыч хәлдә. Шамил исә иҗади торгынлык*

*чорын кичерә, «Каты токым»ының очына чыга алмый азаплана. Алай да, болай да боргаладь романын, аннары калдырып торырга булды. Бу хәлне Ибраһим абый да ишеткән.*

*Кәшердә без берничә сәгать булдык. Ибраһим абый мәктәпнең эченә кергәнче, озын агач бинаны тышкы яктан карап әйләнде, имән тирәүләргә, кыйшайган тәрәзәләргә игътибар итте. Аннары колхоз җитәкчеләрен чакыртырга кушты. СССР Верховный Советы депутаты янына алар бик тиз килеп җиттеләр.*

*— Яңа мәктәп әле кайчан була. Сезне, Ибраһим абый, балалар көтә, — диделәр укытучылар. — Залга рәхим итегез.*

*— Мине дә шул «әле кайчаны» борчый, — диде Ибраһим абый, сәер генә елмаеп, — чакыргач, керәбез инде.*

*Зал шыгрым тулы иде. Нәниләрдән алып, югары класс укучылары, укытучылар һәм колхоз җитәкчеләренә кадәр «тере» язучының чыгышын аяк өсте баскан килеш, мавыгып тыңладылар. Шул очрашудан соң озак та үтмәде, тиешле оешмаларда смета-лар, проектлар хәрәкәткә килде. Яңа Кәшердә мәһабәт яңа мәктәп бинасы да калкып чыкты. Сүзен сүз иткән, «әле»ләргә, «ләкин»нәргә урын калдырмаган Ибраһим агабыз. Аны хәзер «Ибраһим Гази мәктәбе» дип йөртәләр.*

*Ә Лениногорскига миңа аз гына соңлабрак барырга туры килде. Бикчуриннар квартирасында, Ибраһим абый белән Шамил, икәүдән-икәү генә, бәлешнең төбенә төшеп килләр иде. Өстәлдә шешә заты күренми. Монысына гаҗәпләнмәдем дә. Чөнки Ибраһим Гази гомер-гомерендә эчемлек тирәсеннән читтә булды.*

*— Син безне бәлеш ашап кына утыралар икән дип уйлама, — диде Ибраһим Гази, мине өстәл янына дәшеп, — романның да төбенә төшеп киләбез.*

*Чыннан да, өстәл кырыенда битләре ачылган кульязма ята. Шамил нигәдер күрше бүлмәгә чыкты. Ибраһим Гази сабыр гына, яратып кына:*

*— Шами-и-л, кил әле монда, без кайда туктальп калдык әле? — дигәч, буш кул белән кире өстәл янына әйләнеп килде, кульязманың кайсыдыр битеннән укырга тотынды.*

*— Җитте! — дип туктатты аны өлкән язучы. — Хәзер алдагы ун битнең эчтәлеген сөйлә. Ә без ашый торыйк...*

*Вакыт кысан булганда, калын кульязма белән шул рәвешчә дә танышып чыгарга мөмкин икән бит. Юнәлеш бирү өчен әсәрнең асылын аңлау да җитә кайчакта.*

*— Әйбәт роман булачак, — дигәне хәтердә Ибраһим Газиның, — мин әйткәннәрне истә тотсаң, өч айда өлгертәсең.*

*Балалар бүлмәсеннән кинәт пәйда булган Гайшә ханым, сөенеченнән нишләргә белмичә, Ибраһим абыйга ялвара ук башлады.*

*— Зинһар, катырак итеп әйтегез әле шуңа, Ибраһим абый!*

*Шамил, гаепле кеше сыман, башын түбән иеп утырды:*

*— Әллә мине дивана дип белдеңме, Ибраһим абый сүзен тыңламаска...*

*Берничә ай вакыт үткәч, Шамил Бикчурин «Каты токым» романын Әлмәт бүлегенә алып килде.*

*...Ибраһим Гази кешеләрне, чәчәкләрне ярата иде. Моннан ун еллар чамасы элек Минзәлә якларында әдәбият атналыгы үткәрелде. Әлмәт бүлегеннән анда Шамил Бикчурин, Саҗидә Сөләйманова, ә Казаннан Ибраһим Гази, Зәки Нури, тагын берничә язучы катнашты. Күпчелек язучылар пароход белән кайтырга җыенгач, Ибраһим Гази:*

*— Пионнарым чәчәк аткандыр инде, — ди дә Казанга самолет белән оча. Кайтып җитүгә, Әлмәткә дә, Лениногорскига да җылы-җылы хатлар язып җибәрә.*

*Әдәби атналыкта башланган шушы дуслык элемтәләре өлкән язучының ахыргы көннәренә кадәр дәвам итте. Аккош күле буендагы бакчасыннан Ибраһим Гази Әлмәткә туфрагы белән чәчәкләр биреп җибәрә торган иде. Алар хәзер дә исәннәр, ел саен бөреләнеп чәчәк аталар.*

ӘДИП МАЛИКОВ.

# Ибраһим Гази

## Чирәм ерту - һәр язучы бурычы

Иптәшләр! Икмәкне барыбыз да колхозчылар кулыннан ашыйбыз. Күмерне, нефтьне, газны эшчеләр бирә. Җир йөзендәге бөтен байлык — бәрәңгедән алып реактив самолетларга тикле барысы да кул һәм акыл хезмәте тарафыннан барлыкка китерелгән. Безнең иң зур хыялларыбыз һәм иң бөек идеалларыбыз хезмәт көче белән тормышка аша. Дөнья кит балыгы җилкәсендә тормый, дөнья хезмәт җилкәсенә элэгеп тора.

Әдәбият, сәнгать — икмәк түгел... Әмма сәнгать әсәренең кешегә тәэсире икмәк эше генә түгел. Сәнгать елата да, көлдерә дә, сәнгать кешеләрне утка да алып кереп китә. Дөрес, ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттә, дип халык белеп әйткән, ач чакта күңел китапка төшмәсә дә гаҗәп түгел. Хәзер «икмәк» көн тәртибеннән төште.

Безнең замана — кеше күңеле, кеше рухы өчен бөек көрәш заманасы. Ә кеше рухы өчен барган каты көрәштә сәнгатьнең, әдәбиятның урыны иң алгы сафта. Димәк, сәнгать, әдәбият уен түгел икән, сәнгать, әдәбият **«кем кемне!»** мәсьәләсен, эпохабызның бик зур, бик катлаулы проблемасын чишүдә хәлиткеч рольне уйный.

Безнең әдәбият үзенең гуманлылыгы белән, үзенең идея омтылышы белән, халыкчанлыгы, партияле булуы белән көчле, ул хезмәткә, көрәшкә, батырлыкка чакыруы белән көчле, дошмани идеяләр белән килешмәүчән сәнгать булуы белән көчле!

Алда партиябезнең XXIV съезды тора. Ул безнең тормышыбызга никдидер яңалыклар кертәчәк, яңа перспективалар, яңа борылышлар ачачак. Без үзебезнең бу җыелышыбызны партия съездын каршылау йөзеннән эшләнә торган бер эш итеп карыйбыз. Әдәбият дөньясында да борылышлар булыр. Хосусан алганда, без, татар язучылары, хезмәт темасына йөз белән ныграк борылырга тиеш булырбыз.

Татар әдәбиятында хезмәт темасы гомер-гомергә зур урын алып торды, хезмәт кешесе әсәрләребезнең төп герое булып килде. Моңа кадәр без күбрәк авыл хезмәтен яздык. Моның тарихи сәбәпләре бар, ул сәбәпләрне сез беләсез. Авыл тормышын, аның проблемаларын, көнкүреш, гореф-гадәтләрен, уеннарын, җырларын, крестьян агаеның характерын безнең язучылар яхшы беләләр иде, чөнки үзләре дә буразнада туганнар, ат саклап үскәннәр. Бүгенге авыл хезмәте, авылның кешеләре, көнкүреше бик каты үзгәрсә дә, һәр яктан шәһәргә якынайса да, безнең язучыларыбыз авылга курыкмыйча барып ябыша алалар. Ә шәһәргә, заводка, фабрикага килгәндә, алар шүрләп кала. Чөнки эшчеләр дөньясы бөтенләй яңа бер планета, безнең язучылар ул планета белән рәтләп таныш түгел.

Нефть дөньясын гына алыйк, гәрчә нефтьтә эшләүчеләр шул ук крестьяннан «азган» эшчеләр булсалар да, алар инде башка кешеләр, хезмәтләре, психологияләре, гореф-гадәтләре үк бүтән. Алар янына барганда иске үлчәү белән барырга ярамый. Шул ук вакытта алар безнең шикелле үк кешеләр: безгә хас — аларга да хас, аларда шул ук совет кешесе характеры, шул ук совет кешесе психологиясе, шул ук интереслар, шул ук максат. Димәк, без совет кешеләре булу ягыннан бертуган агай-эне, кардәш...

Димәк, һич курыкмыйча эшче сыйныф темасына барып ябышырга була. Ябышу безнең бурыч, бурыч кына да түгел, укучы, халык бездән шуны таләп итә. Сугыш

---

1970 елның көзендә нефтьчеләр шәһәре Әлмәттә «Матур әдәбиятта хезмәт кешесе» дигән темага киңәшмә уздырыла. Бу — шул киңәшмәне ачу алдыннан сөйләнгән сүз.

романтизмын җырладык, мәхәббәт романтизмын гел җырлап торабыз, хезмәт романтизмын җырларга кирәк!

Дөрес, яңа эшкә керешәсең икән, каешыңа яңа тишек тиш, дигәннәр. Тотынгач-тотынгач, димәк, җиң сызганып, бик җитди ният белән тотынырга кирәк булачак һәм, кәҗә маең сыгылачагын алдан ук чамалап, каешыңа яңа тишекне тишеп куярга кирәк. Язучы кеше, мәрхүм Маяковский сүзләре белән әйтсәк, тапталган, ансат, такыр юлдан йөрмәскә тиеш, яңа юллар салу, чирәм ерту үзен хөрмәт иткән язучының бурычы.

Бу җыелышка хәзерләнгән чакта, мин РСФСР язучыларының III съездында язган блокнотымны актарып карадым. Драма әсәрләре буенча докладчы Мостай Кәрим: безнең драматургларыбыз хезмәт темасыннан ераклаштылар, дип борчылып сөйләде. Акыллы башлар безгә әйтәләр, диде ул, сәхнәдә хезмәтне турыдан-туры күрсәтмәгез, алай итүдән ерак торыгыз, диделәр, без ераклаштык, хезмәт темасыннан киттек.

Хуҗа Насретдинның хатыны: «Кит!» дип әйткән, имеш. Хуҗа киткән. Өч көн буе барган, шуннан соң гына артына әйләнеп карап хатынына кычкырган: «Җитәрлек киттемме?» Без дә, Хуҗа кебек, хезмәт темасыннан киттек тә киттек,— диде Мостай Кәрим съезд трибунасыннан. Ул драмада хезмәт кешесен күрсәтүгә яңадан борылып кайтырга чакыра.

Съезд үзенең резолюциясендә: «Драматургиянең бүгенге хәле безне борчый», дигән фикерне әйтте.

Проза хакында доклад белән чыгучы Михаил Алексеев әдәбиятта уңай герой, идеаль герой түгел, уңай герой мәсьәләсен куеп, бу геройга үз характеристикасын бирде. Уңай герой ул минем идеалларыма турылыклы минем якын кешем, минем иптәшем, минем фикердәшем. Аның матур булуы, яки ямьсез булуы мөмкин. Кимчелекле яклары булуы да ихтимал. Ләкин аның бу кимчелекләре төп яхшы сыйфатларын каплап тормаска тиеш — ул безнең идея кешесе. Аның кыйбласы — безнең кыйбла, аның кылган гамәлләре безнең максатыбызга хезмәт итә. Уңай герой ул иҗтимагый кеше, ягъни матур кеше генә түгел, ягымлы, сөйкемле, юмарт яки акыллы кеше генә түгел, шушындый матур сыйфатларның барысы өстенә, янсә андый сыйфатлары булмаган хәлдә дә, ул безнең сыйныф кешесе, безнең идеаллар кешесе!

Әлбәттә, уңай геройга икенче төрлерәк характеристика да биреп булыр иде. Бу — вариантларның берсе. Әһәмиятлесе шул, РСФСР язучыларының III съезды уңай герой мәсьәләсен яңадан китереп куйды.

Без үзебезнең уңай геройларыбызны, шулай ук уңайсызларын да хезмәт кешеләре арасыннан эзлибез. Алар безнең арада йөри: йорт салалар, нефть чыгаралар, икмәк үстерәләр, яңа заводлар торгызалар, балалар укыталар, китаплар язалар — барысы да безнең булачак китапларыбызның геройлары. Тик бары язучылар иренмәскә, үткенрәк сүзле булырга, өйдә ятмыйча, эшчеләр белән ешрак аралашырга, оригиналь, кызык характерлар эзләргә, кешеләрне борчыган проблемаларны өйрәнергә, китап битләренә күчерергә кирәк.

Беләбез диючеләр булыр. Дөрес, беләбез, тик ни өчендер эшләмибез? Шушы җыелыш мүк үсә башлаган күңелләрне кузгатып җибәрмәсме икән? Бу җыелышны җыюдан максат бер шаулашып, сөйләшеп алу гына түгел, андый җыелышны без Әлмәт хәтле җиргә килмичә, Казанда да уздыра алган булыр идек. Максат — йоклаган күңелләрне уяту, язучыларны хезмәткә йөз белән бору, республикабызда көннән-көн үсә барган эшче сыйныф турында яңа китаплар иҗат итү. Җыелышны уздырудан максат әнә шул. Әдәбият дигән нәрсә мүкләнгән күңелләрне, битарафлыкны яратмый, язучы үзенә таләпчән булсын, үзен гел тәнкыйть астында тотсын. Кичә эшләнгән эш белән бүген канәгатьләнмичә, ул үзен гел алга, яңаракка, камилрәккә әйдәсен.

Язучыга да гомер бер генә килә, үлгәндә үкенерлек булмасын! Юкса бит, Гамил Афзал әйтмешли, «елгалар ага тора, оныклар үсә тора!», ә үткән гомер кире кайтмый.

Җыелышыбызны ачык дияргә рөхсәт итегез!

*27/X.70.*

# Язучыларга хатлар



*20 март, 1962 ел. Казан.*

Шамил,

син яхшы төзәткәнсең, әсәр[1] җыйнакланган, әйбәтләнгән. Молодец дип мактарлык булган. Мин кайбер кабатланган урыннарын табып бераз кыскарткаладым, әлбәттә, бозмаска тырыштым.

Синдә йомшак юмор бар, табигый итеп тасвирлый белү осталыгы бар. Әсәреңдә тамчы да ясалмалык сизелми, бу — зур уңыш. Киләчәктә дә агач аякка (ходулига) күтәрелмичә табигый язарга тырыш, Лобанов җанлы кеше, ике мастерга гына үзенчәлек җитеп бетми.

Хәзер ахыры турында. Мин сиңа Мәскәүгә баруны төшерикме әллә дип әйткән идем шикелле? Син калдыргансың. Калдырып шәп итмәгәнсең. Ул җирдә эч пошыргыч шалтыравык сүзләр күп. Н. С. Х.[2] ны кунакка дәшүнең дә хәзер әһәмияте юк, вакыт узган, ул да килмәгән. Кыскасы, мин ул главаны аллаһ әкбәр! Озатып калу белән тәмам була.

Минем бу хатымда күңел хакы өчен генә әйтелгән юмалау сүзе юк. Чын күңелдән мактадым, юкса, мин дәшми генә калыр идем.

**Сәлам белән: Ибраһим Гази.**

Чираттагы номерларның берсенә керер дип өмет итәм.

*7 декабрь, 1962 ел. Казан.*

Шамил,

мин сиңа күптәннән хат язып җибәрергә җыенып йөрим, һаман кул тими.Ниләр бетереп ятасың? Берәр яңа нәрсә язмыйсыңмы? Хикәяң юкмы?

Хат язуның төп сәбәбе: синең хикәяң (дөресрәге, озын хикәяң) турында «Чаян»да[3] бик урынсыз, һич дөрес булмаган карикатура чыкты, үзләренчә, алар файдалы эш эшләдек дип уйлыйлардыр. Ләкин яшь авторның беренче зур әсәре турында шулай күсәк күтәреп чыгу бер генә яктан да дөрес түгел. Без монда «чаян»чыларга әйттек, ләкин бит инде эш узган. Ул карикатурага карап, син борыныңны салма, синең ул хикәяң нефть темасына язылган әйберләр арасында берсенекеннән дә начар түгел, хәтта, киресенчә! Чын реализмга нигезләп, бик табигый телдә язылган. Укуы да алар әйткәнчә күңелсез түгел. Мин моны синең күңелеңне табар өчен генә әйтмим.

Әгәр язган хикәяң булса, журналга җибәр. Язганы булмаса, яз.

Казанда хәлләр искечә, әллә ни алга сикергән җиребез юк. Гадәттәгечә, кылтыймылтый гына барабыз. Үзгәртеп атмасалар, февральдә Татарстан язучыларының съезды булыр дип көтәбез. РСФСРныкы майларда булыр дип көтелә.

**Сәлам белән: Ибраһим Гази.**

*14 август, 1968 ел. Казан.*

Шамил!

Син теге вакытта кереп чыктың да шуннан соң тавышың-тының бетте. Нишләп ятасың? Мин радиодан синең очеркны ишеткән идем — бик ошаттым. Шуны шул хәлендәме, бераз тагын ит-май кундырыпмы, 50 еллыкка чыгарырга кирәк. 50 еллыкка тагын ниләр язасың? Пьесаң өлгереп җитәме? Давай, яшь чакта вакытны әрәм итмә. Эшләргә! Эшләргә! Синең хәзер нәкъ өлгереп җиткән чагың...

Яратып:

**Ибраһим абыең.**

---

[1] Сүз Шамил Бикчуринның «Кайнар чишмә» исемле документаль повесте хакында бара. Ул «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 5 санында басыла.

[2] Н. С. Х. — Никита Сергеевич Хрущев.

[3] «Чаян» журналының 1962 елгы 15 санында Э. Гельмсның «Тәмугта» дигән карикатурасы турында.

*17 март, 1970 ел. Казан.*

Шамил,

хатыңны алдым, үпкәләреңне кабул итмим. Гомумәм, үпкәләү ирләр эше түгел.

Үпкәләү кешене кечерәйтә, авызың тулы кан булса да төкермә, сиздермә...

Син әйтәсең, көз көне иҗат йортына барыр идем, дисең. Анысын ачык итеп әйт, югыйсә, ул һавадагы торнага әйләнә.

Сентябрь? Октябрь?

Вакытын әйтеп, райком белән килештереп, соңыннан «бара алмыйм»га урын калмаслык итеп, (Лерон Хәмидуллинга) литфондка яз, бик тиз яз, соңга каласың. Мин аңа әйтеп куйдым. Әлегә урыннар бар.

Романны[1] төн утырып булса да эшлә!

Уңышлар теләп: **Ибраһим абыең!**

*22 октябрь, 1970 ел. Казан.*

Шамил!

Көз көне сөйләшкән идек, син, романым әзергә якын, дигән идең. Романың ни хәлдә? Редакциядән китеп, роман өстендә генә утырырга ниятләмисеңме?

Аннары син язучымы, әллә редактормы?

Сузма, романга утыр, хәзерлә, бир.

Романга утырсаң, акчалата ярдәм итәрбез.

**Ибраһим абыең.**

*4 ноябрь, 1970 ел. Казан.*

Шамил,

мин Юрий Николаевич[2] дигәне белән сөйләштем, сине гаҗәп тә әйбәт язучы дип мактадым, синең эшең хакында сөйләдем, язып бетерергә ирек бирүләрен үтендем. Ул гел «ладно», «ладно» дип торды, ягъни ризалык белдерде.

Гайшә ханымга сәлам.

Балаларга да сәлам!

**Ибраһим Гази.**

*14 май, 1968 ел. Казан.*

Саҗидәсе,

мин бик каты эш кешесенә әйләнеп барам, вакытында җавап бирә алмадым, үпкәләмә инде.

Үткән бәйрәм белән дә, киләчәк бәйрәмнәрнең дә кайберләре белән алдан ук котлап куям.

Мин начальник[3] булсам да, үземне һич начальник итеп сизмим һәм начальник була да белмим, булырга (була белергә) тырышмыйм да. Кирәк дип тапкан эшләрне эшлим — бары шул.

Аннары колагыңа гына әйтә алам: мин көн үткәч өстәлдә тотып карарлык бер «эш» күрергә өйрәнгән. Хәзер исә мин үземнең эшемне тотып та, иснәп тә, ялап та (әчеме-төчеме), күз белән карап та күрә алмыйм. Шушы минем күңелне гел кимереп, җанны кыйнап тора: көн үтте, ә синең күзгә күренерлек эшең юк! Аннары безнең авылда болай дип әйтәләр: кояш чыга да бата, ә гомер артмый.

Зарлануга охшаган бу «фәлсәфәдән» соң, чәчәкләрең үсәме? Минем чәчәкләр гөрләп үсә, озакламый бакча тулы гөл булачак.

Картыңа миннән сәлам.

Ихтирам белән: **Ибраһим абыең.**

Кул астында яхшы конверт булмады.

---

[1] Сүз Ш. Бикчуринның нефтьчеләргә багышланган яңа романы турында бара. Әсәр, «Каты токым» дигән исем белән, беренче тапкыр «Казан утлары» журналының 1972 елгы саннарында басыла.

[2] Сүз ул елларда КПССның Лениногорск шәһәр комитетының икенче секретаре булып эшләгән Юрий Иванович Калежирин хакында барса кирәк.

[3] Татарстан язучыларының VII съездында Ибраһим Гази Язучылар союзы идарәсенең председателе итеп сайлана.

*1968 ел. Казан.*

Саҗидә, Әдип!

Икегезгә дә бик күп сәлам. Балалар үсәме инде: үзегезне тотып кыйнарлык булдылармы? Ни эшләр бетереп ятасыз? Шагыйрь җаны түзмидер, ни дә булса язасыздыр? Әдип ерак җирләрне гизеп кайтты, журнал өчен берәр нәрсә хәзерлиме? Мәсәлән, для начала, юл язмалары? Ә Саҗидәкәй үзе быел безне нәрсә язып куандырачак? Аккош күленә килгәч сөйләгән планнары тормышка ашып бетәме? Әллә бүтән берәр нәрсә язамы?

Тагын көз, кар, тайгак, грипп, тамак төпләре кытыклана, тагын җиде ай көтәргә кирәк, яшел яфракны күрергә зар вә интизар булып бетәргә туры килә, ярый әле, тәрәзә төбендә гөлләр бар, шуларга карап алам.

Сәлам белән: **Ибраһим Гази.**

P. S. Сезнең китап кибетендә «Детская энциклопедия»нең сәнгатькә (искусствога) багышланган саны (10 булса кирәк) юкмы икән?[1]

*14 ноябрь, 1968 ел. Казан.*

Итәгатьсез Саҗидә!

Ике хатыгызны да алдым. Шигырь турында бәхәскә дә кермәкче идем дә, шагыйрьләрнең көе скрипка көе кебек, я үпкәләтеп куярмын дип, ул кофер уемнан кайттым. Җибәргән шигырьләрегезне түкми-чәчми Арсланга[2] кертеп тапшырдым.

Ритм мәсьәләсенә килгәндә, һәр чатанның үз ритмы булган кебек, һәр шагыйрьнең үз ритмы... Шул хәтлесе кызык: шигырьне мактасам, бу кеше шигырьне аңламый димиләр, тәнкыйтьләсәм — аңламый диләр. Димәк, аңлаучы исемен күтәрү өчен, шагыйрьләрне мактарга кирәк!

Сез бик тырышып яклаган Әнвәр Давыдовның беренче поэмасын мин җыелышларда мактап чыккан кеше. Димәк, мин шигырьне аңлыйм икән! Робертның[3] ул шигырен аңлау өчен, кытайча, һич югында, кырмыска телен белергә кирәктер.

Чөнки ул, форма белән чамадан тыш мавыгып китеп, гап-гади генә нәрсәне — җөмлә аңлашылуы кирәклеген онытткан. Робертның «Таш аргамагы»н менә яраттым. Гомумән, Робертның шигырьләре миңа ошыйлар — талантлы егет.

Димәк, мин шигырьне аңлыйм булып чыга түгелме соң?

Тәнкыйтьләсәм, тагын аңламыйм булып чыгачак!

Әдипкә сәлам. «Сахалины» газетада чыга башлады.

Сәлам белән: **Ибраһим Гази.**

*5 май, 1970 ел. Казан.*

Саҗидә, сәламәтмесез!

Карт кешене бөтенләй онытып ташламаганыгыз өчен рәхмәт.

Җибәргән шигырьләрегезне укып чыктым (байтактан), язмый торуның сәбәбе: үзем Әлмәт ягына ниятләп торган идем, авырып киттем, бара алмыйм.

Аңлый алуым ни дәрәҗәдәдер, мин шигырьләрнең бик күбесенә «әйбәт», «матур», «матур гына», «мәгънәле шигырь» дип язгалап куйдым. «Табигый матурлык җитми», «аңашып бетми», «мәгънәсен аңлап булмый, сизенеп кенә була» дип язганнарым да бар. «Иртән» дигән шигырьгә «строфалар рассыпаются, җилем юк» дип язып куйганмын; «Фәридә»гә «артык сузылган» дип резолюция салганмын. «Бергә чакта каен утын яктык» дигән шигырьгә, мәсәлән, «матур» дип куйганмын.

[1] Бу хатның датасы билгесез. Эчтәлегенә караганда, ул 1968 елның көзендә язылган булырга тиеш.
[2] Арслан — күренекле шагыйрь Нури Арсланов, ул елларда «Казан утлары» журналының поэзия бүлеге мөдире булып эшли.
[3] Шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов, аның «Сәгать суга» дигән шигыре турында сүз бара.

«Матур» сүзенә мин «мәгънәсе бар, шигъри эшләнеше яхшы» дигән мәгънә салам. «Этюд»ка, «Көзләр якты быел»га, «Чишмә», «Ай кашы», «Уфа минем яшьлегем», «Улыма», аннары тагын берничә «...» өч түрткеле шигырьгә (исемсез шигырьгә — ред.) менә шулай «матур» дип куйганмын.

Теләсәгез, бер очрашканда җыентыкны күрсәтермен, анда бүтән язулар да бар. Әгәр мине укып чыгып, шундый тамгалар салып чыксалар, мин бик куаныр идем.

Кыскасы, лирикага Сездә осталык бар, интимныйрак лирикага дип тә өстәргә була.

Исәнлек-саулык теләп: **Ибраһим абыегыз.**

Әдипкә дә сәлам әйтегез.

P. S. Миннән алып киткән гөлләргә сәлам.

**И. Г.**

## Беренче китап

Ананың беренче баласы, өй кыегындагы беренче сыерчык, куктә сайраган беренче тургай күңелгә бик якын була. Язучының икенче китабы да чыга, икенчесе, бәлки, беренчесеннән яхшырак та була торгандыр, ләкин язучы күңеле өчен барыбер беренчесе кебек үк газиз булмый.

Башлап язучы Мөдәррис Хөсәенов иптәш үзенең «Борылыш» исемле[1] беренче хикәяләр җыентыгын бастырып чыгарды. Аның хикәяләрендәге кешеләр безнең барыбызга да таныш: без аларны күреп, я ишетеп беләбез. Колхоз тәртәсенә керергә теләмичә, шәһәр урамнарында «озын акча» артыннан куып йөрүче «ала канат», «адашкан каз» Габдрахман, колхоз өчен резервлар табарга яратучы һәм шуның өчен «син үзең бик зур резерв» дигән мактау сүзләре ишеткән Мәгъсүм агай, берсе дүшәмбегә, берсе чәршәмбегә карап яшәүче ике кода — Сәмигулла белән Сәхип карт, кыек күңелле һәм туры күңелле ике күрше Хөршидә белән Мәрьям — мондый кешеләрнең тормышта барлыгын без гомумән алганда белә идек, менә хәзер аларның конкрет йөзләрен дә күрдек. Берсе өчен куандык, икенчеләре өчен көендек.

Ә Хөсәенов, үзенең геройлары белән бергә яшәү сәбәпле, кешеләрнең уң ягын да, сул ягын да бик белеп яза. Ул аларны әле бу якка, әле теге якка әйләндереп, төрле яклары белән укучыга күрсәтә. Менә карагыз әле сез Әсәдулла агайны, ди ул безгә, илле сумлык облигациясенә биш мең отты да саклык кассасына салырга куркып йөри. Янәсе, кем белә бит аны саклык кассасы мөдире Шәйморатовны! Акчаны алуын алыр да, соңыннан бирмәсә нишләрсең? Юк инде, кесәдә ятканы хәерле! Без Әсәдулла агайның юкка өркеп йөрүләреннән көләбез. Ә менә авторота шоферы Рәис бөтенләй икенче калыпка калыпланган кеше. Машинасына ялгыш килеп эләккән ят чемоданның хуҗасын табарга тырышып, җан талашып эзләп йөри ул.

Хикәя укылсын өчен, аның сюжеты кызык булырга тиеш дип баручылар юк түгел. Хөсәеновның хикәяләрендә кызыклы сюжет бөтенләй юк, ә хикәяләрен ялыкмыйча укып була, чөнки без андагы кешеләрнең үзләре белән мавыгып китәбез. Гади сюжет, гади вакыйгалар, гади кешеләр, ә шулай да кызык! Шул ук вакытта бик мавыктыргыч сюжетлы хикәяләрне дә ахырына хәтле укыйсы килмәгән чаклар була. Димәк, эш кызыктыргыч сюжетта гына түгел икән, ә хикәяләрдәге кешеләрдә икән.

Язучыны беренче китабы, беренче уңышы белән котлап, алда иптәш Хөсәенов кешеләрнең характерындагы төрле үзенчәлекләргә күбрәк игътибар итсен иде диясе килә.

---

[1] Мәкаләнең язылу вакыты билгесез. М. Хөсәеновның хикәяләр җыентыгы Татарстан китап нәшриятында 1959 елда басылып чыга.

# УЛ БЕЗГӘ ДӘ КАДЕРЛЕ

Урта Азия кешеләре элек-электән тугандаш татар халкы белән якыннан аралашып, Тукайча әйткәндә, «тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып» яшәгәннәр. Алар арасындагы кардәшлек җепләре Төркестан җирләре Россиягә кушылганнан соң тагын да ныгый төшә. Бу вакытта үзбәк, казакъ һәм башка халыклар арасына прогрессив идеяләр белән сугарылган рус әдәбияты үтеп керә башлый, татар әдәбиятының йогынтысы көчәя. Күренекле татар әдипләренең Казан матбугатларында басылган китапларын үзбәкләр, казакълар, каракалпаклар һәм башка төрки халыклар кулдан-кулга йөртеп укыйлар. Габдулла Тукайның күп санлы шигырьләре, Фатих Әмирханның чәчмә әсәрләре киң тарала. Соңга таба боларга Галимҗан Ибраһимовның хикәяләре, романнары өстәлә.

Октябрь революциясенә кадәрге елларда ук инде үзбәк һәм казакъның талантлы яшь шагыйрьләре, язучылары татар әдипләренең яңа әсәрләрен, публицистик язмаларын яратып укыйлар. Г. Ибраһимовның «Карак мулла», «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» кебек хикәяләре укучылар арасында популяр була. Психологик планда язылган «Яшь йөрәкләр» романындагы геройларның язмышы күпләрне уйландыра. Урта Азия халыкларының яшь талантлары аның иҗтимагый-политик темаларга язылган мәкаләләрен, яңа әдәби әсәрләргә рецензияләрен укыйлар, күренекле әдипнең әдәбият тарихына кагылышлы фикерләре белән кызыксынып торалар.

Бу чорда Галимҗан Ибраһимов Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә педагог һәм тәрбияче буларак та зур эш алып бара.

«Галия»дә ул укыган лекцияләр әдәби-иҗтимагый мәсьәләләрне бөтен тирәнлеге белән кую, тормышка бәйләнештә каралуы белән кызыктырган. Галим һәм педагог Галимҗан Ибраһимов төрле милли әдәбиятларның үзара мөнәсәбәтләре, бер-берсен баетулары турында сөйли. Яшьләрне әдәбият тарихын, көнбатыш һәм көнчыгыш каләм осталарының бай мирасын өйрәнергә, рус прогрессив әдәбиятының традицияләрен үзләштерергә өнди.

Мәдрәсә шәкертләре арасында казакъ һәм үзбәкнең яшь язучылары, шагыйрьләре Мирмөхсин Шермөхәммәдов, Лотфулла Галими, Бәймбет Майлин һәм башкалар булган. Остазлары аларның эшчәнлегенә юнәлеш биреп, бу өметле яшьләрне үзбәк, казакъ әдәбиятларын үстерүгә өлеш кертерлек шәхесләр итеп тәрбияләргә омтылган. Бу юлда Г. Ибраһимов салган эзләр тарих тузанына күмелерлек түгел.

Галимҗан Ибраһимов чәчкән орлык уңдырышлы туфракка төшә. Аның йогынтысы астында үскән яшь язучылар зур күләмле беренче әсәрләрен язалар. Үзбәкстанда яңа реалистик проза, публицистика һәм драматургия формалаша. Хәмзә үзенең «Милли роман»ын яза. Абдулла Кадыйри «Бәхетсез кияү», Мирмөхсин Шермөхәммәдов «Баласыз Ачилдибай», «Карт Төркестан XX гасырда», «Зиндан» (1916—1917) кебек әсәрләрен иҗат итәләр. Боларда Г. Ибраһимов йогынтысы ачык күренә.

Татар әдәбиятының, аерым алганда, Г. Ибраһимовның үзбәк язучыларына йогынтысы Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң тагын да көчәя. Тәнкыйть шуны ачыклый: «Безнең көннәр», «Казакъ кызы» әсәрләрендә сурәтләнгән вакыйгалар Төркестан якларындагы конкрет-тарихи шартларга бик туры килә. Алай гына да түгел, әлеге вакыйгалар шушындагы тормышның социаль бәрелешләр кайнап торган урыныннан алынган шикелле. Персонажларның теле дә үзбәк укучыларына бик аңлаешлы. Геройлар хәрәкәт иткән мөхит, аларның гадәт-йолалары да Үзбәкстан кешеләренә якын. Әсәрдә күтәрелгән социаль проблемалар исә нәкъ менә алар хәл итәргә тиешле мәсьәләләр сыман. Менә шуңа күрә дә Г. Ибраһимовның бу әсәрләре безнең як укучылары арасында киң тарала, үзбәк язучылары даирәсендә зур кызыксыну белән укыла.

Үзбәкстанда реалистик проза жанрына нигез салучы Абдулла Кадыйри, Галимҗан Ибраһимов иҗатына югары бәя биреп, «Безнең көннәр» романында сурәтләнгән тарихи вакыйгаларның үзбәк халкы тормышына да хас һәм характерлы булуын билгели.

Урта Азиядә әдипнең хикәяләре һәм романнары гына түгел, галим сыйфатында башкарган хезмәтләре — татар халкының революцион көрәш сәхифәләренә багышланган мәкаләләре дә киң тарала. Ә язучылар аның әдәбият теориясе буенча хезмәтләрен өйрәнәләр.

Революциядән соң Г. Ибраһимов безнең үзбәк язучылары белән аралашып, хат алышып тора. Ул Үзбәкстанга барырга, республиканың тормышын үз күзләре белән күрергә дә бик теләгән. Профессор Булат Салиев, башка үзбәк язучылары аны Ташкентка чакырып хатлар язалар, очрашкан чакларда кунак булып килергә өндиләр.

Күренекле татар әдибенең хикәяләре һәм романнары Мирмөхсин Шермөхәммәдов белән Абдулла Кадыйри иҗатына аеруча шифалы йогынты ясый. Кадыйриның 1925 елда язылган «Үткән көннәр» романында Урта Азия халыкларының бүлгәләнгән булуы, алар арасында XIX йөзнең кырыгынчы елларында барган сугышлар сурәтләнә. Тарихи фонны гәүдәләндерүдә автор Г. Ибраһимовтан өйрәнә, аңа хас алымнар белән эш итә. Төп геройлар — Атабәк һәм Көмешнең мәхәббәте тарихи вакыйгаларга бәйләп сурәтләнә. Алар — бер-берен яраткан ике яшь йөрәк — үз бәхетләре һәм халык бәхете өчен көрәшкә күтәреләләр. «Менбәрдәге чаян» әсәрендә үзбәк язучысы ханлык тәртипләрен тәнкыйть итә, гаделсезлеккә каршы чыга. Әсәрнең баш геройлары гаделсезлектән котылу юлын ак патша карамагындагы Ташкентка китүдә күрәләр. Төп хикмәт аларның кая китүендә түгел, бәлки гаделсезлекне аңлап, аңа каршы чыгуларында һәм бу гаделсезлектән чыгу юлын эзләүләрендә. Әсәрнең «Казакъ кызы» романы белән аваздаш булуы да геройларның шушы сыйфаты белән билгеләнә ала. Мөселман хатын-кызлары хөрлек һәм тигез хокук даулап көрәшкә күтәрелә. Мондый образ ул чор үзбәк әдәбиятында җитди һәм кыю адым була. Андый иҗади кыюлыкны үзбәк әдибенә Г. Ибраһимов үрнәге бирә.

Билгеле булганча, Кадыйри егерме бишенче елларда Мәскәүдә укый. Аның белән бергә Үзбәкстан китап нәшриятында эшләгән тәрҗемәче һәм журналист Сәхәват Шәфигуллинның истәлекләренә таянып, шуны әйтә алабыз: Кадыйри татар язучысы Кәрим Тинчурин белән бергә Мәскәү китапханәләрендә рус классик әдәбиятын өйрәнә, Көнбатыш Европа әдипләрен һәм татар язучыларын укый. Галимҗан Ибраһимовны ул иң яраткан язучысы итеп һәм остаз дип саный.

Шагыйрь Алтай 1976 елда «Шәрыкъ йолдызы» журналында «Иҗат — үлемсез» дигән истәлек-мәкалә бастырды. Аның әйтүенчә, А. Кадыйриның бик яратып укыган китапларыннан берсе «Безнең көннәр» романы булган. Үзенең тарихи романына «Үткән көннәр» дигән исем бирүен дә уйласак, күп нәрсә ачыклана.

Шул чордан башлап, Үзбәкстанда Г. Ибраһимов иҗаты белән кызыксыну елданел көчәя бара. Егерменче еллар ахырында әдипнең юбилее үткәрелә. Шул уңай белән республикада аның әсәрләре үзбәкчәгә тәрҗемә итеп басыла. Вакытлы матбугатта Г. Ибраһимовның тормышы һәм иҗат юлы турында мәкаләләр чыга. Шун-

дыйлардан Ш. Сөләйманның «Егерме еллык әдәби хезмәтләр» («Мәгариф вә укытучы» журналында), З. Бәширинең «Галимҗан Ибраһимов юбилее» дигән мәкаләсе («Кызыл Үзбәкстан» газетасы, 1927 ел, декабрь) игътибарга лаек. «Киләсе елда күренекле татар язучысы Г. Ибраһимовның егерме еллык юбилее булачак,— дип яза Шакир Сөләйман.— Бу талантлы әдип халык арасында киң танылган. Без аның юбилеен түземсезлек белән көтәбез».

Галимҗан Ибраһимовның күп кырлы, тирән мәгънәле, сәнгатьчә эшләнеш ягыннан кабатланмаслык иҗаты белән кызыксыну безнең көннәрдә тагын да көчәйде. Соңгы елларда гына үзбәк телендә аның «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар» һәм башка әсәрләре басылып чыкты.

Язучының 70 һәм 80 еллык юбилейларын, тугандаш Татарстан халкы белән бергә, бөтен Урта Азия хезмәт ияләре, шул исәптән безнең Үзбәкстан җәмәгатьчелеге дә бик зурлап үткәрде. Бәйрәм уңае белән, Урта Азия һәм Казагыстан матбугаты битләрендә Мохтар Ауэзов, Сабит Моканов, Берди Кербабаев, Гафур Гөләм, Иззат Солтанов кебек күренекле әдипләрнең мәкаләләре басылды. Алар барысы да Галимҗан Ибраһимов иҗатының үзбәк, казакъ, төркмән әдәбиятларына йогынтысын раслыйлар, тормышның тирән агымнарын сурәтләгән бу иҗатка югары бәя бирәләр.

Әдипнең 90 еллык бәйрәме дә безнең борынгы үзбәк җирендә, гомумән, бөтен Урта Азиядә милли әдәбиятларның туганлык бәйрәме итеп үткәрелә. Галимҗан Ибраһимов исеме барыбызга да кадерле.

**ШЕРАЛИ ТУРДЫЕВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

Шамил Монасыйпов

# СЫЗЫЛЫП КЫНА МОҢ ЧЫККАНДА...

*Татар кыллы музыка сәнгате тарихыннан*

Татар кыллы музыка сәнгате тарихы, аерым алганда, сызгыч ярдәмендә уйнала торган музыка кораллары тарихы, моңарчы махсус рәвештә җентекләп тикшерелгәне юк[1]. Хәлбуки, сызгыч (кыяк) белән башкару ысулы дөньякүләм музыка культурасы үсешендә дә, һәр аерым халыкның музыка сәнгате үсешендә дә күренекле урын алып тора. Кылга сызгыч сыздыртып аваз чыгару ысулы безнең эраның VIII—IX йөзләрендә Азиядә барлыкка килә. Иң бөек культура казанышлары рәтенә кертелергә лаек булган бу ачыш, Б. Асафьев[2] әйтүенчә, инструментчылыкны «кешелеклеләндерү»гә, аны кеше рухына якынайтуга ярдәм итә. Ә бу исә, үз чиратында, уен коралларында көй башкаруның музыка сәнгатендә мөстәкыйль төр буларак аерылып чыгуы өчен гаять мөһим этәргеч ясый. Кыллы (сызгычлы) музыка коралларының халык арасында таралуы инструменталь музыканы халык күңеленә якынайтуга җирлек әзерли; алар ялгыз башкаруга җайланган уен коралы булып җитешә. Җыр сәнгате белән тыгыз бәйләнештә торып, җыр культурасының иң югары казанышларын үзләренә сеңдерә барганлыктан, сызгыч белән уйнала торган инструментлар халык музыка сәнгатенең милли рухын һәм үзенчәлеген гаять дәрәҗәдә тирән чагылдыра. Шуңа күрә дә сызгыч белән башкарыла торган кыллы музыка сәнгатен өйрәнү халыкның музыкаль культурасы хакындагы мәгълүматыбызны баета, музыкаль культура үсешенең аерым этапларын күзалларга, халык музыкасының һәм башкаручылыгының үзгә йөзен, үзенчәлекле сыйфатларын ачыкларга ярдәм итә. Соңгысының исә теоретик яктан гына түгел, практик яктан да әһәмияте бар.

Бу мәкалә татар сызгычлы сәнгатенең башлангыч чорларын чамаларга, аның үсешендәге кайбер төп моментларны билгеләргә омтылу максатыннан чыгып язылды. Шунысын әйтергә кирәк, татар музыкасының элгәрге чорлары турында безгә килеп җиткән мәгълүматларның җитәрлек булмавы мәсьәләне шактый катлауландыра[3].

Татар халкының уен кораллары һәм башкаручылык сәнгате тарихи яктан борынгы шәрык музыка культурасы белән тыгыз бәйләнгән. Төрки халыклар берничә мең ел белән исәпләнелә торган төрле тарихи чорларда Хорәзм, Иран, Гыйрак (Месопотамия), Кытай халыклары белән якыннан аралашып яшәгәннәр. Көнчыгыш һәм Көнбатыш Азия, Көнчыгыш Европа халыклары арасында музыка кораллары алмашуга еш

---

[1] Сүз сызгыч ярдәмендә уйнала торган кыллы музыка кораллары сәнгате хакында бара.
[2] Б. Асафьев. Музыкальная форма как процесс. Икенче китап. Интонация. Мәскәү, 1947 ел, 13 бит.
[3] Бу хакта кара: М. Нигъмәтҗанов. «Халык музыкасы» исемле мәкалә. «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» дигән китаптан. Мәскәү, 1967 ел.

кына алар сәбәпче булган. Бу хәл кыллы музыка коралларының төрле төбәкләрдә киң таралуына ярдәм иткән [1].

Бүгенге заман галимнәре уйлавынча, сызгычлы ысул белән аваз чыгару Урта Азиядә барлыкка килә. Кайбер тикшеренүчеләр төркиләрне көй башкаруның шушы ысулын ачуга турыдан-туры катнашы булган, аны практикада беренче булып куллана башлаган халыклар дип уйлыйлар. Мәсәлән, М. Р. Газимиһалнең «Азия һәм Анатолиядә сызгычлы инструментлар» дигән хезмәтендә шундый фикер алга сөрелә [2]. Урта гасырда яшәгән галимнәрнең хезмәтләрен һәм борынгы шәрык музыка коралларын тикшергәннән соң, ул сызгычлы ысул белән көй чыгару төрки телле уйгурларның музыкаль практикасыннан киткән дигән нәтиҗәгә килә.

Чыннан да, кайбер тарихи язмаларны күздән кичерсәк, без борынгы төркиләрнең музыкаль культурасында сызгыч белән авазлар чыгару ысулының тууы өчен кайбер алшартлар булуын күрербез. Безнең эраның беренче мең еллыгының икенче яртысында Кытай чыганакларында хәбәр ителгәнчә, уйгурларның тормыш-көнкүрешендә кыллы музыка кораллары киң кулланышта булган һәм алар «сузынкы, озын» көйләрне «бүреләр төсле улап» җырларга яратканнар [3]. Менә шушы хәл, күрәсең, аларны көйнең озын һәм салмак та, моңлы да яңгырашын тудырырлык яңа чаралар эзләүгә этәргән. Кыллы музыка коралларына борынгы төркиләр аеруча зур хөрмәт белән караганнар. Европага Азия культурасы казанышларын алып килгән төркиләр сызгычлы музыка инструментларының Көнчыгыш Европа халыклары арасында таралуында зур роль уйнаганнар. Хосусан алганда, әлеге музыка коралларының көньяк славяннар арасына үтеп керүен галимнәр Балкан ярымутравына төрки кабиләләр килүгә бәйле рәвештә аңлаталар. Ә көньяк славяннар сызгычлы яңа ысул белән аваз чыгаруны Европа халыклары арасында беренчеләрдән булып үзләштергәннәр дип исәпләнелә [4]. Көнчыгыш дөньясын Көнбатыш белән бәйләүче үзәкнең икенче берсе Идел буе була. Идел — Кама буенда оешкан Бөек Болгар дәүләте Европа һәм Азия континентлары арасындагы эре сәүдә һәм культура үзәге булып тора. Болгарлар үзләре акча сугалар, Европада беренче булып корыч коюны үзләштерәләр, монда һөнәрчелек нык үсеш ала, көнкүреш сәнгате югары дәрәҗәгә ирешә. Болгарлар Урта Азия, Иран һәм башка шәрык илләренең культура казанышлары белән яхшы таныш булалар. Ибн Фадлан, мәсәлән, болгарларның тамбурга охшаш кыллы музыка инструментын телгә ала [5]. Сызгычлы музыка коралының Идел буена нәкъ менә болгар чорында, алар белән бергә үтеп кергән булуы бик ихтимал.

Шунысын да әйтеп үтик, шәрык культурасының җимешләре болгарлар аша Көнчыгыш Европаның башка төбәкләренә дә тарала. Болгар дәүләте рус һәм Балтик буе илләре белән шактый тыгыз сәүдә мөнәсәбәтләрендә тора. Сызгычлы уен коралларына килгәндә исә, ул Көнчыгыш Европага, аерым алганда, славяннарга Балкан дәүләтләре аша гына түгел, Болгар иле аша да кергәндер дип уйларга нигез бар. Борынгы руслрга болгар культурасының уңай йогынтысы булуын тикшеренүче галимнәр дә инкарь итми [6].

Борынгы төркиләрнең төп уен коралы кобыз [7] булган. «Чын төрки инструменты»

---

[1] Фәнни тикшеренүчеләр раславынча, Көнчыгыш Азиядән Иранга, Месопотамиягә төркиләр аша күп кенә музыка кораллары, шул исәптән, кыллы инструментлар (мәсәлән, ятаган) үтеп кергән. Кара: Grove's Dictionary of music and musicians. VIII том, Лондон, 1954 ел, 510 бит.

[2] M. R. Gazimihâl. Asya ve Anadolu kaynaklarinda Iklig. Ankara, 1958, ел, 8—9 битләр. Тагын: W. Bachmann. Die Anfänge des Streichinstrumentenspiels. Лейпциг, 1964 ел, 54—70 битләр.

[3] Н. Я. Бичурин (Иакинф). Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. I том, Мәскәү — Ленинград, 1962 ел, 205, 216, 231 битләр.

[4] Н. И. Привалов. Гудок, древнерусский народный музыкальный инструмент, в связи со смычковыми инструментами других стран. Санкт-Петербург, 1904 ел, 16 бит.

[5] Frähn. Ihn Fozlan's und anderer Araber Berichte über die Russen älterer Zeit. 1823 ел, 15 бит.

[6] А. П. Смирнов. Волжские булгары. Мәскәү, 1951 ел; Ф. Х. Валеев. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1975 ел. Идел-Кама якларында яшәүче фин-угор телле халык һәм кабиләләр сызгычлы музыка коралын Идел буе төркиләреннән кабул иткән дип әйтергә мөмкин. Инструментның төрки исем белән (мариларда — «ковыж», чувашларда — «купас») йөртелүе һәм формасының охшаш булуы шул хакта сөйли.

[7] Музыка белемендә бу борынгы атама төрлечә язылышта һәм әйтелештә (кобуз, кобыз, кобас, кобза һ. б.) йөри. Татарларда «кубыз» дип әйтелә. Ләкин XIX—XX йөзләрдә бер телле варганны да кубыз дип йөртә башлаганнар һәм шул исем аңа нык ябышып калган. «Кубыз»ны куллану һәр очракта өстәмә рәвештә аңлатып торуны таләп иткәнгә күрә, без борынгы төрки сүзлекләрендәгечә — «кобыз» формасын алуны мәгъкуль санадык. — Авт. искәрмәсе.

кобызның ике төре — бармак белән чиертеп һәм сызгыч белән сыздырып уйный торган төрләре кулланылган [1]. Башкаруның яңа ысулы — сызгычлы ысул барлыкка килсә дә, инструментның исеме үзгәрми һәм һәр ике уен коралы да озак вакытлар төркиләрдә бер үк исем белән йөри.

Кобыздан башка төркиләрнең «бучи» яки «кунхау» дип аталган арфага охшаш кыллы инструментлары булган. Аны татар гөсләсенең ерак бабасы дип тә әйтергә мөмкин.

Ике төрле кобызның бер үк исем белән аталып йөртелүе сызгыч барлыкка килгән чорда бер үк инструменттан төрлечә файдаланганнар, сызгыч белән сыздырып яисә чиертеп уйнаганнар дигән фикергә китерә. Корпусы белән лютняны хәтерләтүче ул инструментка бер яки ике (соңрак өч) кыл беркетелгән булган.

Күчмә төрки кабиләләр тормышында кыллы кобызның нинди урын алып торуы, ни дәрәҗәдә таралган булуы хакында угыз эпосы «Дэдэ Коркыт»тән чыгып фикер йөртергә мөмкин. Унынчы йөзгә караган әсәр булса да, аңарда төркиләрнең элгәрерәк чорлардагы яшәешләре дә чагылыш таба. Легендар җырчы һәм музыкант хакында бәян итүче ул әсәрдән алынган мәгълүматлар болгар-татарларның үткәненә дә якыннан кагыла. Монда аның безгә әнә шул ягы әһәмиятле [2].

Коркыт хакындагы легендалардан кобыз профессиональ җырчы-музыкантларның төп уен коралы булып аңлашыла. Борында узан яки озан дип йөртелгән профессиональ җырчылар арасында кобызның киң таралган булуын академик В. А. Гордлевский да күрсәтеп үтә. Проф. М. Ф. Кепрюлюзадәнең «Төрек әдәбиятының әрмән әдәбиятына йогынтысы» дигән фактик материалга бай хезмәтенә таянып, ул «алгы Азия төркиләрендә генә түгел, башкаларында да Атилла чорында ук хәзерге ашыкларны хәтерләтүче җырчылар булган, алар халык бәйрәмнәрендә һәм бәк сарайларында җырлый торган булганнар», дип яза [3].

Угыз эпосыннан күренүенчә, кобыз югары катлау кешеләре арасында да, халык көнкүрешендә дә күренекле урын тоткан. Тантаналы вакыйгалар, төрле йола бәйрәмнәре аннан башка үтмәгән; хәрби походта да ул күчмә сугышчының юлдашы булган [4]. Мәҗүси төркиләрдә мәет янына кобыз куеп күмү йоласы булуы да билгеле. Коркыт турындагы эпоста, аны изге санап, кобызы белән бергә күмәләр. «Каберенә кобызны куйдылар... аның сагышлы авазларында Хөр-Хет исеме ишетелә иде» [5], диелә риваятьтә. Монда бер сызгычлы инструмент хакында сүз бара дип уйлыйбыз. Текстта җырчының исеме аваз ияртемнәре ярдәмендә ясалганлыгы сизелә. Чыннан да, кылларга сызгыч белән кагылганда хырылдавыклы авазлар чыга һәм Хөр-Хет сүзенең яңгырашында сызгычлы уен коралына хас шушы үзенчәлек чагылыш таба.

Төрки телле халыкларның ислам диненә кадәрге гореф-гадәтләреннән хәбәр бирүче бу эпос безнең эраның беренче мең елы ахырларында инде төрки халыклар сызгычлы инструмент белән яхшы таныш булганнар дигән фикер тудыра. Казагыстанда язып алынган легендаларда [6], мәсәлән, Хөрхетнең бахшыларны кобызда уйнарга өйрәтүе хакында әйтелә. Ә казакъ бахшыларының уен коралы булып сызгычлы кобыз хезмәт иткәнлеге билгеле нәрсә [7]. Хөр-Хет сүзенә кире кайтып, шуны өстик: ул исем

---

[1] H. Vambery. Das Türkenvolk in seinen ethnologischen und ethnographischen Bezichungen. Лейпциг, 1885 ел, 192 бит. Бу урында шуны искә алып үтик: урта гасырда Европада фидель дип аталган инструментның шулай ук ике формасы — чиертеп һәм сыздырып уйный торган формалары булган. (Н. Исәнбәт кобызның бер төрен «кыл кубызы», икенчесен «кул кубызы» дип атый. Татар халык мәкальләре, III том. Казан, 1967 ел, 569 бит. (Редакция искәрмәсе.)

[2] Тарихтан мәгълүм ки, угызлар болгарларга кардәш һәм күрше кабиләләр булганнар, аралашып яшәгәннәр. Алар арасындагы охшашлык антропологиядә дә, материаль һәм рухи культурада да, гореф-гадәт һәм телдә дә чагыла. (Кара: С. Г. Агаджанов. Огузские племена Средней Азии IX—XIII вв. «Шәрык илләре һәм халыклары» исемле китаптан очерк. X чыгарылыш, Мәскәү, 1971 ел; А. Х. Халиков. Татар халкының килеп чыгышы. Казан, 1974 ел һ. б.)

[3] В. А. Гордлевский. Сайланма әсәрләр. III том, Мәскәү, 1962 ел, 264 бит.

[4] Угыз риваятьләренең берсендә, мәсәлән, бөек Казан-бәк җырларга теләк белдереп, кобыз сорап ала. Кара: В. В. Бартольд. Книга моего деда Коркута. Мәскәү — Ленинград, 1962 ел, 94—95, 113—114 битләр. Кобызда оста уйнаучы принц хакында икенче бер борынгы төрки чыганагында (X йөз) искә алына. P. Pelliot. La version ouigore de l'histoire des princes Kalyānamkara et Papamkara. T'oung Pao. Лейде, 1914 ел, XV том.

[5] П. С. Спиридонов. Один из вариантов легенды о Хор-Хуте. Төркестан археология сөючеләр түгәрәге протоколлары. XIII кисәк, Ташкент, 1909 ел, 19—20 битләр. Унынчы йөздә Идел буе Болгар дәүләтенә килгән гарәп сәяхәтчесе Ибн Фадлан мәет янына, иң хаҗәт әйберләр белән бергә, кыллы музыка инструменты күмү йоласы хакында сөйли.

[6] Ч. Ч. Вәлиханов. Әсәрләр. Санкт-Петербург, 1904 ел, 29 бит.

[7] А. Жубанов. Струны столетий. Алма-Ата, 1958 ел, 6, 18 битләр.

түгел, ә кушамат. Заманы өчен гадәти булмаган яңа ысул — сызгыч белән уйнаганга, җырчыны шулай атаганнар.

Сызгыч белән уйнау угызларга яхшы таныш булса, болгарлар өчен дә ул ят нәрсә булмаган. Чөнки, әйткәнебезчә, алар угыз кабиләләре белән аралашып яшәгәннәр һәм рухи тормышлары белән алардан аз аерылып торганнар.

Татарларда сызгычлы сәнгатьнең ничек үсүе мәсьәләсенә күчкәнче, бу төр инструментларда уйнауның ялгыз җырлауга бәйләнешен карап үтик. Риваятьләрдә сөйләнгәнчә, Коркыт легендар кобызчы гына түгел, җырчы да булган. Ул чыгарган җырларны узаннар, бахшылар, халык җырчылары отып алганнар. Алар да, Коркыт кебек үк, кобызда уйнап җырлаганнар. Күп кенә борынгы гореф-гадәтләрне саклап калган Әстерхан һәм Оренбург нугайларының музыкаль традицияләрен өйрәнгән В. А. Мошков XIX йөз ахырында болай дип яза: «Табиплык һөнәреннән тыш, бакса күп очракта халык риваятьләрен һәм җырларын да яхшы белә. Җырларны алар туйларда һәм башка тантаналы очракларда башкаралар...» [1]

Сызгычлы инструмент төрки җырчы-рапсодлар арасында популяр булса, чиертеп уйный торган кобыз биюче-музыкантлар тарафыннан киң кулланыла. Бу очракта ул күбесенчә башка уен кораллары белән ансамбль тәшкил итә [2]. Сызгычлы кыл кобызы бию һәм күмәк күңел ачулар вакытында бик киң кулланылмый. Күренекле тюрколог Г. Вамбери дә, күчмә кабиләләр тормыш-көнкүрешендә кыл һәм кул кобызларының нинди урын тотуы хакында сөйләгәндә, беренчесенең ролен җырга иярү белән чикли [3]. Бу аңлашыла да. Күмәк күңел ачу вакытында көчле һәм кискен ритмлы көйләрне башкару өчен чиертеп уйный торган инструментлар кулайрак. Сызгычлы инструментта уйнаганда көйнең яңгырашы сизелерлек зәгыйфьләнә, ә аны көчәйтү башкару техникасын үстерү, инструментны камилләштерүгә бәйле. (Ә бу гасырлар буена сузыла торган процесс.) Әмма, аның каравы, сызгычлы уен коралы музыкаль авазларның озынлыгын арттыра, көйнең сузынкы һәм моңлы яңгыравына ирешергә мөмкинлек бирә. Төрки халыкларның җырлары бер тавышлы характерда булганлыктан, инструментта уйнаучы һәм җырчы көйне унисон башкаралар, ягъни инструмент авазлары җырчы тавышына тулысынча тәңгәл килә. Шуңа күрә инструменттагы кыллар саны аның яңгыраш куәтен арттыруда сизелерлек роль уйнамый. Төркиләрнең сызгычлы кобызы озак вакытлар ике кыллы булып кала. Солтан Бабур язмаларына караганда, гыйҗеккә өченче кылны беренче булып XVI йөздә яшәгән музыкант Мөхәммәт Уди куйган. Сызгычлы инструментларның күмәк уеннардагы ролен күтәрү аның тавышын көчәйтүгә һәм яңгыраш сыйфатларын яхшыртуга бәйләнгән. Шушы юнәлештә тикшеренү алып барганда, кызык кына күренешкә тап булабыз. Казан татарлары көнкүрешендә кобызның тоткан урыны инде нык үзгәрә. Ул бию көйләрен башкару өчен дә киң кулланыла башлый. XIV—XVI йөзләргә караган чыганаклар әнә шул хакта сөйли. Сызгыч белән һәм чиертеп уйнала торган инструментлар бу чорда инде төрле исемнәр белән йөртеләләр. Беренчесе элеккечә «кобыз» дип, икенчесе «тамбур» сүзеннән үзгәртелеп «думбра» дип атала [4]. Әлеге атамалар беренче тапкыр «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дә очрый (Казан, 1882, 40 бит). Икенче бер әдәби чыганак — «Түләк һәм Сусылу» легендасында да без шундый ук хәлне күрәбез. Легенданың без танышкан вариантында [5] Түләк тарафыннан ясалган музыкаль «уенчык» турында сөйләнә. Кобыз, думбра һәм кундак [6] составындагы ансамбльне тәшкил итүче ул «уенчык»та бию көйләре башкарыла. Монда көйләрнең җырчы катнашыннан башка, ялгыз гына башкарылуы да игътибарны җәлеп итә. «Түләк һәм Сусылу» легендасындагы мондый мәгълүматлар очраклы нәрсә түгел. Казан чоры татарлары көнкүрешендә бию көйләрен башкарган музыкаль ансамбльләр составын-

[1] В. А. Мошков. Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края. Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре. XII том, 1 чыгарылыш, 1894 ел, кереш сүз.

[2] С. Абдуллаева. Әзербәйҗан халык музыка инструментлары. Баку, 1972 ел, 4 бит.

[3] H. Vambery. Das Türkenvolk... Лейпциг, 1885 ел, 192—193 битләр. Бу фикер Төркестан һәм Алтайны өйрәнгән башка галимнәрнең материаллары белән дә раслана. Мәсәлән, А. Параев. Алтай халык музыка кораллары. Горно-Алтайск, 1963 ел.

[4] Чиертеп уйнала торган инструментның исеме үзгәрү гарәп-фарсы тамбуры урнәгендә инструментның төзелеше үзгәртелү белән дә аңлатылырга мөмкин. Кайбер тикшеренүчеләрнең хезмәтләрендә тамбурның болгарларга да үтеп керүе әйтелә. Мәсәлән, Н. Финдейзен. Очерки по истории музыки в России. 1 том, 1 чыгарылыш, Мәскәү — Ленинград, 1928 ел, 58 бит.

[5] Ул вариант хакында безгә М. А. Усманов хәбәр итте.

[6] «Кундак», күрәсең, барабан яки бубен тибындагы уен коралы булгандыр.

да сызгычлы инструмент ныклы урын алып торган. Бу XVI йөздә билгесез рус авторы тарафыннан язылган «Казан тарихы» мәгълүматлары белән дә раслана. Аның авторы егерме еллар чамасы татарлар арасында яши, халыкның көнкүрешен, гореф-гадәтен яхшы белә. Бәйрәмнәрдә халыкның ничек күңел ачуы хакында язганда ул милли кыллы музыка коралларын да искә алып үтә. Казанлылар «...үзләренең гөсләләрендә һәм прегудницаларында уйнап... күңел ачалар... биилар, тирә-юнь шаулап, гөрләп тора...» [1], дип яза ул.

Текстны анализлаганда, «прегудница»ның сызгычлы инструментка туры килүе аңлашыла. Әлеге уен коралының динамик мөмкинлекләре бу чорда инде, димәк, шактый үсә, уен техникасы да камилләшә.

Кызганычка каршы, Казан чорында сызгычлы музыка коралларының кайсылары киңрәк кулланылуын, бу төр инструментның ни дәрәҗәдә үзгәреш кичерүен кистереп әйтүе кыен. Һәрхәлдә, музыка коралларына заман куйган таләпләрнең үсә баруы аларны камилләштерүгә этәрми калмый. Казан шартларында ул чорда ук, кобыз белән бергә, аның куәтлерәк авазлы кардәше гыҗек тә кулланылган булуы ихтимал.

Ул елларда татар кыллы музыка кораллары сәнгатенең торышына йомгак ясап, шуны әйтергә кирәк: бу төр инструментның бию көйләрен башкаруда кулланылуы, аваз-яңгыраш куәтенең артуы, башкарудагы яңа алымнар — болар барысы да инструменталь музыканың мөстәкыйль жанр булып бүленеп чыгу процессының көчәюе турында сөйлиләр. Һәм әгәр без татар сызгычлы музыка кораллары сәнгатенең формалашу тарихын шартлы рәвештә өч этапка: көйләрне инструментта җырчы белән бергә башкару, аның башка төр музыка кораллары белән бергә мөстәкыйль ансамбль сыйфатында аерылып чыгу юнәлешендә үсүе һәм башкаруның аерым төре буларак яши башлавы этапларына бүлеп карасак, Казанда инде икенче этапның гамәлгә керә башлавын күрәбез.

XVI йөзнең урталарыннан алып татар музыка сәнгате үсү өчен шартлар кыенлаша. Рус самодержаниесенең колониаль политикасы, Казан халкын авыл һәм бистәләргә күчерү, халык җырчы-музыкантларын эзәрлекләү, ислам диненең кысуы халык музыка сәнгатен торгынлык хәленә китерә. Казан татарларының музыкаль культурасы хакында бик аз мәгълүмат нигездә соңгы йөз илле елга, бигрәк тә XIX гасырның соңгы яртысына карый. XIX йөз чыганакларына килгәндә исә, тикшеренүчеләр аларда популяр Европа инструментларының кулланылуы турындагы мәгълүматларны гына очратканнар. Моның ничек аңлатырга соң? Кайбер тикшеренүчеләр борынгы татар музыка кораллары көнкүрештән ислам дине эзәрлекләве нәтиҗәсендә тулысынча кысрыклап чыгарылган дигән фикергә килделәр. Шушы концепция буенча әлеге чорда музыка инструментына яшәү мөмкинлеген бирә торган төп шарт — аның зәгыйфь, кечкенә яңгырашлы, чит кешеләрдән яшеренеп, посып уйнар өчен кулай булуы [2].

Шушы таләпкә җавап бирмәгән уен кораллары эзсез югалган инструментлар рәтендә карала. Барлык кыллы инструментлар, шул исәптән, кобыз, татар гөсләсе һ. б. әнә шундый уен кораллары исәбеннән саналып йөртелә. Аларның урынын зәгыйфь авазлы примитив уен кораллары — авыз кубызы, курай, камыш сыбызгы алган дип санала. «Татар халык мәкальләре» дигән хезмәтендә язучы һәм фольклорчы галим Н. Исәнбәт сызгычлы кобыз, саз, думбра, гыҗек кебек исемнәре халык авыз иҗатында гына калган уен кораллары мөселман руханиларының эзәрлекләве нәтиҗәсендә халыкның музыкаль практикасыннан күптән төшеп калуын күрсәтеп үтә. Кыл һәм кул кобызы урынын кечкенә тавышлы авыз кубызы алган, борынгы кыллы инструментның исеме дә шуңа күчерелгән дип саный [3].

Бу концепциянең йомшак ягы шунда ки, аның авторлары яңа инструментлар куллана башлаган чорны борынгы кыллы уен кораллары югалган чордан аерып куялар. Иске музыка коралларының кулланылыштан кысрыклап чыгарылуын урта гасырдагы дини эзәрлекләүләр чорына, яңаларының таралуын капитализмның интенсив үскән

---

[1] Казан тарихы. Мәскәү — Ленинград, 1954 ел, 149 бит.
[2] Татары Среднего Поволжья и Приуралья. Мәскәү, 1967 ел, 448 бит.
[3] Татар халык мәкальләре. Казан, 1967 ел, 3 том, 569 бит.



*Татар музыкантлары. Рус художнигы И. М. Прянишников рәсеме. 1888 ел.*

(XIX йөз) һәм Идел буе мөселманнары көнкүрешенә Европа культурасының тәэсире көчәйгән чорга кайтарып калдыралар. Мәсәлән, хәзерге Татарстанда скрипка XIX йөздә тарала башлаган һәм ул кайчандыр яшәештә булган кобыз урынын алган дип санала[1].

Хәлбуки, И. Георгиның мәгълүм хезмәтендә[2] кыл кобызы, думбра, күп кыллы гөсләкебек музыка коралларының әле XVIII йөзнең икенче яртысында көндәлек практикада кулланылуы бик ачык әйтелә. Ләкин кайбер тикшеренүчеләр бу мәгълүматларны типик түгел, ниндидер гадәттән тыш хәлләр китереп чыгарган очраклы күренеш диләр[3]. Бездеңчә, монда очраклылык турында сөйләп булмый. XVIII йөздә дә әле иске музыка кораллары шактый киң кулланылган. Шул ук вакытта аларга тагын да көррәк, ачыграк тавышлы скрипка килеп өстәлә. Менә шушы хәл югарыда әйтелгән концепциягә каршы килә, аңа тәнкыйть күзе белән карауны таләп итә. Шуның белән бергә, элеккеге кайбер музыка кораллары фәкать дин-шәригать әзерлекләве нәтиҗәсендә генә юкка чыккан дигән фикернең дә бәхәссез булмавы ачыклана.

Татарларда скрипка уйнау хакындагы без таба алган иң элгәрге мәгълүмат XVIII йөзнең беренче яртысына һәм урталарына карый. Р. Фәхретдинов «Асар» исемле тарихи китабында XVIII йөздә яшәгән ике танылган музыкант хакында сөйләп үтә[4]. Алар икесе дә гади халык арасыннан чыкканнар, озак еллар буе скрипкада уйнап тамак туйдырганнар.

Музыкантларның беренчесе, Мөхәммәт ибне Гали (халык арасында Казакай-Ахун, ягъни Казый акай Ахун — хөрмәтле, укымышлы зат) Сакмар суы буендагы Кандрау авылында туа. Туган елы билгеле түгел. Р. Фәхретдинов язганча, аның кабер ташындагы язуның кайсы елда туганлыгын күрсәткән өлеше сакланмаган. 1795 елны вафат булган. Таштагы язуга караганда, Мөхәммәт озын тормыш юлы кичә. Ул кече яшеннән үк алпавытка хезмәт итәргә мәҗбүр була. Скрипкада оста уйнарга өйрәнүе генә аңа крепостнойлык коллыгыннан котылырга мөмкинлек бирә[5]. Мөхәммәтнең музыкантлык эшчәнлеге XVIII йөзнең беренче яртысында башлана. Бу музыкант хакында кайбер мәгълүматлар татар журналисты И. Рәминең «Әдәби сүзлеге»ндә дә бар[6].

Р. Фәхретдиновның «Асар»ында күрсәтелгән икенче музыкант, Заһид улы Ишмө-


[1] Татар совет музыкасы тарихын укыту программасы (проект). Казан, 1966 ел, 14 бит.
[2] И. Г. Георги. Описание всех обитающих в Российском государстве народов. Санкт-Петербург, 1799 ел.
[3] Татары Среднего Поволжья и Приуралья. Мәскәү, 1967 ел, 448 бит.
[4] Фәхретдин улы Риза-эт-дин. Асар. Мәмләкәтемездә улан ислам галимнәренең вә мәшһүр кемсәләренең вә табакалары, тарих виладәт вә вафатлары, вә башка әхвальләре хакында язылмыш китапдыр. Оренбург, т. I, II кисәк, 1901 ел, 66 бит; VIII кисәк, 450 бит.
[5] Алпавыт йортында үткән мәҗлесләрнең берсендә ул гадәттәгечә скрипкада уйнап, кунакларны таң калдыра. Күңелләре нечкәргән морзалар хуҗаны Мөхәммәткә шәхси ирек бүләк итәргә күндерәләр.
[6] Бу белешмәнең кулъязма данәләреннән берсе Татарстан Язучылар союзында саклана.

хәммәт, Бәләбәй өязе Күбәк авылыннан чыга. Ул, Р. Фәхретдинов әйтүенчә, йөз яшькә җитеп, 1841 елны үлә [1].

Монда шуны әйтеп үтик, музыкантларның икесе дә скрипка уйнарга мөселман авылында өйрәнә, инструмент белән авылдашлары аша таныша. Димәк, скрипка XVIII йөзнең беренче яртысында татарлар арасында инде таралган булган. Безнең фикеребезчә, бу музыка коралы татарларда XVII йөзнең икенче яртысы янсә ахырларына табан күренә башлый. Бу чор русларда инструменталь башкаручылыкның киң таралуы белән характерлы. Бу чорда руслар аша Идел буена Европа культурасы элементлары үтеп керә. Бу шулай ук рус һәм татар хезмәт иясе массаларының социаль изелүгә каршы көрәштә бер-берсенә якынайган, үзара бәйләнешләре көчәйгән чор.

Кыллы кобызга килгәндә исә, ул озак вакытлар скрипка белән параллель төстә кулланылган. Югарыда искә алынган И. Георги үз хезмәте өчен мәгълүматларны XVIII йөзнең җитмешенче елларында җыйган һәм беренче тапкыр 1776 елда бастырып чыгарган. Бу вакытта Россия монархы вак халыкларның тормыш-көнкүрешен өйрәнергә «рөхсәт иткән» була. Шул ук гасырның сиксәненче елларында татарларның кобызда уйнавын этнограф Милькович та күргән. Инструментны ул «ике кыллы, өсте капланып һәм корабка охшатып ясалган скрипка» дип атый. «Кылларга бармаклар белән чиертеп һәм сызгыч йөртеп уйныйлар»,— ди [2].

Ике этнограф та кобызның сирәк кулланылуын һәм көнкүрештәге башка инструментлар белән чагыштырганда зәгыйфьрәк яңгырашлы булуын билгеләп үтәләр [3].



Борынгы татар музыка коралларының Т. Ялчыгол китабында бирелгән сызымнары (югарыдан түбәнгә): гөслә, скрипка, думбра, әрилә.

Татарларның кыллы музыка кораллары арасында Милькович скрипка, кобыз һәм агач кысалы гөсләне атый. Үзеннән-үзе аңлашыла ки, кобызның сирәгрәк кулланылуы динамик һәм тембр мөмкинлекләре ягыннан аның скрипка белән ярыша алмавыннан килә [4].

Сызгычлы музыка кораллары хакында халык авыз иҗатында шактый мәгълүматлар табарга мөмкин. Мәкальләрдә, әйтемнәрдә, табышмакларда, җыр сүзләрендә скрипканы кобыздан аерып торган сыйфатлар мактала. Скрипканың кыллары сеңердән булган, бу исә аның тавыш-яңгырашын арттырырга мөмкинлек биргән. «Ат кылыннан скрипка ясаганчы, шуны мичкә як та аш пешереп аша!» ди халык мәкале.

Кыллы музыка инструментлары турындагы мәгълүматларны шагыйрь һәм галим Таҗетдин Ялчыгол әл Болгариның (1768—1839) яңа табылган әсәрендә дә очратырга мөмкин. Поэзия турында трак-


[1] Ишмөхәммәтнең бала чагы һәм үсмер чоры туган авылында үтә. Яшьләрнең кичәләре, авылдагы бәйрәмнәр аңардан башка узмый, скрипка егетнең төп һөнәре булып әверелә. Инде музыкант буларак танылгач, егерме ике яшендә авылдан чыгып китә һәм егерме ел чамасы илгизәр музыкант булып йөри.

[2] Милькович. Быт и верования татар Симбирской губернии в 1783 году. Известия по Казанской епархии. Казан, 1905 ел, 461—463 битләр.

[3] Күрәсең, «сирәк кулланыла» дигән сүздән чыгып, кайбер тикшеренүчеләр аны онытылган уен кораллары исәбенә керткәннәрдер дә. Сирәк кулланылу, әлбәттә, юкка чыгу дигән сүз түгел әле.

[4] XVIII йөздә татарларда скрипка булуын башка чыганаклар да раслый. Мәсәлән, кара: Татарча сүзлек. Төзүчесе Хәлфин, II кисәк, Казан, 1785 ел, 654—655 битләр.


тат характерындагы бу әсәрнең табылуына әле берничә ел гына узды һәм андагы мәгълүматлар әлегә киң җәмәгатьчелеккә билгеле түгел [1]. Ул XVIII гасырдан торып халык кыллы музыка кораллары хакында мәгълүмат биргән һәм сурәтле иллюстрацияләр белән баетылган бердәнбер милли язма чыганак булса кирәк. Әсәрдә Ялчыгол дүрт төрле кыллы татар инструментын: 24 кыллы татар гөсләсен, скрипка, думбра һәм тәгәрмәчле лираны тасвирлый. Скрипка хакында ул: «Бу инструментның сыйфатлары ребабка якын тора. Сеңердән яки ефәктән ясалган дүрт кылы бар... Бездә аны «эскрипкә» дип, ә кыллар өстеннән шудырып йөртә торган коралны «кыяк» дип атыйлар» (гарәпчәдән тәрҗемә) дип яза. Автор бу музыка коралының график рәсемен дә урнаштыра. Рәсемнән күренгәнчә, XVIII йөз скрипкасы Европа үрнәгендә ясалган, кобыздан ул кылларының югары сыйфаты һәм корпусының камиллеге, тавышының ачык һәм моңлылыгы, виртуоз мөмкинлекләренең зур булуы белән аерылып тора. Ә XVI йөздән соң әллә ни камилләштерелмәгән кобыз исә скрипкадан күп калыша. Шул рәвешчә, кобызның тәмам онытылып югалып калуына яңа һәм камил музыка коралы скрипканың өстенлек алуы сәбәп булган дип ышанып әйтә алабыз. Әмма шулай да кобыз, элгәрерәк яшәгән инструмент буларак, скрипканың киң кулланылышка кереп китүе өчен җирлек хезмәтен үтәгән. Без халыкның яраткан уен коралы скрипка сәнгатен бик борынгы заманнардан бирле килгән һәм, XVI йөздә берникадәр тоткарлык кичерүгә карамастан, үсүдән туктамаган процессның, музыкаль традициянең табигый дәвам итүе күренеше дип карый алабыз. Бу фактта шулай ук Россиянең көнчыгыш Европа һәм башка төбәкләрдә яшәүче халыкларга карата цивилизацияләштерү роле дә чагыла.



*Мари ковыжлары. Ул бүгенге көнгә кадәр сакланып калган төрки кыллы музыка коралларының иң борынгысы.*

Татар скрипка сәнгате сызгычлы уен коралларында борынгыдан килгән башкару традицияләрен бик табигый рәвештә үзенә сеңдергән. Халык арасыннан чыккан осталар тарафыннан ачылган, гасырлар буе үзләштерелгән һәм күнегелгән уен алымнары яңа инструментка күчерелгән. Әнә шуңа күрә дә халык музыкантлары югары уен техникасына ия булганнар. Рус скрипкачысы И. А. Козлов, революциягә кадәрге татар музыкантлары уены белән танышкач, «Төньяк мөселманнарының халык музыкасы турында» дигән докладында түбәндәгеләрне яза: «Миңа мөселман халык музыкасын скрипкада башкаруда тыңларга туры килде... анда көй һәртөрле форшлаглар, трельләр, рулладалар һәм пассажлар белән күмелеп китә... боларга татарлар бик хирыс халык. Шунысы кызык, халык музыкантлары, безнең Европа артистлары кебек, көн саен берничәшәр сәгать музыка белән

[1] Ялчыгол әсәрен Сарман районында яшәүче М. Х. Әгъләмовадан 1973 елны Казан университеты Лобачевский исемендәге китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә эшләүче А. Фәтхиев табып алган.



*Борынгы татар музыка коралы — гөслә.*

*Бу нәфис музыка коралының төрле вариантлары Идел буе халыклары арасында киң таралган. Күбесенчә аңарда хатын-кызлар уйный.*

шөгыльләнмиләр. Татар башкаручыларының күбесе сәүдә эшендә эшли, хуҗалык белән яисә иң авыр физик хезмәт белән шөгыльләнә. Ә шулай да, үзләренең халык җырларын башкарганда, аларның бармак техникасы шундый югары, көннәр буе гаммалар, күнегүләр һәм этюдлар белән шөгыльләнгән кешеләрнең дә һәрберсе андый дәрәҗәгә ирешә алмый... Скрипкада аларның сул кулы гаҗәеп җитез эшли» [1].

Әйткәнебезчә, скрипка кыска гына бер чор эчендә халык күңеленә үтеп керә, аның иң яраткан музыка коралына әверелә [2].

XVIII һәм XIX гасырга караган барлык чынанаклар да диярлек скрипканың татарларда универсаль музыка коралы булып әверелүе турында сөйли. Яңа инструмент үзләштерелү белән музыканың бу өлкәсендә сыйфат үзгәрешләре барлыкка килә. Скрипка аккомпанемент өчен яисә ансамбль белән генә түгел, ялгыз башкаруда да киң файдаланыла. Моны без, мәсәлән, Казан университеты тарафыннан оештырылган фольклор-этнография экспедицияләре материалларыннан да күрәбез. Казан арты авылларының берсендә профессор К. Фукс берничә музыкантның «кулдан ясалган скрипкада уйнап, ирләрне биергә чакыруларын» күзәтә. «Немец һәм француз бию көйләрен ишетеп, казачокка биюләрен күреп гаҗәпкә калдым», дип яза ул [3]. XIX йөздә татарларның көнкүрешен өйрәнгән П. Шино һәм М. Лаптев та татарларның скрипка уйнап казачок, камаринская кебек җегәрле көйләргә биергә яратулары хакында сөйлиләр [4].

Борынгы татар кобызының ансамбль составында бию көйләре башкару өчен кулланылуын без инде беләбез. Ә скрипка исә төрле күңел ачулар вакытында төп уен коралы булып әверелә. Бию көйләре гадәттә аңарда ялгыз башкарылган. «Урал меселманнарының музыка һәм җырлары» дигән хезмәтендә С. Г. Рыбаков, «татарлар гадәттә скрипкада уйнап бииләр», дип турыдан-туры күрсәтеп үтә [5].

Шул рәвешчә, скрипканы үзләштерү татар кыллы музыка сәнгатендә яңа сәхифә ача. Инструменталь музыка бу этапта мөстәкыйль башкару төре буларак яшәүгә тулы хокук ала. Көйләрне скрипкада ялгыз башкару гадәткә керә, кыллы музыка сәнгатенең бер өлкәсе буларак үсә башлый. XVIII йөздә үк Казакай-Ахун, Заһид улы Ишмөхәммәт кебек халык музыкантларының күтәрелеп чыгуы әнә шул хакта сөйли дә.

Скрипкада халык көйләрен ялгыз башкаруның татар музыка практикасында киң таралыш алуы милли инструменталь музыканың башлангыч жанрларын үстерү, халык массаларының рухи дөньясын инструменталь музыка әсәрләрен кабул итүгә хәзерләүдә гаять зур роль уйный. Татар кыллы музыка культурасы алга табан профессиональ скрипка сәнгатен булдыру һәм скрипка өчен милли музыка әсәрләре тудыру юнәлешендә үсә. Бу тема исә махсус тикшеренүне таләп итә.

---

[1] И. А. Козлов. Төньяк мөселманнарының халык музыкасы турында. Рус телендә. 1928 елның 4 маенда сөйләгән доклад. Халык музыкантлары уенына хас виртуоз техника әлгәрге уен коралларында буыннан-буынга тупланып, үзләштерелеп килгән алымнар булуы белән дә аңлатыла. Элекке «флажолетлы» инструментларда уйнаучылар кылларга җиңелчә генә кагылып, бармакларын грифка тидермичә уйнаганнар.

[2] Кара: М. Мәхмудов. Практическое руководство к изучению татарского языка. Казан, 1857 ел, 253—255 битләр.

[3] К. Фукс. Казан татарларының бәйрәмнәре. Рус телендә. «Заволжский муравей» журналы, III кисәк, 1834 ел, № 17, 190—193 битләр.

[4] Россия географиясе өчен материаллар. Төзүчесе М. Лаптев. Санкт-Петербург, 1861 ел, 209 бит; П. А. Шино. Волжские татары. «Современник» журналы, т. XXXI, Спб., 1860 ел, 261 бит.

[5] С. Г. Рыбаков. Музыка и песни уральских татар с очерком их быта. Санкт-Петербург, 1897 ел, 49 бит.

Анатолий Новицкий

# ЗИРӘКЛЕК һӘМ КАМИЛЛЕКГАДИЛЕГЕ

Сәнгать әсәрләренә карата иң актыккы хөкемне вакыт әйтә дигән сүзне күп ишеткәнебез бар. Әлбәттә, хак сүз. Әмма туганда ук камиллеге белән һичнинди бәхәс уятмаслык булып туган, берьюлы һәм бик табигый рәвештә халык күңеленә, аңына кереп урнашып, шул халыкның милли рухын тирән чагылдырган, һәм шуңа күрә, һәрчак үзенең иң тәүге, иң беренчел мәгънәсендә кабул ителә торган сәнгать күренешләре була. Татар рәсем сәнгатенең иң күренекле вәкилләреннән берсе Бакый Урманче иҗат иткән әсәрләрнең дә байтагы әнә шундый.

Аның иҗат җимешләре замандашларыбызның рухи культурасында ныклы урын били, бүгенге сәнгатебез ирешкән биеклекләрнең берсен тәшкил итә. Рәссамның иҗаты халык сәнгате чишмәсеннән туенып тора, тамырлары белән халык иҗатына барып тоташа. Бакый Урманче иҗатында хезмәт халкының матурлыкка, тормыш хакыйкатенә омтылышы күркәм чагылыш таба. Әнә шуңа күрә дә рәссам иҗат иткән әсәрләр, ул тудырган образлар дөньясы хезмәт кешесе өчен якын да, аңлаешлы да. Һәр әсәре белән ул реализмның бөек формуласын — сәнгатьнең бердәнбер һәм мәңгелек чыганагы чынбарлык икәнлеген раслый.

Рәссам иҗатының тормышчанлык куәтен, социаль һәм рухи оптимизмын әнә шул билгели.

Бакый ага Урманчега сиксән яшь тулды. Шуның алтмыш елы диярлек сәнгатькә багышланган. Үзенең бәхетен һәм яшәү мәгънәсен рәссам өзлексез хезмәттә күрә. Эшсез үткән көнне ул әрәм үткән көн дип исәпли. Һәр иртәне Бакый ага үзенең остаханәсендә каршылый — дистәләрчә ел элек тә һәм хәзер дә бу шулай. Чын яшьләрчә дәрт-дәрман белән эшли Казан рәссамнарының аксакалы; уй-ниятләре бетәсе түгел аның, хис-тойгылары ташып тора, күңел күзе еракны күрә.

Бакый ага Урманченың сәнгать колачы гаять киң. Сынлы сәнгать төрләре арасында ул эшләмәгән өлкә юктыр да. Рәсем һәм гравюралар ясау, әдәби әсәрләрне иллюстрацияләү, акварель, сынлы һәм монументаль нәкыш, керамика, декоратив-гамәли сәнгать, скульптура, театр өчен декорацияләр — боларның һәрберсендә рәссам үз сүзен әйтә алды. Жанр төрлелеге ягыннан караганда да аның иҗаты күпкырлы. Әсәрләре арасында без нәни пейзаж янсә тын табигать, портрет, күп фигуралы тематик һәм тарихи композицияләр, нәни скульптур сыннар, монументаль һәйкәлләр очратабыз.

Б. И. Урманченың остаханәсендә кеше өзелми дип әйтерлек. Бирегә завод-фабрика эшчеләре һәм балыкчылар да, галим һәм әдипләр дә, хәрбиләр, инженер-

лар, студентлар да кила. Рәссам өчен алар натура ияләре генә түгел, ә барыннан да элек — останың замандашлары. Алар рәссамны үз заманының вәкилләре, чынбарлыкны үзгәртеп кору эшендә уртак фикер, уртак омтылыш кешеләре буларак җәлеп итә. Урманче иҗатының күзгә ачык күренеп торган үзенчәлеге — образларның психологик тирәнлеге әнә шуннан да килә.



Бакый Урманче татарлардан беренче буларак рәсем сәнгате буенча югары белем алу бәхетенә ирешә. Милли профессиональ сынлы сәнгать, нәкыш, графика һәм скульптура аның иҗаты белән тәпи басып китә. һәм без аны татар профессиональ сурәт сәнгатенә нигез салучыларның берсе һәм беренчесе дип хаклы рәвештә әйтә алабыз.

Совет власте елларында Татарстанда зур һәм талантлы художниклар коллективы үсеп җитте. Инде без бүген татар сынлы сәнгать культурасының шактый бай традицияләре турында сөйли алабыз. Бакый Урманче исә бүген дә — рәссамнарыбызның алгы сафында. Иҗатының күркәм җимешләре белән генә түгел, тәрбияви-педагогик һәм җәмәгать эшчәнлеге, сәнгать тәнкыйте өлкәсендәге чыгышлары белән дә ул сәнгать культурасын үстерүгә ярдәм итә. Сәнгатькә яңа юллар ярып килүче һәр уңай күренешне, үзенчәлекле талантка ия булган яшь көчләрне ул канат астына ала, сәнгатькяр яшьләргә ярдәм кулын суза. Рәссам үзе дә мәңге яшь булу серләрен белә. Әсәрләреннән дә шундый ук саф хисләр, яшьлек эчкерсезлеге сирпелеп тора. Тормышта, кешеләргә мөнәсәбәтендә ул бик гади; хезмәтләрендә дә фикер ачыклыгыннан, образларының тормышчанлыгыннан килә торган гадилекне тоясың. Зирәклек һәм камиллек гадилеге бу.

Бакый Урманченың тормыш һәм иҗат юлы хезмәт иясе арасыннан чыккан өлкән буын совет художникларының күбесенекенә охшаш. Бакый Идрис улы Урманче 1897 елның 23 февралендә хәзерге Буа районы, Күл-Черкене авылында мөгаллим гаиләсендә туа. Үз авылында башлангыч белемне алганнан соң, ул 1913 елда Казандагы сәнгать мәктәбенә укырга керергә омтылыш ясый. Әмма патша Россиясе шартларында татар балалары өчен андый мәктәпләрнең ишекләре ябык була. Революциягә кадәр Урманче Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Бөек Октябрь революциясе генә аның хыялын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. 1919 елда ул Казан сәнгать мәктәбенә укырга керә. Бу чорда әлеге мәктәп Ирекле сәнгать остаханәсе (мастерское) исемендә йөртелә. Яшь Бакый монда атаклы Казан художнигы Н. И. Фешинның шәкерте В. К. Тимофеевта һәм скульптор Г. В. Козловта укый.

1920 елда ул республика Хәрби революцион советы Политидарәсенең хезмәткәре сыйфатында Мәскәүгә торырга күчә һәм анда Югары сәнгать-техник остаханәсенә (ВХУТЕМАС) укырга җибәрелә, берьюлы ике факультетта — нәкыш һәм скульптура факультетларында укый. Уку йортын 1926 елда тәмам итеп, Б. Урманче Казанга кайта һәм мөстәкыйль иҗат эшчәнлеген башлап җибәрә. Бер үк вакытта ул, татарлар

арасыннан беренче булып, Казан сәнгать техникумында мөгаллимлек итә. Яшь рәссам техникум каршында керамика остаханәсе оештыра.

1933 елдан 1941 елгача Б. Урманче Мәскәүдә эшли. 1934 елда ул берничә әсәре белән Яшь рәссамнарның беренче бөтенсоюз күргәзмәсендә катнаша һәм сәнгать белгечләренең игътибарын җәлеп итә, аның рәсемнәренең фоторепродукцияләре үзәктәге вакытлы матбугат битләрендә күренә. 1937 елда Урманче СССР Художниклар союзына кабул ителә. Рәссамның күпкырлы таланты 1937—1941 елларда Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсен төзү-бизәү эшләрендә бигрәк тә күркәм ачыла. Монда ул Башкортстан, Карел-фин ССРы, «Авыл хуҗалыгын механикалаштыру», «Терлекчелек» павильоннарын бизәүдә катнаша.

1941 елның җәендә рәссамны атаклы казакъ мәгърифәтчесе һәм шагыйре Абайның тууына йөз ел тулуга багышланган юбилейга хәзерлек уңае белән Алма-Атага чакыралар. Бөек Ватан сугышы башлану хәбәрен ул әнә шулай юлда ишетә... Бакый Урманчега бу сәфәреннән тиз генә әйләнеп кайтырга насыйп булмый. Совет чорында беренче адымнарын атлаган һәм тәҗрибәле рәссамның иҗади ярдәменә мохтаҗ булган Казагыстан, Урта Азия республикаларының сынлы сәнгатендә аны бик күп җитди эшләр көтеп тора. 1957 елга кадәр Б. Урманче Алма-Ата, Сәмәрканд, Ташкент шәһәрләрендә эшли. Үзе дә даими иҗат итә, сәләтле яшьләрне укыту-тәрбияләүгә дә күп көч түгә, озак еллар Ташкент театр-сәнгать институты нәкыш һәм скульптура факультетларының өлкән курсларында дәресләр бирә. 1957 елда татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнашу өчен ул Казанга чакырыла һәм бер елдан соң туган ягына бөтенләйгә кайта.

Бакый аганың сынлы сәнгать, графика, скульптура, монументаль композицияләр өлкәсендәге хезмәтләре совет тамашачысына бик таныш. Бөтенсоюз, Бөтенроссия, республика сәнгать күргәзмәләрендә, чит илләрдә оештырылган күргәзмәләрдә Б. Урманче әсәрләре даими рәвештә күрсәтелеп килә. Рәссамның иҗат җимешләре илебезнең егерме музеенда саклана. Алар төрле җәмәгать биналары интерьерларын, урам һәм мәйданнарны да бизи.

Сәнгать өлкәсендәге күпьеллык хезмәтләре өчен Б. И. Урманчега 1960 елда Татарстанның халык рәссамы, ә 1972 елда РСФСРның атказанган художнигы исемнәре бирелде. 1967 елда ул республикабызның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек булды.

Рәссамның иҗат үзенчәлеге иң элек график рәсемнәрдә сизелмәнә башлый. Б. Урманче эшчәнлегенең бик киң өлкәсе бу. Рәсемнәрдә ул тормыштан алган тәэсирләрен терки, әдәби әсәрләрнең образларын сурәткә ала, иллюстрацияләр ясый. Мәсәлән, Г. Тукай, Дәрдмәнд шигырьләренә иҗат ителгән рәсемнәре аеруча зур әһәмияткә ия. Рәссам иҗатының милли үзенчәлеге аның графикасында аеруча күркәм чагылыш таба. Әйтик, рәссам үзе «Татар орнаменты» темасына фантазияләр дип атаган рәсемнәрдә үсемлек дөньясының күп төрле формалары милли орнаментның тотрыклы элементлары аша чагыла. Табигать поэзиясе аларда гаҗәеп нечкә гәүдәләнә.

Егерменче елларда башкарылган «Сепаратор янындагы хатын», «Бикбулатов портреты», «Кичүдә» һ. б. рәсемнәрдә үк Урманченың үзенчәлекле нәкышчелек таланты да ачык төсмерләнә. Шуннан соңгы еллар эчендә ул киндердә һәм агачта, гипста һәм мәрмәрдә замандашларының йөзләрчә портретларын гәүдәләндереп киң колачлы художник булып таныла. Бу галереяда без эшчеләр һәм колхозчыларны да, Бөек Ватан сугышы батырларын да, әдәбият, сәнгать, фән эшлеклеләрен дә очратабыз.

Рәссам Бакый Урманче, әйткәнебезчә, сюжетлы композицияләр остасы да. Боларда ул туган җиребезнең гүзәллеген, хезмәт кешесенең күркәм рухи сыйфатларын тасвирлый, Ватаныбызның үткәне, тарихи-революцион сәхифәләренә мөрәҗәгать итә. Соңгылары арасында хәтергә уелып кала торган әсәрләрдән, мәсәлән, «Салават Юлаев Белорет заводында чыгыш ясый», «Ибн Фадланның Болгарга килүе» дип аталган, шулай ук Е. Пугачев, казакъ халкының милли азатлык каһарманы Амангельды Имановка багышланган картиналарны атарга була.



*«Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш»*
*поэмасына иллюстрация.*

Б. Урманченың монументаль хезмәтләре дә шактый. Мәскәүдәге Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә, Балхаш металлургия комбинаты культура сараена һ. б. куелган әсәрләре, Абай Кунанбаев, Рудаки, Әбугалисина һәйкәлләре өчен әзерләгән проектлары әнә шундыйлардан.

Беренче татар марксисты Х. Ямашев, татар әдипләре һәм сәнгать эшлеклеләре Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Камал, Дәрдмәнд, Ш. Бабич, Г. Кариев, М. Җәлил, Н. Исәнбәт, Н. Җиһанов, мәгърифәтче галимнәр Ш. Мәрҗани, К. Насыйриның скульптур портретлары сериясе рәссамның иң зур иҗат казанышларыннан саналырга тиеш. Ә «Кол Гали», «Язгы моңнар», «Сагыш» кебек аллегорик скульптуралары исә художникның тирән фәлсәфи гомумиләштерүләр биеклегенә күтәрелүе хакында сөйли.

Бакый Урманченың үзенчәлекле иҗат йөзен, аңа хас тасвирлау рәвешен, әсәрләренең үзгә хасиятен ачыграк күзаллау өчен хезмәтләренең берничәсен генә булса да якыннан тикшереп карыйк.

«Сепаратор янындагы хатын» картинасы рәссамның беренче чор иҗатындагы иң яхшы хезмәтләреннән саналырга хаклы. Беренче карашка бик садә һәм гадәти күренеш: хуҗа хатын үз өендә көндәлек эшләрен башкара. Әнә ул эшеннән тукталып, бер мизгелгә генә безгә әйләнеп караган һәм шул мизгел бик күпне сыйдырган. Без монда гади крестьян хатын-кызының бөтен тормыш юлын күз алдына бастыра алабыз, аның сабыр һәм нык ихтыярга ия булуын, характер бөтенлеген тоябыз. Ул, мөгаен, теләсә нинди эшне дә җай белән, җитез һәм җиңел башкара, өен пөхтә тота торгандыр. Кыенлыклар да аны тиз генә өркетә алмыйдыр. Йөзгә бик үк чибәр түгел түгелен, әмма караган саен без аңарда кабатланмас күркәм сыйфатлар табабыз, аңа ышанабыз, якын күрәбез. Рәсемдәге калку итеп тасвирланган көнкүреш детальләре, милли кием-салым, савыт-саба шушы тәэсирләребезне тагын да көчәйтә төшә. Художникның нечкә күңеле көндәлек тормыш күренешендә шигърият нурын тотып алган. Урманченың рәссамлык үзенчәлекләреннән берсе нәкъ менә шунда чагыла да инде. Ул чын мәгънәсендә милли художник. Татар халкына хас фикер сөреше, аның дөньяны тою һәм хисләрне белдерү рәвеше, милли характер калыбын ул гаять нечкә сизә, чынбарлыкны тотрыклы милли характер яссылыгы аша күрә һәм сурәтли белә. Шул ук вакытта, Б. Урманче әсәрләрендәге миллилек татарлар өчен электән үк гадәти булган, күнегелгән төс-буяулар, традицион психологик сыйфатларны, поэтиканы, көнкүреш һәм кием-салымны сурәтләү белән генә чикләнми; әсәрләрендә ул бүгенге көнгә хас күренешләрне, миллилекнең үсеш динамикасын да күрсәтә белә.

Казагыстанда, Үзбәкстанда, Башкортстанда озак вакытлар эшләү дәверендә Б. Урманче ул республикаларның да тарихи үсеше һәм культуралары үзенчәлекләрен яхшы үзләштерә. һәм рәссамның хезмәтләрендә без казакъ, үзбәк, башкортларга хас характер үзенчәлекләренең дә төгәл чагылышын күрәбез. Ул халыклар Б. И. Урманчены үз рәссамнары дип саныйлар икән, бу һич тә очраклы хәл түгел.

Сәнгатьтә интернациональлек биеклекләренә юл миллилек аша үтә. Татар рәссамына хас иҗат индивидуальлеге аша Б. Урманче совет сынлы сәнгате осталары арасында лаеклы урын алды.

Кырыгынчы-илленче елларда һәм бигрәк тә аннан соңрак чорда рәссам халыкның сәнгатьчә фикер йөртү ысулы-рәвешен һаман тирәнрәк үзләштерә бара. Моңа ышану өчен Урманченың Бөек Ватан сугышы елларында иҗат ителгән хирург А. Н. Сызганов, артистка Шара Жандарбекова портретларын, алтмышынчы-җитмешенче елларда язылган «Урал тау эргәсендә», «Ибн Фадланның Болгарга килүе» картиналарын һәм күп кенә скульптур портретларны хәтергә төшерү дә җитәр иде.


Боларның һәрберсенең нигезендә рәссамның җитди уйлану-эзләнүләре, гыйльми тикшеренүләре ята. Б. Урманче күптәннән һәм даими рәвештә фәнни ориенталистика белән шөгыльләнә, тарихны өйрәнә. Гыйльми эзләнүләре рәссамның иҗатын яңа сыйфат баскычына күтәрде дип әйтергә мөмкин. Тарих, этнография, архитектура, әдәбият, тел белеме өлкәләрендә дистәләрчә еллар буена туплаган белем хәзинәсе аңа иҗатта гыйльми төгәллеккә ирешергә, әсәрләренең ышандыру көчен арттырырга мөмкинлек бирәләр.

Җитмешенче елларда төгәлләнгән ике картинага тукталып үтик. «Урал тау эргәсендә» дигән картина рәссамның Башкортстан җирендә алган тәэсирләрен үзенә сыйдырган. Аңа карау белән оста күңелендә ул якларның табигате һәм кешеләре белән очрашудан калган якты бер хис яшәвен тоймый мөмкин түгел. Картинада без күреп гадәтләнгән сюжет юк, әсәрдә ул кирәкми дә, чөнки автор Башкортстан җире хакында тулаем бер эмоциональ төшенчә бирергә тели. Рәссам, үз максатына яраштырып, тауларны да, агач һәм чәчәкләрне дә стилизацияли, атлар да, ат өстендәге җайдаклар да, казлар да — һәммә нәрсә монда символ дәрәҗәсенә җиткерелеп гомумиләштерелгән. һәм шуңа да карамастан, картина шушы җир, шушы төбәккә карата реаль кешенең хискичерешен чагылдыра.



*Урал тау эргәсендә.*

«Ибн Фадланның Болгарга килүе» исемле композиция дә сызыклар һәм төсләр гармониясенә корылган. Автор ерак калган тарихи эпохага мөрәҗәгать итә. Әсәр Багдад хәлифәсе Моктадир тарафыннан җибәрелгән зур



*В. И. Ленин портреты.*

илчелекнең 921—922 елны Идел буе Болгар иленә килүе турында сөйли. Шул илчелекнең секретаре Ибн Фадлан калдырган бай сәяхәтнамәгә таянып, рәссам илчелекне хан җәйләвендә ничек каршы алуларын тасвирлый. Әсәрнең объектив эчтәлеге исә аның сюжетыннан күпкә киңрәк. Рәссам анда ерак чорның рухын, җанлы сулышын күз алдына бастырырга омтыла.

Бакый ага Урманче иҗаты хакында сөйләгәндә, игътибардан читтә калдырып булмый торган бер тема бар. Ул — В. И. Ленин темасы. Телевидениедән ясаган бер чыгышында бу хакта рәссам болай дигән иде:

«Казанда яшәүче сурәт остасы, миңа калса, Ленин темасын читләтеп уза алмый. Ул фикере, дөньяга карашы белән нәкъ менә шушы җирдә формалашкан бит, яшьлегендәге иң мөһим карарын шушында кабул иткән, үз юлын сайлаган. Ильичның әсәрләрен, аның хакындагы истәлекләрне мин күп укыдым. Аңа фикер иясе һәм юлбашчы буларак та, шәхес буларак та гаять зур ихтирам, хөрмәт һәм, шуның белән бергә, чын мәхәббәт хисе тойдым. Портретта әнә шуларны чагылдырырга тырыштым...»

Таланты һәм осталыгы тәмам камилләшеп җиткәннән соң гына теге яки бу рәссам юлбашчыбыз образын, аның җанлы сурәтен тудыру эшен гамәлгә ашыруга керешергә җөрьәт итә ала. Сәнгать ленинианасын тәшкил иткән нәкыш, графика, скульптура әсәрләре арасында чын сәнгать дәрәҗәсендә торганнары аз түгел. Художникны монда үзеннән алда тудырылган әнә шул сәнгать хәзинәсе үрнәкләренә ияреп китү, башкалар тапканның йогынтысына бирелеп, элекке табышларны кабатлау юлына басу куркынычы сагалый. Шуңа күрә дә Ленин темасы рәссамның идея һәм сәнгать осталыгы ягыннан өлгергәнлек дәрәҗәсен, үзенчә һәм тирән фикер йөртә алу сәләтен күрсәтә дә.

Б. И. Урманченың юлбашчыбызга багышланган әсәрләре аның нәкъ әнә шундый сыйфатларга ия булган оста икәнлеген исбат итә. Әлбәттә, бу уңышларына ул озак еллар аша, гаять зур хезмәт түгеп килде. 1964 елда рәссам В. И. Ленинның скульптур портретын тәмамлый. Ә тагын ун елдан соң аның кискече астында яшь студент Володя Ульянов скульптурасы туа.

Юлбашчының мраморга уелган бюсты таң калдыра. Шәхеснең эчке тормышын, рухи куәтен гәүдәләндерү осталыгы ягыннан рәссам монда үзенең иң югары дәрәҗәсенә күтәрелә. Бакый Урманче трактовкасындагы Ленин образы юлбашчының гаять зур ихтыяр көчен, даһи акылын, бетмәс-төкәнмәс оптимизмын, аның күңел җылысын калку гәүдәләндерә. Мәскәүдә укыган елларында Бакый ага үзе дә Ленинны күрү бәхетенә ирешкән. Юлбашчының тере чалымнары шул чакта ук аның хәтеренә гомерлеккә уелып калган. Бу бюст хәзер Татарстан сынлы сәнгать музеенда саклана.

В. И. Ленинның яшьлек чорын сурәтләгән әсәрен Урманче бөтенләй башка психологик нигезгә кора. Ун елга диярлек сузылган эзләнү чорында, мөгаен, скульптура

сынын бөтен итеп бирү фикере генә үзгәрешсез калгандыр. Ә гәүдә торышы, йөз борылышы, башка детальләр кат-кат үзгәртелә. Композицион вариантлар арасында уңышлылары да булмый түгел, әмма нидер җитми, күңеле белән рәссам төгәл табылып җитмәгән билге-сызыклар барлыгын сизә. Һәм ул, инде ничәнче тапкыр, документларны, истәлекләрне күздән кичерә, тарихи хезмәтләрне укый, фоторәсемнәрне өйрәнә. Ниһаять, Казанда яшәгән чорда Володя Ульяновның рухи халәте, фикер юнәлешенә тәгаен төшенеп җиткәч кенә, ул элекке вариантларда нәрсә җитенкерәмәвен күрә.

Яшь Ильич образын гәүдәләндергәндә художниклар кайчак, үзләре дә сизмәстән, мәгънә акцентларын үзгәртеп җибәрәләр. Ильичның соңгырак чордагы билге-чалымнары мондый очракта аның яшьлек чорына күчерелеп куела. Бу, әлбәттә, чынбарлыктагы дөреслеккә хилафлык китерә. Б. Урманче Володя Ульяновның нәкъ менә шул чордагы эчке халәтен аңларга тырышып, озак еллар эзләнә дә. Ә шуңа ирешү белән образның оригиналь, төгәл һәм ышандыргыч пластик чишелешен таба.

Володя Ульянов яр читендәге тәбәнәк кенә эскәмиядә утырып тора. Ул яшьләрчә түгәрәк йөзле, җиңел гәүдәле. Аның характеры үсештә бирелә. Гәүдә пластикасындагы һәр яңа борылыш образның нинди дә булса сыйфатын ача.

Бакый Урманченың Ленин темасына караган әсәрләре янына Мария Александровна Ульянованың Кокушкино авылындагы мәктәп каршына куелган монументаль портретын да өстәргә кирәк. Аның якты елмаю белән балкыган йөзендә без ана хисләренең олылыгын, авыр сынауларга да бирешми торган рухи ныклыкны тоябыз. Күп борчу-кайгылар эзен саклаган бу йөз күзгә бәрелеп тормый торган матурлыгы белән соклану хисе уята.

Илленче еллардан башлап Бакый ага Урманче иҗатында скульптура һаман зуррак урын ала бара. Бу һич тә очраклы хәл түгел. Скульптурада төп сурәтләү чаралары — хәрәкәт пластикасы, күләмне, кисәк һәм бөтен арасындагы нисбәтне тою. Шулар аша бөтенне җанлы итеп күз алдына бастыру, аның динамикасын, эчке яшәешен бирү таләп ителә. Скульптурада гәүдәләндерелгән образ үзе белән тирән идея, символ дәрәҗәсендәге дип әйтерлек югарылыкка күтәрелгән мәгънә алып килергә, үзенә бер төрле романтик күтәренкелеккә ия булырга тиеш. Башкача әйтсәк, потенциаль мөмкинлекләре ягыннан караганда, скульптура — тагын да фәлсәфирәк сәнгать төре.

Б. И. Урманченың осталыгы үсеп, иҗаты чын фикри җитлегү чорына кергәч, чынбарлыкны нәкыш чаралары белән генә тасвирлау аны канәгатьләндереп җиткерми башлый. Ул күңелендәге идеяне пластикада гәүдәләндерүгә ихтыяҗ сизә. Урманче шәһәребез скульпторлары арасында беренче булып яңа материал — мәрмәр куллана башлый. Казанда яшәгән егерме елга якын вакыт эчендә рәссам берничә дистә скульптура әсәре иҗат итә. Аларның күпчелек өлеше татар мәдәниятенең олуг вәкилләрен, җәмәгать һәм фән эшлеклеләрен гәүдәләндергән циклардан тора. Татар халкының алдынгы улларына багышланган портрет сериясендә Бакый Урманче үз замандашлары образларына да, тарихи шәхесләргә дә мөрәҗәгать итә. Халыкның иң изге сыйфатларын үзләренә туплаган, тугрылык һәм фидакарьлек үрнәге булып хезмәт итәрлек шәхесләрнең образларын тудыруны скульптор үзе милли сәнгать алдындагы бурычларның берсе дип карый. Бер мәкаләдә аның бу өлкәдәге барлык эшләре турында сөйләү мөмкин түгел. Без монда аларның икесенә генә тукталып үтәбез.

Рәссам кечкенә яшеннән үк Тукай шигъриятенә гашыйк була. Бөек татар шагыйренең портретын тудыру хакында ул иҗатының башлангыч чорында ук хыяллана. Илленче еллар уртасында Тукай образын гәүдәләндерү фикере өлгереп җитә һәм Сәмарканд шәһәрендә ул шагыйрьнең бюстын ясауга керешә. Соңрак, Ташкент сәнгать институтында дәрес биргән елларда да бу эшен туктатмый һәм портретны гипста төгәлли. Әмма Казанга кайткач та әле рәссам образ өстендә эшләвен дәвам иттерә һәм бары тик 1959 елда гына аны мәрмәргә күчереп тәмам итә.

Тукай портретының композициясендә үк тирән фикер салынган. Шагыйрьнең иңбашлары, баш һәм куллары бер бөтен мәрмәр кисәгеннән үсеп чыга һәм әдип белән аны тудырган халык арасында өзелмәс бердәмлекне символлаштыра. Тукай аз гына иелә төшеп, кулларын күкрәгенә кушырган да, терсәкләренә таянган килеш, тирән



*Г. Тукай портреты.*

уйга талган. Портрет композициясендәге мондый торгынлык тыштан караганда аны катып калганлыкка, статизмга дучар итә сыман, әмма чынлыкта скульптор образның эчке киеренкелеген бирә алган. Без портретта Тукайның фикер хәрәкәтен тоябыз кебек. Рәссам моңа урынлы кулланылган пластик чаралар ярдәмендә ирешә. Карашы белән шагыйрь каядыр еракка төбәлгән, ирене тирәсендәге кайгылы сызык аның кыю йөзенә хәсрәт билгесе салган. Шуларның барысы артында образның барлык сыйфатларын бер бөтен итеп берләштергән сыгылмас ихтыяр көче сизелеп тора. Урманче тарафыннан тудырылган бу образда республика җәмәгатьчелеге һәм тамашачыларның киң даирәсе үзләренең сөекле шагыйрен таныды.

Герой-шагыйребез Муса Җәлил бюстын эшләргә карар иткәч тә, Бакый ага озак вакытлар аның образын күңелендә иркәләп йөртә. М. Җәлил белән ул сугышка кадәр Мәскәүдә эшләгән елларда ук таныш була. 1939 елда, татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына әзерлек барган чорда, Җәлил белән алар бергә хезмәттәшлек итәләр. Рәссам ул очрашуларны кадерле истәлек итеп саклый. Җәлилнең скульптур портретында «Моабит дәфтәре» шигырьләренең авторы, баһадир йөрәкле көрәшче образы белән әнә шул, сугышка чаклы якын таныш, тыйнак, сөйкемле иптәш булган кеше икесе бергә кушылган, табигый бердәмлек хасил иткән. Скульптор Муса Җәлил батырлыгының нинди дә булса гадәттән тыш сыйфатлардан бигрәк, аның рухи көченнән, кешелеклегеннән килүен күрсәтергә омтыла. Кайбер художникларның әсәрләрендә патриот-шагыйрь гаять экспрессив төстә, тумыштан ук искиткеч зур кодрәт иясе итеп сурәтләнде. Урманченең Җәлиле исә икенчерәк. Ул тудырган образ натура ягыннан тирәнлеге һәм бөтенлеге өстенә күңел йомшаклыгы, инсафлылык белән дә аерылып тора. Образ трактовкасына теманың героик яңгырашыннан бигрәк лирик һәм эпик поэзия рухы хас. Мондый трактовка шагыйрь образының асылын төгәл чагылдыра.

Татар культурасы вәкилләренең иң яхшы портретларында Бакый Урманче кешенең кешелек бурычы, чынбарлыктагы урыны, тугрылык һәм илгә мәхәббәт кебек яшәешнең төп мәсьәләләрен куя. Әмма шуннан соңгы уйлану һәм эзләнүләре аны художникның дөньяга фәлсәфи мөнәсәбәтен чагылдыра торган гомум-аллегорик образлар тудыруга этәрә. Мондый характердагы иң яхшы әсәрләренә мисал итеп, «Язгы моңнар» һәм «Сагыш»ны китерергә кирәк. Агачтан ясалган бу ике сын скульптур диптих тәшкил итә. Ясый башлаган вакытта ук бер бөтен итеп уйланылган ул сыннар образлылык ягыннан бер-берсенә каршы торалар, һәм шул ук вакытта, фикер җәһәтеннән бер-берсен тулыландыралар да. Аларда кеше гомеренең диалектикасы чагыла. Беренчесе гомер юлының башын, икенчесе аның йомгагын, котылгысыз рәвештә гомер ахыры якынлашып килгән чагын символлаштыра. Кешенең яшьлек чорын скульптор сылу кыз сынына тиңли, шул образ аша гәүдәләндерә. Әнә ул яшьлек бәхетенә күмелеп болында утыра. Җиңел гәүдәсендә тормыш һәм яшәү шатлыгы. Өмет һәм ышаныч та, алда торган бәхетле көннәрен сизеп куану да — һәммәсе бер якты образ, яшьлек образы булып береккән. Бу образ Урманченең пластикадагы иң зур казанышларыннан берсе. Кызның күңелендәге гармония статуяның пластик камиллегендә ачыла. Монда барысы да берьюлы әйтелгән, тамашачыга зиһен җыеп, уйланып,

яшерен мәгънә эзләп торырга кирәкми. Образда гәүдәләнгән сафлык, бәхет дөньясы аңа болай да якын, аңлаешлы. Автор әсәре белән тормышка мәдхия җырлый.

«Сагыш» исә образ корылышы белән бик нык аерылып тора. Ул — уйлану, фикер итү дә, сагыну һәм сагыш та, ул — газаплы да, татлы да тормыш моңы... Сырышып үскән юан груша агачының мугыллары арасыннан рәссам озын гомер юлы кичкән аксакал картның кырыс һәм мәһабәт йөзен калкытып чыгарган. Бу йөздә картлык нуры уйный, сүнү-сулу зәхмәте әйтерсең аңа кагылмаган да. Эре төерләр белән капланган киң маңгае, кысынкы иреннәр, уелып килгән йөз чалымнары аның зирәк акылы, көчле ихтыяры хакында сөйлиләр. Аксакалның тирән күз карашында үткән гомер шәүләсе чагылган. Кичергән кайгылар, югалтулар ачысы, татлы хатирәләр һәм тагын тел белән әйтеп бетереп булмый торган күп төрле хис-тойгылар барысы бергә... Шулай да үткен әле аның күзләре. Башкалар күрмәгәнне күрә, яшәешнең иң яшерен серләренә үтеп керә төсле алар. Карт вакытның үзенә башка тыгыз һәм югары бер үлчәнешендә яши. Үлем котылгысыз булса да, ул аның акыл һәм тәҗрибәсен юкка чыгара алмый. Тормыш мәңгелек, аның бер чаткысы гомер дә бакый. «Сагыш»та Урманче иҗатына хас төп сыйфатлар тыгыз итеп үрелгән. Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Дәрдмәнд һәм башка образлардагы фикер киеренкелеге, кеше рухының балкышлары монда символик, гомуми фәлсәфи яңгыраш алган.

Бакый Урманченың нәни сыннар өлкәсендәге иҗаты да өйрәнелүгә лаек. Нәкышендәме, график әсәрләрендәме, һәр нәрсәдә диярлек декоратив башлангыч үзен нык сиздерә. Ә аның остаханәсеннән чыккан декоратив һәм көнкүреш сәнгате әйберләре күңелне иркәләп, көндәлек тормышка ямь биреп торалар.

Урманда тапкан агач тамыры, ботак-санак иҗат остасы өчен нәни скульптура материалы булып хезмәт итә. Ул еш кына агач кисәгенә табигать үзе «салып калдырган» образны файдалана, берничә җиңелчә хәрәкәт белән аны кыргыйлык әсирлегеннән «азат итә» белә. Шаян шүрәләләр, мәкерле су иясләре, иҗади илһам билгесе — канатлы толпарлар, халык әкиятләренең башка геройлары кинәт «терелеп» безнең арада яши башлыйлар.

Бакый аганың яңа гына тәмам иткән, яисә әле бүген язылып яткан әсәрләре дә аз түгел. Аларга аксакал рәссамның гомер буе җыйган бай акыл тәҗрибәсе, күңел җылысы түгелгән... «Хатирәләр» дип аталган картиналар сериясе нәкъ әнә шундый тәэсир калдыра. Автор боларда үзенең еракта калган бала чак көннәренә әйләнеп кайта, авылның күп төрле төс-бизәкләр белән тулы сабан туйларын, ямьле печән өсләрен, көнкүреш күренешләрен үзенә бер төрле шигъри моң белән сурәтли.

Рәссам монда тормышны хәрәкәткә китерүче, яшәешкә ямь, мәгънә бирүче гади һәм мәңгелек хакыйкатьләрне раслый. Чын гүзәллек хезмәттә, хезмәте белән туган җирне бизәүче кешедә! — ди ул.

Б. Урманченың соңгы елларда башкарган хезмәтләреннән Кырлайдагы Г. Тукай мемориаль комплексы, Сөембикә портреты, Е. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышына багышланган композиция һәм башка әсәрләре барысы да әнә шундый югары гуманизм белән сугарылганнар.

Бакый ага Урманче иҗаты замандашларына тирән фикерләр, якты хисләр алып килә. Аның әсәрләре халкыбызның рухи тормышын баета, күп милләтле совет сәнгатенә яңа төс-мәгънәләр өсти. Рәссамның бөтен тормыш юлы — илгә, халыкка тугрылыклы хезмәт итүнең матур бер үрнәге.

# АЛЕКСЕЙ ТОЛСТОЙ КАЗАНДА

1941 елда, татар язучылары белән очрашуы вакытында, Алексей Николаевич Толстой Казанны үзенең туган шәһәре итеп диярлек санавын әйтә. Күренекле язучының шулай дип әйтүе нигезендә нәрсә ята соң? Бу сорауга А. Н. Толстойның А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институтында саклана торган документлары ачык җавап бирә. Күп санлы әсәрләренең кульязмалары, көндәлекләре, хатлары Казанның бу язучы тормышына ни дәрәҗәдә тәэсир иткәнлеге турында ачык сөйли.

А. Н. Толстой Казанда беренче тапкыр әнисе Александра Леонтьева белән 1901 елның июнендә була. Шул чакта ул үги әтисе А. А. Бостровка болай дип яза: «Казанда булдым. Шәһәр миңа бик ошады, бәләкәйрәк булса да, Нижнийдан әйбәтрәк: һәрнәрсәдә аристократик төсмер сизелә, ни әйтсәң дә, университетлы шәһәр».

1902 елда Толстой яңадан Казан аша уза һәм Камада үткәргән берничә сәгать вакыт аңарда тагын җылы истәлекләр калдыра.

Ә инде 1905 елда, июньнең беренче яртысында, А. Н. Толстой Казанга үзенең гаиләсе — хатыны Юлия Васильевна Рожанская, улы Юрий һәм хатынының әти-әнисе белән бергә даими яшәү өчен күчеп килә. Рожанскийлар Казан белән электән үк элемтәдә торган булалар. Юлия Васильевнаның Казанда танышлары күп була. Өстәвенә, монда аның туганы Всеволод яши. Казанда Алексей Николаевичның үзенең дә кардәшләре булмый түгел. Шундыйлардан, мәсәлән, князь Хованскийны күрсәтеп үтәргә мөмкин. А. Н. Толстой аның белән 1902 елда кардәше И. Шишковта кунакта булган чакта таныша. Шишков исә Алабугадан 95 чакрым ераклыктагы бер урында пыяла заводы тота. Бу вакытта А. Н. Толстой анда студентлык практикасы уза.

Казанга килгәч, Толстойның гаиләсе Юлия Васильевнаның Зур Кызыл урамында яшәүче туганында урнаша. Рожанскийлар Югары Осланда дача алалар. Хатыны һәм улы дачада ял итә, ә А. Н. Толстой үзе әтисе һәм Юлия Васильевнаның абыйсы белән Уралда, алтын приискаларында була. Аннан ул 1905 елның июль ахырында кайта. 17 сентябрьдә Рожанскийлар шәһәргә күченәләр. Шул ук елның көзендә Алексей Николаевич Толстой хатыны белән Петербургка китә. Казанга ноябрьнең икенче яртысында кайта. Монда ул 1906 елның 15 февраленә кадәр тора. Казанга бу килүендә дә шул ук Рожанскийлар гаиләсендә, әмма башка квартирада — ул вакыттагы Старая Горшечная (хәзерге Бутлеров) урамындагы йортта яши.

А. Н. Толстойның хатыны, аның әтисе Василий Михайлович Рожанский врачлар булалар һәм алар үз һөнәрләре буенча шөгыльләнә башлыйлар. Бу вакытта Толстой, студент буларак, Петербург технология институтын тәмамлау алдында тора. Ләкин 1905 елгы революцион вакыйгалар уңае белән институт ябылган була. Соңрак, укуын дәвам итү өчен, А. Н. Толстой Казаннан китә, ләкин институтны барыбер тәмамлый алмый кала. Моның сәбәбе — Алексей Николаевич үзенең төп сәләтен язучылык эшендә күрә. Яшь Толстойның күңелендәге бу уй Казанда борынлый һәм ул әдәбиятка үзенең беренче адымын шунда ясый.

Әллә ни күп вакытны эченә алмаса да, бу чор язучының иҗат биографиясендә гаять зур әһәмияткә ия булып тора. Чөнки аның Казанга бәйләнешле тормышы Беренче рус революциясенең иң кызган чагына туры килә. Ул вакыттагы революцион

чынбарлык һәм Казанда алган тәэсирләре яшь Толстойның дөньяга карашы формалашуда, һичшиксез, зур роль уйный.

А. Н. Толстой шул вакыттагы вакыйгаларны зур кызыксыну белән күзәтә. Казан пролетариатының революцион көрәше турында ул, әлбәттә, белмичә калмаган. 1905 елның ноябрендә, Толстой Казанда вакытта, Алафузов заводы эшчеләренең стачкалары була. Югары Осланда булуы язучыга андагы крестьяннарның 1905 елгы революцион хәрәкәтләре белән танышырга мөмкинлек бирә.

А. Н. Толстой кайбер митингларда һәм җыелышларда булмый калмагандыр, мөгаен. Казанда, бөтен Россиядәге шикелле үк, большевикларның массаларга йогынтысы үскәннән-үсә. Дөрес, яшь Толстой әле большевизмны аңлаудан ерак була. Ләкин Казанда аның социал-демократларга карата симпатиясе арта. Казаннан ул әти-әнисенә үзенең социал-демократия сафларына керергә теләве турында яза. Булачак язучының бу теләге аның иҗтимагый эшчәнлек белән шөгыльләнергә карар кылуы белән бәйле, әлбәттә. Әмма бу хыял ул вакытта тормышка ашмый. Ләкин ул яза башлый һәм матбугатта беренче тапкыр Казанда чыга. «Волжский листок» газетасында (бу либераль газета була һәм большевиклар аны легаль орган итеп файдаланалар) ул үзенең «Ерактагылар» (1905 елның 6 декабре), «Төш» (1905 елның 18 декабре) һәм «Яңа ел» (1906 елның 1 январе) исемле өч шигырен бастыра. Бу шигырьләрдә революция геройларына дан җырлана, азатлык өчен көрәштә һәлак булганнар искә алына, кешелек бәхете өчен көрәшүчеләрнең төрмәләрдә газап чигүләре турында әйтелә. Автор бу героик көрәшнең эзсез калмаячагына ышаныч белдерә.

А. Н. Толстойның Казанда язган күп кенә прозаик һәм шигъри әсәрләре кульъязма хәлендә калган. Күпчелек очракларда аларның художество формалары әле ахыргача эшләнеп җитмәгән. Шуңа да карамастан, ул әсәрләрдә инде булачак зур художникның талантын сиземләргә мөмкин. Иң әһәмиятлесе — яшь Толстойның беренче әсәрләрендә аның революцион вакыйгалар тудырган кичерешләре, уйлары, тәэсирләре ачыклана. Патша строеның оятсызлыгын, кешелексезлеген, рәхимсезлеген фаш итү — А. Н. Толстой әсәрләрендә төп темаларның берсе. Яшь язучы «Канлы якшәмбе»нең еллыгын «Коралсызлар» дигән шигыре белән билгеләп үтә. Бу шигырен ул Казандагы танышы О. Н. Сергеевскаяның альбомына яза. Коралсыз кешеләр патша катына халыкка азатлык сорап киләләр. һәм шунда кеше ышанмаслык хәл була: аларның соравына җавап итеп атарга әмер бирәләр.

Патша тәхетен яклаучыларның кешелексезлеге язучының «Без хәвефле һәм сизгер йокладык» шигырендә дә фаш ителә. Шигырь тынчу һәм салкын төрмәдә газап чигүчеләрнең берсе сөйләгән сүзләр рәвешендә язылган. Анда казакларның эшчеләрне аяусыз җәзалаулары хакында әйтелә, автор патша ялчыларын ерткыч җәнлекләр белән чагыштыра.

Ачы нәфрәт белән язылган «Һәркайда кан, янгын һәм ыңгырашулар» шигырендә ул самодержавиене террор һәм чиркәү ярдәмендә тормыш тәртипләрен «элек ничек булса, шулай калдырырга» маташуы өчен гаепли. Тормышның үсеш законнарын аңларга тырышып, А. Н. Толстой, революцион вакыйгалар йогынтысы белән, иске дөнья котылгысыз һәлакәткә дучар булачак дигән фикергә килә. Тарихны иҗат итүче халык һичнәрсәгә карамастан, яңа тормыш юлыннан бара. Монархияне яклаучыларга Толстой менә ничек мөрәҗәгать итә:

**Чылбыр белән кабат бәйләп булмый**
**Канатларын җәйгән бөркетне.**

«Реакция — алдакчы» дигән шигырендә язучы, революция үсешенең күп санлы фактларына таянып, реакциянең тарихи көчсезлеген ачып сала. Иске тормышка, иске тәртипләргә каршы көрәшкә чакырып, А. Н. Толстой үзенең әсәрләрендә хезмәт ияләренә азатлык һәм ирек алып килүче революция эшенең мораль чисталыгын, гуманлыгын раслый, дөньяны үзгәртеп кору өчен канат җилпегән бөек Россияне мактый. Революциянең героик образлары азатлыкны яклап баррикадада көрәшүче ана һәм аның улы турындагы шигырьдә тудырылган. Ана — куркусыз йөрәкле, горур кеше. Ул революция эшенең дөреслегенә ышана. Шуңа күрә дошманга каршы көрәшүче улына булыша. Сугышта аның улы һәлак була. Аның гәүдәсе өстенә ул кызыл байрак ябa. Кайгы кичерү белән бергәттән, ана улының халык бәхете өчен батыр-

ләрчә һәлак булуы өчен горурлана. Кайгы аны аяктан екмый. Эшчеләрне ул яңа көрәшкә рухландыра һәм, кызыл байрак күтәреп, бу көрәшне үзе җитәкли. «Ерткычлар! Үтерүчеләр!» — дип кычкыра ул баррикадага якынлашып килгән «мәрхәмәтсез солдатларның соргылт күләгәләренә» карап.

«Машинист Ухтомский» шигыре җәзалап үтерелер алдыннан геройның аңа атачак солдатларга мөрәҗәгате формасында язылган. «Үлем алдындагы газаплар миңа куркыныч түгел», — ди ул, тормышының соңгы минутында палачлар алдында горурлыгын җуймыйча.

«Без — Лаоян геройлары» шигырендә А. Н. Толстой самодержавиенең Ерак Көнчыгыш авантюрасы белән бәйле вакыйгалар йогынтысы белән халыкның политик аңы үсүен чагылдыра. Шигырьдә сүз карт солдат Митяй исеменнән бара. Митяй, халыкның батырлык күрсәтүенә карамастан, рус-япон сугышында рус гаскәрләренең җиңелүе, патша генералларының һәм «алла сынлы» Куропаткинның караклыгы, хезмәт ияләренә мең бәлаләр китергән сугышның гаделсезлеге, кирәк түгеллеге турында сөйли. Хәзер солдатлар генералларны гына түгел, ди Митяй, патшаның үзен юк итәргә, пушканың «артын алга борырга» әзер.

Казанда А. Н. Толстой «Петербург картинкалары» дигән этюдлар циклы өстендә эшли. Ул этюдларның берсендә автор бай салонны тасвирлый, аристократларның революцион чынбарлык турында сөйләшүләрен сурәтли. Үзләрен илнең хуҗалары дип санаучы бу бәндәләр — үлемгә хөкем ителгән иске дөнья вәкилләре. Аларны корал да, реформалар да коткарып кала алмаячак. Забастовкаларны бетерү турында көн-төн кайгыртучы башкала аристократиясенә мөрәҗәгать итеп, автор болай ди: «Забастовкаларны сез туктатырсыз, ә революцияне — һичкайчан».

«Петербург зоология бакчасында» дип аталган эскизда Толстойның реакция алдында чигенергә, тез чүгүгә каршы протесты гәүдәләнә. Башкала зоология бакчасының бөтен обстановкасы декабрь кораллы восстаниесе бастырылганнан соң илдәге атмосфераны символлаштыра: «Кая карама — рәшәткәләр һәм стеналар, аннан арырак — йортлар, тагын рәшәткәләр һәм стеналар, һәркайда күзгә күренмәгән тимер кул тоткан тәртип. Тынчу һәм юеш». Зоология бакчасына күңел ачарга дип килгән обывательләргә күңелсез, ләкин алар монда урнаштырылган тәртипләрне боза алмыйлар. Кешеләрнең ул тәртипләргә табынуы шул кадәр ахмаклык, бу хәтта хайваннарны да гаҗәпкә калдыра. Обывательләрнең гамьсезлеге белән әсәрнең героинясы да килешә алмый. Чөнки ул кешеләрне буган чылбырларны өзәргә тели.

Декабрь кораллы восстаниесе бастырылганнан соң реакция тантана иткән чорны Толстой авыр кичерә. 1906 ел башында Казаннан ул әнисенә һәм үги әтисенә, бу шәһәрдә реакцион партияләр активлашкач, обстановканың искиткеч күңелсез булуы турында яза. Казаннан киткәч, Толстой тагын шул ук темага сүз алып бара. 1906 елның 19 февралендә язган хатында ул болай ди: «Питерда реакция Казандагы кебек үк түгел, ләкин барыбер һава кысан».

А. Н. Толстойның Казанда язылган кайбер әсәрләрендә реакция тантана иткән чорда халыкның рух төшенкелеге һәм күңел боеклыгы да чагыла. Ләкин яшь язучының уйлануларында ахыр чиктә барыбер революция эше җиңәчәгенә ышаныч өстенлек итә. Казаннан китәргә җыенып йөргән көннәрдә ул «Киләчәк төше» дигән шигырь яза. Анда җәмгыятьнең киләчәктәге бәхетле тормышы тасвирлана: ул чагында хезмәт иркәле булачак, техника һәм сәнгать чәчәк атачак, кешеләрнең якты, әчкерсез хисләренә беркем берни киртә булмаячак.

Казанда яшәгәндә туплаган тәэсирләре, тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе булачак зур язучының тормышында эзсез калмый. Бу тәҗрибә Толстойга, символизм белән кыска вакытлы мавыгуыннан соң, реализм юлына басарга ярдәм итә. 1907 елның апрелендә аның декадентлык рухы белән сугарылган «Лирика» исемле җыентыгы басыла. Ләкин озакламый ул аннан үзе үк баш тарта. Шул ук елның җәендә ул үзенең элек язылган дәфтәрләренә мөрәҗәгать итә. Чөнки ул дәфтәрләрдә аның Казанда иҗат ителгән реалистик тәҗрибәләре дә була. Бу дәфтәрләр турында К. Чуковский «Яшь Толстой» дигән истәлекләрендә сөйли. Аларны ул 1907 елның җәендә язучының өстәлендә күрә. А. Н. Толстой үзенең беренче әсәрләре турында танылган язучының фикерен белергә теләптер, күрәсең, дәфтәрләрне К. Чуковскийга күрсәтә.

Халыкның азатлык өчен көрәше темасына эшләвен дәвам итеп Толстой әледән-әле үзенең Казан чоры язмаларына күз сала. С. И. Дымшиц-Толстойның (язучының икенче хатыны) матбугатта басылмаган истәлекләрендә дә язучының 1907 елның җәендә Идел буенда яшәүче халыкларның тормышына багышланган әсәр өстендә эшләве әйтелә. Толстойның «Экспроприаторлар» дигән хикәясе шул чакта язылган һәм автор аның өчен материалын Казанда һәм Югары Осланда туплаган булырга тиеш, дип фикер йөртергә нигезебез бар. Бу хикәядә халык массасының гаделлек өчен көрәшкә күтәрелүе, бу көрәштә төрле милләт вәкилләренең туганлашуы күрсәтелә. Артек Сокол отряды турында сөйләгәндә язучы «чал чәчле татар» образына басым ясый һәм әлеге көрәшнең гуманлылыгын барыннан элек шушы образ аша ачып бирә. «Чал чәчле татар» — киң күңелле, башкаларга карата игътибарлы кеше. Ул әсирләр белән дә кешеләрчә мөгамәлә кыла. А. Н. Толстой көрәшкә күтәрелгән халыкның аңындагы үзгәрешләр, аның дини йолалардан арына баруы турында сөйли. Рус егете дә, «чал чәчле татар» да дингә карата үзләренең кире мөнәсәбәтләрен белдерәләр. Ләкин әле әсәрдә югары революцион аңга ия булган геройлар юк. Отряд сәүдәгәр Башкировның капиталын тартып алу белән чикләнә. Ул вакытта әле язучы үзе дә революцион чынбарлыкны тиешле дәрәҗәдә аңлап бетерми. Әмма шунысы бәхәссез: Казан тәэсирләре А. Н. Толстойга киләчәк уйланулары өчен һичшиксез бай материал биргән. Соңыннан «Кара елан» повестенда язучы рухландыручылары коммунистлар булган революцион батырлыкка мөрәҗәгать итә һәм бу теманы Казан белән бәйли. Повестьта Казанда оештырылган полкның гражданнар сугышы фронтларында алып барган героик көрәше турында сөйләнә. Полк үзенә тапшырылган бурычны уңышлы үтәп чыга: аклар линиясен үтеп, берничә тәүлек буена дошман тылында хәрәкәт итә һәм яңадан кызылларга килеп кушыла. Иң кыен шартларда врангельчылар кулыннан тимер юлны тартып алырга приказ бирелгәч, полк моны да җиренә җиткереп үти. Һәр ике очракта да коммунистлар сокландыргыч батырлык күрсәтәләр.

Әсәрдә эскадрон командиры Дмитрий Васильевич Емельянов образы башкалардан аерылып тора. Повестьтагы төп геройларның берсе — Ольга Зотова. Казанда ул Емельянов белән очраша. Емельяновның революциягә бирелгәнлеге һәм кешелеклелеге Казан сәүдәгәре кызына аңлы һәм куркусыз көрәшче булып үсәргә ярдәм итә.

Ольга Зотованың элекке тормышын сурәтләгәндә язучының шәхси истәлекләрен бик җиңел сиземләргә мөмкин. «Югары Ослангдагы дача, наратлар, болыннар, җемелдәп яткан Идел, чиксез еракларга җәелгән язгы сулар һәм офыкта йөзгән төркем-төркем болытлар...» — боларның барысы да яшь Толстойның Казан тәэсирләре.

Ольга алдында ике юл: тормышка «фикуслар артыннан» тәрәзәдән карап тору яисә революциянең җиңүе өчен көрәш сафына басу. Ул Емельяновлар юлын кабул итә.

Реакция котырынган чорда Казанда акгвардиячеләр сафында булган башкисәр һәм бандит Валька Брыкин образын тудыруга да язучыга, һичшиксез, аның шул чактагы истәлекләре ярдәм иткән. Вальканың әтисе — Казан полицейский приставы турында да шуны ук әйтергә кирәк.

А. Н. Толстой иҗатында интеллигенциянең революциягә килү юлында «газап чигеп йөрү» темасы шулай ук Казан истәлекләре белән аерылгысыз бәйләнгән. Язучының Казанда иҗат иткән беренче әсәрләрендә үк инде халык тормышына, революцион чынбарлыкка мещаннарча ваемсыз караучы интеллигенция аяусыз фаш ителә. Азатлык өчен көрәш бу «салкын кешеләр» өчен ят нәрсә. «Азатлык һәм кояш турында уйлап газапланганда» лирик герой обывательләр һәм мещаннар арасында үзен ялгыз хис итә. А. Н. Толстой иҗатындагы бу мотивның автобиографик нигезе бар. Революция көннәрендә Толстойның иҗтимагый активлыкка омтылуы, хәтта язучы булырга карар итүе үзен чолгап алган якын кешеләр арасында яклау тапмый. 1907 елның урталарында язучының беренче гаиләсе белән аерылышуын да нигездә әнә шул нәрсә хәл итә.

А. Н. Толстой Казаннан китү белән повесть өстендә эшли башлый. Анда ул, әле суынып өлгермәгән истәлекләр эзеннән, бу шәһәрдә күргән-белгәннәре турында сөйли. Әсәр: «...тәбәнәк һәм озын кабак» дигән сүзләр белән башланып китә. Ләкин ул язылып бетмичә кала. Шулай да аның Казандагы тормыш турындагы өлеше тә-

мамланган. Әсәрнең бу өлешендә яшь егет Алексейның рухи яктан пошаманга төшеп йөрүе тасвирлана. Ул интеллигент-обывательләрнең «өметсез, кызганыч тормышын» гаепли. Ләкин: «Ә алда нәрсә булачак? Нәрсә булачак алда?» дигән сорауга ул әле үзе дә җавап бирә алмый. Алексей мещаннарның рухи ярлылыгыннан көлү белән генә чикләнми, үзенең дә буржуаз җәмгыять традицияләре хакимлегендә булуы өчен газаплана. Ул һәр адымда үзен эзәрлекләгән обывательләр янынннан китә. Бу әле геройның «газап чигеп йөрүе»нең башы гына.

Илдә яңа иҗтимагый хәрәкәт көчәйгәч, интеллигенциянең революциягә килү юллары турында мәсьәлә Толстойны яңадан дулкынландыра башлый һәм ул язылып бетмәгән әсәрен кабат кулына ала. Аның материалын ул «Аксак барин» (1912) романын язганда файдалана. Язылып бетмәгән беренче әсәрдә Алексей юл чатында калган булса, романда язучы аны 1905 елгы революция баррикадаларына алып килә (беренче вариантында). Казан повестенда да, романда да язучының игътибар үзәгендә геройның буржуаз җәмгыять белән ике араны өзүе тора. Ә бу процесс җиңел эш түгел. Дворян моралена бәйлелек Алексейны да, князь Краснопольскийны да булмыйча калган дуэль өчен түбәнсетә, газаплый. Хатынын көнләгән Винелин Алексейны мәсхәрәли. Ләкин Алексей дуэльгә риза булмый. Князь Краснопольский да дипломат Мордвинский тарафыннан мәсхәрә ителә. Әмма ул да дуэльдан баш тарта. А. Н. Толстой геройның көнләшкән ир белән аңлашу моментын Казан повестеннан романга бернинди үзгәрешсез диярлек күчергән. Казан повесте герое өчен уңай якка сизелер-сизелмәс башланган рухи үзгәреш князь Краснопольский өчен революция юлына беренче адым булып тора.

Шунысы кызыклы, А. Н. Толстой демократик мохиттан революциягә килгән интеллигентлар тормышын гадәттә Казан белән бәйли. «Аксак барин»да бу интеллигент — Казан университетында укыган доктор Заботкин. Тәмамланмыйча калган шул ук исемдәге романда — Егор Абозов. Романның караламасында Егор Абозов художник Белокопытовка үзенең революцион эшчәнлеген Казанда башлап җибәрүе турынсөйли. «Газап чигеп йөрү» трилогиясендәге Иван Телегинның яшьлеге дә Казанда уза. А. Н. Толстойның беренче әсәрләре белән таныш К. Чуковский шундый нәтиҗә ясый: Әгәр Иван Телегин яшьлегендә шигырьләр язарга уйлаган булса, аларны ул нәкъ яшь Толстой шикелле язган булыр иде. Чыннан да, «газап чигеп йөргән» Иван Телегин образында Толстой үз шәхесеннән күп нәрсә алган, аңа үзенең уй-кичерешләрен ышанып тапшырган. Иван Телегин, мәсәлән, Ватан көрәшче булуны таләп иткән вакытта үземнең кечкенә дөньяма бикләнеп яшәргә хакым бармы минем, дип уйлана. Толстойның Казан лирикасында да шундый ук фикерләр тулып ята.

* * *

Һәрбер художник иҗатының зурлыгын тормыштан алынган аерым тәэсирләр генә түгел, аның халык тормышы белән даими, органик бәйләнештә булуы билгели. Язучы А. Н. Толстойның күп миллионлы совет, шул исәптән татар укучылары белән элемтәсе һәр вакыт өзлексез, аерылгысыз булды. А. Н. Толстой архивында Татарстан әдәбияты һәм сәнгате эшлеклеләренең, күп санлы укучыларның хатлары саклана. Ул татар әдәбиятының үсешен даими күзәтеп торган.

А. Н. Толстой әсәрләре Татарстанда рус һәм татар телләрендә газета-журнал битләрендә кат-кат басылды, аерым китаплар булып чыкты. 1919 елда, гражданнар сугышы барган утлы көннәрдә үк инде, Казанда аның «Касатка» дигән комедиясе басыла. Татар әдәбиятының күренекле эшлеклеләре аның әсәрләрен үз телләренә тәрҗемә итү өлкәсендә зур тырышлык куеп эшләделәр. 1930 елда Фәтхи Бурнаш тарафыннан язучының «Зәңгәр шәһәрләр» дигән әсәре тәрҗемә ителә. Бу әсәр «Яңалиф» журналында басылып чыга. Моннан тыш аның «Икмәк» повесте, «Петр Беренче» романы, «Алтын ачкыч яки Буратиноның маҗаралары» әкияте тәрҗемә ителеп басыла. Бөек Ватан сугышы елларында А. Н. Толстойның публицистик мәкаләләрен тәрҗемә итү һәм бастырып чыгару эше белән И. Гази, А. Шамов, А. Гумеров, Г. Кашшаф шөгыльләнәләр. В. Качалов исемендәге Зур драма театрында «Иван Грозный» пьесасы зур уңыш белән уйнала.

**Филология фәннәре кандидаты**
**В. СЕМЕНОВА.**

# КАПИТАННЫҢ ТӨНЬЯК ОДИССЕЯСЕ

Моннан биш-алты ел элек матбугатта, төгәлрәк итеп әйткәндә, «Новый мир» журналының 1970 елгы унберенче санында, Төньякны өйрәнүче күренекле галим Эрнест Кренкельнең мемуарлары басылып чыкты. 1929—1930 елларда Франц-Иосиф Җиренә оештырылган экспедиция турында сөйләгәндә, укучыларга ул 1914 елда ук инде рус капитаны Ислямовның Флор борынына Россия империясе флагын кадаганлыгы турында хәбәр итә. Ислямов фамилиясе руслар арасында ишетелгән гадәти фамилия түгел. Шуңа күрә мине аның кем һәм нинди милләттән булуы кызыксындырды. Һәм, чыннан да, тикшеренүләрдән күренгәнчә, мемуарлар авторына аны рус капитаны, дип түгел, ә бәлки рус флоты капитаны, дип әйтергә кирәк булган. Чөнки Франц-Иосиф Җирен Россиягә кушкан беренче ранглы капитан И. И. Ислямов милләте буенча — татар.

1962 елда Ленинградта басылып чыккан «Төньяк диңгез юлы»н ачу һәм үзләштерү тарихы»нда Ислямов берничә тапкыр, әмма һәр урында «И. И.» инициаллары белән генә телгә алына. Архивта сакланган материаллар нигезендә капитанның исеме Исхак, әтисенеке Ибраһим булуы ачыкланды.

Исхак Ибраһим улы Ислямов, 1885 елда Кронштадтта диңгезче-инженерлар хәзерли торган училищены тәмамлагач, Балтикада штурман булып хезмәт итә. Аннан соң Диңгез академиясенә укырга керә. Академияне 1894 елда тәмамлап чыга һәм Баш гидрография идарәсе каршындагы метеорологик бүлек начальнигы ярдәмчесе булып шактый вакыт эшли. Сәләтле гидрограф һәм метеоролог Исхак Ислямов шулай да кырыс холыклы һәм гүзәл стихияле диңгезне сагына, 1898 елның июнендә Адмиралтействоның штабс-капитаны Ислямов флотның строевой офицеры итеп күчерелә һәм аңа лейтенант дәрәҗәсе бирелә.

1899 ел Ислямов өчен тагын да истәлеклерәк була: гидрограф һәм метеоролог сыйфатында «Ермак» боздваткычында ул адмирал С. О. Макаров оештырган төньяк экспедициясе составына кертелә. Бу экспедиция вакытында туплаган гидрографик һәм метеорологик күзәтүләрен ул «Штурманлык эше буенча кайбер фикерләр» дигән махсус язмаларында чагылдыра, анда Төньяк киңлекләрдә йөзгәндә очраган маҗаралар турында сөйли.

1904—1905 елларда Исхак Ислямов, Тын океан эскадрасы начальнигы штабының флагман штурман-офицеры булараk, рус-япон сугышында һәм Порт-Артур оборонасында катнаша.

1905 елның язында Юл эшләре министрлыгы Төньяк диңгез экспедициясе оештыра. Бу экспедиция ике максатны — елга судноларын Төньяк диңгезеннән Енисейга алып чыгуны һәм Себер тимер юлы өчен ашыгыч йөкләр илтеп җиткерүне күздә тота. Лейтенант Ислямов шул экспедиция начальнигы ярдәмчесе итеп билгеләнә һәм аңа Енисей тамагына кадәр барып җиткәнче суднолар белән җитәкчелек итү бурычы йөкләнә. 1909—1910 елларда һәр ел саен Кронштадттан Ак һәм Баренц диңгезләренә бара торган «Бакан» судносы белән командалык итә. Аннан соң ул яңадан Ерак Көнчыгышка җибәрелә. Анда 1912 елга кадәр Амур флотилиясендә «Вихрь» һәм «Шквал» канонер суднолары командиры була. Шул ук елның декабрендә аны беренче рангли капитан итеп күтәрәләр. Ул күп кенә сугышчан орденнар, аерым алганда Дүртенче дәрәҗә Владимир, Дүртенче һәм Икенче дәрәҗә Анна, Дүртенче дәрәҗә Станислав орденнары белән бүләкләнә...

Кешеләр гасырлар буенча Төньяк котыпка — меридианнар кисешкән ноктага барып җиту турында хыялланганнар. Әмма алар моңа ирешә алмаганнар. Лейтенант Георгий Седов һәм аның юлдашларының сәяхәте дә уңышсыз тәмамланган. Арктиканы кыю буйсындыручы куркусыз лейтенантның гәүдәсе Рудольф утравына күмелгәнлегеген без хәзер ачык беләбез. Ләкин моннан алтмыш еллар элек — Георгий Седовны һәм аның юлдашларын эзләү өчен 1914 елда экспедиция оештырылганда бу легендар кешенең кайда күмелгәнлеге әле беркемгә дә билгеле булмаган.

Эзләү экспедициясенең начальнигы итеп капитан Ислямов билгеләнә. Экспедиция өч кораб — «Герты», «Андромеда» һәм «Печора» кораблары составында Яңа Җиргә килеп җитәргә, аны җентекләп тикшергәннән соң, төньякка — Франц-Иосиф Җире архипелагына курс алырга тиеш була.

Төньяк боз океаны буйлап йөзгән вакытта Ислямов көндәлек алып бара. Ул көндәлек аның «Өлкән лейтенант Седовны һәм аның юлдашларын эзләү экспедициясе» дигән истәлекләрендә файдаланыла. Бу истәлекләр Октябрь революциясеннән соң 1918 елда «Диңгез җыентыгы» журналында басылып чыга.

Экспедиция Арктикага очу өчен беренче тапкыр шул чор авиациясен файдалана. Бу хакта Ислямов үзе менә болай дип яза: «Экспедицияне аэроплан белән тәэмин итү проектына төньяк диңгезләрендә булган кешеләрнең скептик мөнәсәбәттә булуларына да карамастан, мин үземне хаклы дип санадым... Безнең алда Франц-Иосиф Җире архипелагын тулысынча карап чыгу бурычы тора иде. Очучы исә архипелаг үзегеннән бер сәгать вакыт эчендә утрауларның теләсә кайсы читенә барып чыга ала. Минем үземә моның уңайлыклары бәхәссез иде. һәм дөрестән дә безнең очучыбыз Яңа Җир күгендә очканда үзенә тапшырылган барлык бурычларны үтәде».

Франц-Иосиф Җирен 1872 елда Австрия диңгезчеләре ача. Ә 1914 елның августында, ягъни «Герта» Флор борынына килеп җиткән вакытта, беренче бөтендөнья сугышының иң кызган чагы була. Бу сугышта исә Австрия-Венгрия Россиягә каршы Германия ягыннан торып катнаша. Политик обстановканы бәяләп, Ислямов монда үзе әзерләгән рус милли флагын кадый. Бирәдә ул Франц-Иосиф Җиренең Россия составына кертелүе турында рус һәм инглиз телләрендә язу калдыра. һәм бу акт хакында Петроградка радиотелеграф аша хәбәр итә.

Седовны эзләүләр исә уңай нәтиҗә бирми. Ләкин бу — капитан Ислямов экспедициясенең әһәмиятен һич кенә дә киметми. Чөнки, баш гидрографик идарә инструкциясендә экспедициягә нинди дә булса фәнни тикшеренүләр алып бару бурычы куелмаган булуга да карамастан, өч судноның төньяк диңгезләрендә йөзүе нәтиҗәсендә күп кенә кызыклы нәрсәләр ачыклана. Беренчедән, Ислямов үзе әйткәнчә, «Франц-Иосиф Җире архипелагына билгеле бер максатны тормышка ашыру өчен суднолар елның-елында керә алачак». Экспедициянең төп нәтиҗәләреннән берсе әнә шул. Икенчедән, экспедициядә катнашучылар алып барган метеорологик һәм гидрографик күзәтүләр Арктиканы алга таба өйрәнү өчен файдасыз булмадылар. Моннан тыш экспедиция Яңа Җир ярлары буйлап йөзү мәсьәләсенә кагылышлы навигация язмалары туплый, Баренц диңгезендә июль-август айларында бозларның бүленеше картасын төзи, шуңа нигезләнеп, төньякны тикшеренүчеләрне аэропланнар белән тәэмин итү кирәклеген һәм моның реаль икәнлеген исбатлый.

Арктика кыюларны һәм куркусызларны һәр вакыт үзенә тартып торачак. Хәер, Арктика бүген дә — әле һаман да ахырынача өйрәнелеп, үзләштерелеп бетмәгән очсыз-кырыйсыз киңлек ул. Шунысын да истән чыгарырга ярамый: Арктика, «һава шартлары кухнясы» буларак, безнең илебезнең климатына һәм берочтан, әлбәттә, тормышына да чын мәгънәсендә әйтеп бетергесез зур йогынты ясый.

Арктика — безнең бөек Ватаныбызның бер өлеше. Ул — кар һәм бозлар, туң диңгезләр һәм исәпсез-хисапсыз утраулар гына түгел, илебезнең изге чикләре дә. Бөек Ватан сугышы елларында Баренц диңгезеннән алып Кара диңгезгә кадәр сузылган коры җир фронтлары белән беррәттән, Арктика фронты да бар иде һәм аның диңгезчеләре фашистларның Енисей култыгына кадәр үк килеп җиткән хәрби корабларына каршы батырларча сугыштылар.

Менә шуңа күрә дә бу кырыс киңлекләрдә Россиянең приоритетын яклаган ватандашларыбызның исемнәре халык күңелендә мәңге сакланыр.

**ИЛДАР СИБГАТУЛЛИН.**

# ГИМНАЗИСТ УЛЬЯНОВ ТУРЫНДА ЯҢА КИТАП

В. И. Ленинның тормышын һәм эшчәнлеген өйрәнүгә багышланган күп санлы тикшеренүләргә тагын бер хезмәт өстәлде. Саратов китап нәшриятында «Гимназист Владимир Ульянов» исемле яңа китап дөньяга чыкты. Аның авторы — тарих фәннәре кандидаты Ж. Трофимов.

Бу хезмәтендә ул күп еллардан бирле алып барган эзләнү нәтиҗәсендә җыелган материалларын бергә туплап, Владимир Ульяновның мәктәп еллары хакында укучыга мөмкин кадәр тулырак мәгълүмат бирү максатын куя. Китапта яшьүсмер Володяның гимназиягә укырга керергә әзерләнгән вакытыннан алып, булачак юлбашчының Ватан язмышы, аның киләчәге турында җитди уйлана һәм революциягә килү юлын билгели башлаган еллардагы тормышы сурәтләнә.

Автор үз бурычын ни дәрәҗәдә тормышка ашыра алган соң? Ул моңа кадәр билгеле булган фактлар нигезендә яшь Ильичның биографиясен тагын бер тапкыр кабатлап чыгу белән генә чикләнеп калмаганмы?

Тарихчы Ж. Трофимов Ульяновлар гаиләсенең Идел буендагы, шул исәптән, Казандагы тормышын һәм эшчәнлеген ике дистә ел буе җентекләп өйрәнеп килә. Аның матбугат битләрендә төрле елларда басылган мәкаләләре һәм документаль очерклары В. И. Ульяновның яшьлек еллары хакындагы яңа мәгълүматларга бай булуы белән укучыларның игътибарын җәлеп итте.

Тарихи ленинианага нинди дә булса яңа табышлар өстәү инде мөмкин дә түгел кебек. Юлбашчыбызның тормыш юлы һәрьяклап энәсеннән җебенә кадәр өйрәнелгән ләбаса. һәм, шуңа да карамастан, автор Ильич биографиясенең моңарчы безгә билгеле булмаган кайбер сәхифәләрен ача, Володя Ульянов яшәгән мөхит, шул чордагы тормышның тулы бер картинасын тудыруга ирешә.

Менә Ильичның «малайлык» чорына караган бүлекләр. Монда без Владимир Ульяновның беренче укытучыларыннан берсе, аны гимназиягә әзерләгән педагог В. П. Прушакевич белән очрашабыз. Туганнарының әйтүенчә, яшь Ильич укытучысы янына сабакка «очып кына бара» торган булган. Автор үзенең китабында безне бу халык укытучысының биографиясе белән таныштыра, аның 1878—1879 елгы фоторәсемен урнаштыра. Анда шулай ук Сембер гимназиясе укытучыларына да шактый тулы характеристика бирелә. Ульяновлар яшәгән һәм укыган атмосфераны тасвирлаган, гимназиядә хөкем сөргән гадәт һәм тәртипләр турында сөйли торган бүлекләр зур кызыксыну белән укыла. Автор шул чордагы урта мәктәпләргә хас кимчелекләрне — сабакны яттан сөйләтү, таяк дисциплинасын, уку программаларының җанлы тормыштан аерылган булуын күрсәтә. Владимир Ульяновның, аның кыз туганнары һәм абыйсы Александрның укуда ирешкән уңышлары шул фонда тагын да калкурак күренә. Ульяновлар гаиләсеннән дүрт бала гимназияне бер-бер артлы иң югары бүләк белән тәмамлый. Ж. Трофимов мондый өлгерешнең «серләрен» ача. Ульяновлар гаиләсенең көндәлек тормышы җанлы детальләре белән күз алдына килеп баса: аларның гаилә тәрбиясендәге төп принципларының асыл мәгънәсе ачыла, укыту процессына иҗади килүнең ничек тормышка ашырылуы күренә. Китапта Ульяновларның Сембердәге гаилә дуслары, алар бе-

лән аралашкан кешеләр хакында сөйләгән битләр дә кызыклы. Алар аралашкан, белешкән кешеләрнең күпчелеге халыкны агарту өчен көчләрен кызганмый торган алдынгы карашлы эшлеклеләр булганнар. Бәяләрнең аңы, дөньяга карашы формалашуга алар да зур йогынты ясаган. Н. И. Ульяновның халык мәгарифе өлкәсендәге эшчәнлеге, реакциягә каршы көрәше яңа документлар нигезендә төпле һәм ышандырырлык итеп тасвирлана. Халыкларның дошманы булган патша самодержавиесенә каршы көрәшкә чыкканда Владимир Ильич алдында беренче чиратта әтисенең тормышы үрнәк булып торуын автор басым ясап әйтә...

Китапта Сембер шәһәренең шул чордагы тормышы киң сурәтләнә. Нәкъ менә шәһәрдәге чынбарлык, анда хөкем сөргән тәртипләр бертуган Ульяновларны күп нәрсәләр хакында тирәнтен уйланырга мәҗбүр иткән. Монда да кискен сыйнфый көрәш тукталмаган, яшерен революцион түгәрәкләр эшләгән, яшьләр арасында газаплы идея эзләнүләре барган.

Владимир Ильич Ленин тормышындагы иң хәтәр һәм драматик чорларның берсе— 1887 елның яз көннәренә багышланган бүлек китапта аерым урын алып тора. Патшага каршы заговорда катнашкан өчен абыйсы Александр җәзалап үтерелә. Ананы сөрген көтә, Владимирның үзенең дә Сембердә санаулы көннәре генә калган... Көтелмәгән авыр кайгылар китергән ул көннәр Ульяновлар гаиләсендәге һәр кеше өчен зур сынау була. Бигрәк тә Владимир җилкәсенә авыр йөк төшә: әтисенең вафатыннан һәм абыйсының җәзалап үтерелүеннән соң ир затыннан ул гаиләдә иң өлкән кеше булып кала. 1887 елның язы — Владимир Ульяновның рухи чыныгу чоры. Яшь Ильичның характеры һәм дөньяга карашы формалашуга ул көннәр нык тәэсир ясый. Шуңа күрә Ленин биографиясенең шушы чоры гомуми кызыксыну уята да. Ульяновлар тормышындагы бу айлар галим тарафыннан аеруча тирән һәм тәфсилле тикшерелә. Күп санлы чыганакларга, истәлек һәм архив документларына таянып, автор Ульяновларның Сембердәге реаль тормыш шартларын күз алдына бастыра, элек билгеле булмаган фактларны ачыклый, кайбер вакыйга һәм даталарга дөреслек кертә. Ж. Трофимов гимназист Ульяновның рухи эзләнүләрен, фикерләү рәвешен билгеләргә омтылыш ясый, мәгълүм булган яки бөтенләй билгеле булмаган фактлар арасында сәбәплелек бәйләнешләрен табарга тырыша.

Менә «Логикадан алган дүртле» дип исемләнгән бүлек. Сүз Владимир Ульяновның өлгергәнлек аттестатында тезелеп торган бишлеләр арасына адашып килеп кергән бердәнбер «дүртле» билгесе хакында бара. Автор бу сәер хәлнең сәбәпләрен ачыклый, әлеге дүртлене куйган укытучының — ә логиканы гимназия директоры Ф. М. Керенский үзе укыткан — ни дәрәҗәдә объектив эш итүен тикшерә. Җиденче класс өчен В. Ульяновка, мәсәлән, логика буенча еллык билге итеп дүртле түгел, дүрт ярым бал куелган булган. Билгене ярымшарлап кую исә ул чордагы гимназиядә гадәти бер нәрсә. Өлгергәнлек аттестатына теркәгәндә андый билгене укучының гомуми өлгереш дәрәҗәсеннән чыгып теге яки бу якка түгәрәкли торган булалар. Ильич барлык фәннәр буенча да дәүләт имтиханнарын бишле билгесенә тапшыра. Әмма имтиханда укучыга билге комиссия тарафыннан бирелсә, логика буенча билгене укытучы үзе генә куйган.

Тырышлыгы һәм сәләте белән Владимир Ульяновның башкалардан никадәр аерылып торуын гимназия директоры теләсә кемгә караганда да яхшырак белгән. Сигез класс буе тоташтан беренче килгән укучыга дүрт ярым билгене бишле итеп түгәрәкләү өчен Керенскийның юридик яктан хакы да, фактик яктан нигезләре дә, әлбәттә, җитәрлек булган, дип яза Ж. Трофимов. һәм аңлатып бирә: «Үзенең тугры хезмәтче икәнлеген күрсәтергә теләп һәм кулында булган мөмкинлектән файдаланып, ул дәүләт җинаятьчесе Александр Ульяновның бертуган энесенә логика буенча билгене киметә. Владимир Ульяновның өлгергәнлек аттестатындагы бердәнбер дүртле билгесе әнә шулай пәйда була...»

Шул ук Ф. М. Керенский тарафыннан Владимир Ульяновка бирелгән характеристиканы да автор җентекләп тикшерә. Мондый документ яшь кешенең политик ышанычлылыгы хакында сөйләүче таныклык хезмәтен үтәгән һәм империянең югары уку йортлары аннан башка беркемне дә кабул итмәгән. Конфиденциаль циркуляр таләп иткәнчә, характеристика гомуми сүзләрдән генә тормыйча, гимназияне тәмамлаучының характер үзенчәлекләре, фикер юнәлеше, белеме һәм хәзерлеге хакында төпле мәгълүмат бирерлек итеп язылырга тиеш булган. Игътибар үзәгенә укучының социаль мәсьәләләргә һәм дингә

мөнәсәбәте куелган. Мондый шартларда характеристика бирүчегә нинди җаваплылык йөкләнүе ачык аңлашыла.

Гимназия директоры үзенең иң яхшы укучысына нинди́рәк аттестация биргән соң? Ж. Трофимовның ачыклавынча, ул монда да юмартлык күрсәтмәгән. Ульяновның классташларына бирелгән характеристикалар белән чагыштырганда бу бигрәк тә ачык күренә. Эш төп мәсьәләгә килеп җиткәч, социаль проблемаларга һәм дингә мөнәсәбәт мәсьәләсенә кагылгач, гимназия директоры туры җаваптан кача: «Ул Владимир Ульяновның дингә ышануы-ышанмавы хакында да турысын язмый, — ди автор. — Башкаларга килгәндә исә, аларның дини итәгатьлелеген мактап бетерә алмый». Александр Ульянов туганының социаль проблемаларга нинди мөнәсәбәттә торуы хакында да директор берни өзеп әйтми. Күренә ки, Ф. М. Керенский В. Ульяновны артык мактап ташлаудан курыккан. Алай гына да түгел, характеристикага ул болай дип өстәүне кирәк таба: «Мин аның үз эченә йомылган булуын, хәтта таныш кешеләр белән, ә гимназиядән читтә исә иптәшләре белән дә, — аралашудан качарга тырышуын, гомумән әйткәндә, кешеләрдән читләшүен күрми кала алмадым...»

Бу хезмәтнең әһәмияте тагын шунда ки, автор Ульяновлар гаиләсенең Сембердәге тормыш-көнкүрешен җентекләп тикшереп кенә калмый. Владимир Ульяновның шәхес буларак формалашуында ул мөхитнең нинди роль уйнавын да күрсәтергә тырыша. Мондый хезмәт барлык чыганакларны һәрьяклап тирән өйрәнү нигезендә генә туарга мөмкин. Кереш сүзендә автор китапның егерме ел дәвамында алып барылган тикшеренү нәтиҗәсе икәнлеген әйтеп үтә. Шуңа күрә дә ул ленинианага яңа сәхифә өсти торган хезмәт дип бәяләнергә лаек.

**ЖАН МИНДУБАЕВ.**

# ВИТАМИНЛЫ ШИГЫРЬЛӘР ӨЧЕН

Ни әйтергә? Ничек әйтергә?.. Фатих Хөсни хаклы, язучыны гомер буе шушы ике сорау борчып, тынгысызлап тора. Инде балалар әдәбияты өлкәсендә эшләүчеләргә килсәк, аларга әлеге сорауларның икенчесе — «Ничек әйтергә?» дигәне — бигрәк тә нык кагыла, бигрәк тә мөһим булса кирәк.

Шәүкәт Галиев — менә шушы «мөһимлек»не аеруча тирән аңлаучы шагыйрьләрнең берсе. Шуңа күрә аның балалар өчен язган шигырьләрен Татарстанда гына түгел, Башкортстанда да яратып укыйлар. Авторның күптән түгел Башкортстан китап нәшриятында чыккан «Витаминлы хәрефләр» китабын башкорт балалары шатланып каршы алды.

Шәүкәт Галиевнең балаларга әйтәсе сүзе күп. Ул балалар белән ихлас күңелдән сөйләшә белә. Әйтәсе килгән сүзен «ничек әйтергә» икәнен белә.

**Шигырьләр бит, балалар,**
**Витамин кебек алар,**
**Күңелләрне үстерә,**
**Йөрәкләргә көч бирә.**
**Булса кайчак әчкелтем,**
**Монысын белә һәр кем —**
**Хак сүз булмый төчкелтем!**

«Әчкелтем» булган хак сүзне витаминга әйләндереп бирү — балалар әдәбиятының мөһим бер үзенчәлеге. Шәүкәт Галиев шул үзенчәлекне истә тота, үзенең шигырьләрен чынлап та витаминлы хәрефләрдән, витаминлы сүзләрдән, җөмләләрдән, витаминлы ритмнан, интонациядән төзи. Ул балалар психологиясен, балалар күңелен яхшы аңлый, тормыш күренешләренә балалар күзлегеннән карый. Аның күпчелек шигырьләренә уен элементларының хас булуы шуны раслап тора.

**Оча, оча, чебешләр оча!**
**Тилгәннәр куып җитә алмыйлар,**
**Ябалаклар алып китә алмыйлар,**
**Каргалар да азык итә алмыйлар.**

**Оча, оча, чебешләр оча!**
**Чебешләрнең эш хутта —**
**Чебешләр оча самолетта!**

Уенга, шуклыкка корылган бу шигырьне тыңлагач, рәхәтләнеп бер көләсең, эстетик ләззәт шатлыгын кичерәсең.

Тавышлар... Безнең бу тормыш төрле-төрле тавышлар гармониясеннән тора бит. Тавышка карата балалар бигрәк тә сизгерләр. Үзләре дә шауларга, йөгерергә, сикерергә яраталар. Балалар дөньясын без шушы хәрәкәт, тавыш, шау-шулардан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Балалар тормышына хас әлеге үзенчәлекләрне Шәүкәт һәр вакыт күз уңында тота.

**Яна бозлар ялтыр-елтыр,**
**Сына бозлар чалтыр-чолтыр.**

Шагыйрь монда «ялтырап янган» бозларны күрсәтеп кенә калмый, аларның тавышларын да ишеттерә. Шатлыклы, музыкаль ритмнар аның әсәрләренә аерым бер җанлылык өстәп тора.

Шәүкәт Галиевнең тынгысыз геройлары тормыштагы һәрбер нәрсә, һәрбер күренеш белән кызыксыналар. Дөньяны танып-белергә омтылу — аларның характерын билгели. Һәрбер яңа көн алар өчен нинди дә булса берәр яңалык алып килә. Икенче төрле әйткәндә, галимнәр кебек үк, алар дөнья серләрен ачучылар. Ә дөнья серләрен ачучы кешеләрнең эзләнүләре гел генә табышлардан тормый. Табышлар да, хаталар да еш очрый.

Шагыйрь аларның эзләнүләрдән торган тормышын идеаллаштырмый. Алар эзләнәләр, хаталаналар, ниһаять, дөрес нәтиҗәгә киләләр. Кулына беренче тапкыр борау тоткан малай да («Борау»), ашханәдән камыр алып кайтучы малай да («Пәрәмәч»), кыяр, помидорларга түбәтәй кидерүче малай да («Түбәтәйле кыярлар»), салкын тимергә тел тидергән Биктимер дә («Биктимер белән тимер») — барсы да яхшы күңелле балалар. Ләкин алар әнә еш кына ялгыш эшләр эшлиләр. Мажаралы ситуацияләргә эләгәләр. Бу мажаралар, ахыр чиктә, аларны тормышны танып-белергә, тормышны яратырга өйрәтә.

Ш. Галиев шигырьләрендә төрле кошкортлар, хайваннар күп очрый. Авторның саф күңелле нәни геройлары хайваннар белән яхшы мөнәсәбәттә яшиләр.

**Тиенкәйне тоттылар,**
**Калага озаттылар,**
**Тар читлеккә яптылар.**
**...Тиенкәй хәлен беләм,**
**Кителмәсен дә күрәм,**
**Жәлләп чикләвек бирәм —**
**Туктагач бер кимерсен,**
**Дуслары барын белсен,—**

ди «Тиенкәй» шигыренең герое. Тиз тәэсирләнүчән бала күңелендә дөньяның һәрбер җан иясенә карата теләктәшлек уяту, кайгысын уртаклашу, шатлыгын бүлешү кебек кадерле сыйфатлар тәрбияләүне автор үзенең изге бурычы итеп саный. Тиен дә, мәче дә, төлке дә, бозау да, чебеш тә, казлар да — балаларның дуслары.

Балалар язучысы өчен иҗат фантазиясенең роле иксез-чиксез зур. Шәүкәт Галиев иҗаты тагын бер тапкыр шул фикерне куәтли. Шагыйрьнең иҗат фантазиясе кайсы чакта булмаганны да булган дәрәҗәсенә күтәрә ала. Балаларның хыял юнәлешен яхшы тоеп эш иткәндә, ышанмаслык хәлгә дә ышанасың, ышану гына түгел, хәтта чын күңелдән шатлык кичерәсең... Авторның «Тилгән килгән шәһәргә» шигырен алыйк, мәсәлән. Тилгән килеп, чын бәбкә урынына пластмасса бәбкәне күтәреп алып оча. Тормышта була торган хәл түгел бу. Шулай да без шагыйрьне, «ник юкны яздың?» дип битәрли алмыйбыз. Баланың канатлы хыялы шуны таләп итә: ничек тә булса явыз тилгәннән дә үч алырга кирәк, алдарга кирәк аны. Һәм шагыйрь баланың теләген үти: тилгәнне пластмасса бәбкә белән алдый...

Шагыйрь юморга бай канатлы фантазия белән оста эш итә белә. Шулай да кайсы чакта фантазиянең чамасын да онытып куя. Бу чамасызлык аны шул чак тормыш дөреслегеннән читкә алып китә. «Мыеклы бозау» шигыренең эчтәлеге кызыклы гына булса да, сурәтләнгән вакыйга чынбарлыкка тап килми, монда ниндидер аңлашылмаучылык килеп чыккан. Ә инде «Космонавт булабыз дип» исемле шигырьдәге геройлар кебек сандыкка бикләнеп яту да чаманы онытып ташлауны күрсәтмиме икән?!. Сандыкка бикләнеп ятуларның күңелсез хәлләргә алып килгәне дә бар бит. Бәхеткә каршы, китапта мондый характердагы кимчелекләр аз очрый.

Россия язучыларының IV съездында сөйләгән докладында С. Михалков, совет балалар әдәбиятының йөзен билгеләп: «Ул (балалар әдәбияты) бүгенге яшь кешене иртәгәге зур тормышка әзерли. Ул үз заманының җимеше», — диде. Шуңа күрә дә партиябез, илебез алдында торган катлаулы бурычлар балалар әдәбиятыннан читтә кала алмый. Шәүкәт Галиев — менә шушы җитди бурычларны тирән аңлап иҗат итүче шагыйрьләрнең берсе.

**ШАКИР БИККОЛОВ.**

## Шәүкәт Галиев

### Яз чиге шушы икән

Ала-кола карда
Бара кара карга.
Бара чаңгы эзеннән,
Чаңгы эзе — тезеннән.
Тап-такырдан килгәндә
Чаңгы эзе бер мәлдә
Гөрләвек булып киткән —
Яз чиге шушы икән!

Инде ала карга
Яшел кырдан бара.

### Эзкуарга имтихан

Маэмаем минем
Чыгып югалды,
Ахры, шәһәрдә
Адашып калды...

Ачыгадыр ул,
Туңадыр инде,
Кайларда гына
Кунадыр инде...

Кайтыр иде дә,
Белми адресны.
Әткәй юата:
— Беләдер исне!

Эзләп карадым,
Сорап карадым,
Елап карадым —
Таба алмадым...

Минем арттан ук
Кайтты бит көчек —
Мин тапмаганны,
Тапкан ул ничек?

Баскычны исни,
Ишекне исни:
Борыны белән
Укый адресны!

Әткәй мактады:
— Моннан эш туар —
Имтихан үтте
Синең эзкуар!

## Песнәк, пес-пес...

Бер песнәк килеп
Кунды куакка.
Ничек эндәшим
Икән кунакка?

Кумәч салдым да:
— Песнәк, пес-пес!— дим,
Курыкма бер дә,
Җиргә төш, төш!— дим.

«Чит-чит, чит-чит»,— ди,
Песнәк кымшанмый.
Чынлап әйтәм бит,
Нишләп ышанмый?

Песнәк очкачтын
Күрдем песине:
— Ник килдең әле,
Дәшмим бит сине!

Тирбәлеп калган
Куакка карый,
Ымсынып карый —
Иренен ялый.

«Песнәк бирер»,— дип,
Торганмы иснәп?!
«Мәкерле бу...»— дип,
Киттеме песнәк?..

Песнәк тә очты,
Песи дә сызды.
Сөйләшә белмәү
Араны бозды...

## Оттырыш...

Кадыйр тоткан
Рогатка:
— Ерак ата —
Трах-тах-та!

Бармы, Вазыйх,
Тотканың,
Ичмаса, бер
Атканың?

Юкмыни? Ах,
Мескенкәй...
Җебегәннәр
Бетсен, әй,

Әнә мишень,
Күрәмсең —
Кыекта бер
Күгәрчен?

Юк, тидерә
Алмыйсың.
Булмас. Булмас!
Алдыйсың.

Әйдә бәхәс!
Бир бишне:
Отсаң, сиңа
Тиешле.

... Вазыйх атты.
Тиде бит!
Кадыйр:
— Шәп, шәп!—
Диде бит.—

Менә дигән
Мәргәнсең —

Нәкъ күзенә
Бәргәнсең!

Оттың, малай,
Нык ордың!
... Ә бит, Вазыйх,
Оттырдың...

## Көчле келәшчә

Келәшчә шап-шоп
Суга да тора.
Тактага кадак
Чума да тора.

Арада була
Кире кадаклар —
Аяк терәр дә,
Керми азаплар;

Башын кыйшайтып
Кәкрәеп төшәр,
Шул тискәрегә
Терәлер эшләр...

Келәшчә җәһәт
Каптырып ала,
Чыелдаттырып
Тарттырып ала!

Ятулар кая
Монда турсаеп —
Кайнар кадагың
Баса тураеп.

Очкын чәчрәтеп
Эшләгән чакта
Келәшчә кырыс —
Тәртип ярата!

## Җил бакчага кергән...

Җил бакчага
Кергән,
Зур алмалар
Күргән.

Ботакларга
Кунган,
Җиргә алма
Койган.

Этләр өргән
Аңа:
«Сорамыйча
Алма!!»

Җил капканы
Ачкан —
Җил-җилаяк
Качкан...

Әмма халык
Белгән:
— Җил бакчага
Кергән!—

Көз буена
Җилдән
Алма исе
Килгән...

**Кизәнов**

# ЧӘНЕЧКЕЛЕ МОНОЛОГЛАР

### АЕРЫЛЫШКАЧ

— Мин бит аңа тормышымда иң кыйммәт нәрсәне — бердәнбер баламны бирдем, ә ул, явыз хатын, миннән тагын алимент та даулап маташа, — ди икән... бер тол ир.

### САК БУЛУ ТУРЫНДА

— Самогон куганда аны шулай итеп эшләргә кирәк ки, хәтта исе дә чыкмаслык булсын, — ди икән... участковый милиционер.

### УРЫНЛЫ ТӨЗӘТМӘ

— Бер дуңгыз «минем итем дә нәкъ елкы ите кебек» дип мактанып йөри, имеш. Тукта, мин аны бүген шашлык итеп кыздырыйм әле,— ди икән... аш-су остасы.

### КУЛЬТУРА РАБОТНИГЫ

— Мине дә культура работнигы итеп санарга тиешләр, чөнки бөтен барабаннар да минем тиремнән ясала бит, — ди икән... ишәк.

### ЮККА ТЫРЫША...

— Сандугач ул тамак яра-яра төннәр буе сайрап юкка тырыша, аның урынында булсам, мин бер-ике мәртәбә «чирик-чирик» итәр идем дә тәмләп йокыга китәр идем, — ди икән... чыпчык.

### КЫЗЫКТЫРГЫЧ ГАЛСТУК

— Бөтен шпаргалкаларымны да бер галстукка язып мин бик ялгышканмын, ахрысы, чөнки күргән бере «мондыйны кая саталар?» дигән бер үк сорау белән бәйләнә, — ди икән... студент.

### АШХАНӘДӘ

— Ярый, бер сәгать көтәсең ди инде син. Ә шуның өчен нигә тавыш куптарырга кирәк соң? Әнә теге өстәлдәге абзый синнән дә күбрәк көтте, хәзер инде тавыш-тын чыгармыйча рәхәтләнеп черем итә, — ди икән... официант.

### ТЫНЫЧЛЫК КИРӘК

— Сезнең сырхавыгыз көчәйгәннән-көчәя бара. Сезгә тынычлык кирәк, артык көч куярга ярамый, ашыгу исә бөтенләй тыела. Шуңа күрә дә мин сезгә эшкә чыгарга язу бирәм, — ди икән... врач.

### КАЙСЫ ЯХШЫРАК!

— Миңа калса, дүшәмбе көн якшәмбедән яхшырак. Чөнки якшәмбе көнне кунаклар киләләр дә өйдә бик күп аракы эчәләр, ә бушаган савытларны дүшәмбедә мин сатам! — ди икән... бер бала.

## Сәет Кальметов

# ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ДӘВАЛАУ

*Юмореска*

Ул көнне күңелем көр, авызым ерык иде. Иске тимер-томырга китәргә ажгырып торган экскаватор белән планны 132 процентка үтәдем. Башка көннәрне траншея казыганда ул тимер үләтнең шөрепләре коелып теңкәмә тия иде. Вахта машинасын көтеп торган арада, «Алсу таң» совхозы басуында яңа гына өлгереп килгән борчак кузагы да состым. Вахта машинасына утыргач, корсагымны сыйпый-сыйпый, яшел витамин умырдым әле дип, иптәшләр алдында шапырынып алырга да өлгердем.

Автовокзалга кайтып җитүгә, тотынды эч авыртырга, тотынды, мин сиңа әйтим, әйтерсең лә эчәкләремнән аркан ишәләр! Шофер минем хәлне шунда ук сизеп алды:

— Хәлең мөшкел, ахры, дус кеше, әйдә, больниска илтим үзеңне.

Больнис, имеш! Анда эләксәң, өч көн буе анализ алалар, дүрт көн буе диагноз куялар, биш көн буе укол кадыйлар... Шунда барып керсәм, төп башына утырып калам ич мин. Конторга яңа техника кайтырга тора. Үзе юкның күзе юк, диләр. Зарифуллин җимерек техника белән дә рекорд куя дип, яңа экскаваторны башка бирәүгә бирәчәкләр. Аны-сын көт тә тор.

— Мин үзем дә дәвалана беләм, — дигәч, шофер мине өемә генә китерде.

Ишектән керү белән, дарулар тартмасыннан шешәләр алып өстәлгә тездем. Иң элек стаканга касторка агыздым, аның өстенә балык мае. Стакан тулсын дип көнбагыш мае да өстәдем. Чырайны сыта-сыта, стаканны көч-хәл белән бушаттым. Аннары, эчне уа-уа бөтерелә торгач,

бажай өчен саклап тоткан аракыга чират җитте. Эзләп-эзләп тә кызыл борыч таба алмагач, ике кашык кара борыч салып болгаттым да ялт бер рюмканы! Узәр әле дип, кушеткага сузылдым.

Менә узды да! Борчак микробларын аяктан егарга ике йөз грамм да җитә икән ич! Шатлыктан көлеп җибәрүем булды, тотынды бит эч янарга! Борчакларга бензин сибеп ут төрткәннәр диярсең. Чәбәләнәм, урынымнан һич кузгала алмыйм. Аптырагач:

— Су, су, су! — дип акырдым.

Котлары алынган күрше хатыннары бүлмәмә кереп тулды. Әмма миңа бер чүмеч су бирергә ник берсенең башына килсенче! Томана чәрелдекләрнең бар белгәне «ашыгыч ярдәм» дә «больница».

...Хәзер сәламәтлегем корычтай. Тезәмә куеп ломны бөгәрлек хәлдә. Шунысына мең шөкер, хирургылар эчне ярмадылар. Тик менә больнистан чыкканда, баш врачның кулын кысып, рәхмәт әйтергә дип кабинетына кергәч, бәлагә тап булдым. Палатада ятканда көйләп-чөйләп сөйләшә торган баш врач кашларын сындырып, минем каерыны салдыра башлады:

— Үз-үзеңне дәвалау җинаять! Туп-туры безгә килсәң, өч сәгатьтә дәвалый идек без сине. Җәй уртасында экскаваторчы унөч көн буе больницада аунап ятсын әле! Начальнигың булсам, мин сине судка бирер идем, әйе, әйе, судка!

Чәчләрем үрә торды, коелып төштем. Кая бу кансыз бәндәгә рәхмәт әйтү, алдыма-артыма карамыйча, тизрәк кабинеттан чыгып тайдым. Әйе, Зарифуллинны майлы ботка көтми икән! Эш зурга киткәнче, аңлатма язуы язып, контор башлыгының өстәленә илтеп салырга кирәк дигән карарга килдем.

Өйгә кайту белән ашыга-ашыга шуны әвәли башладым. Ни җитте шулай итеп язасы килми, язмышымны хәл итәчәк язу бит бу! Аны укыгач, башлыкның күзе яшьләнерлек булсын. Аңлатмада үземне бер гөнаһсыз бәндә итеп күрсәттем. Медицинаның белем бакчасыннан бер җимеш тә өзеп капмаганга күрә шулай ялгышуымны әйттем. Сәламәтлегемә зыян килмәде, иске экскаваторда да теттереп эшли алам, дидем. Хискә бирелеп яза торгач, талмутым шактый озынга сузылды. Ә безнең башлык сүз боткасын яратмый. Аңлатманы мәгънәле, кыска итеп, телеграф теле белән язарга куша. Кат-кат кыскарта торгач, ул менә болай килеп чыкты: «Контор башлыгына. «Тәмәке зарарлы», «Аракы зарарлы» дип язылган плакатларны еш очратканым бар. Әмма «Үз-үзеңне дәвалама!» дигәне күземә чалынмады. Хатыным больниста хисапчы булып эшли. Стажы тугыз ел. Ул да бу хакта миңа бернинди кисәтү ясамады. Иптәшләр суды хатынга 15 сум штраф салсын».

Судан коры чыгар өчен хатынга әнә шулай юри каты бәрелдем. Кулдан экскаваторны тартып алмасалар, хатынга нейлон тиресеннән теккән тун алып бирәчәкмен.

Ярар, кузгалыйм. Башлыкның кәефе шәп булса гына күзенә күренәм. Хөрти булса, аңлатманы секретарьга гына калдырам. Конторга җитү белән, урамдагы эскәмиягә утырдым. Берәрсе чыкса, «Башлыкның кәефе ничек?» дип сорарга исәп. Күп тә үтмәде, башлык үзе килеп чыкты. Ул, мине күрүгә, теш арасыннан гына:

— Зарифуллин, сезгә карата приказ язылган анда, — диде дә ашыгып китеп тә барды. Башлыкның бу сүзе минем колагыма: «Сиңа хөкем карары чыгарылган инде», — дип ишетелде. Конторга кердем дә приказ тактасы янына килдем... «Зарифуллинга яңа экскаватор бирергә» дигән сүзләрне калтырана-калтырана укый башладым.

# КАРАТАУ МӘЗӘКЛӘРЕ

Каратау (Черногория) — Югославиядә бик кечкенә республика. Башкаласы — Титоград. Каратау кешеләре, чыннан да, текә тау итәкләренә салынган бәләкәй авыллар һәм калаларда яшәп, иген игәләр, кораблар төзиләр, алюминий эшкәртәләр. Шул халыкның тапкыр һәм зирәк иҗатыннан кайбер үрнәкләр тәрҗемәсен укыгыз.

*
* *

Элекке заманнарда Каратау кешесе хәрби хезмәткә алынгач аягына иң зур итек яки иң зур ботинка алырга тырыша торган була. Шундыйның берәвеннән: «Ни өчен аяк киеменең зуры кирәк сиңа?» дип сорагач, ул әйтә икән:

— Аякка иркенне кигәч яхшы хезмәт итела ул. «Артыңа әйләнеп бас!» дигән команда бирелсә, мәсәлән, аягыңны тиз генә әйләндереп куясың, ә итегең яки ботинкаң үз урынында кала.

*
* *

Таулар арасындагы авылыннан читкә китеп бик озак торгач, Звонко Мичунович Титоградка самолет белән кайтып төшә. Аны алырга авылдашлары бик үшән бер алаша җибәрәләр — янәсе, атка күптән инде атланмаган кунак иярдән әйләнеп төшә күрмәсен. Мичунович авылга кайтып җиткәч, аны, беренче булып, җиде яшьлек бер малай очрата. Сөйләшеп китәләр.

— Син бит Вуков онысы буласың.
— Әйе шул. Ничек белдең син моны?
— Вукны исемә төшереп.
— Әһә. Син үзең, димәк, Звонко буласың?
— Дөрес. Ә ничек белдең шуны?
— Алашаңа карап.

*
* *

Егерменче елларда була бу хәл. Бер байның чит илдә укыган улы каникул вакытында авылга кайта. Гомер буе ялчы булып тир түккән кардәш-туганын «агартырга» теләп, студент егет аңа «Ничек баеп була» дигән китап бирә. Аны бик юка кәгазьгә басканнар икән. Бер атнадан студент үзенең кардәш-туганы белән тагын күрешә:

— Я, ничек, китап ошадымы соң?

— Бик әйбәт нәрсә. Мин аның очына да чыктым инде. Тәмәке менә дигән итеп төрелә! Киләсе елда кайтыр булсаң, тагын берне алырга онытма. Ә бәлки папиросын ук табарсың? Чөнки хәзер бездә тәмәке табулары бик үк җиңелдән түгел...

*
* *

Авылда партизаннар отряды оештырырга булалар. Бер үсмергә бик кыска көпшәле итальян карабины бирелә. Ә ул исә бабасыннан сорый икән:

— Аңлат әле, зинһар, бабакаем: ник миңа шундый кыска мылтык бирәләр? Моңардан бит пуля әллә кая ерак оча алмый. Ә мин дошманны ничек кырырга тиеш булам?

— Ә син, — дип киңәш кыла баба кеше, — дошманга үзең якынрак бар, балам.

*
* *

Элек заманнарда Каратауның кайбер кешеләре бәхет эзләп Америкага күчә торган булганнар. Менә күптән түгел океан артында ярты гасырдан артык яшәгән шундый берәү, туристлар белән бергә, Титоградка килеп чыга. Аннан исә ул үзенең туган җире Которга да барып чыгарга тели. Ләкин юлда әлеге кеше автобустан диңгез ярындагы хәзерге Которда түгел, ә кыя таулар арасындагы Цетиньеда, ягъни Каратауның элеккеге башкаласында төшеп кала. Һич таныш булмаган урамнар буйлап аптырап-каңгырып йөри торгач, турист дигәнебез үзенең ялгыш урында тукталуын аңлый.

— Әйтегезче, галиҗәнаб кешем,— дип сорый «Америка» кешесе каядыр узып баручы берәүдән. — Которга пароход тиздән китәме?

— Бик тә тиз китүе мөмкин, — ди аңа узгынчы. — Төштән соң бер сәгать узгач ук... ләкин әгәр су булса гына.

*
* *

Люблянга командировкага килгән бер каратаулы кунакханәдә туктала. Аңа шулай ук командировкадагы Словен кешесе белән бер бүлмәдә торырга туры килә. Кичен аларның электр утлары сүнә икән.

— Хәзер төзәтәбез аны, — дип, — словенлы абзый дежурныйдан тиз генә лампочка алып килә. — Мә, тот шуны кулыңа, менеп бас минем җилкәмә!

Каратаулы аның җилкәсенә менеп баса, ләкин ут һаман кабынмый да кабынмый. Словен кешесе, башын күтәреп, сорый шул чакны:

— Нишләп бормыйсың инде шул лампочканы?

— Ә ник син үзең баскан урыныңда әйләнгәләп тормыйсың, дускай? — ди аңа әлеге бүлмәдәш.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## НӘШРИЯТЫБЫЗ 1977 ЕЛДА

Биредә 320 исемдә яңа басма чыгарга тиеш — марксизм-ленинизм классиклары әсәрләре, тарихи, фәнни-популяр, техника-экономика һәм авыл хуҗалыгы темасы китаплары, документаль җыентыклар. Планда 31 яңа проза, 18 поэзия, 3 драма, 7 тәнкыйть һәм әдәбият белеме китаплары, СССР халыклары һәм дөнья әдәбиятыннан татарчага тәрҗемә ителгән 18 китап чыгару күздә тотыла. Татарчадан русчага исә 8 әсәр тәрҗемә ителәчәк.

Дәреслекләр һәм укыту-педагогик китаплар саны — 33. Татар телендә стена календаре, ике дистәдән артык альбом һәм буклет, листовка һәм плакат чыгачак. Татар композиторларының 9 җыентыгы укучыларга нота язмалары белән тәкъдим ителә.

Нәшриятның аңлатмалы тематик планы илебезнең барча китап сәүдәсе оешмаларына таратылды. Китаплар урыннарга килеп җитмәгән очракта, аларны почта аша соратып алырга мөмкин. Адреслар: 420000, Казань, Баумана, 19, магазин № 1. Казань, Октябрьская, 18, магазин № 14 — «Книга-почтой».

## ҮЗӘК НӘШРИЯТЛАРДА БЫЕЛ РУС ТЕЛЕНДӘ ЧЫГАЛАР

### «Советский писатель» нәшрияты

1. Габдрахман Әпсәләмов. «Огонь неугасимый». Роман. 31 табак. Тиражы 100 мең.
2. Сәҗидә Сөләйманова. «Предсказание». Шигырьләр һәм поэма. 3 табак. Тиражы 10 мең.
3. Сибгат Хәким. «Врата времен». Шигырьләр һәм поэмалар. 4 табак. Тиражы 20 мең.
4. Риза Ишморатов. «Буре навстречу». Пьесалар. 10 табак. Тиражы 15 мең.

### «Советская Россия» нәшрияты

5. Әхмәт Фәйзи. «Тукай». Роман. 15 табак. Тиражы 50 мең.

### «Современник» нәшрияты

6. Аяз Гыйләҗев. «Любовь и ненависть». Повестьлар. 18 табак. Тиражы 30 мең.
7. Әмирхан Еники. «Одно лишь слово». Повестьлар һәм хикәяләр. 17 табак. Тиражы 30 мең.
8. Атилла Расих. «Весенние голоса». Роман. 16 табак. Тиражы 75 мең.
9. Ренат Харисов. «Русские ворота». Шигырьләр. 2 табак. Тиражы 10 мең.
10. Илгиз Кәлимуллин. «Дорога к людям». Шигырьләр. 2 табак. Тиражы 10 мең.
11. Хәсән Туфан. «Долгий день». Шигырьләр. 4 табак. Тиражы 10 мең.

### «Молодая гвардия» нәшрияты

12. Рафаэль Мостафин. «Муса Джалиль». Балалык еллары һәм сугышчан яшьлеге турында повесть. 12 табак. Тиражы 75 мең.

## «ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫ» КИТАПЛАРЫ

Алар подписка белән дә таратылачак 12 томлы басма итеп чыгарыла. «Кыска җырлар — дүртьюллыклар» дигәне инде 1976 елда ук укучылар кулына ирештерелде, быел «Табышмаклар» томы чыга. 1982 елга хәтле чыгасы томнар түбәндәгеләр: «Әкиятләр» (3 том), «Мәзәкләр», «Риваятьләр һәм легендалар», «Дастаннар», «Бәетләр», «Мәкальләр һәм әйтемнәр», «Йола һәм уен җырлары», «Лиро-эпик һәм лирик җырлар». Һәр томның якынча күләме 25 табак, бәясе 1 сум 52 тиен. Бер томның бәясе подписка вакытында алдан түләнә. Подписканы Таткниготоргның барлык кибетләре кабул итәләр.

## ФРАНЦУЗ ӘДИБЕ КАМАЗДА

Язучы-коммунист Андре Ремакль Чаллыда иҗат командировкасында булып китте. Ул Марсельда чыга торган газетада эшли, аның «Яшәү заманы» дигән романы Мәскәүдә рус телендә чыкты, «Иностранная литература» журналында «Өч көнш урамы» исемле романы чыга. Әдипнең күпкырлы һәм зур иҗаты нигездә эшче кешеләр тормышын, аларның бәхет өчен көрәшен сурәтләүгә багышлана. КамАЗ турында исә ул документаль хикәя-уйланулар язачак. «Үз китабымда, — ди Андре Ремакль, — Советлар иле чынбарлыгын дөрес итеп, иң зур объективлык белән күрсәтергә телим. КамАЗ — гаять җитди тема. Мин, язучы кеше, аны язуга бирелгән гигант заводлар комплексы кебек үк зур булган хезмәт итеп карыйм».

## ШИГЫРЬ ҺӘМ ҖЫР КИЧӘСЕ

Патриот шагыйрь Муса Җәлил батырлыгы һәм иҗатына багышланган зур әдәби-музыкаль кичә Мәскәүдә «Главмосстрой» культура һәм техника йортында уздырылды. Аны Мәскәүдәге яшь шагыйрь Әхмәт Саттар алып бара, танылган рус шагыйре һәм драматургы Павел Железнов кичәдә Мусаның Мәскәүдәге студент

еллары, бергәләп җәмәгать эшләрендә катнашуы, Луначарский лекцияләрен тыңлавы турында сөйли. Шунда ук Һиндстаннан килгән кунак — бенгаль шагыйре Бадрул Хасан Баблу да чыгыш ясап Бангладеш газеталарында Муса иҗаты турында күп язылганлыгын әйтә. Реакция елларында аның «Моабит дәфтәре»н инглиз телендә укыганнар. Кичәдә катнашучы яшь шагыйрьләр Җәлил турында әсәрләрен төрле телләрдә (Спартак Әхмәтов — русча һәм казакъча, Ваган Карапетян — әрмәнчә, Тәнзилә Юлдабаева — башкортча һәм русча) укыйлар. Аннары Муса сүзләренә язылган җырлар яңгырый.

## ТӨРЛЕ РЕСПУБЛИКАЛАР һӘМ ӨЛКӘЛӘРДӘ

Үзбәкстанның «Яшь гвардия» нәшриятында «Муса белән иңгә-иң торып» дигән китап рус телендә чыгачак. Аның авторы—филология фәннәре кандидаты Исхак Зәбиров. Ул фронтта һәм фашист концлагерьларында Муса Җәлил белән бергә көрәшкән батырлар турында яза.

*

* *

Чуваш халык шагыйре Педер Хузангайның «Песни Телли» исемле китабында «Минем Россиям» дигән поэма тәрҗемәсе дә бар. Анда Татарстанның элеккеге Бизнә авылында крестьяннар восстаниесе (1861 ел) күренешләре тасвирлана, ә «Җирдә ятмыйбыз» поэмасында исә Казан коммунисты Фәйзетдинов Галимҗан образы бирелә.

*

* *

Кировта чыккан «Вятка» исемле җыентыкта якташыбыз, Советлар Союзы Герое, очучы Новоселов батырлыгы турында очерк («Поединок») басылган.

*

* *

Мәскәүдә «Просвещение» нәшрияты чыгарган балалар әдәбияты хрестоматиясенә «Өч кыз» исемле татар халык әкияте һәм Муса Җәлил шигырьләре кергән.

*

* *

Мәскәүнең «Искусство» нәшрияты үзешчән театрлар өчен репертуар туплап «Бердәм көлү» исемле өченче җыентык чыгарды. Концертларда башкарырга ул Шәүкәт Галиевнең ике шигырен («Журналист әйтте», «О'кей») тәкъдим итә.

*

* *

Уралда гражданнар сугышында актив катнашкан революционер Михаил Кодомцев Минзәлә төрмәсеннән кача. Шул чакны ул Казан революционерлары белән элемтәдә була. «Политиздат» чыгарган «Смело, товарищи...» (В. Кашиц, Мәскәү.) дигән китапта аның турында аерым бүлек бар.

*

* *

Мари халык шагыйре Миклай Казаков рус телендә чыгарган «Дорогой жизни» китабына татар халкы һәм татар шәһәрләренә багышланган өч шигырь кергән («Фатыйма», «Татар дустыма», «Өч кала») һәм «Гвардеецлар» поэмасында Казан большевигы Әхмәт образын бик оста тасвирлаган.

## СОВЕТ ТЮРКОЛОГЛАРЫНЫҢ ЗУР ФОРУМЫ

Алма-Ата шәһәрендә совет тюркологларының СССР Фәннәр академиясенең тел, әдәбият һәм тарих бүлекләре, Казагыстан ССР Фәннәр академиясенең иҗтимагый фәннәр бүлеге һәм совет тюркологлары комитеты оештырган Бөтенсоюз конференциясе булды. Ул Октябрь революциясенең 60 еллыгына һәм тюркологларның 1926 елда Бакуда булган беренче съездының 50 еллыгына багышланды.

Анда, 350 дән артык делегат һәм чит илләрдән вәкилләр катнашып, төрки тел белеме, әдәбият теориясе, шулай ук фольклористика, тарих, археология һәм этнография буенча зур-зур докладлар тыңланды. Мәсәлән: «Хәзерге көндә СССР-да төрки тел белеме» (академик А. Н. Кононов), «Совет чорында СССРдагы төрки телләрнең үсеше» дигән коллектив доклад (Казакъ Фәннәр академиясе академигы С. К. Кенесбаев сөйләде), СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты Г. И. Ломидзенең «Күп милләтле совет әдәбиятының эстетик баю юллары» проблемасына багышланган чыгышы һәм башкалар.

«Төрки халыкларының экономикасы һәм культурасы бары тик Совет власте елларында гына һәм ленинчыл милли политиканы тормышка ашыру нәтиҗәсендә чын мәгънәсендә чәчәк атты», — диде академик Кононов. Бөек Октябрь революциясеннән соң төрки әдәби тел нормаларын эшкәртү, орфография,* орфоэпия, алфавит һәм терминология мәсьәләләрен тикшерү аеруча актуаль булды, чөнки туган телдә оештырылган халык мәгарифе нигезендә грамотасызлыкны бетерү төп максат иде.

Конференция совет тюркологларының марксистик-ленинчыл методология нигезендә зур уңышларга ирешүен, күп санлы милли кадрларның республика фәннәр академияләрендә, университетларда, гыйльми-тикшеренү институтларында, язучылар союзларында, журналларда төрки халыкларның әдәбияты, фольклоры, тарих, археология һәм этнография буенча фундаменталь хезмәтләр иҗат итүләрен билгеләп үтте.

Татарстанның фән докторлары М. Мөхәррәмов, М. Зәкиев, Д. Тумашева, В. Хаков, Нил Юзеев, Г. Ахунҗанов, А. Халиков, Г. Саттаров, фән кандидатлары Азат

Әхмәдуллин, И. Надиров, А. Кәримова, Ф. Сафиуллина, С. Ибраһимов, Ф. Ганиев, Л. Арсланов, Р. Әхмәтҗанов, З. Вәлиуллина һ. б., Башкортстаннан фән докторлары Ә. Харисов, Р. Кузеев, Г. Хөсәенов, Г. Әхәтов, З. Ураксин, Н. Ишбулатов һәм берничә фән кандидатлары конференция утырышларында тирән эчтәлекле һәм кызыклы докладлар белән чыгыш ясадылар.

## АЛДА — ЗУР МАРШРУТ

Казанның Опера һәм балет театры сәхнәсендә яңа программа белән чыгышлардан соң республикабызның җыр һәм бию ансамбле Горький, Саратов, Волгоград, Әстерхан, Саранск, Уфа һәм Оренбург маршруты буйлап гастрольгә чыгып китте.

## «ТЕАТР ТОРМЫШЫ» ЖУРНАЛЫ БЕЗДӘ КУНАКТА

Казанның Актерлар йортында шушы журналга багышланган зур кичә Мәскәү һәм Ленинград театрлары артистлары катнашы белән үткәрелде. Аны журналның баш редакторы Ю. А. Зубков алып барды.

## ЕРАКТА, ДНЕПР ЯРЫНДА

Бөек Ватан сугышы партизаны, Белоруссиядәге Орша шәһәренең мактаулы гражданины шагыйрь Зәки Нури күптән түгел анда кунакта булды. Атаклы Константин Заслонов җитәкләгән партизаннар бригадасының көрәштәшләре белән очрашулар шагыйрь яза торган «Үлгәннәр дә үч алды» исемле икенче китапның яңа материалы булачак. Оршада ул Заслонов исемендәге депо һәм житен комбинаты эшчеләре, Заслонов исемен йөрткән ике мактап коллективы алдында чыгышлар ясады, Заслонов музеенда булды, тимер юлчыларның культура сараенда әдәби кичә үткәрде. «Ленин чакыруы» исемле газета аның «Заслоновта — кунакта» исемле мәкаләсен һәм яңа шигырьләре тәржемәләрен басып чыгарды.

## КЫРЫМДА ОЧРАШУЛАР

Кырымдагы Ялта һәм Коктебель иҗат йортларында безнең әдипләребез дә ел саен була. Алар күп милләтле совет әдәбиятын, шул җөмләдән, әлбәттә, татар әдәбиятын, пропагандалый торган чыгышларда да актив катнашалар. Күптән түгел, мәсәлән, Ялтада «Алтын көз» дигән бәйрәмнең әдәби өлешендә, анпары 21 нче номерлы һөнәр мәктәбендә китап сөючеләрнең «Замандаш» дигән әдәби клубын ачканда шагыйрь Зәки Нури катнашты. Радиф Гатауллин чыгышын эстрада театрында тыңладылар, «Шахтер» исемле санаторийда китап укучылар белән Гәрәй Рәхим, Ренат Суфиев, Рәис Даутов һәм Зәки Нури очрашты. Алар ике тапкыр Советлар Союзы Герое Амет-хан Солтан һәйкәленә чәчәк куйдылар.

## ОТЧЕТ БИРЕП, ПЛАННАР ТУРЫНДА СӨЙЛӘП

* * *

Лаеш районының Кече Елга, Пәрәү, Имән Кискә һәм Янтык авылларында журналыбыз укучылары белән очрашулар булды. Бу әдәби-музыкаль кичәләрдә редакциянең бүлек мөдире, шагыйрь Абдулла Сәләхетдинов колхозчыларга журналда быел басылачак яңа әсәрләр турында сөйләде, яңа шигырьләр, мәсәлләр укыды. Татарстанның халык артисты Эмиль Җәләлетдинов, республикабызның хор җәмгыяте председателе, җырчы Мингол Галиев һәм баянчы Зиннур Гыйбадуллин авыл хезмәтчәннәрен яңа җырлар, музыкаль әсәрләр белән таныштырдылар. Шушы кичәләрдә «Победа», «Кызыл йолдыз», «Маяк» һәм «Кызыл ялкын» колхозларының идарәләре һәм партоешмалары алдынгы механизаторларны, сыер савучыларны, агитаторларны «Казан утлары» журналына еллык подписка белән бүләкләделәр.

* * *

Лениногорск нефть төбәгендәге әдәби берләшмәдән танылган әдип Шамил Бикчурин, яшь язучы Әсрар Галиев һәм яшь шагыйрьләр Разим Вәлиуллин белән Җәдит Хәбибуллин Бәкер курортында ял итүчеләр белән очрашу уздырдылар. Әдәби әсәрләр уку җыр-музыка белән аралашып барды: Илдус Тарханов, Миңнеәхмәт Фәйрушин, үзешчән композитор Разим Вәлиуллин популяр җырлар һәм үзләре иҗат иткән көйләрне башкардылар.

## КАЗАН ДУЭТЫ МӘСКӘҮДӘ

Илебез башкаласының Гнесиных исемендәге музыкаль-педагогия институты залында Казан дәүләт консерваториясенең яшь педагоглары Гөлфирә Сафина (виолончель) һәм Әлфия Борнашева (фортепиано) парлап уйнап бик күп әсәрләрне гаять оста башкардылар. «Стильне нечкә тою сәләте булган искиткеч дуэт! Илһамлы музыка!»— Мәскәү музыка җәмәгатьчелеге алар чыгышын шулай бәяләде.

## КОМПОЗИТОРЛАРЫБЫЗ ОТЧЕТЫ

Союз идарәсенең чираттагы XV пленумында тыңланган концертлардан чыгып әйткәндә, менә ул отчет нидән гыйбарәт: Нәҗип Җиһанов, Фасил Әхмәтов һәм Илдус Якупов симфония, Б. Трубин «Бегелмә коменданты» операсына фрагментлар, А. Луппов Муса Җәлил әсәре буенча «Сандугач һәм Чишмә» балетын язганнар, М. Ногман, С. Хәким, Г. Латыйп, З. Нури, Р. Гатауллин, Ф. Яруллин һ. б. шигырьләренә язылган яңа җырлар башкарылды. Пленумда консерваториябез студентлары да чыгыш ясадылар.

### «ОРФЕЙ» — ЛАУРЕАТ

Бу — Татарстан дәүләт филармониясенең 1975 елда оешкан вокаль-инструменталь ансамбле. 1976 елның ноябрендә совет җырын башкаручыларның Сочида тәмамланган Бөтенроссия конкурсында ул, ярышкан 32 ансамбльнең берсе буларак, икенче бүләкне алды һәм лауреат исеменә лаек булды.

### «ЯШЬЛЕК»КӘ ДАН

Шундый исемле җыр һәм бию ансамбле Сарман районы культура йортында моннан дүрт ел элек оешты һәм эшли башлады. Бу үзешчән коллективта йөздән артык механизатор, терлекче, укытучы, медицина хезмәткәрләре, культура һәм комсомол эшчәннәре хорда җырлау осталыгына өйрәнде, классик бию әлифбасын үзләштерде. Үткән елны авыл үзешчәннәренең республика смотрында уңышлы чыгыш ясаганнан соң ансамбль (җитәкчесе Казан культура институтын тәмамлаган Илдус Садыйков) Бөтенсоюз смотрында лауреат исемен яулады һәм Болгариягә туристлык путевкасы белән бүләкләнде...

Менә алар чыгышын хуплап Болгар дуслар иле тамашачылары кул чаба: Бургас, Плевсен, Велико-Тырново, Русе, Приморск шәһәрләре белән бистәләренең эшчеләр клублары һәм паркларында алар «Яшьлек» ансамбленең егерме биш чыгышын карыйлар. Социалистик илләрнең үзешчән сәнгать буенча халыкара конкурсында бу ансамбль алты алтын, җиде көмеш, ике бакыр медаль, алтмыш бер мактау кәгазе һәм беренче дәрәҗә ике диплом яулады.

### ТАГЫН ТАШКЕНТТА

Ташкент каласының «Кызыл таң» исемле тегү фирмасы коллективында чыгыш ясап, филология фәннәре кандидаты, Муса Җәлил иҗатын һәм тормышын өйрәнүче галим Исхак Зәбиров эшчеләр һәм хезмәткәрләрне Муса һәм аның көрәштәшләренең сирәк рәсемнәре һәм алар батырлыгына бәйле документлар белән таныштырды. Шушы ук кичәдә Мусаның сугышка хәтле дуслары Ибраһим Бари улы һәм Биби Хәсән кызы Кадыйровлар (Пермь шәһәреннән) истәлек сөйләделәр. Фирманың яшь эшчеләре Муса Җәлил исемендәге бригада членлыгына лаек булырга теләк белдерде.

## ЗӘКИЯ ТУФАЙЛОВА

1977 елның 11 январенда балалар язучысы Зәкия Туфайлова (Шәйхетдинова Зәкия Туфайловна) вафат булды.

Зәкия Туфайлова 1907 елның 29 январенда Башкортстанның Кушнаренко районы, Илморза авылында туа.

1930 елны Свердловскида педагогия техникумын тәмамлаганнан соң Урал шәһәрләрендә, Ленинградта, Казанда эшче яшьләрнең кичке мәктәпләрендә, һөнәр училищеларында укыта. Соңыннан китапханәчеләр курсын тәмамлап, Ленин исемендәге республика китапханәсендә эшли.

Зәкия Туфайлованың беренче шигырьләре 1926 нчы елларда Уфада «Игенчеләр атнасы» газетасында күренә башлый. Әмма актив әдәби эшчәнлеге илленче елларда башланып, гомеренең соңгы көненә кадәр ул «Табышмаклар», «Зәңгәр кикрикле әтәч», «Менә мин ул», «Яңа сүз өйрәндем», «Фамилиясез Локман», «Нәни капитаннар» һ. б. китаплар чыгара.

Бөтен иҗатын балаларга багышлаган Зәкия Туфайлова балалар бакчаларында, мәктәпләрдә көтеп алынган язучы булды, аның китапларын һәркайда яратып укыдылар.

Ачык йөзле, олы җанлы шагыйрәне нәни дуслары да, аның каләмдәш иптәшләре дә һәр вакыт тирән ихтирам белән күңелләрендә сакларлар.

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ**
**ҺӘМ «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ.**

## Республикабызның әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре



Филология фәннәре докторы *МӨХӘММӘТ ГАЙНУЛЛИН.*

В. И. КУДЕЛЬКИН портреты.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Журналыбызның 3 нче саны Сибгат Хәкимнең чорыбызның бөек төзелешләре, аның кешеләре, яшәү мәгънәсе турындагы яңа шигырьләре белән ачыла.

Шушы ук санда Гариф Ахуновның «Идел кызы» романы дәвам итә. Гәрәй Рәхимнең «Соклanыйк без...» дигән шигырьләр бәйләме, Марсель Галиевнең «Кайтавазлар» исемле шигъри парчалары урнаштырыла

Март аенда күренекле язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 90 ел тула. Шул уңай белән журналда Мансур Хәсәновның «Әдипнең бөеклеге», Гали Халитның «Чынлык һәм гүзәллек гармониясе» дигән зур күләмле хезмәтләре, Р. Ганиева, А. Әхмәдуллин, Н. Юзиев, Р. Мөхәммәдиев, Г. Әхәтов, С. Поварисов, И. Абдуллиннарның әдип иҗатына караган мәкаләләре басыла.

Журналыбызның күренекле урынында шагыйрьләребез иҗаты. «Ай, кояш һәм чәчәкләр» исеме астында Клара Булатова, Салисә Гәрәева, Резеда Вәлиева, Шәрига Таһирова, Эльмира Шәрифуллина шигырьләрен укырсыз.

Очерклар бүлеге документалист-кинооператор Харис Фәхретдинов турында язылган «КамАЗ елъязмачысы» һәм «Ык Тамагында» дигән очерклар тәкъдим итә. Аларның авторлары — Хәмзә Зарипов һәм Эдуард Касыймов.

Сәлам Алишевның «Тарихтан бер сәхифә» дигән язмасы Казанның 800 еллыгы уңае белән бирелә.

Болардан тыш «Төрлесеннән», «Китап күзәтү», «Укучы сүзе», «Елмаеп та, көлеп тә...» дигән бүлекләрдә төрле характерда язылган күп кенә кызыклы материаллар урнаштырыла.

«Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары»ннан да сез төрле-төрле мәгълүматлар алырсыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210